



# КАЗАН УТЛАРЫ

3
МАРТ
1980

# ЧӘЧӘК БИРГӘНДӘ

САРА САДЫЙКОВА музыкасы

ЗӘКИ НУРИ шигыре




Ашыктым, тордым сүземдә:
Алып килдем чәчәк!
Куандыр мине үзең дә
Чәчәк кебек яшәп.

Сулма син, һаман балкып тор,
Хуш исеңне тарат.
Күңелләр күзен тартып тор,
Елмаюны ярат.

Китердем сиңа бүләккә,
Сиңа чәчәк бирәм.
Тамыры аның йөрәктә
Тирән, дустым, тирән.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

3

МАРТ
1980

## Бу санда

С. ХӘКИМ. Туй итә Казан. Шигырьләр . . . . 3
Г. АХУНОВ. Агыйдел егете . . . . . . . . . . 7
Х. САРЬЯН. Җәза. Повесть . . . . . . . . . . 9

8 МАРТ — ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ

К. БУЛАТОВА. Беренчеләр идек. Шигырьләр . . 52
Р. ИШМОРАТОВА. Сүз. Хикәя . . . . . . . . 53
С. ГӘРӘЕВА. Гаҗәп матур бер җәй җәйләдем. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Б. РӘХИМОВА. Күләргәме, еларгамы! Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
И. ГАНИЕВА. Шатлыгым. Шигырьләр . . . . . 77
И. САЛАХОВ. Мәхәббәт картаямы! Повесть . . 78

В. И. ЛЕНИННЫҢ ТУУЫНА — 110 ЕЛ

«ВАКЫТ ҺӘМ КЕШЕЛӘР» КОНКУРСЫНА

М. ГӘРӘЕВ. Ильичка хатлар . . . . . . . . . 114

ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

А. ҖӘЛӘЛЕВ. Таң атканда. Очерк . . . . . . 122
М. МОСТАФИН. Җир уллары. Очерк . . . . . 129

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Ф. ХУҖИӘХМӘТОВА. Шулай була икән. Хикәя . 134
Ф. НИЗАМОВА. Кояш нурын эчәр өчен. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Ф. САДРИЕВ. Ә елга һаман ага. Хикәя . . . . 141

БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 35 ЕЛЛЫГЫНА

Г. ГУРЬЕВ. Лачын йөрәкле егет. Очерк . . . . 145

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

С. МАННАПОВ. Тормыш үзәннәреннән . . . . 152

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**В. ХАКОВ.** «Мәхәббәтнамә» әсәре һәм татар әдәбиятында аның традицияләре . . . . . . . 161

ДУСЛАР ИҖАТЫ

**Г. КАҺҺАРИ.** Мәңгелек факел. Поэмадан өзек . 168

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**М. МӘҺДИЕВ.** Рус ориенталистларының эшчәнлеге һәм татар вакытлы матбугаты . . . . . 170

**Г. ДӘҮЛӘТШИН.** Болгар язма культурасы . . . 176

ТЕЛ БЕЛЕМЕ

**Г. ӘХӘТОВ.** Сүзнең хикмәтен табып . . . . . 180

КИТАП КҮЗӘТҮ

**М. ВӘЛИЕВ.** Авыл урамнары буйлап . . . . . 185

**Т. ӘЙДИ.** Тел дигән дәрья бар . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор—3-07-60, баш редактор урынбасары—3-07-60, җаваплы секретарь—3-07-09, проза бүлеге—3-07-61, поэзия бүлеге—3-07-61, тәнкыйть бүлеге—3-07-63, сәнгать бүлеге—3-07-63, очерклар бүлеге—3-07-63, хатлар бүлеге—3-07-61, корректорлар—3-07-65, техник редактор—3-07-65, машинисткалар—3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шамил Бикчурин, Аяз Гыйләҗев, Марсель Зарипов, Зөлфәт, Шәйхи Маннур, Фәрваз Миңнуллин, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Кояш Тимбикова** (җаваплы секретарь), **Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Т. Шакирҗанова*

Производствога бирелде 3/XII-79 ел. Басарга кул куелды 25/II-1980 ел. ПФ 09005. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 94000 экз. Заказ Ц-458. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1980 ел.

## Сибгат Хәким

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

## Туй итә Казан

Ленин һәйкәле алдына
Өзеп алып хисләрдән,
Салалар туй чәчәкләре
Яңа өйләнешкәннәр.
Читтән бер шаһит шикелле
Яшьләрнең кавышуына,
Кушылып безнең заманның,
Казанның шау-шуына,
Йөрим мин шунда, мәйданда,
Чәчәкләр учма-учма,
Саныйм, күпме кыз кияүдә,
Күпме яшь кыз тормышта...
Яшиләр, көрәшәләрдер
Биргән антлар өчен дә,
Ирек мәйданына яуган
Ап-ак саф кар өстендә
Яталар янып чәчәкләр...
Үзе баш кода Казан,
Ленталар белән бизәлеп,
Кая ашкына Казан?
Туй итә Казан, мәйданда
Йөрим гүя сан өчен,
Йөрим калган чәчәкләрнең
Җыеп соңгы сагышын.

1979

## Сугышның дәһшәте, көче...

Сугышның дәһшәте, көче
(Тарихка язсын Дуга)
Алдынгы сызыкка бәреп
Кергәннәр ярсуында.
Алдынгы сызык тупчыга
Түгел ләкин уч төбең,

Кайчак үз солдатларыңа
Бәрә ялгыш үз тубың.
Күпме көч салынган «Ура»
Сүрелеп, сүнеп шунда,
Яңгырый алмыйча кала
Меңнәрнең сулышында.
Дугада, кыр уртасында,
Окоптан торып басып,
Алып кыр буйлап сузылган
Телефон трубкасын,
Рота командиры сүгенә
Ата-анасы белән;
Үз кешеләреңә оста
Ата аласың, беләм.
Мин хәлен аңлыйм сүгенгән
Рота командирының,
Гафуы йөзенә язылган
Утта калган җиренең.
Телефон трубкасыннан
Әйтерсең үтте шул чор,
Кычкыра карлыккан тавыш:
«Алгарак утны күчер».
Фәкать кыр, юк бернинди бүтән
Штаб аның алдында:
«Алгарак күчер утыңны,
Күчер дошманнарыңа».

Күпме ел инде Дугадан,
Киткәнгә минем шуннан,
Ишетәм, яңгырый һаман
Авазы телефоннан.
Йөри гомремә ияреп,
Йөри шул кеше бергә.
«Онытма, шигырь утыңны
Алгарак күчерергә».

1979

## Карыйм документаль фильм

Карыйм документаль фильм
Егерме серияле,
Зур сугыш үзе турында
Һаман да сөйли әле.
Карыйм сынау күзе белән,
Сугыштан каным арган,
Карыйм һәм үземне таныйм
Шундагы кадрлардан.
Ул да таныган шикелле
Тукталып калды кинәт,
Янында фронтташлары
Тупларны барды сөйрәп.
Тузанлы таш юл өстендә
Ул август кояшында
Тора дөньясын онытып,
Сусап бер авыз суга,

Чыккан да кара тәреле
Танклар зиратыннан,
Тора, бар рәхәт минутлар
Уйларны җыя торган.
Йөзендә горур шәүләләр,
Ул басып калган җир нык.
Прохоровка кырларында
Урнашып калган тынлык
Йөзендә аның чагыла,
Йөзендә алтын ирке,
Аңына яңа килгән күк
Тора ул аңгы-миңге.
Гомренең шушы бердәнбер
Бәхетле секундына
Ышанып бетмәгән төсле
Эченнән сөенеп тора.
— Син өйдә, рәхәт, эшләгән
Чорың барысын сиңа,
Яз да яз, минем Дугадан
Чыгып барышым гына...

Шинеле төрелгән тыгыз,
Өстә кат-катлы дуга.
Мин — яшьлегемә, ул минем
Текәлгән картлыгыма.
Текәлгән, таныйм, бары тик
Кул биреп күрешәсе,
Экранга тамарга тора
Өзелеп күзнең яше.
Яшьлегем, чыннан да бу мин,
Мәҗбүр икърар кылырга,
Бөек көннәремне озатып,
Калдым экран төбендә.
Калдым мин картлыгым белән,
Эчкән дарулар белән,
Дәвалыйм хәзер үземне
Кичкән давыллар белән.

1979

## Әйтелмәгән васыять

*Әмирхан Еникигә*

Кылганнар йөгрә далада,
Тын башкорт даласында,
Йөгрә карт тарих — Акъбикә
Шул ташкын арасында.
Кылганнар йөгрә далада,
Кылганнар белән көреш,
Заманнар чәче агарган,
Заманнар чәче көмеш.
Кылганнар йөгрә далада,
Чуклары — чулпылары,
Ишетелеп куйган шикелле

Акъбикә сулкылдавы.
Кылганнар йөгрә далада,
Сөям шул хасиятләрен,
Сөйлиләр әйтелми калган
Мәңгелек васыятьләрен.

1979

## Яз җитте

Яз җитте, тагын да яз җитте,
Җир эреп, ага бозлар,
Китми нишлисең дигән күк
Иренеп ага бозлар.
Боз килә Казан суында,
Боз килә көймә сыман,
— Сез кайдан?
Гөжелди бозлар:
— Без Киме тирәсеннән.
Китәләр, бәхилләшәләр,
Бетми сөйләр сүзләре,
Еракта, ләкин колакта
Бозларның гөжелдәве.

1979

## Ак пионнар

Җил кебек исте гомерләр,
Су кебек акты еллар,
Сафлыктан, шатлыктан ташып,
Утыра ак пионнар.
«Син яшь чакта да үстек без,
Бүген дә шул рәвештә,
Без сине күрдек, син безне
Салындың күрмәмешкә».
Әйтегез, таң кебек якты
Мәхәббәт пионнары,
Кайсыгыз кемнең яры?
Кайсыгыз кемнең сөйгәне?
Кемнәрдер минем шикелле
Чумып татлы уйларга,
Сөйлидер хәзер хисләрен
Иелеп пионнарга.

1979

------------

# АГЫЙДЕЛ ЕГЕТЕ



Аңа быел, март аенда 50 яшь тулган булыр иде. Көтә иде ул бәйрәмен. Җиңне ныграк сызганып, йөрәксенебрәк тотынган иде иҗат эшенә. Әллә алдагырак елларны китаплар язасы вакыты тормыш мәшәкате белән узгангамы — соңгы ике елда ул бер-бер артлы ике повесть тәмамлаган һәм әле шушы якын арада язасы әсәрләренең сюжетын каләмдәш дуслары белән теләбрәк уртаклаша башлаган иде.

Ә бит язасы материалы күп иде аның, бик күп иде.

Аның эш кабинетында бик пөхтә итеп, бөтен стенаны тутырып, үз кулы белән ясаган китап киштәсе бар. Ул киштәдә бик тә сайлап, бөртекләп җыйган дөнья әдәбият хәзинәсе бар. Шунда ук Хемингуэйның мул сакал эченнән ифрат та ягымлы елмаеп торган портреты бар. Хемингуэй — аның кумиры иде.

Менә соңгы баруда, үлеменә бер ел тулганны билгеләп узарга килгәч, без аның кабинетында яңа бер әсәр — Сарьянның үзенең портреты өстәлгәнне күрдек. Марсель Әһкамов дигән яшь художник абыйсының портретына аның барлык хыялын, тормышын, яшәү рәвешен һәм рухи дөньясын салган. Столяр верстагы янында таза беләкле, хезмәт кешесенә хас зур куллы берәү күлмәктән утыра. Җиңнәрен сызганып куйган. Йөзе нык, карашы нык, күңеле тулы үй. Арткы планда чарлаклы, сары бүрәнәдән салган йорт, бүкәнгә чабып куйган үткен балта, тәрәзә рамы күзгә ташлана; верстак каршысында — яшел ябалдашлы агач, ябалдашта — ике бит кәгазь; портретның өске өлешеннән Хемингуэй карый — җанлы, тере Хемингуэй; һәм шуннан тагын да өстәрәк — Сарьян үзе, хатыны һәм нәни уллары.

Әйбәт тотып алган аның дөньясын яшь рәссам. Ул җир кешесе иде, ул табигатьне, хайваннарны, урман-суларны үлеп ярата иде — табигать белән бәйләнешын ул күңеленә җыеп асрый һәм гаять матур итеп үз кулы белән салган йортларына күчерә иде.

Әйе, балта остасы иде ул — шул хакта «Әткәм һөнәре» дигән повесть язды, повестьны укучылар да, язучылар җәмәгатьчелеге дә бик хуплап каршылады. Әсәр сулышының киңлеге, кешеләренең матур күңелле, эшчән булулары белән безне сокландырды.

Туган телебезнең уяу сакчысы иде ул — шуны «Бер ананың биш улы» исемле сәнгатьчә югары язылган повестенда да, хикәяләрендә дә, тел хакында язган махсус мәкаләләрендә дә исбат итә алды.

Күршебез Башкортстан республикасының Илеш районында, 1930 елның 24 мартында, Иске Аю авылында туган Сарьян Салихҗан улы Хәсәнов (Хәсән Сарьян) язучылык эшенә тотынганчы шактый зур һәм катлаулы тормыш юлы үзә. Үсмер егет чагыннан ук туган авылында колхозчы, клуб мөдире булып эшли. Аннары Бөре педучилищесын, Башкорт педагогия институтын тәмамлый, шунда ук тел һәм әдәбият укыта, күп еллар журналист булып эшли. «Кызыл таң», «Совет Башкортстаны» газеталарында, «Һәнәк», «Азат хатын» журналларында әдәбият бүлекләрен алып бара.

Алтмышынчы еллар башында ул Уфадан Казанга күчеп килде.

Агыйдел буйларында туып үскән, башкорт далаларының моңын үзенә сеңдергән, азамат ирләренең тарихын өйрәнгән, телгә карата үтә дә сизгер егет Казанда ныклап иҗат эшенә керешә. 1962 елдан башлап ул бер-бер артлы хикәя җыентыклары бастырды, СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры, Татарстан Язучылар союзы каршындагы проза секциясенең җитәкчесе, «Идел» яшьләр альманахының редакторы булып эшләде.

Аның беренче иҗат чорына балалар өчен язылган кыска хикәяләр хас иде. Иҗат сәләтен ул нәкъ менә хикәя жанрында тапты. Без инде аны гомер буе хикәя жанрына тугры булып яшәр дип уйлый идек. Бик тә бөртекләп, тәмен белеп, сүзләренең кирәклесен генә сайлап яза иде ул аларны. Әмма аңар, язучы буларак, «Өткәм һөнәре», «Бер ананың биш улы» дигән повестьлары белән дан алырга язган икән. Бу әсәрләр татар совет әдәбиятына лаеклы өлеш булып керделәр.

Шул ук вакытта ул тел галиме иде, төрки телләрдә сөйләшкән илебез халыкларының китапларын аларның үз телләрендә укый иде, тел өлкәсендә ул күп кенә гыйльми хезмәтләр язды. Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүдә катнашты, тел һәм стиль мәсьәләләренә багышланган китаплар бастырды, радиодан әдәби телебезгә кагылышлы күп санлы әңгәмәләр алып барды.

Хәсән Сарьянның повесть һәм хикәяләрендәге лиризм, җылылык укучыларны дулкынландыра, аның әсәрләрендәге теленең төгәллеге, гадилеге һәм халыкчанлыгы барыбызны да сокландыра. Тел мәсьәләсендә аңа Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Әмирхан Еники кебек өлкән язучыларыбыз, аксакалларыбыз да мөрәҗәгать итә, әсәрләренең теле хакында әледән-әле киңәшә иде.

Әдипнең әсәрләре рус, мари, удмурт, башкорт телләренә тәрҗемә ителде. Ул үзе безнең заманның күренекле язучысы Чыңгыз Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» повестен кыргызчадан татарчага тәрҗемә итте.

Татар әдәбиятында ямьле Агыйдел буйларыннан, Урал тавы итәкләреннән килгән язучылар байтак. Галимҗан Ибраһимов, Нәкый Исәнбәт, Мирсәй Әмир, Фатих Кәрим, Гази Кашшаф, Әмирхан Еники, Әхсән Баян, Илдар һәм Нил Юзиевләр, тагын башка дистәләгән язучылар — Башкортстан туфрагында туып үскән, Татарстанга килеп, Идел буйларында канат кагып оча башлаган әдипләр. Алар беркайчан да туган-үскән Башкортстаннарына да, гомер кичергән, канат чыныктырган Татарстаннарына да кызыллык китермәделәр. Тормышларында һәм иҗатларында ике республикага да лаек булдылар. Безнең арабыздан бик иртә, 48 яшендә үк киткән язучы Хәсән Сарьян үзеннән элгәреге әдипләр янына саф күңел белән килде, татар совет әдәбиятына намус белән хезмәт итте. Һәм бу Агыйдел егетенең әдәбиятта калдырган мирасы алга таба тагын да җентекләбрәк тикшерелер, үз бәясен алыр дип ышанабыз.

Хәсән Сарьянның 50 яше тулган көннәрдә «Казан утлары» журналына аның әле беркайда да басылмаган, үлеренннән берничә ай элек кенә язып калдырган «Җәза» исемле яңа повестен тәкъдим итәм.

Повесть каләмдәш дустыбызга хас үткен, төгәл, образлы тел белән язылган, совет кешеләренең яшәү мәгънәсен, көрәшен, коммунистик идеалларга турылыгын, аның бернинди эчке һәм тышкы дошманнар да какшата алмаслыгын ныклы иман, күңел көрлеге белән бәян иткән.

Бу повесть Хәсән Сарьянның якты истәлеген тагын бер мәртәбә матур әдәбият яратучыларыбызның күңелендә яңартыр дип ышанам.

**ГАРИФ АХУНОВ,**

Хәсән Сарьян

# ҖӘЗА

ПОВЕСТЬ

## 1



Мең тугыз йөз кырыгынчы елның июнь уртасы иде.

Болын житеп килгән чак. Инде Кама ягыннан искән дымсу җил белән борыннарга сутлы үлән, пеше тал исләре кагылып китә; Сөләй кашлагында мәмрәп пешкән, чалгы артыннан теземнәрдә тәгәрәп калган җиләкләрен уйласаң, авызлардан сулар килә иде.

Инде Мәгъдән алачыгы алдында ике бригаданың да чапкычы белән җыйгычын эшләтеп карадылар. Мисбах бабай бер ат йөге ап-ак тырма ясап куйды. Өй саен диярлек чың да чың чалгы тапыйлар, чалгы көйлиләр. Ундүрт-унбиш яшьлек малайлар да болынга чыгарга җыена — көн туды исә, йөгән кашларына җиз тәңкәләр сугып, ярыша-ярыша, нәзек каештан сигезле камчы үрәләр иде. Алар бәхетле: алар чүмәлә тарттырачак...

Быел гына уналтысы тулган Мәйсәрә апам да печән җыярга чыгачак. Инде тәтәй коштай вак-вак борчак төшкән ак күлмәге белән алъяпкычын, ап-ак оек-чабаталарын әзерләп куйды. Әти миңа да район кибетеннән җебе-ние белән чын кармаклар алып кайткан. Мин дә быел апам белән болынга чыгып, Би күлендә күзгә күренеп йөзгән кара сыртлы балыкларны җиң сызганып тотарга җыена идем. Болында әле безгә эш юк.

Шулай дәртләнеп-янып йөргән көннәрнең берсендә Акчурин агай идарә җыйды да:

— Мәчет манарасы бер бездә генә калган, иптәшләр. Печәнгә төшкәнче кисеп, эшен бетереп куярга кирәк, соңыннан кул житмәс — тагы калыр, — диде.

Бик озак бәхәс, үгеттән соң манараны тегермәнче Фидаил абый кисеп, безнең әти трактор белән тартып төшерергә сөйләштеләр. Партизан Нәмәт карт:

— Тик җомга үтсен, җәмәгать. Базар көнгә калдырыйк без аны: халык та базарда булачак, — диде.

Якшәмбе көн таң күзеннән әни белән ике апа—базарга ,әти МТСы-

на китте. Мин алардан уянып калсам да, әле бик иртә иде, тышка гына чыктым да, яңадан кереп яттым.

Мин кеше сөйләшкән тавышларга уянып киттем. Инде каршы як таудан өй эченә кайнар кояш төшкән — бүген дә кыздырачак иде. Торып, идарә ягын ачып карадым. МТСлы авылдан Хәмитшин белән милиционер килгән икән: безнең Акчурин агай белән күрешеп, хәл-әхвәл сорашып торалар. Идарәдә тагы бездән биш-алты кеше бар. Хәмитшин абыйларны көтеп торганнар күрәсең: алар килгәч, манараны ничек-ничек кисәргә дип, каты гына киңәшеп алдылар да тиз-тиз чыгып та киттеләр. Мәчет бездән ерак түгел иде.

Мин түбән очка — дустым Гафиятләргә йөгердем.

Гафият тә торган. Җылы ипи белән мичкә тәгәрәткән кайнар бәрәңге ашап утыра иде. Өйләре тын алырлык түгел — эссе. Шул эссе белән кушылып, мичтән әле генә чыккан арыш ипиенең әчкелтем хуш исе тамакларга килеп капланды.

— Әйдә тизрәк! Мәчет манарасын кисәләр!.. — дидем мин.

Хәмидәттәй баздан катык алып чыгып килә иде — кулыннан чүлмәге төшеп китеп, икегә ярылды.

— Ходаем! Кем әйтте аны?..

— Акчурин агай. Болынга чыкканчы кисәргә диделәр. Инде сельсовет председателе белән милиция дә килде. Милициясе — мин белгән түгел. Ярхәм абый белән Кара Самихны арканга җибәрделәр. Әти дә иртүк тракторын алырга китте... — Колхоз идарәсе безнең өйдә булганлыктан, мин бар хәбәрне кешедән алда белеп тора идем. — Әйдә инде! Иң кызыгын күрми калабыз бит! — дип Гафиятне ашыктырдым.

Ул, идәнгә түгелгән катыкка караган килеш, авызындагы бәрәңгесен пешә-пешә йотып җибәрде дә:

— Мин — кайткач, әни, — дип, шатыр-дөбер торып басты. Сәкедә генә кепкасы ята иде, аны эләктерде. — Әйдә!..

— Иллә, малай, ишетсен колагың: бер әйберенә дә кагыласы булма — кулың корып кына төшәр! — диде аңа Хәмидәттәй.

Без чыгып чаптык.

Түбән очка миннән башка да хәбәр җиткән:

— Манара кисәләр!.. Манара!.. — дип малайлар йөгерешә, алар артыннан тәрәзәдер, ишектер ачылып, аптырау йөзләр карап кала иде.

Әле кисә башламаганнар. Озын таза буйлы милиционер абый беркемне якын җибәрми. Белеп булса кирәк, базарга бармый калган кешеләр Мисбах бабайлар ишегалдына җыелган да шуннан тамаша итәләр; койма, читән башларына малай-шалай менеп атланган иде. Без дә шунда кердек.

Мәчет күләгәсендә Акчурин агайлар сөйләшеп тора. Ә читтәрәк, кояшта, Ярхәм абый белән Кара Самих, тагын ике бригадир чүмәлә тарттыра торган сүс арканнарны бер-берсенә бәйләп кайнашалар иде. Ул арада ямь-яшел чирәмле мәчет тавыннан туп-туры — тракторы белән әти кайтып төште. Җендәй трактор тавышына манарадан күгәрченнәр очып чыгып, күккә сибелделәр.

Әти җиңел генә җиргә сикереп, Акчурин агайлар янына килде. Шуннан алар, бер манарага, бер тирә-якка карый-карый, киңәш корып калдылар. Аннары Фидаил абый белән Ярхәм абый икәү биек баскычтан мәчеткә кереп киттеләр.

Мисбах бабай калтыранган тавышы белән.

— Тегеләре, ярый, камунис та камсамул — диннәре-иманнары беткән — бу Фидаиленә ни калгандыр? — диде. — Бәлхис кортканы тереләй гүргә кертә ләбаса бу!... Үстер менә үксез баланы «Минем балам — анасы, балдыйн татлы баласы» дип!..

— Ходаем кәрим, ярлыка!—дип, таякка таянган Сәйдә әби дә көрсенеп куйды. — Әүвәл мәчет юлын ташлаттылар, инде хәзер манарасын

да кисәләр. Ил өстендә дога кунар җир дә калмый икән, болай булгач... Җан бирәселәребез барлыгын уйламый микәнни соң болар бер дә?..

— И Сәйдәттәй, Сәйдәттәй! — диде аңа Мисбах бабай. — Син әле Нуриманның ни сөйләгәннәрен белмисең... Җан дигән нәрсә юк ул, ди. Кешене йөрәге белән кан гына йөртә, ди. Үлгәч мине тураклап иткә ташласалар да, миңа барыбер: мин аны тоймыйм, ди. Менә сөйләш син алар белән!..

— Әстәгъфирулла тәүбә, алласыз җан икән!..

Минем шунда Мисбах карт белән шул бөкре карчыкка җен ачуларым чыгып: «Әти дөрес әйтә — җан юк ул! Китапта да шулай язылган», — дип кычкырып җибәрәсем килде.

— Әнә, менделәр! — диде Гафият.

Мин башымны күтәреп өскә карадым. Фидаил абыйлар, манараның икесе ике тәрәзәсеннән башларын тыгып, өскә карап торалар иде. Аннары Ярхәм абый юк булды, ә Фидаил абый тәрәзәгә аркасы белән басты.

— Ярхәм манара очына менеп китте! — дип хәбәр салды кайсыдыр.

Анысын шәйли алмый калдым. Мәгәр беләм: сабан туйларында багана башына менәргә дигәндә Ярхәм абыйдан да остасы юк иде.

Чыннан да, күп тә үтмәде, манара очыннан тук та тук иткән тавыш килә башлады. Кайсы төштән икәнлеген күз чамалап өлгергәнче, «мин монда!» дигәндәй, бик югарыдан бер такта кубып чыкты. Аның артыннан — икенчесе. Бөтен кеше, авызын ачып, өскә караган иде. Яңа ясалган тишектән еландай шуышып нәзек бау төшә башлады.

Фидаил абый манара тәрәзәсеннән астагыларга кычкырды:

— Арканны меңгерегез!..

Мәчет кырыена янгын сараеның озын баскычы сөяп куелган иде. Кара Самих, аркан очын тотып, түбәгә менеп китте. Такта читенә ябышаябыша менеп җитте дә, манара төбенә атланып утырып, өстән төшкән каеш бауга аркан очын бәйләп куйды. Ярхәм абый аны өстән әкрен генә тартып ала башлады. Бераздан аркан очы тишеккә кереп югалды.

Байтак вакыт маташканнан соң, әчтән Ярхәм абый тавышы килде. Кара Самих бар көче белән арканны тартып, бер-ике кабат тикшереп карады. Шуннан соң гына, «менә, нык бәйләнгәнен күрегез» дигәндәй, шуңа тотына-тотына, түбә буйлап төшеп китте. Бауның җирдәге очын тракторга бәйләп куйдылар. Әти аны Шәйхел бабайларның бәрәңге бакчасы ягына алып китте дә, аркан кылдай турайгач, сүндерми генә тракторын туктатты.

Мисбах бабайлар ишегалдына кеше тулган иде инде. Өлкән җиңгиләр әкрен генә сөйләшеп алдылар:

— Тәки кыйбла якка авар микән, ходайның рәхмәте?

— Шул якка тарттырып бәйләп куйгач, кая аусын бүтән?.. Шәкүрт корткасы өенә аудармаслар бит инде аны.

— Туйнш мәчетенең манарасы төшкәч, җир икегә ярылып, ае җиргә иңеп киткән икән, — дип, Сәйдә әби тагын сүз кушты.

— Киткән менә сиңа! Әнә алачыкларында ята. Бу заманда юк сүз сөйләп, иске мунча себеркесе чәйнәп тормагыз. Манара җиргә авып төшкәч тә, мин дә аен үзем алып китәм. Коммунистлар да мәңгегә килмәгән — үлгәч каберләренә йолдыз ясарга кирәк булыр бит...

Моны әйткән — усал йөзле тимерче Мәгъдән абзый иде.

— Кәҗәгә җан кайгысы, суючыга мал кайгысы! — диде аңа бер апа.

Ә түбә астында Фидаил абыйлар манара кисәләр. Бер ара мәчетне төбе-тамыры белән селкеткәндәй, балта чаба башлый да, янә туктап кала. Әкрен генә мотор эшләп торуга карамастан, сәер бер тынлыкта түбә эченнән үткен пычкы кискән бер көй ишетелгәндәй иде.

Әбиләр елаша башлады.

— Жыламагыз, корткалар! Алладан ярдәм, изгеләрдән мәдәт сорагыз. Ил картлары! Кыям басып сәждәгә әзерләнегез...

Мин артыма әйләнеп карадым. Тынлыкта бик каты ишетелгән бу хәлсез тавыш Размулла бабайныкы иде. Аның бөтен йөзе «ярамый, ярамый» дигәндәге сыман бертуктаусыз селкенә иде.

Менә бер вакыт бөтен дөнья тынып калды. Фидаил абый белән Ярхәм абый, мәчеттән чыгып, нигез буйлап кына тау битенә йөгерделәр. Алар менеп житкәч, Акчурин агай:

— Әйдә! Тарт-тыр!.. — дип, әтигә кул изәде.

Шуны гына көтеп торган әти, тракторын яман үкертеп, әкрен генә кузгалып китте. Мәчет манарасы йолкынып, башы әйләнеп киткәндәй, аз гына чайкалып торды да, гөрселдәп җиргә ауды. Бабайлар сәждәгә егылды.

Җирдә җансыз яткан манараны шундук сүтә дә башладылар. Ае белән гөмбәзен, чыннан да, җизенә була, Мәгъдән абзый алып китәргә иткән иде дә — картлар, бик каты тавыш күтәреп, якын да җибәрмәделәр. Һәм алар, барысы бергә тотынып, мәет кебек итеп, Размулла бабайлар ишегалдына алып кереп киттеләр.

Шулай кистеләр мәчет манарасын...

## 2

Әни көзен әтине үтерделәр.

Кырыгынчы ел, алтынчы ноябрь, чәршәмбе көн иде. Әти төштән соң, яхшыга дигән киемнәрен киеп, МТСка үзләренең бәйрәм тантанасына китте.

— Фидаилләргә кереп, өйдә булса, чәчне алдырып чыгармын, — дип, иртәрәк тә китте.

Без дә ул көнне кич, докладтан соң, үзебезнең клубта концерт куйдык. Концерт беткәч, Ярхәм абыйлар, бала-чаганы куып чыгарып, яшьләр кичәсе башлап җибәрделәр. Апалар кичәдә калды, мин кайтып киттем. Өйдә әни үзе генә иде.

— Әти кайтмадымыни әле? — дидем мин.

— Җәприм дәдәңнәргә кергәндер. Тиз генә кайтмас та инде ул анда керсә, — диде әни. — Көтеп утырма, ят, улым.

«Иртәгә бәйрәм!» шатлыгы белән мин йокларга яттым. Иртәгә демонстрация булачак! Без һәр елдагыча кызыл әләмнәр күтәреп, «Яшәсен, яшәсен шанлы Октябрь бәйрәме!» дип, җырлый-җырлый, урам әйләнәчәкбез. Минем өчен шуннан да күңеллесе юк. Әти дә демонстрациягә безнең белән чыгачак.

Ләкин иртән бик тә сәер дөньяга уянып киттем. Әни кичтән, иртүк торып пешерергә дип, камырлар куйган иде. Күземне ачсам — шыксыз салкын мич авызын ыржайтып утыра — өй эче җансыз, хәрәкәтсез, хәтта шомлы иде. Әтиләр урыны буш, җыештырылмаган. Мәйсәрә апа да юк, стена буенда төпчек апа гына йоклап ята. Кая киткәннәр болар дип, аптырап сәгатькә карадым. Әти чылбырын тартырга оныткан күрәсең: сәгатьнең дә гере төшеп туктаган иде. Әллә йоклап калганмынмы мин?..

Сикереп торып, аягыма ката гына эләктердем дә ишегалларын әйләнеп кердем. Ләкин бер җирдә, бер кем юк. Кызык! Әллә әни дә демонстрациягә киткәнме?..

Кереп төпчек апаны уяттым:

— Апа, тор әле!.. Тор!..

Ул көчкә күзен ачып, берни төшенмичә, миңа карады.

— Әниләр кайда, белмисеңме? — дидем мин.

Төпчек апа, инде уянып житеп, күзен як-якка йөртеп чыкты.

— Белмим шул, — диде ул үзе дә аптырап. — Ишегалдында, чоланда түгелме?..

— Юк. Бар җирне карап кердем. Су чиләкләре дә кузгалмаган.

— Алайса Җәприм дәдәйләргә китмәделәр микән?

— Әти кичә кайтмадымыни?

— Без кайтканда — юк иде.

Мин тиз-тиз киендем дә мәктәпкә йөгердем. Демонстрациягә чыгасы халык шунда җыела иде. Ләкин, барсам, мәктәптә бер кем юк. Мәгәр ишеге шар ачык тора, флаг-ниләр дә кузгалган. Димәк — монда бүген кеше булган... Тик кая киткәннәр соң алар ишек ябарга да онытып?.. Кире урамга чыгып, Октябрь капкасы ягына карадым — ник бер җан иясе булсын! Үтә дә сәер хәл иде бу. Әллә юкса мин бар кешедән дә алда торып килгәнменме?.. Алай дисәм, инде яктырып беткән, күктә сыек кына ак болытлар агыла; җир туңдырып җибәреп, бит кенә сизә торган, җиңел рәхәт салкын иртә иде.

Димәк, бүген мин үзем соңга калганмын...

Тик кешеләр кая киткән соң?..

Шулай карап торганда, югары очтан Мәйсәрә апамның кайтып килүен күрдем. Йөгерүеннән үк нидер сизенгән йөрәгем дөп-дөп тибә башлады: нидер булган...

Көчкә көтеп алдым.

— Нишләп торасың монда, Даниал үскәнем?.. — диде апа.

Тавышыннан йөрәгем өзелеп төшеп китте.

— Апа, әтиләр кайда?.. — дидем мин.

Мәйсәрә апа сыгылып төшеп елап җибәрде. Аның болай да бөтен бите күз яшенә чыланып беткән, күп елаудан иреннәре йомшарган иде.

— И үскәнем!.. И туганым!.. Әткәйне үтергәннәр бит!..

Сыным катты да китте. Апа мине кочаклап алды: ул мине бик тә ярата иде.

— Әйдә, үскәнем, монда тормыйк, кайтыйк...

— Юк, мин кайтмыйм, — дидем мин. — Минем әтине күрәсем килә...

— Анда барырга ярамый, үскәнем... Анда барма: йөрәгең күтәрмәс...

— Юк, мин барам!.. Минем әтине күрәсем килә.

Апа кулыннан ычкындым да, үз-үземне белештермәстән, югары очка йөгердем.

Каршыга кешеләр очрый башлады. Ләкин — берсендә бер кайгым юк: күз берни күрми иде. Шулай йөгерә торгач, урам киселеп кенә бетеп, юл ярдан түбәнгә, үзәнлеккә төшеп китте. Мин бер генә минутка туктап калдым. Каршыда гына керәшен авылы җәйрәп ята. Ике ара бер чакрым да юк. Ике авылга бер елга — Сүсән елгасы. Кыш буе күпме тирес, күпме чүп-чар түгүләренә карамастан, быел язын өске юл белән бергә, Мәгъдән абзыйларның ярты бакчасын җимереп алып китте. Киләсе язга инде өйләре дер калтырап тора иде. Болай барса, ике-өч елдан югары очны очы белән йотачак дип, май аенда Сүсәнне авыл башыннан ике-өч йөз метр читкә борып җибәргәннәр иде.

Менә шул елганың яңа яры буена, Көҗмә дәдәй тегермәненнән астарак, бик күп кеше җыелган иде.

Мин, барып житү белән, халыкны ерып эчкә кердем. Төбе ләмле сай гына канаудан аккан елга эчендә башы белән агымга каршы, йөзтүбән капланып, әтинең үле гәүдәсе ята иде. Бу турыда елга минем тездән генә булып, әти гәүдәсен күмәр-күммәс кенә тора. Шәп агым әти өстендәге кайры тунны кабартып куйган. Су шыбырдап кына яка эченнән агып кереп китә дә чабуыннан килеп чыга. Әтинең бүреге юк, чип-чиста итеп кырылган ап-ак башы салкын су эчендә ята... Моны күргәч, мин тагы елап җибәрдем — өши торгандыр бит башы!..

Яр читенә якын җибәрмәделәр. Артымнан әни килеп, үз янына тартып алды.

Инде авыл Советына ат чаптырганнар. Мин килгәч, күп тә үтмәде, идарә юргасын менгән Кара Самих җилдәй очып кайтып та җитте. Гел карлыккан тавышы белән Акчурин агайга хәбәр бирде:

— Хәзер киләләр! Хәмитшин абый район белән сөйләшергә генә калды. Ике авылга да җиткерегез: бер кем бер кая чыгып китмәсен, диде. Районнан тиешле кешеләр килеп җитми торып, мәеткә бармак та тигермәскә кушты.

Акчурин агай борчулы тавыш белән:

— Анысын шулай эшлибез дә инде,— диде. Аннары Кара Самихка боерды:— Бар алайса, хәзер үк Бикләнгә чап, Гөргери агайның үзен күреп, сельсовет әмерен аңа да җиткез.

Юрга әле тыелырга да өлгермәгән иде. Кара Самих тезгенен бушатып, ялына иелү белән, йомылып кына күрше авылга чапты.

Акчурин агай янында торганнарга:

— Кем уйлаган, ә!.. Кем уйлаган!.. Нинди кеше иде бит!..— дип баш чайкап, сөйләнеп куйды.

Җыелган кешеләр:

— Демонстрация булмас болай булгач...— дип шыбырдашып алдылар. Инде кайтырга борылучылар да бар иде. Безне укыткан Юматов абый халыкка:

— Иптәшләр! Таралмый торыгыз! Хәмитшин ага килеп җитсен инде, демонстрация мәсьәләсен бергәләп хәл итәрбез,— диде.

Шунда кемдер:

— Киләләр!..— дип сөрән салды.

Барча күз Биклән ягына карады. Көҗмә дәдәйнең тегермән өе почмагыннан эре адымнар белән юыртып, кара тарантас җигелгән кара айгыр килеп чыкты. Бу тарантас белән бу айгырны танымаган кеше юк, ул — Хәмитшин абыйныкы иде. Аның сул ягына биек булып тагы бер кеше утырган, анысын да халыкерактан ук таный: анысы — фуражкасы югары очта күренү белән түбән очта бала-чага куркып качкан милиционер иде.

Алар килеп җиткәнне дә көтмичә, бала-чага тиз-тиз авыл ягына тая башлады; өлкәннәр дә, алдан ук юл биреп, читкә чигенделәр. Яр буенда, әүвәлгечә, Акчурин агайлар гына торып калды.

Хәмитшин абыйлар килеп җитү белән, күрешкәч-ниткәч, бераз эти гәүдәсенә карап торгач, киңәшләшеп алдылар да, Хәмитшин абый алга чыгып, уң кулын күтәрде:

— Колхозчылар и укучылар! Сез бүген Бөек Октябрьның егерме өч еллыгы намена демонстрациягә дип җыелгансыз. Ләкин нәкъ шушы бәйрәм көнне авылның гына түгел, ә районның алдынгы кешесе, коммунист Нуриаздинов Нуриман иптәшнең гомерен кистеләр. Кистеләр димен, чөнки ул, үзегез күреп торасыз, тиктомалдан менә шушы көзге салкын суга кереп, капланып ятып үлмәгән. Аны үтереп суга ташлаганнар. Димәк ки, безнең арада дошман элементлары бетеп җитмәгән икән әле. Ләкин алар ялгышмасын без сыгылып төшәр дип... Ә хәзер, иптәшләр, әйдәгез, сәяси яктан бердәмлекне күрсәтеп, шушылай туплanган килеш, Октябрь капкасына китик. Мин дә сезнең демонстрациягә кушылам.— Ул әз генә тын алып, Акчурин агайга әйтте: — Син монда каравыл калдыр инде.

Акчурин агай тиз генә:

— Нәмәт абзый! Син бер-ике егет белән үлек янында каласың,— диде.

Алар сөйләп бетергәч, милиционер абый үзенең тилгән күзе белән халык өстенә карады.

— Бер генә минутка дикъкать, иптәшләр!— диде ул һәм гәүдәседәй калын, усал тавыш белән күңелләргә кадап әйтте:— Демонстрациядән соң беркем авылдан чыгып китми. Райүзәктән тикшерүче килеп җиту

белән сорау алу башланачак. Һәр кайсыгызның һәр минутта кирәк булуы мөмкин. Үтерүчене без табарга тиеш!.. Минем — бетте. Миңа монда калырга рөхсәт итегез.

Аның сүзләре төндәй кара бушлык биләп алган күңелемне айкап җибәрде. Шунда Юматов абый да көзге җилдәй ачы тавышы белән:

— Дүртәрләп тезелергә! Тезелү тәртибен беләсез!— дип команда бирде.

Кешеләр кайгыдан авыр адымнар белән сүзсез генә сафка баса башладылар.

Безнең өй эче бу олы кайгыдан сафка басып барыр хәлдә түгел иде. Әни, күрәм, егылмас чиктә генә тора, аны инде елап туктаган, ләкин әле күпме елыйсы ике апа ике ягыннан тотып, бер читтән генә кайтып киттеләр.

— Даниал кайда? Даниал!.. — диде әни.

Мәйсәрә апам да безнең якка каерылып:

— Даниал!..— дип дәште.

Ләкин мин, Юматов абый командасына буйсынып, барысы белән бергә кузгалып киткән идем инде. Минем, ир малай буларак, кеше алдында җебеп төшәсем килми: мин — тиз йөгерүче, тиз йөзүче, сугыш уеннарында гел разведчик булып уйнаучы, Юматов абыйдан «Уноч» дигән киноны ишеткән, «Чапаевны» үзем караган кеше!— җебеп төшәргә тиешме? Әнә Хәмитшин абый да: «Сыгылып төшәр дип уйламасыннар», диде бит. Һәм мин, шул сүзләр белән дәртләнеп, әтине үтергән кешене бүген үк тотарларына нык ышанып, саф белән бергә киттем.

## 3

Без, бүтән елдагыча, түбән очка ук барып җитмәдек, алар да ишетерлек итеп бер «ура» кычкырдык та кирегә борылдык. Мәктәп каршындагы Октябрь капкасы янында демонстрация таралды. Иртәдән бирле ачык җилдә торып, тәннәргә суык төшкән иде, өйгә кайтып кергәч, тешем тешкә тимичә, калтыранып өши башладым. Өе дә суык: мичкә яңа гына ягып җибәргәннәр. Шулай да өй өй инде, дөрләп янган мич каршына җилкәм куеп утыра торгач, эчемә җылы кереп, иренем иренне тоя башлау белән, мин тагын әти янына китәргә кузгалдым.

Әни дә сәке йөзлегеннән купты.

— Кая! Ни гамь белән утырам әле мин өйдә? Барыймчы әле мин дә яннарына!..

Күршебез дә, кардәшебез дә Гөл җиңги, табалар әзерләп, тәбикмәк пешерергә йөри иде, юата-юата, әнине кире сәкегә утыртты.

— Сабыр бул, алма җиңгәм, сабырлар бул!..— Син барып кына нииләр кыласың? Йөрәгеңә тагын яра өстәргәме? Болай да инде күз алларыннан китәрлек түгел...

Әни йөрәк тавышы белән әйтте:

— Боздай сулар эчендә ята бит ул туңып!..

Минем ирен тагы тартыша башлады, мин тизрәк урамга йөгереп чыгып, бирешмәскә уйладым, ләкин булмады — өйалдына чыгу белән үкереп елап җибәрдем.

Елау мине буынсыз итте. Һәм мин егылмас өчен ишек артында торган чорма баскычына барып тотындым да битемне өй бүрәнәсенә терәдем — күз яшем салкын агач өстен эретеп агып китте.

Мәйсәрә апам өйдән чыгып:

— Әйдә, үскәнем, өйгә кер... Ашамагансың да бит әле син бүген...— дип, башымны күкрәгенә кысканда, мин инде еламый идем, тын гына үксүдән гәүдәм генә тартыша иде.

Шунда салкын битемә жып-жылы тамчы төште,— инде апама да минем сыман җебеп еларга ирек бирмәс өчен, кочагыннан кинәт тартылып чыктым да:

— Юк, мин өйгә кермим, мин әти янына барам!— дип тышка атылдым.

Исемә килгәндә, мин урам буйлап югары очка таба йөгерә идем.

Үзәнлеккә кешеләр тагын җыела башлаган, күрше Бикләннекеләр дә байтак. Баягыча, яр буена берәүне дә якын җибәрмиләр. Нәмәт карт күренми, аның урынына калган Әхмәдиша бабай:

— Якын килмәгез, җәмәгать! Якын килмәгез!.. Бәлки әзе торып калгандыр, тапталмасын!..— дип, кешеләрне читкә чигендереп тора иде.

— Инде әзенең әзе дә калмагандыр: баягынак күпме кеше таптады,— диде кемдер.

— Алай димә. Иртән түң иде. Әле генә җебетә төште. Салкын булса да, кояш үзенекен итә ул...

Шунда гына мин көннең аяз, кояшлы икәнен күрдем.

Әти һаман шул урында ята. Тун якасы эченнән һаман да су агып кереп тора. Бүтән бер нинди үзгәреш юк. Тикшерүче кеше килеп җитмәгән әле. Район үзәген безгә егерме биш чакрым диләр, кайчан килеп җитә әле ул!

Ә халык китә!.. Ни көтәләр алар? Бәйрәм көн җылы өйдә рәхәтләнеп хәсрәтсез генә утырмаска? Тирә-якта ыбыр-чыбыр бала-чага йөри. Аларга минем әтинең үлеме кызык кынадыр инде... Минем дә биш яшь чагымда дәү әнием үлгән иде. Ул мине бик ярата иде. Җеназасын алып чыгар алдыннан, әни миңа дәү әниемнең очлы иякле, очлы борынлы сап-сары йөзен ачып күрсәтте дә:

— Карап кал, улым. Дәү әниең бүтән булмаячак инде...— дигән иде.

Ә мин еламадым да. Исән чагында дәү әнием миңа:

— Кешенең, үзе үлсә дә, җаны үлми, шул җаны күбәләк булып өйгә кайтыр да дога көтеп йөрер,— дип сөйли торган иде.

Шуңа күрә, йөзенә карап торганда, миңа да дәү әнинең инде чыккан җаны, мөгаен, күренмичә генә карап тора торгандыр кебек тоелды. Һәм соныннан нинди генә күбәләк күрсәм дә, ул миңа гел дәү әниемнең җаныдыр төсле тоела иде. Шуңа күрә мин күбәләк тотып, аны китап эченә тыгып та киптермәдем...

Мине әти дә бик ярата иде. Дүрт кыздан соң бердәнбер малай булгач!.. Мин моны бик яхшы белә идем. Менә шундый, мин туганны көтеп алган, мине бик ярата торган әтием — инде юк; әнә, йөгереп килеп, сикереп кенә чыгарлык елгада капланып үлеп ята. Дәү әнинең җаны гел очып йөри кебек иде — әткәемнең җаны очып та йөрмәячәк. Чөнки инде мин, мәктәптә иң яхшы укучы малай, җанның юклыгын гына беләм. Китапта шулай язылган. Юматов абый да шулай сөйләде. Ул — белә! Ул Казанда укыган. Ул — Халхин Гол буенда сугышып кайткан. Инде ике ел укыта, ә шинелен һаман салганы юк, чөнки шинельдән дә матур кием юк...

Мин инде җанның гына түгел, алланың да юклыгын беләм... Тик менә — әтием үлгәч нишләргә?.. Җан булмагач, инде әти бөтенләйгә үлгән булып чыгамы? Мин инде бүтән мәңге күрә алмыйм булып чыга түгелме?.. Их, газиз әтием!.. Нигә инде бу тикшерүчесе дә тизрәк килми? Ник яткыралар әтине салкын суда?.. Нигә, әти, үзең генә сикереп торып чыкмыйсың икән?.. Салкындыр бит инде сиңа салкын суда? Өшү генә түгел, туңыплар беткәнсеңдер...

Мин әкрен генә яр буена китеп барганмын. Мине беркем тотмады, туктатмады. Менә мин, елга читенә басып, әтинең канланып яткан олы гәүдәсенә карап торам. Су һаман яка эченә ага. Бикләр авылы өстендә — үрелеп буй җитәр биеклектә генә торган кояш та, туктап, ялгыз

хәсрәт белән этиемә текәлеп калган кебек: этиемнең баш түбәсе турында гына, су өстендә тәңкәдәй нур уйный иде... Бүреге булса да, ичмасам, башы бу тиклем дә өшемәс иде!

Шунда бөтен дөнья тынып, колагыма эти аркасы буйлап төшеп, тун эченнән чылтерәп кенә агып чыккан нәзек су тавышы гына ишетелеп тора башлады. Бер заман ул су минем аркам буйлап та, инде шаулап, мине дә туңдырып-өшеттереп ага башлады. Эти гәүдәсе калкынгандай итте — торырга җыена түгелме соң?..

— Э-ти-и!..— дип акырып җибәрдем.

Шунда артымда гына милиционерның усал тавышы яңгырап китте:

— Алыгыз әле бу малайны моннан!..

Мин, яр астыннан атылып менеп, халык төркеменә барып сыендым. Этием белән бергә эшләүче, күрше авылның Җәприм дәдәй шунда гына икән, мине үзенең алдына бастырып, кочаклап алды. Мин дер-дер калтырый идем. Җәприм дәдәй озын тун чабуын ычкындырып мине төрде.

— Курыктыңмыни? Курыкма син аннан. Этиең сынлы нык бул.

Мин, аркам җылы тәнгә тигәч, тиз җылындым. Җылы рәхәтен тоеп, инде тагын йөрәгемнән эти уе агып киткәндә, халык дәррәү мине сискәндереп:

— Киләләр!..— дип дулкындай чайкала башлады.

«Киләләр!» дисәләр дә, килүче кеше бер үзе генә иде.

Килеп җитеп, нәкъ минем каршыда гына җирән атын туктатты да, иске генә тарантасыннан җитез генә сикереп төшеп, Акчурин агайлар янына килде, кул биреп күрешеп чыкты. Мин аны Хәмитшин абый шикелле күн киемнәр кигән, наган аскан гыйбрәт таза гәүдәле бер кешедер дип уйласам — ул буйга милиционерның иңбашыннан гына диярлек иде. Өстендә дә күн түгел — шинельдәй озын шәһәр пальтосы, башында эшләпә, аягында итек; шарфы эченнән галстук төене күренеп тора иде. Беренче соравы:

— Үлекне кузгатмадыгызмы? — дигән сүз булды.

«Үлек» сүзе башыма суккандай итте: нинди «үлек» булсын — минем эти ич ул!..

— Юк, кузгатмадык, иптәш Вахитов,— диде милиционер.— Шаһитлар күргәндә кай җирдә булса, шул җирдә ята.

— Яхшы. Елга буен таптап йөрүчеләр булмадымы?

— Мин килгәч булмады,— диде милиционер абый.— Бигрәк тә югары якны күз астында тоттык.

— Ә елга буен үзегез тикшереп чыкмадыгызмы?

— Юк, иптәш Вахитов. Мин сез килгәнне көттем.

Әле генә миңа акырган, тилгән карашлы милиционерның шушы абзыйга йомшак тавыш белән «иптәш Вахитов» дип кенә торуы миңа бик сәер, хәтта кызык тоелып китте: милиционер да песи була икән! Тикшерүче абый минем күз алдымда үсеп, серле бер көчкә әйләнде. Мин инде аңа өмет һәм хөрмәт белән, күзне дә алмый карап тора башладым. Миңа ул тагын «яхшы» диде дә, Акчурин агайга карады:

— Мин райүзәктән врач алып килмәдем. Ерак җир. Сезнең Урсай больницасы белән генә сөйләштем. Хәзер үк ат җибәрегез, баш врач үзем киләм диде. Әле вакыт бар, шулай да тоткарланмый килеп җитсен.

Акчурин агайның күз уңыннан бер карыш та читкә китми торган идарә йомышчысы Кара Самих бу әмерне ишетеп тора иде инде, председатель ым кагу белән юк та булды.

Тикшерүче абый:

— Ә хәзер әйдәгез эшкә башлыйк,— дип, тарантасыннан кыр сумкасын алды да, җыелган халыкка бернинди игътибар бирмәстән, хәтта күрмәгән дә кебек, эти гәүдәсе яткан җиргә китте. Аңа Акчурин агайлар иярде.

Су читенә житәрәк, тикшерүче аларны кул ишарәсе белән туктатты да, бераз алга китеп, үзе дә туктады. Бер эти гәүдәсенә, бер тирә-якка күз ташлый-ташлый, сумкасын тезенә куеп яза башлады. Аннары бер үзе генә су читенә төшеп, бик нык иелеп, агымның югары ягыннан да, түбән ягыннан да унбиш-егерме адым урап килде. Анысын да язып куйды. Аннары әкрен генә Сусәннең теге ярына чыкты. Ул ягын да җентекләп тикшерде.

Аннары алар, милиционер белән икәүләп, сузылма метрны этинең гәүдәсенә куеп, теге яктан да, бу яктан да үлчәп чыктылар. Бу кадәресен дә язып куйгач, киңәшләшеп алдылар да, милиционер абый кемнәргәдер карап:

— Итек кигәннәр, бер өч кеше бире килегез әле. Мәетне чыгарырга!— дип кул изәде.

Юматов абый белән комсомол Ярхәм, тагы мине кочаклап торган Җәприм дәдәй беренче булып кузгалып киттеләр.

Йөрәгем тибүдән туктады.

Юматов абыйлар, эти гәүдәсенең өчесе өч җиреннән тотып, әкрен генә ярга алып чыктылар. Әтинең туны, итеге эченнән шыбырдап су агып килә иде. Кай арада брезент китереп җәйгәннәрдер, этине шуның өстенә чалкан китереп салдылар. Халык, авып китәргә җыенгандай, алга сөрлекте.

— Артка чигенегез! Артка!..—дип, милиционер каты әмер бирде.

Һәркайсысы кире чигенеп, үз урыннарына кайтып баскач кына, мин этинең йөзен күрдем. Йөзе танырлык түгел: күз төпләренә, мыегына тоташ лай каткан иде. Туны төймәләнмәгән — ачык чабулары судан авыраеп, ике якка каерылып төште.

— Йөрәгенә кадаганнар...— диде кемдер.

Чыннан да, эти сул кулын бөкләп, учы белән йөрәк турысын тоткан иде; бөтен йөзе, иңбашлары җыерылып, күкрәгенә тартылып каткан — эти, һаман да йөрәгенең авыртуына чыдый алмыйча, тирән газап эчендә ята сыман иде.

Мин башкача түзә алмадым — «Әт-кә-ем!» дип кычкырып җибәрдем. Ләкин шунда миңа да кемдер китереп кадагандай булды.

Мин башкасын хәтерләмим.

Соңыннан сөйләделәр: мин эти гәүдәсе яткан җиргә ташланганмын икән. Ләкин барып җитә алмаганмын — эти төсле, күкрәгемне тотып җиргә капланганмын. Мине өйгә Җәприм дәдәй күтәреп китереп куйган...

## 4

Исем кайтканда, иң әүвәл еракта бик әкрен генә: «Мунча кергәнмен икән...» дигән уй килде. Мин мунча керүне яратмыйм: мунчадан соң минем ике тәүлек буе башым сызлый. Әле дә менә чатный гына!.. Ләкин өскә нәрсә өйгәннәр? Кайда мин бу кадәр бастырылып ятам?.. Капшап карадым: өстемә юрган, юрган өстенә толып ябып куйганнар, ә түшәгем лычма су. Мин, бик авырлык белән, сызлаган күземне ачып җибәрдем. Тирә-ягым кап-кара, сул күземә генә кара төн эченнән сукыр бер яктылык сирпелгәндәй. Интегеп кенә башымны күтәрсәм кучкарда ут яна — җиделе лапма кысып кына куелган. Үзебезнең өйдә ләбаса мин...

Шул чак идарә ягыннан бик таныш бер тавыш миемә кисеп керде:

— Бүген иртә белән сезгә тимерче Мәгъдән Мәрданов кергәндә сәгать ничәләр бар иде?

— Мин торганда, көндәгечә, биш тулып кына киткән иде. Торып киенгәнче-ниткәнче алтынчы ярты җиткәндер. Шуннан мал-туар янына

чыктым. Асларын туккәнче, эчерткәнче, ашатканчы дигәндәй, сана, бер сәгать кенә үткәндер. Артык та булмаса әле... Өйгә кереп, өстемнән салып кына торганда, Мәгъдән килеп керде. Килеп керде бу шулай. Аю кебек Мәгъдән куяндай кечерәеп калган. «Көжмә тегермәненә Сусән буйлап бара идем, күрәм: су эчендә кара нәрсә ята. Күземне ачып карасам — кеше!» ди. Шуннан, кире чабып кайтып, безгә кергән. Чыны да, ни, көчкә сулыш ала иде... Ул минем күрше генә. Кичтән бераз нитеп тә, кунак булып та утырган иек...

Мин инде бу тавышны да таныдым. Ул — минем белән бер класста укыган Бәздәвинең этисе, көтүче Баһау карт иде. Шунда мин, инде тәмам уянып, бу әрнүле дөньяга кайттым. Һәр минуты ничә газап белән, ничә сызлап үткән чиксез озын көннең кара, калын пәрдәсе ачылып китте. Кичтән үк демонстрациягә ашкынган күңел. Без быел Гафият белән икебез ике саплы әләм тотып барасы идек... Уянсам — якты иртә, салкын өй... Салкын су эчендә йөзтүбән капланып, йөрәген тотып яткан эти... Чип-чиста итеп кырылган башы өстендә кояш чагыла...

Шабыр тиргә баткан тәнем тунудан калтыранып куйды. Мин торырга итеп ике терсәгемне дә түшәккә кададым. Тик — башны ничек мендәрдән аерырга? Бигрәкләр дә авырайган шул!.. Мин түгелдер анда — таштыр... Ләкин торырга кирәк. Капыл күтәрсәм, мие чайкалып китәр төсле. Менә шулай, менә шулай... Ы-ыһ! Булмый — баш кире мендәргә төште. Ы-ыһ!..

— Чү, улым, чү...

Әни уң ягымда гына утыра икән, боздай салкын кулын маңгаема куйды.

— Ни кирәк, улым? Йомышың бармы әллә?

— Теге якка чыгасым килә... — дидем мин.

— Анда ярамый... Торганыңны күрсәләр — безне дә чыгарып җибәрерләр.

— Кемнәр?

— Теге абыеңнар. Түтәңнәреңне дә чыгарып җибәрделәр әнә.

— Ә сине?

— Мине синең аркада гына калдырдылар.

Әни колагыма иелеп, пышылдап кына сөйләшә. Минем тавышым исә бөтенләй зәгыйфь — үземә дә чак кына ишетелә иде.

— Әтине алып кайттыларммы? — дидем мин.

Әни җавап бирмәде, минем кайтарып сорарга тыным кысылды. Икебез дә тынып калдык. Әни әкрен генә торып, салкын суга чүпрәк чылатып килде. Аны иләп кенә маңгаема япты. Мин салкын сулы чүпрәкнең рәхәтен тойдым.

— Инде тын гына ят. Йокла... — диде әни.

Ләкин йоклый алмый идем инде мин. Зиһенемне туктаусыз теге яктан килгән серле дә, шомлы да сүзләр уятып тора. Бу ялгыз, дөм-сукыр тынлыкта теге бүлмәдә сөйләшкән һәр сүз колакны ярып керә иде.

— ...Мәгъдән Мәрдәнов сезне үзе белән бергә шаһит булып барырга чакырган. Сез баш тарткансыз. Ни өчен? Үзегез әйткәнчә, «минават» буласыгыз килмәүдән генәме? Шаһитның дөрес сөйләмәгәндә генә виноват булуы мөмкин.

— Минем әле шаһит булып ни каршына басканым юк. Хөкем каршына. Мине минават кына иттеләр.

— Бәлки ачыграк сөйләрсез.

— Менә борынымны күрәсеңме? — диде кинәт Баһау карт калын, усал тавыш белән. — Ул мине кыйнаудан шулай нитеп, кимерчәге сынып, ямьшәеп калган... Хәзер менә бу ярыкны күр. Ул да — тукмалган эз! Менә бу кулымны да тукмап сындырдылар. Анысы — кәкрәеп ялганды...

— Кемнәр кыйнады соң сезне?

— Байлар булмый кем булсын!.. Нишләп үлмәгәнмен әле?.. Стражниклар килеп житмәсә, үтерәселәре дә булган... Аннан инде — баструк. Ике елдан артык утырдым. Ярый, революция чыгып коткардылар.

— Ни өчен утырдыгыз инде?

— Ни өчен буламыни? Знамо ат карагы булганым өчен. Атасыз үскән бала — яшьләй үк шул ниләр шайкасына уралып кереп киттем инде. Урманыбыз тулы ни — качкылар...

— Анысы кирәкми, — диде тикшерүче. — Сорауга җавап бирегез: мәчет манарасын кискәндә сез бар идегезме?

— Юк ием. Мин такыр басуда көтүдә ием. Колхоз чыкканнан бирле көтүдә инде мин. Башка нием юк, өнәрем. Көтү эшен беләм дә мылтык тота беләм. Әле дә менә ау житмәгән, өйдә генә ятам. Мал-туар тирәсендә кайнашам. Дөньясы каралмаган кеше булса, ул — көтүче булыр. Бәй, кайчан карасын ул дөньясын? Бәрәңге утыртканда да көтүдә, алганда да. Кешеләр каралты-кура ныгыта, ә көтүче көтү көтә...

Баһау карт, чыннан да, иртә яздан алып кара көзгә тикле халыкның сыерын, сарыгын көтә. Авыл бәләкәй булгач, аеры-аеры ике көтүче яллагмыйлар. Кышын аңа эш юк, кышын ул ауга йөри. Инде дә куяннарның жанын ала! Көнләшеп үләрлек! Аңардан да бигрәк мин Бәздәвидән көнләшәм: ул җәй буе этисе белән көтү көтә, кышын, ял көннәрендә, хәтта дәресен ташлап, ауга йөри. Үзе атып алганмы-юкмы, мәгәр ике ягына ике куян асып, тау өстеннән этисе белән бергә кайтып төшәрләр иде. Шуңамы Бәздәви укудан алдыра алмый — син аңа чаңгы бир дә мылтык бир, тик хәреф кенә күрсәтмә... Ат карагы диген, ә! Менә кем булган икән Бәздәвинең этисе!..

Тикшерүче сүзне тагын мәчеткә борып кайтарды:

— Мәчет манарасын кискәндә, мәрхүм Нуриман Нуриазданов та булган. Ягъни ул киселгән манараны тракторы белән тартып төшергән. Беләсездер?

— Беләм. Андый эшкә бик хирыс ие мәрхүм.

— Соравым: манара кисешкән өчен аңа бирәрсенең янаганын ишетмәдегезме?

— Кайлардан ишетим инде мин? Көннең көн буена, эт шикелле, көтү артыннан чабып йөре дә! Сыерлар сөйләсенмени аны миңа?..

— Тагы бер сорау: мәчет манарасын кискән көнне Мәгъдән Мәрдәнов янау кебегрәк бер сүз ычкындырган. Күрше буларак, ул сүз сезгә мәгълүмме?

— Нindидер сүз әйткән бугай инде ул. Ләкин мин ишетмәдем. Үзем ишетмәгәч, кеше гөнаһысына керә алмыйм.

Тикшерүче кинәт бөтенләй башка сорау бирде:

— Ә сез үзегез манара кисүне ничек кабул иттегез?

— Минме? — диде Баһау карт. — Миңа ниемә манара! Гомерем буе мәчеткә йөрмәдем дисәм дә, һич ни түгел — ялган түгел. Малай чакны бик малай иєм. Аннан — мәчет кайгысы булмады. Мәчетнең үзендә яшереп ат токкан чакларны гына исәпкә тыксам инде... — Шулай дигәч, Баһау картның ютәлле көлүе ишетелде. — Динен дә, алласын да белми үстем мин. Бу нидә, чутта мәрхүм Нуриман белән икебез бер иек. Ул да бит: «Мин үлгәч, гәүдәмне чокырга чыгарып ташласалар да, утта яндырсалар да, мин инде аны сизмим, миңа инде барыбер», — дип сөйләгән

Колагыма: «И мәрхүм...» дигән утлы пышылдау авазы килде. Шунда мин әнинең дә тегеләр сүзен тыңлап утыруын белдем.

Инде йокым тәмам ачылып беткән, хәтта бая гына чатнап сызлаган күзем-башым да жиңеләеп басылган иде. «Этине үтергән кеше кем? Кайчан тотарлар?» дигән сабырсыз уй каныма ут салды. Мин тагы, хы-

ялым ялкындай кабынып, бөтенләем белән, стена аша аермачык ишетелеп торган, бүгенге көн карасыдай серле сүзләргә йотылдым.

Кинәт тикшерүче мин бөтенләй көтмәгән яктан китереп сорау бирде:

— Чәчегезне кем алды?

— Чәчебезне, ни, үзебезнең тегермәнче Фидаил алды инде, — диде Баһау карт. Шунда ул кинәт: «Тукта-тукта, погоди!..» дип нәрсәнедер исенә төшереп алды. — Кичке якта, ни дә, мәрхүм Нуриман да кереп китте түгелме соң аларга?..

— Кайда күрдегез?

— Тәрәзәдән күреп калдым. Фидаилләр өе безнең каршыда гына диярлек. Чапрышта гына. Мин тәрәзәдән караганда, Нуриман Фидаилләр капкасына борылган иде. Кайры тунын кигән. Мәгәр тунын нан да биграк аякларын нитеп, эчкәрерәк басып селлин-селлин атлавыннан таныдым.

— Сәгать ничәләр иде инде?

— Тәгаен генә әйтә алмыйм, энем. Якты ие әле.

— Чыгып киткәнен күрдегезме?

— Анысын менә — күрмәдем. Күз бәйләнгәч, күршем Мәгъдән кереп, празник хөрмәтенә бераз сыйланып утырдык.

— Мәгъдән Мәрдәновмы инде ул?

— Шул инде, үзе.

— Ул сездә күпме утырды? — Тикшерүченең тавышы янә ныгып китте.

— Байтак гомер утырылган инде. Празник бит. Ул чыгып киткәндә, бик караңгы ие инде. Аның бит хәзер караңгысы да бик иртә төшә. Аннары ни, әз дисәң дә, икебезгә бер чирек беткән. Мәгъдәнгә нәрсә аңа! Ул — таза. Аның бер үзенә бер чирек кирәк. Ә минем сыңар илле бишен узып киткән бер картка эчкән хәтлесе дә бик җитә. Йөрәгем бүген дә авырта, менә кулларым калтырый.

— Мәгъдән Мәрдәновны озата чыктыгызмы?

— Чыкмыйча теге! Өйалды ишегенә хәтле нитеп куйдым.

— Ә капкагыздан чыгып киткәнен күрдегезме?

— Бәй соң, күрмичә! Капканы ябып чыгып киткәнче, ишекне япмый тордым.

— Кайсы якка киткәнен чамаладыгызмы?

— Шактый җибегән идем инде, клубка китте микән, үзләренәме — караңгыда абайлый алмадым. Үзләренә булыр, клубта аңар ни калган икән?..

— Ә өйләре кай якта?

— Өйләре шул, үзең күрдең, авыл чите инде. Югары очта.

Тикшерүче Баһау карт сөйләгәннәрне язып утырды, ахры: бик озак бернинди тавыш чыкмый торды. Бәлки алай бик озак та булмагандыр, мәгәр миңа, сүзләренең һәрберсен кайнар тыным белән тартып алырга торганда, бу өзеклек караңгы бушлыктай чиксез иде. Ниһаять, тикшерүче язып бетерде бугай:

— Тагы нәрсәләр өсти аласыз? — дип сорады.

Мин аның, шулай дип, Баһау картның яньчелгән борынына текәлеп катканлыгын күргәндәй булдым.

— Юк шикелле...

— Булмаса, менә сөйләгәннәрегезне укыгыз да имзагызны куегыз.

— Мин укый да, яза да белмим, энем. Имзалык өч кенә хәреф белән калдым. Баш китәр ниләр язмагансыңдыр бит? Кая имзамны тырнаклап бирим...

— Искәртеп куям: тикшерү бетмичә торып бер кая китмисез. Момент арасында кирәк булуыгыз бар.

— Кая китим инде мин!.. — дип, Баһау карт дөбердәп урыныннан торды. Дөп-дөп басып чыгып китте.

Өй эче тып-тын булып калды. Шик тулы, шөбһә тулы тынлык. Минем хыял үзенекен уйлый башлаган иде инде. Әллә юкса Мәгъдән абзый үтергәнме соң этине? Мәчет манарасын кискәндә, үз колакларым белән ишеттем бит: «Коммунистлар да мәңгегә килмәгән — үлгәч каберләренә йолдыз ясарга кирәк булыр», диде бит. Менә ул урамга чыккан да этине эзләп киткән. Яки кара төндә, читәнгә елышып, этинең кайтканын көтеп торган. Әти алар турына җиткәч, олы кара гәүдәсе белән эти өстенә ташланган да, эһ тә иттермичә, йөрәгенә пычак кадаган. Эти — йөрәген генә тота алган... Шулай эшен бетергәч, эти гәүдәсен, капчыктай, җилкәсенә салган да Сусәнгә илтеп ыргыткан... Үзе соңыннан «үлек күрдем» дип сөрән салып, Баһау картларга кергән...

Авыру хыялым шушы җиргә җиткәч, тәнемдәге бала йоннарын кабартып, йөрәгемне капыл чәч пәкесе йөзедәй салкын шом телеп үтте. Мин бик озак, тешем тешкә тимичә, калтыранып яттым. Миңа тикшерүче абыйның иртәгә иртүк Мәгъдән абзыйны богаулап, милиционер абыйны сакка куеп, районга алып китүе күз алдыма чын булып килеп басты. Этине үтергән кешене кеше алдында багана төбенә бастырып аталар микән?.. Әгәр Баһау картны чакырып алып: «Куянга бик тиз атасың икән, менә син курше, атып күрсәт әле!» — дисәләр, атар иде микән?..

Колак төбендә зеңләп торган бу тынлык бик озакка китте. Тикшерүче абый нишли анда? Язып утырамы, уйлапмы?.. Кемне кулга алыр ул иртәгә?..

Бу тынлык әнине дә ялкытты, ахры: менә ул буйдан-буйга тик утырган җиреннән торып, идәнгә басты; өй тулы төн карасын ярып ишеккә юнәлде. Һәм шомлы тынлыкка кереп күздән югалды. Бераздан аның бер көн эчендә хәсрәт баскан тавышы ишетелде:

— Бәй, йоклап утырасың түгелме соң, энем? Кая тор. Хәзер урын җәеп бирәм.

— Мәшәкатьләнмәгез, апа. Мондый көнне...

— Соң, өстәлгә баш куеп яталармыни шулай? Ярамаганны... Әйтәләр аны. Баһау абзый чыгып киткәч тә, урын җәеп бирер идем. Мин бит эш белән утыра икән дип торам. Утың да сүнмәгән.

— Арылган икән. Бу арада эше дә күп булды. Сезнең укытучы Юматов, эшең беткәч, үзебезгә кайтып кунарсың дип, квартирын да күрсәткән иде. Инде бик соң — унике тулып килә. Чит кеше ишеген бу вакытта шакып йөрисем килмәде.

— Ашамагансың да бит әле син, энем. Аш җылытып биримме соң әллә?

— Берүк мәшәкатьләнә күрмәгез, апа.

Баһау карттан сорау алганда, бөтенләй башка иде бу абыйның тавышы: йөрәккә суккан усал түгел, мәгәр юаш та түгел иде. Әйттерми, сөйләттерми калмас кебек иде. Чыны исә бөтенләй башка — ягымлы икән.

Әнинең аны шул кадәр дә ашатасы килә иде.

— Сөт белән ипи булса да кабып ал, энем. Ач карын йөрмә болай.

Әни шулай дип үзебезнең якка керде. Тычкан утыдай гына янган лампаның филтәсен күтәреп, шүрлектән ипи алып кисте, сәкедәге чүлмәктән җамаякка сөт агызды. Икесен ике кулына тотып чыгып китте.

— Мә, энем. Җиңелдән генә булса да тамагың ялгап ал.

— И апа, бу кадәр!.. — диде тикшерүче абый. Шул тикле дә кыенсынып әйтте.

Бөтен халык, исемен ишеткәндә дә хөрмәт катыш дертләп кинәт прокурорлар, судьялар, әллә нинди ГПУларда да шушындый, безнең шикелле үк кешеләр эшли микәнни? — дип, бик аптырап уйлап куйдым. Әнә ул әни кулыннан сөт алып эчә. Моны Баһау карт күрсә, аның соравына җавап биреп торыр иде микән?..

Шунда тикшерүче абый әнидән сорап куйды:

— Өегездә канцелярия тоту бик мәшәкатьледер инде сезгә, апа?

— Мәшәкать дип... кирәк бит. Яңа кәнсәләрне язга өлгертерләр, түз инде, карчык, ди торган ие мәрхүм... Ә минем зарланганым булмады да. Исән-сау кешегә теге ягы да бик житкән. Кешеләргә дә бик иялəшеп беткән иек. Кеше булмый торса, әллә ничек күңелсез дә иде әле.

— Улыгызның хәле ничек, апа? Аңы кайтмадымы әле?

— Әле бая гына уттай янып уянып китте. Маңгаена сулы чүпрәк куйгач, жинеләйде, ахры.

— Апа, бер соравым бар сезгә. Тик сорау ала икән дип уйламагыз. Мәчет манарасын кискәч, ирегезгә янаучылар булмадымы?

— Кем янасын инде хәзер, энем... Бездә генә кисмәделәр бит мәчет манарасын. Тирә-як авылларда күптән кистеләр. «Сезнеке генә күзгә төшкән ак булып тора», дип, килгән бере тиргәде председательләрне. Колхоз чыкканнан бирле дигәндәй, кәнсәләр тоткач, ишетмәсәң дә ишетәсең. Ә председательләр алмашынып кына торды. Колхоз да мантымый. Һәр кайсысы әйтә: «Манара кисүдән башлый алмыйм: мина кешеләр белән эшләргә кирәк», ди. Шулай кала килде. Менә инде, шөкер. Акчурин өченче елын эшли. Колхозыбыз да тернәкләнә башлады. Чәчү беткәч сөйләштеләр: быел кисик шул манараны, диделәр. Актив жыйдылар. Фидаилне кисәргә үгетләделәр. Көчкә риза булды. Кискәч — тартып аударырга кирәк. Минем карт МТСыннан кайтып кына кергән иде. Коммунист кеше. Чыкты кәнсәләр ягына. «Күптән вакыт иде инде, ди. Бау тартырга егет-жилән жыеп азапланмагыз. Кешенең төрлесе бар, күбебезнең әби-бабасы гына түгел, әти-әнисе дә дин сөременнән азат түгел, ата белән бала жәдәле китәр, ди. Трактор үземнең кулда, баганаларын кисеп куйсагыз, манарасын үзем тарттырып төшерермен, ди. Тракторның кулы да, аягы да корымас, ә мин — коммунист кеше», — диде мәрхүм.

Мин үзем каршы ием. Курыктым. Тиюләреннән түгел — ил каргышы төшүдән курыктым. Илдә сүз күп йөрде бит. Теге авылның мәчет манарасын кискән фәлән кеше акылдан язган; бу авылның — үз өенә үзе ут төрткән; берсенең кулы корыган, икенчесе телдән язган... Ни генә ишетмәдек ул елларны!.. Манара кискәннәрне үтереп ташлаулар да булмады түгел, булды бит. Минем сүзгә уен белән генә жавап бирде мәрхүм: «Син бер дә борчылма, әнкәсе. Динен дә, алласын да танымагач, каргышы да төшәргә тиеш түгел»,— диде. Акчурин да әйтте: «Нуриман абыйның илдә ихтирамы зур, бернинди каргыш төшмәс, апа»,— диде. Күңелем барыбер күнмәде. Илдәге сүзне күбрәк без — хатыннар ишетә бит!.. Ишетелде инде сүзләр, ишетелде... Мәгәр мин, кемдер янады дибәйтеп, кеше гөнаһысына керә алмыйм... Янаганнармы, юкмы, инде аңардан ни файда: үлгән кире кайтырмы!..

Әни мышкылдап елый башлады. Тикшерүче абый:

— Тынычланыгыз, апа. Тынычланыгыз. Елаудан да файда юк бит...— дип, әнине күңел тавышы белән юатып алды.

— Еламый нишлим?.. Еламый нишлим соң?.. Йөрәгенә чәнечкәннәр бит. Йөрәкләренә!.. Шундый да курыкмас йөрәк иде бит аның йөрәге! Искене гел жимереп барды. Колхозын да ул төзеде. Кырык яшендә тракторга утырды. Сельсоветта иде бит ул, әлеге Хәмитшин урынында иде. Начар идеме әллә эше? Шуны ташлады. Шул тимер шайтанны йөгәнләп йөртәсем килә дип, әлеге эшен ташлап, яшьләр белән тиң тракторга өйрәнде мәрхүм...

5

Сорау алу икенче көнне дә дәвам итте. Икенче көнне дә мин урынымнан тормадым. Минем өйдән чыгып китәсем килми. Хәтта мин шушылай авырып китүем өчен сөенеп тә куйдым. Минем канымны да, жанымны

да тәмам үтерүчене тотып алу вакыйгасы биләп алган. Йөрәгемне бер кысып, я бер каты иттереп тибәргә мәҗбүр иткән бу түземсез көтү сәгатьләре эти кайгысы белән бергә кушылган иде.
Иртә белән беренче кеше итеп тегермәнче Фидаил абыйны чакырдылар.
Фидаил абый зәңгәр күзле, житен чәчле бер кеше иде. Аларның өе югары очтан дүртенче генә. Мин аның эти-әнисе барлыгын белмим, дәү этисе Ибрай белән дәү әнисе Бәлхис әби барлыгын гына беләм. Ибрай бабай тегермәнче иде. Өченче ел үлде. Аның урынына яшьләй үк тегермәндә үскән, бу эшкә чарланып остарган Фидаил абый калды. Болай да ул Ибрай бабайга иптәш тегермәнче булып эшли иде. Аны егерме җиде яшьтә диләр. Шулай да — өйләнмәгән. Урта кул гына бер өйдә әбисе белән генә торалар. Быел инде өйләнергә тиеш булган. Бездән ерак бер авылда вәгъдәләшкән кызы да булган. Көзгә туй ясарга сүз дә куешканнар икән дип сөйләделәр. Кәнсәләргә җыелган халык өчен атна буена җитәрлек хәбәр булган иде. Ләкин быел җәй, мәчет манарасы кискәннән соң, ярәшелгән кызының этисе, бик диндар карт, кисеп әйткән имеш:
— Исемен дә ишетәсем килми денсезнең! Әгәр дә мәгәр, башы бет-керенең, бусагамны атлап керәсе булсамы! — әнә балта, әнә пычак — үземә-үзем хуҗа түгел... Әнә керәшеннәрдән алсын кызны!.. дигән дип сөйләделәр.
Бу хәлләрне ишеткәч, мин Фидаил абыйны гел кызгана идем. Хыялым үзебезнең күрше авылның кат-кат итәкле күлмәкләр кигән, чүпләмле алъяпкычлар бәйләгән, чәчләренә ука чачаклар таккан нәзек билле керәшен кызларына барып бәйләнә. Шуларның берсен — гел алача күлмәктән киенеп, аягына нәфис тула оек белән ак чабата кигәнен гел дә Фидаил абый алып кайтыр кебек уйлый идем...
Йомшак кына тамак кырып, йомшак кына йөткереп, кәнсәләр ягына Фидаил абый килеп керде. Исәнләште.
— Бире килегез. Утырыгыз, — диде аңа тикшерүче.
Бүген инде аның тавышы үткән төн әни белән сөйләшкән сыман түгел — каты иде. Әнинең олы хәсрәтен аңлап, йомшак-ягымлы итеп сөйләшкән тавышның әсәре дә калмаган иде инде. Башта Фидаил абыйның исем-фамилиясен, туган елын, эшләгән урынын, өйләнгәнме-юкмы икәнлеген сорап чыкты. Ярый, исем-фамилиясе кирәк тә булсын ди, ләкин өйләнү-өйләнмәве нәрсәгә? Мин бит беләм, Фидаил абыйдан аны сорарга ярамый. Ул аның — хәсрәте. Шул хәсрәттән ул Свердловск ягына да чыгып китәргә уйлаган дип сөйләделәр. Тик Бәлхис әбине генә ташлап китә алмаган. Бәләкәйдән үк тегермәндә он тузаны йотып үскәнгә, үпкәсенә чир йоккан дип тә сөйлиләр. Булыр да. Гел йомшак кына йөткереп, тамак кырып йөри бит. Ләкин ул — таза, көчле. Беләк тычканын кабартып беләгенә бәйләгән тегәрҗепне шартлатып өзә торган иде.
Тикшерүче үзенең тигез, какшамас тавышы белән мәсьәләнең эченә керде:
— Алтынчы ноябрь көнне төштән соң Нуриман Нуриазданов сезгә чәч алдырырга кердеме?
— Керде, — диде Фидаил абый нык тавыш белән.
— Сәгать ничәләр иде?
— Сәгать биш тулып килә иде инде. Күз бәйләнгән иде. «Караңгы бит, Нуриман абзый. Иртән якты күздә керерсең», дидем. «Иртәгә бәйрәм, чәч алдырып йөрү килешмәс, эшне бүген бетерү тиеш, ди. Мыекны, ди, якты күздә төзәттем, сиңа чәч кенә калды, ди. Синең Гали пәкесе караңгыда да ялмап кына алыр әле», ди. Лампаны кучкарга куеп, Нуриман абыйны шуның яктысына утыртып, чәчен алдым. «Бик чиста да киенгәнсең, кая болай?» дип сорадым. «Бүген үзебезнең эм-те-эста бәйрәм кичәсе була, шуңа барышым», — диде.

— Өегездә тагы кемнәр бар иде?
— Дәү әнидән башка кеше юк иде.
— Нуриман Нуриазданов сездә озак тордымы?
— Шул, чәчен алгач, җылы су салып торып, башын юдым. Әзрәк кипшенсен инде дип, мич буенда бераз утырып торды. Шул бер сәгать үткәндер.
— Кайчан чыгып китте инде?
— Без бергә чыгып киттек. Сәгать алтынчы ярты иде.
— Бу кадәр төгәл әйтүнең сәбәбе бармы?
— Мине сәгать бишкә Бикләң авыл тегермәнчесе Көҗмә дәдәй чакырган иде. Ул — хатыны үлгән, ялгыз. Мин, өйләнмәгән, ялгыз. Бергәбергә бәйрәмне каршыларбыз, диде. Нуриман абзый кергәндә, китәргә җыенып тора идем. Аңа инде: «Минем кунакка барасым бар иде», дип әйтә алмадым. Дәрескә барасы түгел ич!..
— Хуш, бергә чыгып киттегез ди, ә кайда аерылыштыгыз?
— Көҗмә дәдәй тегермәненә чаклы бергә бардык. Мин тегермән өенә кереп калдым, Нуриман абзый МТСына китте.
Фидаил абый йөткереп куйды да, шуның белән сүзе беткәндәй, туктап калды. Тикшерүче аның сүзне тагын да дәвам иттерүен көтте, ахры, ләкин Фидаил абый үзе сүз башламагач, бик сәер генә тавыш белән үзе сорау бирде:
— Нуриаздановны сез яңадан күрдегезме?
— Без Көҗмә дәдәй белән байтак утырганбыз. Ике тегермәнченең сүзе беткәнмени! Көмешкәсе дә бар иде. Башта мин үзебезнең клубтагы спектакльгә кайтып җитәрмен дип уйлаган идем. Тик, кызмача көе кайтып, кеше күзенә күренәсем килмәде. Сөйләшеп утыра бирдек.
— Ниләр сөйләштегез инде? — дип бүлдерде аны тикшерүче.
— Кеше табында ни сөйләшмәс! — дип кырыс кына җавап бирде Фидаил абый. — Табындагы сүзне монда сөйләп бетереп буламыни?..
— Яхшы, дәвам итегез, — диде тикшерүче.
— Сәгать тугызлар булгандыр инде, бер вакыт ишек шакып Нуриман абзый килеп керде. «Тегермәнегез тарта, тәрәзәгездә утыгыз да бар, ди, бәйрәм кичендә кереп чыкмау килешмәс дидем, ди. Бәйрәм хөрмәтенә инде тегермәненне туктатсаң да гөнаһ булмас иде, Кузьма!» — ди.
— Анда ирсез Мәтрүк бодай тарта. Ике капчык бодае күптән ята ие. Бик ялынып сорады. Әйдә, ялгыз катын, тартсын,— ди Көҗмә дәдәй.— Начармыни, тегермән дә тарта, бәйрәм дә итәбез! Әйдә, син дә табынга утыр. Син нык хөрмәтле кеше! Син җир сөрмәсәң, башкалар ана иген чәчмәсә, без дә тегермән тарта алмас иек, дип, Көҗмә дәдәй Нуриман абзыйны табынга кыстый башлады.
— Мин инде бәйрәм итеп кайтып киләм. Мине бүген җыелышта бик зурладылар: ике кызым белән карчыгыма күлмәклек ситса, улым белән икебезгә чалбарлык полсукно бүләк иттеләр,— дип, Нуриман абзый култык астына кыстырган төргәген күрсәтте. — Әле иптәш тракторчым Җәпримнәргә кергән идек. Әйдә, тракторга гына димәгән, үзебезнең дә карбюраторга бераз горючий салыйк әле диде дә, салдык әле, — диде.
Шулай сөйләнә-сөйләнә култык астындагын эскәмиягә куйды. Өстәл янына килеп утырды. Тегермән өе бик эссе иде. «Эссе икән!» дип туныи салды...
Фидаил абый, йөткерә башлап, сүзеннән туктады. Минем тыным кысылды, гүяки мин юк — минем урынга йөрәк кенә калган, ул гына түшәк өстендә сулкылдап тибә иде.
— Ул сезнең белән эчтеме? — дип, тикшерүче сүзне тагын кузгатып җибәрде.
— Бер генә стакан эчте.
— Шуннан?.. Озак утырдымы?

— Юк. Чишенгән яллык та утырмады. «У-у иптәшләр, сәгать ун җитеп килә ләбаса! Кайтыйм әле», — дип урыныннан кузгалды.
— Үзе генә чыгып киттеме?
— Юк. Көҗмә дәдәй белән икебез дә озата чыктык. Бик эссерткән дә иде. Алар тегермәне безнеке сыман — өе аерым, тегермәне аерым түгел. Атлы арба кереп, борылып чыгарлык амбар белән ялганган. Мин Нуриман абзыйны, шул амбар капкасыннан тышка ук чыгып озатып куйдым. Йомышым да бар иде. Көҗмә дәдәй анда ук чыкмады. «Теге катын бетерәме инде, юкмы?» дип, тегермәнгә кереп китте. Мин читкәрәк китеп йомышымны йомышладым да тиз генә кире өйгә кердем.
— Кузьма Асанбаев кайчан керде?
— Ул хәтсез торып керде. Мәтрүк түтәйнең тартып бетергәнен көтеп торган күрәсең. Кырык чөйгә запор салып, кәвесне басып ук кердем, диде.
— Йөзендә берәр төрле үзгәреш — куркып төшү я кабалану галәмәте юк идеме?
— Беленмәде андый галәмәт. Киресе булыр: күңеле бик күтәренке сыман иде. Әллә, мин әйтәм, Мәтрүк түтәй белән шаярып-мазар итеп кердеме бу?.. Аларныкын белмәссең...
— Менә сез: ишектән үк чыгып озатып куйдым, дидегез. Шунда, инде Нуриман Нуриазданов китеп баргач, берәр нәрсә шәйләмәдегезме? Кешеме?.. Сөйләшү-мазармы?..
— Юк. Ай да юк: айның беренче чиреге, сәгать унда ул да бата. Күз бәйләп сукыр тәкә уйнаган төсле. Яктыдан чыккач — бигрәк тә. Нуриман абзый дүрт-биш адым атлау белән күздән юкка чыкты... Колагыма — җырлап җибәргәндәй булды. Ләкин кәвестән аккан су шавы, таш әйләнүе барысын да күмде...
— Ә сез ник өегезгә кайтмадыгыз?..
— Минме?.. Мин — кайтмадым. Дәү әни исереп кайтканны яратмый. Шунда сәкегә ятып йоклаганмын... Ә иртә белән — бу хәбәрне ишеттем. Икебезне дә Акчурин җибәргән кешеләр уятты.
— Менә сез: исергән идем, дидегез. Ләкин күп нәрсәне шул кадәр вак, төгәл итеп сөйләдегез ки, исерек кеше болай сөйли алмас иде кебек? Ә?
— Мин бит чучкадай исермәгән идем, бөтен нәрсәне онытырга.
— Нуриазданов мануфактурасын алып чыгып киттеме?
— Алды. Моны оныта күрмим тагы дип алды.
— Ә ни өчен ул мануфактура тегермән өйалдыннан табылган.
— Тегермән өйалдыннан?.. Белмим...— Фидаил абыйның тавышы бөтенләй коелып төште.
Икесе дә тынып торды. Минем, әкрен генә торып, ишек ярыгыннан карыйсым килеп китте. Ләкин кузгалсам, берәр нәрсә шыгырдап китәр, я төшеп ватылыр төсле сизеп, тын да тартмый ята бирдем. Әни үзе чыгып киткәндә миңа торырга кушмады.
— Чирле икәнсең — ят. Ишек төбенә барып танавыңны суза күрмә. Чыгарып кына җибәрерләр. Милиция дә монда. Сорау алганда чит кеше тыңларга ярамый. Синең авыру икәнлегең өчен генә калырга рөхсәт. Без Ислам абызагаең белән этиеңне алырга бүлнискә китәбез,— дип чыгып киткән иде.
Аңа да инде байтак гомер үтте. Милиционер абый тагы кемне китереп кертер инде дип ятканда, тикшерүче абый кинәт:
— Менә бу безне таныйсызмы? — дип сорап куйды.
Мин, йөрәгем тибүдән туктап, ястыкка сеңдем. Бу сорау Фидаил абыйның да өнен алды бугай: бик озак җавап бирми торды. Ахырда бөтенләй икенче, беткән бер тавыш белән:
— Бәй, бу без... Көҗмә дәдәйнең... чучка кадый торган безе бит!..— дип әйтә алды.

Йөрәгемә без кадагандай булдылар: димәк, эти йөрәгенә без белән кадаганнар!..

— Мондый без тагы берәрсендә бармы?

— Белмим. Мәгъдән абзыйда гына булмаса...

— Нишләп Мәгъдән Мәрдәновта булырга тиеш дип уйлыйсыз?

— Көҗмә дәдәйгә аны Мәгъдән абзый ясап биргән иде.

— Алтынчы ноябрь көнне Мәгъдән Мәрдәновны кайчан күрдегез?

— Көндез күрдем. Иптәш тегермәнчем Гыйният бабай әйтте: «Бар кайт, улым. Празнигыгызны яса», диде. Өйгә кайтып күп тә үтмәгәндер, минем кайтканны күреп торгандай, Мәгъдән абзый килеп керде.

— Менә кайтканыңны күрдем әле, яхшы булды,— ди.— Тегермәндә чират күпме? Сәлимә апаң ару он бетте ди. Бер капчык булса да тартып алып кайтсаң иде дип колагымны или,— ди.

— Чират булса да бер генә капчыкны үткәреп тә бирер ием — тик бу арада гел арыш тартабыз,— дип җавап бирдем. Төрлесе бар — әремлесе, билчәнлесе. Чират торучылардан берәүнең дә әремле арыш артыннан мөшкәгә бодай саласы килми. Шулай берсен берсе тик көтәләр. Әле аның бер ишесе теләсә нинди бодай артыннан да салмый. Мәгъдән абзыйга әйттем: «Менә колхоз белән тартканны көтәбез», дидем. «Алай икән, алайса Көҗмәнең хәлен белим инде алайса», дип чыгып китте. Баргандырмы, юкмы, анысын белмим. Көҗмә дәдәй ул турыда үзе дә әйтмәде.

Тагын шактый вакыт тынып торганнан соң, тикшерүче Фидаил абыйга да:

— Менә, укып кулыгызны куегыз,— диде.

Фидаил абый салмак кына басып чыгып киткәндә, аның артыннан тикшерүче:

— Кузьма Асанбаев кэрсен!— дип кычкырып калды.

Ләкин Көҗмә дәдәй урынына кичәге милиционер абый килеп керде. Усал, каты тавыш белән:

— Кузьма Асанбаев өендә юк. Өч баш дуңгызы югалган, шуны эзли китте, диделәр.

Тикшерүче тагы да катырак тавыш белән:

— Хәзер үк берничә кеше табып, эзләргә чыгыгыз. Табу белән туры бирегә алып килегез,— дип боерды. Ул моны шундый итеп әйтте ки, күз алдына кинәт аттай гәүдәле милиционер абый бәләкәйләнеп калгандай булып килеп басты.

Ул арада өйгә Акчурин агайлар килеп керде. Тикшерүчегәме, башкагамы:

— Мәетне алып кайттылар,— диде.

Өстәл, урындыклар күчә башлады. Ике көн күренмәгән хисапчы абыйның тавышы килде. Партизан Нәмәт карт, янә башка өлкән кешеләр тавышы ишетелде. Сүзләренә, аяк тавышларына караганда, кәнсәләр ягына бер унлап кеше кергән булырга тиеш. Акчурин агай башчылык итә иде.

— Барыгыз мәетне алып керегез. Ә синең, Нигъмәтулла бабай, колашаларың-ниләрең әзерме? Үлек юасы картларың бирeдәме?..

— Барысы да әзер. Күршедә сулар да җылытып куелган.

— Яхшы алайса. Җәмәгать, кабер әзер, инде мәетне өченче төн дә яткырып булмас. Шәригатькә дә, законга да сыя торган эш түгел. Мәрхүмгә хөрмәт кирәк,— дип, Акчурин агай бик борчу белән сөйләп алды.— Менә, тикшерүче иптәш, алып кайткан кәгазе. Инде дә күмәргә рөхсәттер?

Шул сүзнең сихере тигән кебек өй эче тынып калды.

Мин инде дә ятып тора алмый идем. Юрганны атып кына бәреп, сикереп торырга иттем. Ләкин, колагым бик сак, зиһенем сау булса да, хәлем, чыннан да, юк икән: көчкә торып, салкын идәнгә бастым. Пон

оекбашым мич башында булырга тиеш иде, шуларны табып алып кидем. Күлмәгем өстемдә иде, чалбарым кайда икән дип, чөйләрне, киштәләрне караштырып торганда әни кайтып керде.

— И балакаем! Нигә тордың!— диде.

— Минем — әтине күрәсем килә!..— дидем мин.

— Әле ярамый, улым. Башта юсыннар. Әле анда кереп-чыгып йөриләр,. өзлегеп китүең бар. Ятып тор, балам. Ятып тор. Әтиеңне карарга ярагач та, мин үзем әйтермен. Юган чакны мин үзем дә синең янда гына торам.

— Мәйсәрә апалар кайда?— дидем мин.

— Гөл җиңгәңнәрдә. Алар да — югач кына кайта...

Мин бер кигән оекбашымны салмыйча гына кире урыныма менеп яттым. Әни, таң белән мич ягып, өйне бик нык итеп җылыткан иде, ләкин миңа барыбер салкын тоелды: әллә өшүдән, әллә хәл бетүдән — мин урынга яткач та байтак калтырап, дер-дер килеп яттым. Инде сорау алу өзелгәч, мине теге яктагы сүзләр кызыктырмый, мин җинаятьне үз юлым, үз хыялым белән эзли киттем. Тик, миңа калса, инде эзләп торасы да юктыр. Мәсьәлә ачык. Нигә, бер кая китмисез дигәч тә, чыгып киткән Көжмә дәдәй? Тыңлыйсы иде, нинди җавап бирер иде икән? Аның безе диде бит!.. Бәлки Фидаил абый да дөрес сөйләмәгәндер? Бәлки әтине тегермәнче өендә үк үтергәннәрдер?

Бик тавышланмыйча гына әти гәүдәсен алып керделәр. Менә өстәл өстенә салдылар шинелен. Ислам абызагайның «менә справкасы» дигән сүзе ишетелде. Шул сүзнең сихере тигән кебек, өй эче кинәт тынып калды. Мин: «Нигә тикшерүченең тавышы-тыны юк, әллә чыгып киттеме?» дип борчылып беткән идем инде, тынлык эченнән аның тавышы тишеп чыкты:

— Монда чит кеше юк, иптәшләр, мәсьәлә ачыкланды. Йөзгә йөз басып, һич көтмәгәндә, без белән китереп кадаганнар. Шундый көч белән йөрәкнең үзенә генә кадалган ки — тыгып кына алган төсле иткәннәр — мәрхүм йөрәген генә тотарга өлгергән. Артык исерек тә булмаган мәрхүм... Инде күмәргә рөхсәт, иптәшләр.

— Сорау барышы ничек соң — пәрдә чите ачылып китмәдеме?— дип сорады Акчурин агай.

— Тикшерү яңа башлана гына,— дип җавап бирде тикшерүче.

Минемчә, бу туры җавап түгел иде. Шунда минем түбәм күккә тигәндәй булды: мин Акчурин агайга да әйтергә ярамый торган серләрне беләм булып чыга! Хәтта мин белгәнне тикшерүче үзе дә белми бит!..

Бер заман өйдән болар дәррәү чыгып китте дә, башкалар керә башлады. Кемдер колаша сөйрәп керде. Әни белән Гөл җиңги көянтәләп кайнар су кертеп куйдылар. Идарә ягын тиз генә икегә бүлеп, ике карт чаршау элеп куйды. Гөл җиңги белән әни, су таманлап, Нәмәт бабайга биреп тора. Нәмәт бабай чаршау эчендәгеләргә бирә; бер кем бер сүз сөйләшмичә, тын гына әтине юа башладылар.

Комганнан койган, чәчрәп чупылдаган, колашадан өзек-өзек ялгашка аккан су тавышы минем күз алдына яңадан дә әтинең капланып, агым су эчендә яткан сурәтен яңартып җибәрде. Кабарып менгән тун эченнән, әтиемнең аркасы буйлап аккан судай салкынлык йөрәгемнән кабат өшеттереп ага башлады. Нигә болай озак юалар? Юылган бит инде аның тәннәре... Йөрәгемә төшкән салкынлыктан мин яңадан туңа башладым һәм әтинең соңгы кабат йөзен күреп калуым бизгәк тоткандагы саташулы төш кебек кенә булып китте.

Бик озак үткәннән соң, инде теге якка халык берсе керә, берсе чыга йөри башлагач, «әтиеңне күреп кал, улым» дип, әни минем өскә җылы итеп киендерде дә, җилкәмә кулын куеп, теге якка алып чыкты. Җыелып торган халык миңа юл бирде. Әтине инде кәфенгә төреп, җәймә ябып, өстәл өстенә куйганнар; ияге өскәрәк чөелеп, йөзе түшәмгә кара-

ган иде. Бәйрәм алдыннан гына чип-чиста итеп кырынган ияген, яңагын жирән төк баскан; күзе йомык. Иөрәгенә чәнечкәнгә дә, ярып, әчен актаруга да инде исе китмәгәндәй, маңгай җыерчыклары да бетеп, йөзе язылып киткән иде. Ияк очына кадәр ярып, эре генә атлатып тегелгән тегәрҗептәй калын җепне күргәч, күземә яшь тулып, әтиемнең йөзе бозылып, кыегаеп, су төбенә төшеп киткәндәй юкка чыкты.

Юк, мин кереп ятмадым. Мәетне алып чыгып киткәндә дә, мин стенага сөялеп басып тордым, елый-елый, «мин дә зиратка барам» дип карадым, ләкин әнием, зур апам мине үгетләп кире урынга яткырдылар, минем аркада зур апа, үзе дә зиратка бармыйча, минем янда утырып калды.

Әтине алып китеп, сәгатькә якын вакыт үткәч, тау өстендәге зират ягыннан өч кабат мылтык аткан тавыш ишетелде.

## 6

Мин шул ятудан, бизгәк чирем кузгалып, айдан артык урын өстеннән кузгалмадым. Тәнем тыштан кызып янса да, бөтен эчем — боз иде. Астымда ике кат түшәк, өстемдә юрган, аның өстендә әтинең сырма пальтосы, аның өстендә — толып. Ләкин янып торган мичкә ташласаң да, минем эчкә җылы төшәрлек түгел, шул кадәр кием астында туңып-бөгәрләнеп, тешкә тешне тигерә алмыйча, дерелдәп ята идем. Ул эчкән хинин даруыннан авыз эчем тулы ачы тәм. Үземне үзем белешмәстән, бу дөньядан китеп торган араларда, мин саташулы бер халәттә яшим: Кама суыдай салкын дәрьяларга төшеп, һич чыга алмыйча, ташкын эчендә агып барам да, дөньяда күрмәгән тау куышларына, әллә нинди караңгы мәгарәләргә кереп китеп югалам. Я мин, күкрәгемә атланып утырган килбәтсез җеннәрне алып ташлый алмыйча, тирләп чыгып, бастырылып ятам. Бу бәладән мине, ыңгырашуымнан белеп, әни йолып ала иде. Ул артымнан унысы ун без тотып, мине куып килүчеләр дисеңме, минем шулардан кача алмый, йөгерә алмый интегүләрем: мине бит беркем тота алмый иде, ни булган, ник йөгерә алмыйм дип әрнеп елауларым; әтинең гел, атылган йолдыз кебек, миннән еракка китеп, башы чыпчык башыдай гына калып, күздән югалулары дисеңме... Бу саташуларны сөйләп бетерерлек кенә түгел иде...

Мин тәмам ябыгып, саргаеп, декабрь урталарында гына аякка бастым. Ләкин мин әле барыбер кышкы каникулга кадәр укуга йөри алмадым. Укытучы абый, ике-өч мәртәбә өйгә килеп миңа дәресләр өйрәтеп китте, көндәлек биремне Гафият аша җибәреп торды.

Ләкин чир киткәч тә, башыма килгән беренче сорау: «Әтине үтерүче кеше тотылдымы, нишләттеләр, аттылармы?» дигән сорау булды.

Ләкин, ату түгел, әле үтерүчене дә белмәгәннәр булып чыкты. Мин моңа бик гаҗәпләндем. Ничек алай? Миңа калса көн кебек ачык иде бит инде!

Әтине күмгән көннең икенче көнендә үк Мәгъдән, Кузьма, Фидаил абыйларның өчесен дә кулга алып, район төрмәсенә илтеп япканнар. Күпме кешене кузгатып, күпме тикшерүгә карамастан, өчесенең берсе дә гаепне танымаган: «Юк, мин үтермәдем!» дип барганнар. Инде дә әйттерә алмагач, Казанга алып киткәннәр, анда да шул ук хәл дип сөйләделәр. Бу хәбәрләр, мин терелеп аякка басуга, күңелләрдән кимегән, ак финнәр белән сугыш башланып, авылның унҗиде яшьтән алып кырык яшькә җиткән ирләре агач мылтык, агач гранаталар асып, аръяк басуда муеннан кар ярып, сугыш уенына өйрәнеп йөри иде. Боларга Юматов абый башчылык итә. Алай гына түгел, атнага бер кабат ул хатын-кызларны да, нәкъ ирләрне йөрткән шикелле, шулай өйрәтеп кайтара.

Шулай мәш килеп йөргән айларның берсендә, январь ахырында, Казанның үзеннән безнең авылга өч кеше килеп төште. Нинди комиссия булгандыр ул, аны белүче юк, белсәләр дә, безгә әйтүче юк. Ләкин шунысы мәгълүм: болар безнең әтинең үтерелү сәбәпләрен тикшерергә килүчеләр иде. Аларга теге вакытны бездә сорау алган үзебезнең район тикшерүчесе дә ияргән иде. Килеп төшкән сәгатьтә үк сугыш уены уйнап йөргән агайларны зиратка менгереп җибәрделәр, һәм алар анда, милиционер күзәтүе астында әллә күпме җир көрәп, әтинең каберен эзләп таптылар да ломнар-көрәкләр белән әтинең каберен актара башладылар. Ә безнең өйдә, өр-яңадан шаһитләрне чакырып, сорау алырга керештеләр. Без, көнне чибәр җиңгиләрдә үткәреп, өйгә кунарга гына кайта идек.

Халык тәшвишкә төште. Нигә казыталар? Нигә мәетне кабереннән алалар?..

Хәбәр тиз йөри. Күңелләрне шомландырып, безнең дә колакка иреште. «Яңадан яралар икән, күзен ачтырып, күзенең кешесен карточкага төшереп алалар икән, үтергән кешенең сурәте күзенең ясмыгында торып кала икән...»—дип сөйләделәр. Ничек кала? «Әнә, кеше күзенә кара, үзеңне үзең шунда күрәсең бит»,— дип, безне бер-беребезнең күзләренә карарга куштылар. Чыннан да! Без, апалар белән алмаш-тилмәш, күзләргә керердәй булып, бер-беребезгә караштык. Апаның күз карасында энә күзеннән әз генә зур булып мин басып тора идем.

Күңелләргә өмет дулкыны йөгерде. «Берәү аркасында икәү интегеп ятмас, нахакка ябылганнары кайтыр иде, ичмасам»,— дип сөйләделәр.

Әти гәүдәсен кабат казып алуларын ишеткәч, кызганган булып, бүтәннәргә сабак итеп, ходай җәзасын искә алучылар да булмады түгел, булды. «Менә бит — үзенә кайтты бит мәрхүмнең әйткәннәре: мине үлгәч, тураклап эткә ташласыннар, миңа барыбер дигән ди бит — менә, эткә ташламасалар да, турыйлар»,— дип ачуны китерүчеләр дә бар иде.

Кышкы көн «әнә» дигәнче үтеп тә китте — каберне ул көнне ача алмадылар: январь тәкерек җиргә төшмәс дәрәҗә суык булып, җир туңы бер метрдан ашу, диделәр. Икенче көнне иртә белән, без укырга барганда, ир-ат ломнарын, көрәкләрен тотып зират тавыннан менеп баралар иде.

Дүрт дәрес бетү белән мин, кайтып та тормыйча (барыбер өйгә кертмиләр), зиратка менеп киттем. Миңа бер-беребездән һич аерылгысыз дустым Гафият тә иярде. Ә зират капкасы төбеннән киң табанлы, үрәчәле чана борылып киткән. Ә зират эчендә карга билдән чумган кеше эзләре генә иде. Без шул эздән эчкә кердек. Безнең зиратта бер кәкре нарат, берничә сәрви куагыннан гайре бер нинди агач заты юк. Бүрәнәдән бурап ясалган сирәк-мирәк чардуганнар кар өстеннән күренеп тора иде.

Без, кешеләр ярган эздән туң каберләрне таптап, әти кабере янына килдек. Куркып кына кабер читенә килеп бастык — упкындай ачык кабер авызыннан җылы бу бәрелгәндәй булды. Кабер дә буш. Тирә-як дөньясы да буш. Яп-якты салкын кояш, төшлегеннән төшеп, баешына бара иде, без басып торган зират өстендә кар себертеп, салкын җил генә уйный иде. Ул инде кабер читенә кар сара һәм инде әз генә тутенли башлаган иде.

Без, артка борылып карарга да шикләнеп, зираттан чыктык та авылның хәлсез тын урамына төштек.

Мин әти гәүдәсен больницадан кире алып кайтуларын үз күзем белән күрергә теләп, соңгы өйдә ут алганчы, урам таптап йөрсәм дә, больницадан кайтучы булмады. Инде өметемне өзгәч кенә, берничә тапкыр Гафиятләргә кереп җылынып чыгуыма карамастан, өшеп-туңып чибәр җиңгиләргә кайтып кердем. Үзебезнең өйдә сорау алу бетмәгән иде әле,

Җиңгиләрнең өйләре җылы, тәрәзәләренә хәтле эрү иде, мин дә аш ашагач, майдай эреп кенә киткәнмен һәм шунда йоклап та калганмын. Апалар да, көндәгечә, җиңгиләрдә йоклаган, мин әни тавышына уянып киттем.

— Төннә белән алып кайтып күмгәннәр... Ни гөнаһлары булды икән үлгәч тә тынгы бирмәслек?..

Мин әнинең йөзенә карый алмыйча, йөрәгем әрнеп, күземне читкә алдым. Ул елап туктагач кына, яңа уянган кеше кебек, «уянып» киттем. Әни миңа этине алып кайтып күмүләре турында бер сүз дә әйтмәде. «Тордыңмы, балам» дип әйтү белән чикләнде.

Ял көне иде.

— Тикшерүчеләр китмәдеме әле?— дип сорадым мин әнидән.

— Юк әле,— диде әни күңелсез генә.— Йөриләр эт ризыгы ашап. Караңгыда кеше сурәте күзгә төшәмени? Яктыда үтергәннәр дисеңмени син аны!..

Ул боларны миңа сөйләми, төпчек абзый белән төпчек җиңгигә сөйли иде.

— Бүген дә печәнгә барылмады, кайчан китәрләр инде,— дип куйды төпчек абзый.

Ашагач, мин киенеп тә куйдым.

— Кая барасың?— диде әни.

— Тау шуарга,— дидем.

Узган кыш әти Казанга барып, миңа элмәдән ясалган сыгылмалы чын чаңгы алып кайткан иде. Шуны үзебезнең чоланнан гына кереп алдым да, ишек төбендә үк тагып, зиратка менеп киттем. Аста, авыл урамында йомшак кына уйнап очкалап йөргән кар өстә, зират тау башында котырып дулый иде. Кичәгедән бернинди эз калмаган диярлек. Эти каберен күмеп куйганнар, кантар-кантар өелеп торган кабер түбәсе кар белән тигезләнеп бара иде инде.

Көне дә, күңелем дә тау шуа торган түгел иде. Мин котырынып дулаган буранга каршы, башымны да имичә, авылга таба шуып киттем. Ул көнне башкача өйдән чыкмадым. Ике апа да һәр ялны клубта була торган вечерга бармадылар.

Казаннан килгән комиссия, шул көнне эшен бетереп, дүшәмбе көн иртә белән китеп барды.

Килеп ни яңалык ачтылар, күз кабагы ачылгандай, җинаятьнең кара пәрдәсе күтәрелеп китмәгәнме — бер кем бер ни белмәде, бу үзе төндәй караңгылыкта калды. Этине, инде кеше-кара яткач, милиционер сагы астында дүрт кеше күмгән. Икенче көнне үк: «Нуриманны күзе өчен генә кабереннән чокып алганнар икән, ике күзен дә тикшерер өчен Казанга алып киткәннәр», дигән сүз таралды. Күмүчеләр сер саклый.

— Безгә кеше ятуга әзер торырга куштылар. Үз кәфене инде череп теттелгән иде. Ап-ак җәймәгә урап кайтарганнар, нәкъ бала биләгән кебек иткәннәр. Башы-күзе чорналып беткән, йөзен ачып карар җире дә калмаган иде,— дип сөйләгәннәр.

Тик дүртнең берсе — идарә атларын караучы Имай абзый гына:

— Ләхетенә кире төшергәндә, мин баш ягында идем. Баш астын җайлаган булып, ике баш бармагым белән басып, күзен капшап карадым — күз чокыры икесе дә буш иде,— дип әйткән, диделәр.

Мондый сүзләрдән соң, тере сурәте күз өнемнән һич китмәгән этиемне кызгану соң чигенә җитте. Инде бер җәлладнең йөрәгенә без кадап җан алуы җитмәгән — врачлар суеп, камыт энәсе белән генә теккәндәй тегеп куйганнар иде, инде күзен дә чокып алганнармыни? Үлемнән дә бигрәк, менә шушылай интектерүләре йөрәкләрне яра иде. Ике апамның сәке өстендә, башларын чәнчеп куйган тезләренә салып, илереп елаулары күз алдымнан китәсе дә түгел. Толымы сүтелгән чәчләре

тез өстеннән сәке өстенә асылынып төшкән, күз яшьләре шул чәчләре буйлап ага иде...

Комиссия килүнең нәтиҗәсе шул булды: яз җитеп, көндез өй буйларында чыпчыклар су эчә башлаган көннәрнең берендә Казан төрмәсеннән тимерче Мәгъдән абзый кайтып төште. Бик бетерешкән — үгездәй муены сызып, җыерчык җыелган, киган сырмасы да бушаеп, озынаеп калган иде. Котылып кайткан диделәр. «Мәгъдән тикле Мәгъдән дә бу хәлгә калгач, сорау алганда интектерүләре хактыр»,— дип сөйләп утырдылар кәнсәләрдә. Ләкин Мәгъдән абзый үзе, мин мәктәптә, я уенда чакны гына килмәсә, колхоз идарәсенә килмәде. Сабаннарга, тырмаларга ремонт көне җитеп, Акчурин агайның, яңа тимерчедән уңмыйча Мәгъдән абзыйны көн саен искә алып, янып йөргән чагы иде — Мәгъдән абзыйның бөтенләйгә котылып кайтуына сөенеп бетә алмады. Мәгъдән агай үзе дә, тимерлеген сагынып кайткан төсле, икенче көнне үк алачыгына килде. Без карарга бардык. Өстенә шул ук киемнәрен киеп алган: сырган сырма, сырган чалбар, ике кат олтанлы киез итек; майга, корымга буялып беткән, чәчрәп очкын тишкәләгән брезент алъяпкычын бәйләп куйган. Эшләгәндә гомер елмаймаган Мәгъдән абзый, ачык ишек авызында безне күргәч, бер елмаеп куйды. Күзләре бик азга гына миңа тукталып торды. Гел ут, ялкын, төтен эчендә эшләү сәбәпле, элек гел кызарып йөргән күзләре чистарып калган; гел шешенеп торган күз төпләре, күз кабаклары, шеше кайтып, үз урынына төшкән. Чын — шул күзләре аркасында бөтенләй икенче кеше булган иде Мәгъдән абзый!..

Гөжләп күрек өреп торган утлы күмер эчендә, инде алсу утка әйләнеп, сабан төрәне ята; Мәгъдән агай маңгаенда торган, чите каплаулы күзлеген күзенә төшерде дә, ике куллап кыса торган озын, гайрәтле кыскычы белән мичтәге кызыл утка әйләнгән тимерне кыстырып алды да, безгә борылып:

— Китегез! Күзегезгә ут чәчрәмәсен! — диде.

Ул кып-кызыл утка әйләнгән зур бер тимерне сандал өстенә күтәреп салганда, без читкә сибелгән идек инде.

Бераз киткәч, колакка тигез ара белән бер зур чүкеч, бер бәләкәй чүкеч суккан ямьле авазны ишетеп алдым. Шуңа кушылгандай, өй кыекларыннан тыпылдап тамчы тама иде.

Мәгъдән абзыйның, кайтып, икенче көнне үк шулай сагынып эшенә тотынуы бар кешенең күңелен йомшартып җибәрде. Аны барысы да кызганып сөйләделәр. Ләкин ничә ай ябылып торганда ни күргәннәрен үзе берәүгә дә сөйләми диделәр.

Чәчүгә төшәр алдыннан, кичке нәрәттән соң, Акчурин агай, кешеләр китеп беткәч, кәнсәләр ягыннан безнең якка керде.

— Менә, Мәдхиҗамал апа, иртәгә без сездән күченә башлыйбыз. Яңа идарә бинабыз әзер. Кыш өстендә мич чыгарасы килмәүдән генә күченми тордык, үзең беләсең. Инде чәчүгә төшкәнче күченеп бетү кирәк: аннан күченү кайгысы булмас. Рәхмәт инде сезгә...

Әни шатланмады, күңелсез генә әйтте:

— Алайса бөтенләй ятим калабыз икән. Әле кәнсәләр барда иртәдән кичкә хәтле кеше арасында булгач, ялгыз-ятимлекне ул кадәр тоймыйдыр идек, — диде.

— Анысы шулайдыр, Мәдхиҗамал апа. Ләкин барыбер күчәргә туры килә.

— Әллә безнең белән бер чәй эчеп китәсеңме, Солтан энем, — дип, әни аны чәйгә кыстап алды.

— Чәйләр эчеп тормыйм инде, Мәдхиҗамал апа. Хатын мунча ягып көтеп торадыр. Чәчүгә төшкәнче кереп калырга кирәк, аннан тиз генә кереп тә булмас.

— Кара, утырмадың да ичмаса, — диде әни.

— Утырып та тормыйм. Минем бит сезгә әйтәсе сүзем — күчеңү түгел иде. Кичә районда әйттеләр; дөрес булса, Кузьма дәдәй белән Фидаил үзләренең гаепләрен таныганнар: «без үтердек» дип әйткәннәр, имеш...

— И ходаем!.. — дип, әни сәке йөзлегенә лап итеп утырды.

— Һич аңламыйм, башыма да сыймый — ничә айлар буе нигә баш тартып килгәннәрдер... — дип, Акчурин агай саубуллашып чыгып китте. Әни, сәке йөзлегеннән кыймылдамыйча, бик озак утырды.

Бу хәбәр безнең беребезне дә шатландырмады. Киресенчә — әллә Мәгъдән абзыйның нинди булып кайтуын күргәнгәме — күңелгә тагын бер көенеч кенә ягылды.

Пароход төшү белән Кузьма дәдәйнең хатыны Казанга китте. Ләкин ирен дә, Фидаил абыйны да күрә алмаган: «Новосибирскига җибәрделәр дип әйттеләр», дип, ничә елга хөкем ителгәннәрен дә, суд булганмы-булмаганмы икәнен дә белә алмый кайтып төште.

Дөньяда бер кеме калмаган, карап торган бердәнбер онығы — Фидаил абыйның мондый хәлләргә төшүен күтәрә алмаган Бәлхис әбиебез, кыш буена сыза-сыза килеп, май башында гүр иясе булды. Аны әти каберенә якын гына җиргә күмеп тә куйдылар.

Әлбәттә, безнең башка ишелеп төшкән бу олы кайгыны авылыбызда төрле кеше төрлечә кичерде. Беләм, әтинең үлемен дә, безнең ятимлекне дә күп кеше үз кайгысыдай итеп кайгырып үткәрде. Мин моны кешеләрнең безгә карашыннан, базарларга баргач, бер дә белмәгән-күрмәгән кешеләрнең: «Нуриман малае шушымыни инде?» — дип, башларымнан, аркаларымнан сыйпап-сөеп китүләреннән сизеп-күреп йөрдем.

Ләкин, сөенеп әйтелгән сүз булмаса да, җәрәхәтле күңелләргә тоз сипкән усал сүзләрне дә байтак ишетергә туры килде. Дин тоткан картлар түгел, әдин түгел, тәһәраткә комган да тотмаган җиңгиләр зәһәрләрен безнең якка җибәрә торалар иде:

— Мәчет манарасы кискән кешенең әйбәт яшәвен күргәнебез дә, ишеткәнебез дә юк. Әнә берсен тураkладылар, берсе төрмәдә чери...

— Коммунистның да юньләсе манара кисми... — дип, этигә төрттереп әйткән сүзләре минем йөрәккә генә килеп кадала иде.

Шундый күңел җәрәхәте белән без җәйгә кердек. Мин дүртенче классны бетереп, мактау грамотасы алдым. Аны миңа Юматов абый, мине идарәгә чакырып, Акчурин агайлар алдында үз куллары белән тоттырды.

## 7

Тузан бөртеге дә очмаган күк йөзенә җете кояш балкып менгән бер көн иде. Болыннарның күпереп үскән, игеннәрнең буйга сикергән, җирнең тын алганы да ишетелеп торган тын, тыныч, якты көннәр иде. Буа буйларында бәбкә үләне өстендә чалбар төпләребез яшелгә буялганчы пәкеле уйнап, биш ташлы уйнап; күбебез көзен күрше авылга — бишенчегә, кайберебез русчага — кабат дүртенчегә кереп укырга җыенган, план корган чаклар иде.

Колакка дәһшәтле бер сүз килеп ишетелде.

«Сугыш чыккан!..»

«Герман сугыш башлаган!..»

Сугыш... сугыш... сугыш...

Моңа тикле сугышларны ишетеп, укып кына үскән, «Чапай» киносында гына күргән без — малайлар өчен сугыш кызык, мавыктыргыч уен, аның да чыны — атлысы — кылычлысы. «Нигә без үскәнче чыкмый тормады икән?» — дип үкенеп сөйләшүләр. «Нигә без сугыш чыккан җирдә түгел икән? Сугышканнарын читтән генә булса да карап торыр

идек!..» — Ун-унбер яшьлек малайлар хыялында сугышның җиңеллеге сурәтләнә иде.

Ләкин нигә елап озата ирләрне апалар, җиңгиләр, аналар? Безнең җитмеш тугыз гына өйлек авылдан да бер көнне кырык өч кеше китте! Халык, якшәмбе базарына баргандагыдай, пристаньгә иярә барды. Кешеләр киткән буш өй тәрәзәләре генә авылда елап калды. Безнең өйдән китәр кеше юк: әни дә ике апа гына. Мин укытучыбыз Юматов абыйны озатырга булдым. Аның бер кеме юк — әниләре еракта, Казан артында, дип сөйләгәне бар. Сугыш чыгасын белгән кебек, армиядән кайткач та, ике ел буе шинелен салмаган Юматов абый! Безгә үзе күргән барлык киноларын сөйләгән, композитор дигән кешеләр чыгарган көйләр өйрәткән, үзе тальян уйнаган Юматов абый!..

Ләкин каерып ачылган басу капкасын чыгып, ап-ак каүсәләре күзне камаштырган каен урманына җиткәч, әллә кайдан гына зур апам килеп чыкты. Тез астына җитә язган кыска итәкле, кыска җиңле, нәзек билле зәңгәрсу күлмәген кигән: муенына иңбашларын каплап торган зур челтәр яка куеп, аны алдан коңгыздай зур брошка белән каптырып куйган. Мине күргәч, кызарып чыкты.

— Бәй, син нишләп монда, Даниал? — диде апа.

— Мине озата! — диде Юматов абый, елмаеп, апага карады.

Апа тагын кызарды.

— Бар кайт инде, үскәнем. Әни югалтып торыр, — диде апа.

Мин киреләнеп башымны түбән идем.

— Әйдә барсын, — диде Юматов абый.

Мин башымны күтәреп аңа карадым. Юматов абый әз генә шадра, ләкин матур йөзе белән елмаеп апага карап тора иде. Апа оялып кына Юматов абый янәшәсеннән атлый башлады, алар әкрен-әкрен генә артка калдылар. Ә мин алга — ике абыйсын берьюлы озаткан дустым Гафият янына йөгердем.

Шулай озаттык без сугышка беренче китүчеләрне.

Июньнең егерме тугызында, башка елдан бер атнага соңлап, болынга чыктык. Башка елдагы ирләр, егетләр урынына чалгыны илле яшьтән өлкән бабайлар белән бергә егерме-утыз яшьлек апалар тотты. Башка елны чүмәләне дә, ат менеп, уйнап кына, унбиш-уналты яшьлек егетләр тарттыра иде. Анысы безгә күчте.

Болыннан кайтып уракка төштек. Башка елларны ургыч машинага җигелгән ат башында җырлап, сызгырып кына унбиш-уналты яшьлек егетләр йөри иде — ул егетләр ирләр эшенә күчеп, очтагы атлар безгә калды. Моңа кадәр алты атлы суккыч машинада унбиш-уналты яшьлек егетләр ат куа иде, алар авыр көлтә ташу, кибән кую эшенә күчеп, көн буе түгәрәктә әйләнеп йөреп ат куулар безгә торып калды.

Печәнне бетереп, уракка төшәргә әзерләнеп яткан бер вакытта безнең авылга, Ленинградтан эвакуацияләнеп, сигез гаилә килеп төште. Аларны Акчурин абый урынына калган Рамазан бабай белән күрше авылның аттай гәүдәле Палак түтәй — авыл Советының яңа председателе — урнаштырып йөрде. Иң зур гаиләлесен безнең өйгә — колхоз идарәсе чыгып киткәч һаман буш диярлек торган якка урнаштырдылар.

Бик карт бабай белән әби, безнең әнидән яшьрәк апа һәм аның өч кызы. Бишесенең берсе дә безнең дөнья кешесе кебек түгел иде. Бабайның башында беретка, әби төзәнеп, чәчләрен чигәсеннән баскыч-баскыч китереп, каптыргычлар каптырып куйган; аягында безнең әбиләр гомердә кимәгән үкчәле туфли; кызларының да өстендә — авыл кызлары гомер хыялланмаган күлмәктер, кофтадыр — гел курчакка кидергән кебек. Алар яшел чирәм өстендә тәгәрәп уйнаган, пычранып-караеп беткән штансыз бәләкәй малайларга исләре китеп карап торалар. Алар өчен чүмәлә төбендә кабык арбада чүпрәк имезлек имеп яткан бишек баласы — сыер, сарык, кәҗә, үрдәк, күркә, каз шикелле үк сәер, ят иде.

Алар безгә, без аларга ятсынып карап торабыз, сөйләшергә тел юк: алар татарча, без русча бер авыз сүз белмибез.

Ләкин безнең халык аларга үз түрен бирде. Күршеләребез төрлесе төрле яктан маен, күкәен, сөтен кертә башлады. Иң башта бала-чага әбине яратты: ул җыелып, авыз ачып торган ыбыр-чыбырга каз тешедәй тигез тешләре белән елмайды да башта өске тешләрен, аннары аскысын казнасы белән суырып алды. Бала-чага «аһ» итте. Аннары әби тешләрен кире үз оясына куйды да тагын елмайды. Шунда гына бала-чага көлеп җибәрде.

Эшли алганнары, урнашып, әзрәк үзләшү белән, кырга эшкә чыга башлады. Берсе дә урак тота белми, шулай да аларны көлтә биреп торырга, көшел өяргә куштылар. Киеп килгән үкчәле туфлиләр белән ындыр табагында көлтә биреп тә, көшел өеп тә булмый иде, аларны чабата кияргә өйрәттеләр. Безнекеләр ни әйтсә дә, алар елмаеп баш кага, безнекеләр дә нәкъ шулай итә иде.

Безнең әни үзебездәге апага бик озак иттереп чабата кияргә өйрәтте, ләкин апабыз барыбер йон оекбашны ялан аягына кия алмады, «айайай» дип аягыннан тиз генә салып ата иде. Чәнчә, кытыклый шул ул йон оекбаш!

Ләкин безнең апа укытучы булып чыкты. Сентябрь керү белән, ике авылга Ленинградтан килгән унбиш баланы туплап, укыта башлады. Болар — беренчедән алып дүртенчегә кадәрле балалар иде. Аннан өлкәннәр безгә дүрт чакрымлы МТСлы рус авылына йөреп укыдылар.

Мин дә русча укырга тотындым. Без авылдан Гафият белән икәү генә идек. Татарча бишенчедә укыйсы урынга кире дүртенчегә төшеп утырдык. Әтиемнең бик күп рус сүзе өйрәтүе дә, һәм шуларны хәзер кинәт кенә искә төшерә баруым, шуның өстенә көн саен Валентина апаның мине өйдә укытуы, аның кызлары белән бер кызарып, бер агарып, русча сөйләшергә тырышуым бушка китмәде. Мин русчаны бик тиз эләктереп алдым. Дүртенчегә рус мәктәбенә кергән алты баланың дүртесе бер-ике айдан янә дә татар мәктәбенә барып керделәр, ә без Гафият белән укып киттек.

Көз көне сугыштан беренче кеше — Мәгъдән абзыйның зур улы яраланып кайтты. Ул сугышка хәрби хезмәт иткән җиреннән киткән. Аягы яраланып, тездән бөкләнгән килеш гипска катырганнар. Өеннән бигрәк, ире фин сугышында һәлак булган ике балалы Фәгыйлә апаларда яшәде дә, бер айдан артык вакыт торып, кире китте. Фәгыйлә апаның аны без укыган рус авылына кадәр озатып, кочаклап елап калуын үзем күрдем. Яңа елда инде аның да һәлак булды дигән хәбәре килде.

Кырык беренче елның соңгы ае, җиргә төкерек төшмәс салкын декабрь керде. Бу декабрь кырык икенче елның кырлач суыгына ялганып китте. Сугышка кадәр җилле атлар, җилле ирләр барында колхоз малларына гына түгел, үзләренә дә печәнне һәркем ат белән кайтарып кына аудара торган иде. Ирләр генә түгел, атлар да сугышка китте. Калганнары җиде чакрым болыннан үзләренә көчкә ташып өлгертә. Бәләкәй чанага апалар җигелде. Минем бер кыш сугыш уены уйнап йөргән зур апам беренче көнне үк ат белән ирләр эшенә тотынды. Ул печәнне бер караңгыдан икенче караңгыга тикле, унбиш-уналты яшьлек малайлар белән бергә, ат белән ташый. Әни белән кече апа, башкалар кебек үк, зуррак бәләкәй чана ясатып алдылар. Бер караңгыдан икенче караңгыга алар шуның белән печән ташыйлар.

Сугышка кадәр җилле атлар, җилле ирләр барда урманны да ерактан кисеп кайтаралар иде. Хәзер үзебезнең Кама буендагы болыннан тал чыбыгы ташый башладылар. Ләкин ул да коткармады: чи чагында сызып кына битә, киптерсәң — күкерт ялкынын гына күреп каласың.

...Кырык икенче елның зәмһәрир кышында, кырлач ае чыгып, көннәр бераз сындыргач, бер көтмәгәндә-уйламаганда, аны уйларга кайгысын-

да да булмаганда, инде аны беткәнгә санаганда, бер аягын тездән югары өздереп, Фидаил агай кайтып төште. Үлгән кеше әгәр, ләхетен кутәреп килеп чыкса да, кеше бу кадәр шаккатмас иде. Барысы шаккатты.

Күздән каралмаган, күздән кар басып киткән өенә керә алмады. Чыбык очы агай-энесендә атна-ун көн торгач, үзебезнең тегермән өенә күчте. Оста юклыктан гына тегермән тарттырып йөргән Әхмәтдин абзый үз өенә кайтып кунып йөри иде, тегермән өендә шул тегермән тартырга килгән кешеләр җылынып кына чыгып йөриләр иде. Шул өйне колхоз Фидаил абзыйга бирде, бер йөк утын кайтартты. Инде чират торып ашлык тарттыручылар бетсә дә, тегермән тарта иде әле, күп кешенең сугышка кадәрге байлыгы бетмәгән иде. Тегермән түбән очта, хәтта авылдан байтак читтә иде. Фидаил абзый кайтып, шунда тора башлагач, бала-чага ул якка тау шуарга йөрми башлады. «Кеше үтергән» тамгасы әле бик тирәнгә киткән иде.

Ләкин Фидаил абзый һәркем белән ягымлы елмаеп, гаеплемен дигән кебегрәк итеп, күрешеп китә, сөйләшеп торганда, кеше китмичә, беренче булып үзе китәргә кыенсына иде. Ләкин тора-бара алар йорты балачаганың иң яраткан бер урынына әйләнде. Фидаил абзый иркенләп, тәмләп сугыш турында сөйли; яраланса да, немецларны үзе күрми кайткан Газдали абый кебек түгел, бу немецларның агын да, сарысын да күргән; күзгә-күз чекрәешеп немец солдатын чәнечкән, әүмәкләшкән, кылдай каты чәчләреннән йолкып, бугазларыннан ике яктан бармак батырып, кәҗә кебек акыртып, ничә немецны үтергәнен сөйли иде.

Кышкы сайлау җыелышында әзрәк кызмача Баһау карт Рамазан бабайга: «Нигә ул кеше үтерүчене кадерләп җылы тегермән өендә тотасыз?» — дип, бик ямьсез итеп кадалып караган иде дә, авыл Советы — инде шактый усалланып килгән Барбара түти, аяк өсте басып, шашкан телне кисте:

— Аның бөтен документлары тәртиптә, иптәшләр. Гаебе хөкем карары белән расланмаган. Гаебе булса да, ул инде аны үз каны белән аклаган булыр иде. Батырларча сугышып, үлем аны түгел, ә үлемне ул җиңеп кайткан кеше, — диде. Бик сабыр тавыш белән әйтте. Бер Баһау картка гына түгел, башкаларга да үткәзеп әйтте. — Ул җинаятьтә гаепләнгән Кузьма дәдәйнең дә хәле шундый ук дип әйтергә кирәк. Ләкин Кузьма дәдәй инде мәрхүм. Аны да фронтның иң утлы авызына илтеп тыгалар. Аның хакында да безгә хат килде...

Җыелыш халкына бик нык уйлап әйтелгән бу сүзләр минем бу хакта инде уйламыйча, басыла төшкән миемне яңадан кузгатып җибәрделәр. Һәр сүзе зиһенемә ярылып төшкән сорау алу вакыйгасы, минә кичә төнлә, бүген иртә генә булган кебек, терелеп, җанланып, каршыма килеп басты. Тикшерүченең каты тавыш белән сораулары. Аңа Мәгъдән абзыйның, Фидаил абзыйның биргән җаваплары. Кузьма дәдәй ничек җавап биргәндер — анысын белмим. Ләкин тегеләрнең һәр сүзе хәтеремдә. Фидаил абыйның гаепле булуына мин ул вакытта ук ышанып бетмәдем. Баһау картның тимерче Мәгъдән абзый турында сөйләве, өйләреннән чыккач, кайсы таба китүен шикле генә әйтеп куюы... Инде Мәгъдән абзый да юк — фронтка китте дә, хаты килгәнче үлем кәгазе килде... Әтине иң соңгы күрүче бердәнбер кеше — Фидаил абый исән. Кузьма дәдәй белән аны икесен дә штрафной батальонга җибәргәннәр. Кузьма дәдәй керү белән киселгән, һәм минә меңгә бер бәхетле кеше — Фидаил абый кайтты. Ләкин бөтен кеше түгел, ярты кеше. Җәйгә чыгып өен дә рәтләмәде, тегермән өендә яши бирде. Өйләнмәде дә. «Ятимнәр болай да күп, минем дә ятим арттырасым килми», дип әйткән дип сөйләделәр. Дөрес, солдатка Фәгыйлә апаның, Фидаил абый хәлен белеп, ашарларына илтеп кайтып йөргәнлеген авылның бала-чагасына кадәр белә иде. Ләкин беркем аны гаеп санамады, бигрәк тә Фидаил абыйның гаебе санап сөйләмәде. Июньдә буа буган апалар да, Фәгыйлә апа җаен

табып, тегермәндә калганда да: «Җаны барның тыны бар»,— дип куялар иде.

Кырык өченче елга кергәндә Фидаил абыйның хәле начарайды. Ул яралары өстенә куксәүгә әйләнеп, кәкшәеп, әкрен генә сыза барды, сыза барды. Бер йөткерә башласа, тартышып бетеп, маңгаендагы кан тамырлары бүртеп чыкканчы йөткерә иде. Шулай да ул тегермәнен ташламады: эше аз, элеккечә көн-төн тартасы түгел, күпчелектә колхозга фураж тарта иде. Кырык өченче елның башы — кышкы каникул иде. Мин хезмәт көненә тигән бер пот арышны күтәреп, тегермәнгә киттем. Фидаил абый минем өчен генә тегермәнне җибәреп, вак тартырга көйләп куйды да:

—Әйдә, энем, монда катып-туңып торма, өйгә кер, — дип, мине үзе яшәгән тегермән өенә алып керде.

Өй эче шып-шыр — чүпрәк-чапрактан, савыт-сабадан бер нәрсә юк. Эскәтерсез өстәл өстендә тышы янып-корымланып беткән котелок, бер читтәрәк алюмин кружка тора. Мичкә терәтеп стена буена сугылган сәке өстендә — җыелмаган урын, юрган урынына — сары кайры толып ята иде. Чөйгә эленгән бердәнбер кием — сугыштан киеп кайткан шинеле иде. Мәгәр өйгә кот биргән бер нәрсә — аның майдай җылылыгы иде.

Үзе үз сәкесенә барып утырды да, култык таягын мичкә сөяп куйгач, миңа каршы яктан урын күрсәтте. Монысы килгән-киткән ятып торыр өчен ясалган сәке иде.

— Утырып җибәр, энем. Җылын.

— Утырып тормыйм ла мин, — дисәм дә, шундук утырдым да.

Фидаил абый бик озак түбән карап, башын иеп утырды. Аннары:

— Даниал энем, — дип, гаепле генә елмаеп миңа карады. — Безнең синең белән бер дә сөйләшеп утырган юк бит әле. Элек син яшь идең. Хәзер — мондый хәл килеп чыкты... Мин фронттан кайтканнан бирле гел сезгә керергә йөрдем. Җиңги белән, сезнең белән сөйләшергә йөрдем. Тик — булдыра алмадым. Исеменә бер тап төшкәч — булмый икән ул. Син инде бала булырга тиеш булсаң да — бала түгел. Хәзер сезнең яшьтәгеләрнең берсе дә бала түгел. Без үскәндәге шикелле, унҗиде яшькә җиткәнче лапталы уйнап йөрергә туры килмәячәк сезгә... Минем синең хәтереңдә һич кенә дә әтиеңне үтерүче кеше булып каласым килми. Мин нахактан әләктем. Нахактан кыйналдым. Фронт кына миңа ирек бирде. Шуңа мин фашистның бугазын чәйнәдем дә. Хәер, болары сиңа кызык түгел... Инде дөреслекнең бер калкып чыгуына да, гаделлек җиңәсенә дә ышанмыйм, хәтта мин әйткән сүзгә синең ышанырыңа да ышанмыйм. Мәгәр — әйтәм: Нуриман абзыйны мин үтермәдем, энем. Башым нахактан бетте. Их, дөнья! Мин болай идеммени?!. Минем урында рус кешесе булса, иртәгә бәйрәм итәр иде: алар бит туган көнне дә бәйрәм итәләр... Ә иртәгә миңа утыз яшь тула...

Ул шулай дип, уй тулы күзе белән миңа карап торды һәм башкача сүз катмады.

Ә икенче көнне Фидаил абый, йөрәгенә без кадап, үзен-үзе үтергән иде.

Кулының көченә бик ышанып җитмәгәнме, — башта, басып торганда йөрәк тигезлегендә генә итеп, стена бүрәнәсен бораулап, безнең очын үзенә каратып, сабы белән шунда тыгып куйган — күкрәге белән шуңа ташланган булса кирәк. Ап-айнык баш белән шулай эшләгән.

Көн саен фронттан кара кәгазь алып торган кайгылы халык бу кайгыны да үзенеке итте. Тик борыны яньчек Баһау гына (бала-чагага кадәр аны «абзый» дими иде) ач яңаклы усал йөзе белән мәет өстенә акыргандай әйтте:

— Әнә, мин үткән кыш җыелышта: кеше үтерүчене нигә яклыйсыз, дигәч, теге селсәвит Варвара бер дә харап яратмаган иде. Сугышта үзен-үзе аклаган, имеш. Минем Газдалием гаепсез килеш тә сугышта

үлде. Кем сугышмый хәзер? Ә бу үз гөнаһын күтәрә алмаган. Шул сәбәп үзенә кул салган. Үзен дә Нуриман мәрхүмне үтергәнчә үтергән. Безе дә шундый ук бит, ә!.. — дип җыелган халыкны шаккатырды.

Баһау картның зәһәреннән куркып, яклаучысыз ятим апалар йөрәкләрне суырган кызгану эчендә тел шартлатып, ияк кагып, тик тора.

Бу хәл эти үлеменә бер нинди дә ачыклык кертмәде. Киресенчә, төшсә тиз күтәрелми торган кышкы томандай, җирне-күкне бер итеп, каплады да куйды. Иң якындагы маяк та күренмәс булды. Кырык өченче ел башында инде кырыктан узган абзыйларны да фронтка алып киттеләр. Әтинең энесе — моңарчы безгә терәк булып торган шәкерт абзыкайны да алдылар. Болары — туры Сталинградка. Шәкерт абзыкай киткәч, кызы Фәүзия туды. Барып житкәч, хат язгандыр инде ул, ләкин хаты килмәде — хат урынына «батырларча һәлак булды» дигән кәгазе генә килде.

Тагын да өлкәнрәк ирләр хезмәт армиясенә алынып, Свердловск заводларында корал коялар иде. Авылда шул я бик яшьләр, я бик картлар торып калды. Баһау карт — яше белән берсенә дә эләкмәде.

— Баһауның бүресе улый!.. — диләр иде кешеләр.

Ул җәен һаман көтү көтә, ә кышын куян, бүре аулый иде. Көтүдән һәр җәй өч-дүрт сарык «кайтмый кала». Һәм һәр вакыт өендә үсмер егет заты, бабай заты булмаган җиңгиләрнең, апаларның соңгы сарыклары «кайтмый» иде. Безнең авылдан ерак түгел дәүләт урманында качкылар яшәвен дә халыкка бик куркыныч итеп Баһау карт сөйли, хатыны сөйли, минем белән бергә укыган малае сөйли. Чөнки ул да гәүдәгә бик таза-буйчан булып, шул качкылы урман авызларыннан икешәр-өчәр куян асып кайта иде. Югалган сарык һәр вакыт шул качкыларга сылтана иде. Әмма Баһау картлар турыннан нича үтсәң дә, борыннарны ярып, төтен белән бергә ит исе агылып чыга. Баһау картның ике баш бармагы, тире туный-туный, кире якка дугаланып бөгелеп тора иде.

Алар итне гел төнлә белән генә пешерәләр. Казанда ит пешкәндә ут алып тормыйлар. Кышкы төннәрдә өй турыларыннан үтсәң, караңгы өйдә, түң тәрәзә пыяласында шәүләләнеп, учактан төшкән ут уйный; соңрак үзләре сизенепме, берәрсе әйтепме, урам ягы ике тәрәзәне дә томалап куя башладылар. Ләкин ашыйсыларны китереп борын эчен кытыклаган ит исен томалап куеп булмый бит!

Кырык дүртенче елның язында май башында ук безне — алтынчыҗиденче класста укучы тазарак малайларны — укудан азат итеп, сабанга куштылар. Без, Гафият белән икәү, татарча дүртенчене бетереп, русча дүртенчегә барып кергәнлектән, татарча укучы яшьтәшләрдән бер класс артта бара идек. Шуңа күрә дүртенчегә кадәр бер класста укыган иптәшләребез, шул җөмләдән Бәздәви дә, инде җиденчене бетереп чыгып, колхоз эшенә җигелделәр. Бәздәви әтисе урынына көтүгә чыкты, ә әтисе Баһау картны безнең өстән бригадир итеп куйдылар.

Без кояш чыгып кына килгән салкын иртә белән, иңбашларга йөгән, камчы салып, һәркем үз өеннән чыккан малайлар, һәркем аерым-аерым, атлар тибендә йөргән ерак такыр басуга юнәләбез. Басу юлында очрашып, бергә барсак та, такыр басуга җиткәч, һәркем үз атларын эзләп, аерылышып китәбез. Ләкин атлар төн эчендә тышаулы булсалар да, бик еракка китәләр — минем ат берәүгә дә баш бирми торган, тибешә торган җирән бия иде. Ике көннең берендә тышавын өзеп, дәүләт урманына китә иде. Ул такыр басудан ике-өч чакрым җирдә иде.

Куе томан төшкән бер таң иде. Атка барып төртелмичә танып та булмый. Басуның бер башыннан икенче башына, бер аттан икенче ат янына чабып йөреп тә, җирән бияне таба алмагач, сабанда буразнадан йөргән туры алашаны менеп, җиденче басу читеннән урманга таба юыртып киттем. Урман авызына җиткәч, чирәмле иңкүлеккә төшеп

мендем. Тирәнкүл дип аталган, озынлыгы биш-алты чакрымга җиткән чокыр менә шушыннан башланып, безнең авыл башына барып чыга иде. Безнең авыл көтүе урак җиткәнгә кадәр шул Тирәнкүлнең чишмәле, үләнле битләүләрендә йөри дә, игеннәр җыелгач, басуга менә иде.

Җирән биям анда булмагач, мин урман буйлап ары киттем. Атны алай да таба алмагач, үртәлүемнән елар чиккә җитеп, урман эченә барып кердем. Агачларга томан уралган; мин бераз барам да, атымны туктатып, тирә-якка колак салам: ат пошкырмыймы, я булмаса тавыш килмиме, дим. Ара-тирә алашам колагын шомрайтып ала: андый чакта, тәннәремне кымырҗытып, йөрәккә шом төшә иде. Бу — урманның башы гына. Кайда беткәнен без — малайлар белмибез дә. Ләкин элек-электән анда качкылар яши дип сөйлиләр. Урманның исеме дә күңелләрне шигәйтә торган: Качкын урманы дип атала. Үткән-сүткән казыкка гына кисеп алмаса, бер агачын да кистермиләр, шуңа күрә, юл өсте дә булмагач, безнең халык монда йөрми; майда миллек сындырырга гына киләләр, анда да ялгыз түгел — күмәкләп йөриләр.

Ләкин без кичә, мин сабаннан кайткач, җиде кеше тәмам караңгы төшкәнче бу якларны актарып чыктык, әллә нинди аланнарга барып чыктык, ләкин чибәр җиңгиләрнең көтүдән «кайтмый калган» сыерын таба алмадык. Олысына ун яшь, кечесенә бер яшь — дүрт бала белән калган чибәр җиңги канлы күз яшьләрен түгеп елады инде! Бүген инде күрше авыл көтүләреннән эзләргә чыгачаклар иде. Кояш чыккан иде инде, ләкин урман эченә төшмәгән иде әле.

Шунда кинәт атым өркеп китеп, бер читкә сикерде — атның җай гына атлавына көйләнгән гәүдәм моны көтмәгән иде — мин җиргә егылып төштем, ләкин тезгенне кулдан җибәрмәдем. Ат өреккән җирдән күмеләп бетмәгән сыер койрыгы чыгып тора иде. Мин ялт итеп як-ягыма карап алдым — күз күргән кадәр җирдә беркем юк иде. Котым очып, куркудан, мин атка атлана алмый интектем, ахырда мин агач ботагына басып кына атлана алдым. Инде күземә ак-кара күренмичә, ботакларга сыдырылып бетеп, кепкаларым төшеп калып, урман читенә килеп чыктым. Ни күрим — утыз-кырык адымнар гына җирдә җирән биям басып тора. Атымны шул якка бордым.

Тышаулы килеш тә, баласытып, миңа башын бирмичә, гел тибәргә торган бияне мин хәзер тышаусыз килеш, тиз генә йөгәнли алмаячак идем. Хәтта, җиңел тоттырганда да, мин хәзер аттан төшәргә курка идем, шуңа күрә йөгән белән бергә билемә урап куйган чыбыркымны алып, биянең артына төштем. Беләгемдә булган көч белән, чыбыркымны шартлаткан булып, сыртына тамыздым. Ләкин — ни гаҗәп бу! — атым тышаулы булып чыкты. Шунда минем кинәт, куркуым җиңелеп, аның урынына бетмәс ачу кабарып чыкты. Мин сабанга төшкәннән бирле, унбиш көн буена, каныма күп тоз салган, күземнән ачы яшьләр агызган бу җирән шайтанга чиксез ачуым чыгып, чыбыркымны икегә бөкләп яра башладым. Биям, куш аяклап, әле уңга сикерә, әле сулга — чабып китмәкче була. Аның саен мин каршысына чыгып, юлын кисәм. Ике-өч кабат камчы сабы белән нык итеп яңагына да сугып алдым.

Ахырда ул, тышавын өзеп, үзебезнең басу ягына чабып китте. Мин әллә нинди авыр эш эшләгән кебек, көчкә тын алып туктадым. Шунда күзем урман буеннан миңа таба килгән Бәһау картка төште. Нишләргә дә белмәстән, исем китеп, ат өстендә катып калдым.

— Тукта! — дип кычкырды ул килеп җитәрәк.

Тавышында бернинди шәфкать юк; җитмәсә тирә-якта кеше-кара да юк, — мин бер куркыныч сизеп, тыным кысылып, тезгенне кактым, ләкин соң иде инде. Бәһау карт ат башыннан җәһәт кенә эләктереп алып, кәкре борыны белән кыек яңагын миңа төбәде:

— Син монда, малай актыгы, ат кыйнап, корткычлык итеп йөрисеңме әле, ә? Бүген наруш артыннан күзәтеп килдем. Аңладым мин сине хәзер: нурмыңны юри тутырмас өчен монда килеп, ат арытып, ат кыйнап йөрисең икән! Төш хәзер үк аттан, кулак калдыгы!

Мин: «Төшеп, тиз генә чокырга йөгерергә» дип уйлап алдым. Ләкин шунда күкрәгемә каты сугудан җиргә очтым. Мин арка белән барып төшеп, тын ала алмый тордым. Ләкин һушым бик нык әшли иде.— Баһау карт атны читкә генә этәреп, күкрәгемә басардай булып өскә килә башлагач, йомгактай йомарландым да, чирәмле текә тау битеннән чокыр төбенә тәгәрәдем. Тыным да җибәрде. Бу әле куркынычтан котылу түгел иде: Баһау картның ат менеп, минем арттан чокырның сөзәк битеннән төшеп тотуы бар иде. Монда инде мине үтереп куйсалар да беркем күрмәячәк иде. Мин, тәгәрәп туктау белән, сикереп тордым да, иң аста бәләкәй генә инеш чыгып яткан тирән ярга сикердем. Бу ярдан инде ат түгел, кәҗә дә төшә алмый иде. Бу үзәк ярга бара-бара ике яктан да чирәмле тауны ярып төшкән башка ярлар кушыла, һәркайсыннан судыр, чишмәдер чыгып, бер-берсенә кушыла барып, бәләкәй генә бер инешкә әйләнә. Мин шул инеш буйлап элдердем генә! Инде ничә чакрым йөгергәч, авылга җиткәндә, каршы яктан, тау битеннән мөгрәшеп, бәәлдәшеп, сыеры-сарыгы бергә йөргән көтү килгәнен күреп алдым. Көтү артыннан килгән Бәздәви, мине күреп, өстән кычкырды:

— Даниал! Кая чабасың? Ни булды?

Минем чабып килеп тыным кыскан — сүз белән җавап бирә алмадым, кулым белән авыл ягына гына күрсәттем. Бәздәви дә минем өчен хәзер бер кара көч иде. Чибәр җиңгинең сыеры кичә аның көтүеннән кайтмый калган бит! Сыер инә түгел күрми калырга. Көтүендә дә — булса — утыз сыер бардыр...

Мин инде йөгереп кызган идем (менә кайчан кирәк булды ул йөгерә белү!), авылга кергәч тә туктамадым. Туры чибәр җиңгиләргә чабып кердем. Чибәр җиңги баскычтан төшеп килә иде, минем болай чабып килеп керүемне күргәч, тәгаен бер хәбәр китергәнемне сизеп, өмет белән минем күземә текәлде. Ләкин минем сүз әйтерлек хәлем юк: биш чакрым йөгереп кайтып, эчем бер бата, бер калка — сүз әйтергә тыным җитми тора иде.

— Әйт тизрәк — ни булды? Әллә сыерыбыз табылдымы?..

Мин «юк» дигән ишарә белән баш чайкадым. Аннары, бераз хәл җыйгач, озын-озак сузмыйча, күргәнемне сөйләп бирдем.

— Күңелем сизгән иде инде шулай буласын!..— дип, чибәр җиңги тагын елый башлады.— Дүрт сабый күз тегеп торган сыерыбыздан калгач, ничек көн итәрмен инде хәзер!?.

Безгә кереп, әнине иярттек. Идарәдән хисапчы чулак Камай абзый иярде. Без көтү сукмагы белән, Тирәнкүл буйлап, Качкын урманына киттек. Минем бөтен курыкканым — тиренең күмелгән җирен таба алмам дигән уй иде. Ләкин безгә ат эзе ярдәм итте. Мин урманга шактый кергәнмен икән. Байтак кергәч кенә кепканы табып алып кидем. Аннары ат өреккән җиргә дә барып җиттек. Койрык исән — шул килеш тора иде. Без аны бик җиңел тартып чыгардык. Йонына балчык сеңәргә дә өлгермәгән, селкеп җибәрү белән тере сыер тиресе кебек ялтырап китте. Җиргә җәеп салдык. Чибәр җиңги тире өстенә ятып, ауный-тәгәри елый башлады. Беребездә-бер аны туктатырлык көч тә, сүз дә юк иде.

—Ходайның ачы каһәрләре суксын сине суйган кешене!.. Куллары корып, муеннары аска килеп, кәкрәеплэр катсын иде ул бәдбәхет адәм!..— дип туктаусыз кабатлый-кабатлый, тире өстендә канлы яшьләр түгеп елады чибәр җиңги.— Минем каргышым төшмәсме?.. Минем каргышым төшмәсме?..— ди-ди тире өстеннән торды да, тиренең койрыгыннан сөйрәп, зәһәр белән кузгалып китте.

— Кайтам да, йөзенә каплыйм ул канечкечнең!— дип, һичшиксез Баһау картка яный иде.

Әни аның кулыннан иплэп кенә тирене алып, тәгәрәтеп төрде дә ин-сәсенә салды. Шулай дүртәүләп кайтып киттек. Чибәр җиңги бара-бара да:

— Ул балаларга ни ашатырмын да ни эчерермен инде мин хәзер?.. Өзделәр бит авызларымнан сөтне!..— дип шыңшып елый башлады.

Әни йомшак, көйле тавышы белән:

— Елама, килен. Елап каза китмәс. Әле, шөкер, бозавы калды. Күзгә тана булыр, язга — башмак. Аңынчы безнең сыер исән булсын, бергә-бергә җиткерербез...— дип чибәр җиңгинең күңелен күтәрергә тырыша иде.

— И җиңги, җиңги! Үзегезнең дә семья ишле бит!..

Чибәр җиңги өч кызы белән бездә торган Ленинград апасын кертеп әйтә иде. Бабай белән әбиләре кырык өчтә үк аллы-артлы гына вафат булып, икесен дә мин укып йөргән рус авылы зиратына җирләп куйдылар. Эвакуацияләнеп, безнең авылга килгән сигез гаиләнең инде җидесе бер ел эчендә үк кайсы Минзәлә, кайсы Алабуга кебек җирләргә таралышып бетте, бездә торган Валентина апа гына яшәвендә дәвам итте. Инде ул, шактый татарчага өйрәнеп алып, үзебезнең авылда икенче, дүртенче классларны укыта, зур кызы минем белән бергә күрше рус авылына йөреп укый, ә кечесе татар балалары белән бер класста утырып, әнисендә укый иде. Валентина апа, бездән көн саен — әни акчасын алмаска ни кадәр тартышса да — сөт алып тора иде.

Чибәр җиңги әле шул Валентина апаларны да күз алдында тотып, семьягыз ишле дип әйтте дә инде. Ахырда ул:

— Бу күз яшьләрем төшәр әле, төшәр! Төшми калмас, алла бирсә!..— дип өзгәләнеп бер әйтте дә, шул сүзләреннән үзе җиңеләеп киткәндәй, тыныч кына тавыш белән:— Кая, җиңги, үзем күтәрим,— дип әни иңбашыннан алып, үзенең иңбашына салды. Тире алдан да, арттан да асылынып бара иде, шуның алгы як өлешен тере бер җан нясеңдәй, сөеп-сыйпап ала иде.

Без шулай дүртәү, тезелешеп, авылга кайтып кердек, туры колхоз идарәсенә юнәлдек.

Ни күрим: идарәнең болдыр төбендә минем җирән биям тора, ә баш ягында өелешеп биш-алты кеше баскан. Арырак, бүрәнәгә бәйләнгән авыл Советы айгырын күргәч, йөрәгем жу итеп китте. Авыл Советы председателе хәзер Барбара түти түгел, былтыр көз сугыштан сул аягын җәрәхәтләп кайткан, кисеп кенә ташлыйсы табанын кистермичә, шуны селтәп-селтәп ыргытып атлаган, бәләкәй буйлы, каты куллы Шәехов абый иде.

Безне күрү белән, ат янына җыелганнар безгә борылып карады.

— Әнә, шул малай үзе!— дип Баһау карт миңа бармагы белән төртеп күрсәтте.

— Кил әле монда!— диде капыл Шәехов абый.— Бу синең һөнәрме?

Мин якын килеп, атка текәлдем: аның уң күзе йомык, тирәсе эренләп, туктаусыз агып тора иде.

— Менә, шушы йөгән авызлыгы белән сугып, күзен имгәтте,— дип Бахау карт минем билдән төшеп калган йөгәнне селкеп күрсәтте.— Бу беренче генә түгел. Җирәнне ул буразнада да кыйный, нигәдер канык-кан ул аңа. Бүген юри артыннан күзәтеп бардым. Тач кыйнаган чагында өстенә барып чыктым...

— Юк, мин атка йөгән белән сукмадым.— Минем бар ачуым тышка бәреп чыкты.— Мин чыбыркы белән генә суктым. Анда да күзенә түгел — сыртына гына. Йөгән бөтенләй кулда түгел, билгә бәйләнгән иде. Син мине ат өстеннән сугып төшергәч кенә төшеп калды ул,— дип мин

ярсып, кешеләр алдында гайрәтләнеп, йөзенә акырдым.— Син үзең анда сыер тиресе күмеп чыгып килә идең!..

Шунда, беркем бер сүз әйтергә өлгермәде, чибәр җиңги туп-туры Бәһау карт каршына килеп туктады да:

— Мә, тиресен өстеңә бөркән, ерткыч!— дип, кай арада җәеп тоткан сыер тиресен Бәһау картның өстенә ташлады.

Бәһау карт, селтәнә-селтәнә, тирене өстеннән алып ташлады. Ачуы бик нык җыелган әни дә:

— Әле син, йөзең кара, үз гаебеңне яшерер өчен, гаепсез атның күзен чыгарып, минем бала өстенә яла ягарга төштеңме?— дип карчыгадай очып килеп, Бәһау картның кулыннан әле һаман тотып торган йөгәнне тартып алды.

Бу күренештән хәтта ни усал Шәехов абый аптырап калды. Идарә янына, бу хәлне күреп, карты-яше җыела башлады. Килеп басканы бере, мәсьәләне аңлап алу белән, Бәһау карт өстенә сүз ыргыта иде.

Мәсьәлә Бәһау карт өчен катлауланып китте. Үзебезнең председатель Рамазан бабай белән Шәехов абый халыкка таралмаска кушып, идарәгә кереп китте. Бераздан берәм-берәм чибәр җиңгине, хисапчы Чулак Камай абзыйны, әнине, мине чакырып сөйләттеләр. Бәһау карт та кереп, яңагы тагын да кыйгайган кебегрәк килеп чыкты.

Шәехов абый тыелгысыз хәрәкәт кешесе иде. Шундук комиссия төзеп, Бәһау картларга тентү кертте. Комиссия халкы уйланып, баш иеп кенә алдан китте, ә алар артыннан күкрәген киереп, әкрен, эре адымнар белән Бәһау карт бара иде. Соңыннан гына, шигәя-шигәя генә, артларыннан без дә иярдек.

Ләкин халык «ике катлы икән» дип сөйләгән караңгы базларына төшеп эзләсәләр дә, суелган сыер түшкәсе табылмады.

Моның шулай буласын үзе алдан белгән Бәһау карт бик тә гайрәт чәчеп:

— Мин пыркарулга җитәм: тентү керергә сезнең правагыз юк иде! Мин үлгән фронтовик атасы!— дип җикеренә башлаган иде дә, Шәехов абый аны:

— Син, абзый, бездән права таптырма, кирәк булса эзеңә тиз төшәрбез,— дип тиз туктатты.

Ләкин җилкәләр чиләнеп тарткан зур, авыр колхоз эше кырылып ятканда, берәүнең сыеры югалган кебек бәләкәй эшләрнең кирәге булмагандыр: Бәһау карт прокурорга барып тормаган шикелле, аның эзенә дә төшүче булмады. Моның эзе дә шулай кара урман эчләренә кереп юкка чыкты.

## 8

Еллар үтте. Сабыйларның күз төпләренә батып төшкән кара күләгәдәй булып, авырлыгы аналарның-җиңгиләрнең күкрәгенә кан саудырган, малайларның юка җилкәләрен батырып кергән сугыш еллары да инде артта калды. Сугыш чорында күпме газиз күкрәкләргә тигән кургаш кебек, исән күкрәкләргә дә тиеп, сызлатып үткән бер чорда эти кайгысы да, салкын сулар югандай, онытылды. Без инде әтине искә алганда да еламый идек.

Ләкин, еллар үткән саен, бу серле җинаять вакыйгасы күңелемне күбрәк били барды. Песи баласы түгел бит — кеше чаклы кеше — эти! Гаепләнгән өч кешенең берсе үтергәнме аны, әллә тагы шиктән бөтенләй читтә калган чын үтерүче бармы? Алай дисәң, кан коеп сугышып, немец пулясыннан исән калган Фидаил абзый нигә күкрәгенә без кадап, үз-үзен эти үлеменә дучар итә? Мине һаман, үтерү фактының үзеннән бигрәк, яки җинаятьченең кем булуыннан бигрәк, тикшерүнең

үзе кызыксындыра, күңелемне шунысы җәлеп итә иде. Мин теге вакытта да, тикшерүче абый безнең өйдә төн буе сорау алганда да, үлем кайгысын да онытып торып, тикшерүнең эченә керердәй булып, тынчарым буылыр чиккә җитеп тыңлап яттым. Ул төн бүген дә, һәр сүзенә кадәр, бизгәк тоткандагы кайнар ут белән уелып, миемдә тамгадай ярылып ята.

Ни барысы җитмеш тугыз өе булган бер авылда кеше хәтле кешене үтерәләр! Кем үтергән — таба алмыйлар. Башына кигән күн тышлы бүреге юк, ике кызыма күлмәклек, төпчегемә чалбарлык дип, култык астына кыстырып кайткан төргәге юк — аларын да таба алмыйлар — ут булган да су булган! Ләкин бит ничә дуңгызның йөрәген айкап чыккан без бар — без!.. Гаҗәп хәлләр инде — әйтәсе дә түгел...

Димәк, тикшерү дөрес юлдан китмәгән. Ә бит сорау алганда минем бала зиһенем өчен бар нәрсә дә ачык, тикшерүче генә үз өендә ишек таба алмый йөргән төсле иде. Их, теге тикшерүче абыйның фикерен беләсе иде хәзер... Ләкин аны да сугышта үлгән, диделәр. Ә теге Казаннан килгән комиссия нинди нәтиҗә ясаган? Күзнең кешесендә, чыннан да, үтерүче кеше сурәте төшеп калганмы?.. Анысы юктыр. Төшеп калган тәкъдирдә дә күзге төн карасында нинди сурәт булсын ди икән. Аны шул, өйдә, ут яктысында үтереп, чыгарып ташламадылар микән дип кенә караганнардыр инде?..

Әле бит, сугыш бетсә дә, илдә җинаять бетмәгән. Эти — иң соңгы кеше түгел. Сугыш чорында күрәләтә, сабыйларның ризыгын өзеп, «көтүдән кайтмый калган» күпме сарыкны бугазына тыккан, чибәр җиңгинең сыер тикле сыерын җир йоткандай йоткан Баһау карт та әнә җәзасыз йөри. «Тотылмаган — карак түгел»ме? Алай булгач, җәен-кышын ут алмый гына урамны искә тутырып, нинди итләр пешерде соң ул?..

Каракларга, җинаятьчеләргә, үтерүчеләргә киләчәктә дә юл куелса — бу ярый торган эшме соң??.

Мине суд-хөкем, җинаять эшләре шул кадәр дә җәлеп итә башлады ки, мин киләчәк гомеремне, эшемне шул өлкәгә багышларга булдым. Ләкин ничек? Анысы миңа ала-чала гына шәйләнә иде.

Бәхеткә, минем матур язуым ярдәм итте. Җиденче класстан алып, мине колхоз идарәсенә, авыл Советына, МТСка чакырып, бик күп төрле кәгазьләр: учетный карточкалар, ведомостьлар, төрле докладлар, протоколлар яздыралар иде. Я елга бер райондагы барлык мәктәпләрдән матур язучыларны военкомат, я комсомол комитеты чакырып ала да, атна буе шундый ук документлар яздырып утырта. Миңа күпчелектә тоташ язмалар: доклад я протоколлар туры килә иде. Шулай ел саен ике-өч тапкыр күчереп яза торгач (әйтергә кирәк, бу бик йөдәткеч эш — яза-яза кулларга кан төшкән кебек сызлый башлый иде), мин доклад я протокол язуның бөтен серенә төшенә алдым. Шул сәбәпле мәктәпне әйтеп тә тормыйм, үзебезнең колхозда җыелыш булдымы — протокол язарга мине өстәл башына менгереп утырталар иде.

1947 елның февраль ае иде. Мин унынчы класста укыган чак. Без, хәзер күрше рус авылында укыганнар, дүртенчеләр, бишенчеләрдәге шикелле, кеше сәндерәсендә кунып ятмыйбыз — көн саен кайтып йөри идек: биш чакрым юл нәрсә ул! Җыелыш көндез үк башланасы булгач, мин ул көнне, табигый, укырга барып тормадым: көтеп алган бәйрәм кебек, җыелышларны мин бик ярата идем. Халык председатель дип тормый, бригадир дип тормый, вәкил дип тормый — чәчрәп сикереп тора да, бәрә дә әйтә, бәрә дә әйтә. Председательнең кемдә, кайчан кунакта булуын да, аңа ике центнер артык салам бирүен дә, больницага барырга ат бирмәвен дә, ә үзенең колхоз атын җигеп, бер тапкыр кунакка баруын да бик төгәллек белән әйтеп бирәләр иде. Ярты як, председательне алып ыргытырга, ди, ә ярты як — калдырырга, ди. Шуннан — кита талаш, китә талаш, инде колхоз эше онытыла — инде кем кайчан

нәрсә урлаган, кем кайчан эшкә чыкмаган, нинди хатын нинди ирне куна керткән — берсе дә калмый торган иде.

Сүз дә юк, күңелле үтә иде җыелышлар — халыкның югалтасы нәрсәсе юк — эчендәге тышында иде; куркыр нәрсәсе дә юк — һәммәсе фронтовик семьясы, һәммәсе бер үк хезмәт көненә эшли, һәммәсе ил өчен кан көйгән иде.

Бу юлы райкомнан вәкил булып, гомердә килмәгән, ишетеп кенә белгән Вахитов дигән судья килгән иде. Председатель үзебезнең авылның, сугыштан кул-аягын өздерми кайткан бердәнбер кеше — бик гайрәтле Гыйльман абый иде. Эшкә дә ул гайрәтле тотынды — күпчелек кеше аңа ышана, таяна иде. Райком вәкиленең дә аның кандидатурасын якларга килгәнлеге мәгълүм булды. Ләкин җыелыш барыбер җыелыш инде ул — берсенә-берсе очып-очып кунмагач, колхоз җыелышы буламыни ул!

Ревкомиссиянең үзен — сугыш вакытындагы председатель Рамазан бабайның үзен: «Бер йөк Кама болыны печәнен нишләп фермага җибәрмичә, үз капкаңа борып керттең? Әллә үз капкаңны картлык белән ферма капкасы дип ялгыштыңмы?» — дип, аякка бастырып җавап алдылар.

Райком вәкиле Вахитов абый трибуна янында ук утыра иде, мин өстәлнең икенче читендә халыкка яным белән утырам, урыныннан торып, минем янга килде дә, бик йомшак тавыш белән:

— Барысын да яз, энем, берсен дә калдырма, яме,— дип аркама кулын тидереп китте.

Иреннән биш бала белән калган, күпер башы Тәнзиләттәй Рамазан бабай белән председательгә кадалды:

— Уракка төштекме — басу капкасы төбендә хатын-кызның штан төбенә хәтле капшап торасыз — сабыйларына берәр кадак салмаганмы, янәсе! Ә Шәрәфинең төннә заготзернодан кайтканда бричка төбендә ничә кило ашлык кайтканын тикшерәсезме?

Моңа Рамазан бабай я председатель җавап биргәнче, минем янда гына утырган, президиумга сайланган актив — укытучы Сара апа төгәллек кертте:

— Рамазан бабайның штан капшап торганы юк, яла якмагыз, тикшергән вакытларда да: «Хатын-кызның бот тирәсенә кул тигерә алмыйм, кызым. Анысын син кара инде»,— дип миңа куша. Синеңчә әйтсәк, Тәнзилә апа, синекен бернечә тапкыр мин капшадым. Рәхмәт, бер грамм иген белән дә тотылганың булмады.

«Бер арба сөяк» дип аталган бик усал Көбра түтәй ирләр тавышы белән, утырган җиреннән генә:

— Белдек, хатыннарның оят җирен син капшыйсың икән — белдек. Ә синең үзеңнекен кем капшый соң? — дип сорап куймасынмы! Клуб дер селкенеп көлеп җибәрде. Сара апа президиум өстәленә җәелгән кызыл ситса кебек кызарып чыкты.

— Иптәшләр! Тавыш!..— дип, председатель графин шакый башлады.— Иптәшләр! Җыелышны көлкегә әйләндермәгез!..

Аның үзенә дә эләкте:

— Былтыр яз идарә айгырының аягын сындырып суйдырдың. Аның зыянын капладыңмы, и ул керем кенәгәгә теркәлдеме?

Моны сугыш чорында бөтенләй башка сельсоветта председатель булып эшләгән, хәзер бума чире сәбәпле, җаваплы эштә эшли алмаган, этлекле Шәрәфетдин абзый бирде.

Бу бик начар сорау булып чыкты. Былтыр яз, чәчү өстендә, Зират тавыннан төшкәндә дүрт кенә яшьлек идарә айгыры дулап китеп, идарә янында да тыела алмыйча чаптырып, урам уртасындагы күпергә барып керә. Күпернең сынган бүрәнә ярыгына атның ал ягы төшеп китеп, тездән шартлап кына сына да, елкы яшеннән яңа гына чыккан яшь ай-

гырны суеп, тракторчыларга тоталар, бер өлеше сукада, чәчүдә булган колхозчыларга да тия.

Гыйльман абзый шулай аңлатып бирде. Ләкин бума Шәрәфетдин аңа гына канәгать түгел иде.

— Юк, син, Гыйльман, минем сорауга җавап бирмәдең. Мәнә син айгырның аягын сындырдың. Гаеплеме син? Гаепле. Яхшы. Инде шартлап аягы сынган айгырдан мал чыкмый. Суйдыгыз. Инде болай уйлыйк: әгәр син шул айгырны, аягы сынмаган килеш, егып суеп, тракторчыларга ашатсаң — син бит под суд китә идең? Шулай бит, Вахитов иптәш? И айгыр бәһасен дә түли идең.

— Шәрәфетдин, син миңа түгел, җыелышка сорау бир, җыелыш белән сөйләш.

Гыйльман абзый торды. Аның да йөзе агарып киткән иде.

— Иптәшләр! Чыннан да зыян колхозга акчалата кайтарылмады. Мәгәр ел саен суя торган сыер суелмый калды. Дөрес, айгырның аягы сынуда мин гаепле. Ләкин шунысы да дөрес: мин бит аны, аягын сындырыйм әле, аягы сынса, суеп ашарбыз, дип юри, күпер ярыгына аягын тыгып, каерып сындырмадым. Итеннән тыш гомуми зыянны миннән түләтәсез икән, хәтта ки, Шәрәфетдин әйткәнчә, под суд җибәрәсез икән, мәнә сез — җыелыш, сез хәл итегез,— дип урынына утырды.

Сораулардан соң аерым-аерым сөйләүгә күчеп киттеләр. Ләкин бу әле сораулар туктады дигән сүз түгел, сөйләгән кеше артыннан кабынып китәргә һәркемнең уты җитәрлек иде.

Ә башта әйткәнемчә, миңа килгәндә, минем киләчәк юлым шушы җыелыштан соң икенче көнне хәл ителде. Икенче көнне базар көн булып, без мәктәпкә бармадык. Иртән торып, ике апа да эшкә киткәч (зурысы ат белән тирес чыгара, кечесе кар тотуда иде), мин киенеп, абзар чистартырга чыгарга гына дип торганда, идарәдән йомышчы Мәймүнә апа килеп, мине тиз генә районнан килгән судья чакыра дип әйтеп китте. Мин Мәймүнәттәйне дә узып китеп, идарәгә йөгердем. Әлбәттә, кичә колагыма иелеп әйткән йомшак тавышын, иңсәмә куеп кына алган җылы кулын ишетмәсә-тоймасам, мин каушап-куркып коелып төшәр идем, ләкин мине бүген, идарәгә чабып барганда, ниндидер ашкынулы дулкын биләп алды. Мин шул дулкын эчендә идарәгә барып кердем.

Судья абый, мине көтеп торган кебек, көр, ягымлы тавыш белән, гади генә итеп:

— Килдеңме, энем!— диде дә, «әйдә!» дип, такта белән генә бүленгән председатель бүлмәсенә алып кереп китте.

— Утыр әле,— диде ул.

Мин утырып, стенага эленгән Сталин рәсеменә карадым. Вахитов абый түргә, миңа каршы утырып, минем уемдагы судьяларга охшамаган җылылык, ягымлылык белән, хәтта шатланып сөйләнеп алды:

— Менә бүген эшем шул булды: мин синең кичә язган протоколыңны укып чыктым. Һәммәсен төгәл итеп, матур итеп язгансың. Берничә урында сүз яки җөмлә хаталары гына калган. Мин менә күптән синең кебек егетне үземә эшкә алырга эзләп йөри идем...— Йөзен тутырып елмаеп, миңа карады.— Керәсеңме безгә эшкә? Миңа синдәй секретарь егет кирәк.

— Мин укыйм бит әле, абый,— дидем мин.

— Беләм,— диде ул.— Унынчыда укыганыңны да, яхшы укыганлыгыңны да, русчадан грамоталы икәнлегеңне дә — барысын да беләм. Мин инде сораштым. Мин бит — судья. Шуны да белмәгәч! — дип, ул тагы елмайды. Ул әле бөтенләй карт түгел, тулы ак йөзенә көлгәндә генә җыерчык сибелде, ләкин йомшак чәче инде яртылаш агарган иде.

Мин күңелемә тулган шатлыгымны кая куярга, үземнең дә суд тикшерү эшендә эшлисе килүемне сөйләп бирәсем килеп утырам, тик нидән башларга гына белми утырам.

— Я, ризасынмы бездә эшләргә?— дип, Вахитов абый туп-туры күземә карады.

Мин дә көчем җиткән кадәр аның ак-чиста күзләренә карап тордым да, үземнең тикшерү эшләре белән кызыксынып януымны, уку беткәч, шул юнәлештә укырга китәргә ниятләнүемне кызып-кызып сөйләп бирдем.

— Бик яхшы!— дип, Вахитов абый да шатланып өстәлгә шапылдатып учы белән сукты.— Мин нәкъ кешесенә тап булганмын икән! «Бирәсе килгән колына — чыгарып куяр юлына» дип нәкъ менә шундыйга әйтәләр. Укуың бетү белән мин сине үземә секретарьлеккә алам. Син миндә бер ел эшлисеңме, икеме — хөкем процедурасының серләренә төшенәсең. Тәҗрибә туплыйсың. И аннары мин сине, яхшы кәгазь-характеристика язып, үзебезнең Казан университетына җибәрәм. Ленин бабай укыган юридик факультетка! Булдымы? Сөйләштекме?— дип тагын елмайды.

— Сөйләштек,— дидем мин. «Уку беткәнче бик күп бит әле, онытмассызмы икән соң?» дип сорыйсым бик килсә дә, сорый алмадым: бу абыйның ак-чиста, якты күзләре кешене алдый алмый иде.

Шулай булды да. «Их, тизрәк уку бетсен иде!» дип, ашкынулы, сөенеч тулы биш ай озак булса да, тиз үтте. Уку бетеп, аттестат алган көнне директорыбыз Коровкин абый мине Вахитов абый чакыртканлыгын әйтте.

Атна да ял итмәстән, июльнең бересендә судта секретарь булып эшли башладым. Вахитов кул астында эшләгән ике ел эчендә, минем кулдан язылып, күчерелеп, том-том «дело»лар булып, күпме кеше язмышы үтте!

Вахитов абый мине эштә каты таләпчәнлек, төгәллек белән эшләтте, ләкин туганыдай якын күрде. Мин дә ни әтисез, ни абыйсыз үскән малай буларак, көчле ирләргә тартыла торган малайлык йөрәгем белән аны үземә тәрәк иттем. Мин аңа күңелемдә йөргән балалык җәрәхәтемне ачтым. Өр-яңадан карар өчен түгел, тикшерүнең әллә дөрес юлдан китмәгәнме икәнлеген белү өчен ачтым. Юка гына делоны ул архивтан эзләп тапкан, ләкин хәзер, шаһитлары да, гаепләнүчеләре дә бу дөньяда булмау сәбәпле, бер нәрсә эшләп булмавын, күпме вакыт үтүен кызганып әйтүдән узмады.

Вахитов абый сүзендә торды. Төп-төгәл ике ел эшләткәч, мине направление белән Казан университетына җибәрде.

Укырга керү дә, уку да миңа кыен булмады. Дөрес, борынгы Рим хокукларын, Маркснын «Капитал»ын өйрәнгәндә, минем соңгы елларны көчәеп киткән күрә карау күзем үзен бик нык сиздерә; күзлекне дә һаман көчледән көчлегә алмаштыра тора идем. Бик зур көч белән укыганга, күзләр томаланып, хәрефне тота алмас чиккә җиткән чакларым да булмады түгел, булды.

Мин Сталин стипендиясе алып укыдым. Һәм университетны бетерү белән, ике ел республикабызның Югары судында эшләдем дә, аспирантурага кердем. Ә өч елдан юридик фәннәр кандидаты дигән дәрәҗә алып университетта укыта башладым.

Мең тугыз йөз алтмышынчы елны үзебезнең район судьясы Вахитов абыйдан (ул һаман шунда эшли иде) җәйге каникул башланып, минем ялга чыгасы көннәрдә генә бик тиз кайтып җит, дигән телеграмма алдым. Кайтмый калмавымны кисәр өчен, ахры, «нәкъ сине кызыксындырган эш карала», дип өстәгән иде.

Телеграмманы утызынчы июнь шимбә көн алдым, шул көнне үк отпусканы бер атна алга күчереп эшләдек тә, икенче июль дүшәмбе көн мин самолет белән районга очтым. Мине кырык җиде яшендә чәче тәмам ак мамыктай агарып беткән, ләкин йөзе һаман җыерчыксыз калган Вахитов абый каршы алды. Бертуган энеседәй иттереп, кысып кочак-

лап, аркамнан сөйде дә туры өенә алып кайтып китте. Аэропорттан район үзәгенә кайтканда ул машинада минем хәлләрне генә сораштырып кайтты. Фәүзия апа чәй куеп, чәй эчкәндә дә һаман минем хәлләрне генә сорашты. Һәр уңышыма сөенә, хәтта минем белән горурлана иде ул.

— Менә бит безнең районнан да кем чыкты, ә!.. Кем уйлаган бит, ә!..— дип яратып, әле миңа, әле Фәүзия апага карап ала иде.

— Я, Вахитов абый, инде сөйләгез: мине чәй эчереп, болай мактар өчен генә миңа «срочный» телеграмма сукмагансыздыр бит?— дип үтә җанлы, үтә җылы күзләренә карадым.

Мин карау белән аның ак йөзенә кара күләгә йөгерде, күзе моңсу бер кайгыга батты.

— Әйдә, энем, верандага чыгыйк,— диде ул.

Вахитов абый өйне былтыр гына җиткереп кереп, инде һәр җирдә бер мода сыман булып киткән гаҗәеп иркен веранда да сугып куйган иде. Анда карават, өстәл, диван тора. Без диванга утырдык. Вахитов абый кайгылы йөз белән көрсенеп куйды да:

— Шулай шул, энем. Шулай шул...— дип сүз башлады.— Мин сине менә шулай тәмләп бер чәй эчеп утырыр өчен генә дә чакырып кайтарыр идем дә бит — булмый... Үзең дә елга бер дә ике елга бер генә кайтып китәсең. Анысына да шөкер, бер дә кайтмаганнар да бар бит әле... Кыскасы, менә соңгы ике елда гел алиментттыр-нидер, аерылышу-кушылудыр кебек, гел гражданнар «эше» белән мәшгуль булып ятканда, искә төшү белән, йөрәкләргә кан сава торган фаҗига килеп чыкты, энем... Сезнең авыл Баһау картның зур улы Бәздәви бертуган энесен үтерә...

— Хәмзәнеме?— дидем мин. Һәм минем дә йөрәккә бөтен тәннән йөгереп килеп кан бәрде.

— Әйе. Шул Хәмзәне үтерә...

Һәм минем күз алдына Баһау картның бәләкәйдән үк•эткә, песигә көн күрсәтмәгән, ун яшендәме куянга дип этисенең аю табанлы чаңгысын, мылтыгын сөйрәп чыгып киткән, яшьтән үк таза булып үсеп килгән кара-чибәр үсмер егет Хәмзә килеп басты. Мин инде аның егет булып җиткән чагын белмим дә кебек...

— Дүрт ел морфлотта хезмәт итеп, быел яз гына демобилизацияләнеп кайткан булган. Белеме җиде класс кына. Хезмәттән дә һөнәр алып кайтмаган. Колхозда да эшләп чиләнәсе килми. Нефть ягына китәм дип, абыйсы җилкәсендә ике ай ята бу. Инде этиләре карт — эшли алмый. Әни дә карт — ул да эшли алмый. Хәер, болары асыл мәсьәлә түгел, мин сиңа асылын гына сөйлим... Шулай сабан туйлар җитә. Бер көнне бу авылда сабан туй; икенче көнне — икенче авылда. Болар беренче көнне үз авылларында көрәшкәннәр. Абыйсы да, буйга бераз калышса да, бирешердәй түгел. Шулай да, яңа хезмәттән кайткан кеше дип, бүләкне Хәмзә дигәненә бирәләр. Мәгълүм инде, карт аталары белән өчәүләп, сабан туйдан соң эчәләр болар. Икенче көнне, икесе ике атка атланып, Тугай сабан туена китә болар. Анда да, берәм-берәм көрәшә-көрәшә, батырлыкка икәү генә торып калалар. Бәздәви бу авылда ел саен батыр калган кеше. Кичә үз авылларында батырлыкны энесенә бирсә дә, монда, зуррак җирдә, абруен төшерәсе килми — ел саен көрәшеп, инде билне ныгыткан кеше. Көрәшкә аннары бик нык сол да кирәк. Энесендә көч булса да, сол юк, көрәш хәйләсе юк... Ике көрәштә дә абыйсы ега. Кайталар болар өйгә. Тагын эчәргә утыралар. Эчүдә икесе дә батыр. Күрше егетләр дә була. Сүз гел көрәш турында. Бер дә читкә чыкмыйча, гел бер эздән бара-бара, сүз тыелгысыз бәхәскә әйләнеп китә. Монда инде, билгеле, аракы үз сүзен әйтә. Кыскасы, бәхәсне көрәш кенә хәл итә ала. Иптәшләре дә: «Давай!» ди, Хәмзә дә: «Давай!» ди. Монысы үз башына җилкенә инде мәрхүм. Чыгалар болар. Ишегалдында чирәмлек бар. Тотыналар болар кызган баш белән, кай-

нар акыл белән көрәшергә. Абыйсының бу юлы бер дә егасы килми, ләкин үзе дә көрәш башлану белән ектыра алмый: энесе ышанмаячак. Шулай йөриләр болар уңга-сулга, алга-артка сугылып. Инде алышалар, инде мышнийлар. Абыйсы бил бирмәгән булып, ектырырга чама эзләп йөри. Момент килеп чыга: энесе моның билен суыра башлагач, каршы торган булып бирешә бу. Ләкин, гөнаһ шомлыгы, энесе, моны күтәргәч, үзе егылып китә, абыйсы гөпелдәп өстенә барып төшә. «Аяк чалдың!.. Хәрәмләштең!.. Анаңны да, атаңны да!..» дип, Хәмзә сикереп тә тора, кызган баштан нишләгәнен белмәстән, алгы кучәре алып куелган арбадан кендеген суырып ала да һич уенсыз абыйсы өстенә килә. Минут түгел, секунд хәл итә: баш өстендә кендек уйнап киту белән, абыйсы берни уйламастан, фәкать шул секундта кендек төшеп, мие чәчрәп атылып китмәсен өчен, җан саклау инстинкты белән һәм җан ачысы белән, энесенә тибеп җибәрә. Аягы энесенең нәкъ җан җиренә туры килә дә — энесе шул моментта тәгәрәп тә үлә...

Вахитов абый туктап, бу үлемне тач үз күзләре белән күреп торган кеше төсле, авыр итеп көрсенеп куйды.

— Җентеклэбрәк танышырга теләсәң, делоны үзең укып чыга аласың... Җинаять булган — беткән. Бәздәви Баһаветдинов үз җәзасын алыр. Тик, бит аңа, үзең дә күрерсең, егерме ел да, хәтта ун ел да биреп булмый. Бердән, үтерәм дип түгел, үземне саклыйм дип тибеп җибәрергә мәҗбүр була. Һәм берниндн коралсыз килеш. Икенчедән, үз туганын үзе үтереп, ул инде гомерен мәңгелек кайгыга ураган; бу инде — төрмәдән дә, үлемнән дә каты җәза! Бүгеннән атсалар да — бу мәсхәрә, бу кайгыдан котылам, ичмаса, дип кенә үләчәк. Аңа, әлбәттә, иң зур җәза бүген үк тоткынлыктан чыгарып җибәрү булыр иде. Бернинди хөкемсез-нисез. Ләкин закон бар, җинаять кодексы бар. Мин Бәздәви Баһаветдиновны өч-дүрт елга булса да ябарга тиеш. Һәм ул ябылыр да...

Вахитов абый шулай, кеше хәсрәте баскан башын күтәрмичә һәм күтәрә дә алмыйча, сөйләде-сөйләде дә бер тын туктап торды. Бу хәбәр коточкыч сурәте белән минем йөрәкне дә сыткан-изгән иде. Йөрәкне генә түгел, акылны да нидер томалап алды.

Вахитов абый, кинәт башын күтәреп, миңа карады.

— Ә бит мин сине, Даниал энем, «срочный» телеграммалар белән моның өчен чакырмадым. Бөтенләй башка сәбәп белән — синең өчен үтә дә мөһим сәбәп белән чакырдым... Әтиеңне үтергән кеше тотылды бит!..

Һәм ул, күзен дә алмыйча, инде тантана белән балкып, миңа карап тора иде. Монысын мин көтмәгән идем: зиһенем катып, Вахитов абыйның яп-якты күзләре бер мәлгә томаланып киткәндәй булды. Телем дә, үзем дә бәйле, кыймылдарлык та хәлем калмаган иде.

— Кем?.. — дидем мин көчкә.

— Баһау карт ... — диде Вахитов абый. — «Кырын эш кырык елдан соң да беленә» диләр. Юук! Бик беленми торсын әле!.. Әгәр Баһау картның гаиләсендә шушы фаҗига килеп чыкмаса — беленер иде менә! Дөрес, мин сиңа теге вакытта, әтиең үтерелүгә бәйле делоларны укыгач, берни дә әйтмәдем. Хәлбуки анда Баһау картның җавап бирүендә шикле күренгән урыннар да бар иде. Син аның нинди җавап биргәнен хәтерлим дигән идең бит?

— Бүгенгедәй хәтерлим!..

— Анда ул беренче сүзеннән үк үзенең ат карагы булуын, кыйналып бетеп, төрмәгә утыртылуын, инде бер нәрсәгә шаһит та, ни дә булырга теләмәвен, әтиеңнең аны яратмавын да — берсен бер яшермичә, һәм дикъкать ит: сораганны да көтмичә — сайрап түккән. Аның бу үзенә карата нык объективлыгы тикшерүчене (тикшерүче әле егерме биш яшьтә генә була, яшь була) бөтенләй башка юлга этәрә. Дөресрәге, ул Баһау картны үз юлына төшерә алмый — киресенчә, үзе аның юлыннан

китә. Тегермәнче Фидаилгә юнәлтүе дә, тимерче Мәгъдәнне дә, шул якка китте бугай дип, объектив төстә бөтенләй кире якка китте, дип шикләнеп әйтүе дә — аның хәйләсе... Ләкин, үзең дә аңлыйсыңдыр, бу «хәйләсез» сүзләрнең чын асылы менә яңа гына, җинаятьче тотылгач кына бөтен нечкәлеге белән ачылды. Бу турыда синең үзеңнең дә ныклап уйлаганың булмагандыр.

— Ә ничек тотылды җинаятьче? — дидем мин.

— Ул үзен-үзе тоттырды. Билгеле инде, шаһит буларак, Баһау карттан да сорау алдык. Бу хәл аны тәмам бетергән, кабергә илтеп тыга язган: нинди явыз кеше булса да, ике малаеның да атасы бит! Кулы калтырый, башы калтырый. «Бу хәл ничек булды? Сөйләгез», дип әйтү белән: «Мин ничә кешене үтердем, вә ләкин үз туганымны үтергәнем булмады!» — дип әйтеп ташламасынмы! Без моны элеп тә алдык: уен сүз түгел. «Ничә кешене үтердең, я — кемнәрне?» дип таптыра да башладык. «Юк, ди бу, мондый хәсрәт сыман да хәсрәт булмаудан, зиһенем чуалып китүдән генә әйттем», ди. «Юк инде! — дидек без. — Инде авызыңны ачтың — әйтеп бетер!»

«Бу хәсрәтләрне күреп үләрмен дип кем уйлаган!» — дип елап алды. Елау дип, яшьсез генә шыңшу иде. «Миңа инде күп калмаган, өемдә үләргә рөхсәт итегез, барысын да сөйлим», ди. Сөйләде!

Ат карагы булып йөргәндә ничә кешене үтергәнен сөйләде. Дөрес, инде ул аларның кемлеген дә белми. Гөнаһына кермик, ул аларны бәлки белмәгәндер дә. Чөнки барысы да мәҗбүри үтерү — я аларны, я боларны бит инде. Шулай да синең атаң турында ләм-мим әйтми бу. Шунда бер моментны тотып алдым да: «Ә нигә Нуриман Нуриаздановны әйтмисең?»— дип бик каты гына сорап куйдым мин. Бу агарып катты. Яңаклары тартыша башлады. Бер сүз дә әйтә алмыйча, миңа текәлеп калды. Ис алырга ирек бирергә кирәкми иде. «Мөмкинлек биргәндә танып кал: син үтердеңме?»— дидем мин. «Мин,— диде ул.— Нуриманны мин үтердем», — диде. «Сөйлә, ничек булды?» дигәч: «Бүген булмый, хәлем авыраеп китте. Кичектерергә рөхсәт итегез»,— диде. Чыннан да, аның хәле әйбәт түгел иде. Врач чакырттык. Шул көнне үк мин сиңа телеграмма бирдем. Хәзер ул хәлләнеп җитте шикелле. Без аны, үзенә-үзе кул салмасын дип, бик каты күз астында тотабыз. Шулай итеп сорау алуны син кайтуга кичектердек.

— Минем анда катнашуым, утыруым юридик рамкага сыеп бетмәс бит, Вахитов абый. Минем катнашымда гаепләнүчегә басым ясалган дип уйлануы мөмкин.

— Юкны сөйләп утырма сана! Син бит рәсми гаепләүче түгел, суд әгъзасы да түгел. Ләкин синең урының, профессияң теләсә нинди сорау алу, хөкем итү процессында була алу хокукы бирә. Син — тыңлап кына утырасың, теләсәң, сорау да бирә аласың. Үтерүче аннары үз җинаятен син юкта таныды, безнең тарафтан мәҗбүр итү акты тырнак чаклы да булмады.

— Кайчан сорау аласыз?— дидем мин.

— Теләсәң — бүген үк.

— Юк, иртәгәгә калсын,— дидем мин.

Иртәгесен без иртә белән Вахитов абый, мин, тагы ике тикшерүче, бер секретарь тикшерү бүлмәсенә алдан ук кереп утырдык. Конвой Баһау картны алып керде. Ул бик нык бетерешкән, аркасы дугадай бөгелеп, башы күкрәгенә беркетеп куелган шикелле иде. Ләкин күзе үткен, керү белән мине күреп алды — күзенең миңа кадап кына алуыннан тәнем эсселе-суыклы булып китте: теге вакытны ат өстеннән сугып төшергәндә дә шул ук күзләр, шул ук агу иде.

Бөтен сораулар беткәннән соң мәсьәләнең үзәгенә төштеләр.

— Ничек булды? Ни өчен Нуриман Нуриаздановны үтердең? Барысын да сөйләп бир.

— Бик озынга китә инде ул...

— Син асылын сөйлә, Нух пигамбәр заманыннан башлама.

— Нуриманның әтисе бай мәзин иде. Безнең балалар укыган кара-каршы мәктәпләр дә, колхоз амбарлары да, тегермән дә — барысы да аныкы иде. Ун яшьтән мин аңа тамак ялына хезмәтчелеккә кердем. Нуриманга биш кенә яшь иде. Унбиш яшемдә мине мәзин күрше Бикбау байга ат илттерә башлады. Мин төнге ат караган җирдән хуҗа күрсәткән атка атланып алам да юлга чыгам. Мине, билгеләнгән урында, мин белмәгән кешеләр каршы ала; без атларны алмаштырабыз да мин кире кайтып китәм. Без ул атларны күрше авылның Карахмәт абзыйның абзарына кайтарып яба идек. Калганын мин белмим. Минем әти-әни юк. Җәй мәзин абзыйның печәнлегендә, кышын кара мунчасында йоклап гомер иттем. Ак мунчасына кертми иде. Тора-бара инде үзем белеп, ат караклыгына тартылып киттем...

— Гаепләнүче, мәсьәләнең асылын сөйлә: ни сәбәп сезне җинаять эшләргә этәрде?

— Менә шул инде. Нуриманны мин бай мәзин малае булган өчен дә, аның укымышлы, үземнең надан булганым өчен дә, аның бал-май эчендә йөзгәне, үземнең кара мунчада кара икмәк кимереп ятуым өчен дә, көнләшеп, каралай янып яратмый идем. Уникенче елны атасы Кәрим мәзин өченче хатынга өйләнгәндә Нуриманга егерме яшь иде инде. Ата белән улы шушы өйләнү аркасында бик нык бозылышып киттеләр. Улын дөнья сугышына җибәрмичә ничә ел саклап килгән мәзин абзый шуннан соң улын тота да сугышка җибәрә, аның урынына мине алып кала. Шуннан ата белән улының юллары дошман киселеп аерыла. Нуриман инде сугыштан ата бәлшәвик булып кайта. Аклар-кызыллар сугышында да кылыч уйнатып йөри. Унтугызынчы елны мәзин мәрхүмне кызыллар Минзәләгә тотып алып китәләр — шуннан югала мәрхүм. Мин — батрак. Мин калам. Яшь чак. Мин инде мәзиннең егерме яшьлек өченче хатыны белән шаярыштыра башлаган идем. Мәзин үлгәч, без өйләнешергә булдык. Нуриман волисполкомда иде. Бер көнне этрәте белән килеп төштеләр болар. Килеп төштеләр дә атадан калган барлык мал-мөлкәтне сәвиткә бирделәр. Яшь бичә торган дугайлы тәрәзәле йорт, аңа каршы торган тагын бер йорт мәктәп булды. Әнисе, энесе белән сеңелесе яшәгән алты почмаклы йортны гына үзенә алды Нуриман. Тегермәнне кооперативка бирде, атларны атсызларга өләште. Грамоталы кеше, барысын да закунный, кәгазьләр язып эшләде. Мин өйләнергә йөргән яшь бичә, аллаһе экбәр, битен сыйпап торып калды. Миңа, ничәмә ел үзләренә хезмәт иткән батракка, каккан казык та тимәде. «Ничауа, үзеңнең дә башыңа җитәр көннәр килер әле!» — дип мин, ач бүредәй шыңшып, койрыгымны кыстым. Аннары — Качкын урманы янәшә: үзебезнең исән калган караклар янына тайдым. Ләкин заманнар үзгәргән иде инде — мин тагын Нуриман хөкеменә эләктем. Исән кайтсам, барыбер үтерәм, дип колагыма киртеп куйдым. «Синең кулың батыр, йөрәгең куркак», ди торган иде миңа Нуриман. Моны да колакка киртеп куйдым. Ләкин җай чыкмады. Мин яшь чагымнан ук килгән кара көнчелекне җиңә алмадым. Мин — гомер буе батрак, көтүче: мин үз гомеремдә беренче тапкыр урамга ике генә тәрәзәсе карап торган бер өй салып керә алдым. Ә Нуриман — элек тә бай иде, хәзер дә бай, атадан калган алты почмаклы йортта яши. Әнә бит әле дә — минем малай утырмаган сезнең янга, Казаннан кайтып, Нуриман малае утырган.

— Мәсьәләгә кайт,— диде тикшерүче.

— Шуннан кырыгынчы ел җитә. Мәчет манарасын кистеләр. Миңа бу җай булды. «Вакыт җитте, дидем мин, балалар инде югалырдай түгел, власть та югалтмас», дидем. Мәчет манарасы кискәч, картларның бәддога укыганнарын искә алдым. Күршем Мәгъдәннең: «Үз башына чаша, коммунистларның да башы икәү түгелдер әле», — дип кеше ал-

дында әйткән сүзе дә ярап куйды. Миннән Мәгъдән чыгып китү белән, мин дә чыгып киттем. Тау битләп кенә турыдан МТС ягына киттем. Кузьма өендә ут күреп аска төштем. Аран капкасы кеше иркен керерлек кенә ачык. Инде болай гына кереп чыгыйм, Нуриманны очратмадым инде дип, керергә дип ишек төбенә килсәм — өйдән Нуриман тавышы килә. Мин капчыклар артына постым. Кулда әле минем пычактан башка корал да юк. Фидаил дә анда. Анысы да әйбәт. Анысы да манара кискән. Ләкин шунда минем башыма Кузьманың дуңгыз чәнчә торган безе килеп төшә. Аның верстак торган стенага башка инструментлар белән бергә кадаулы торуын беләм. Тегермән ишеге ябык, эчтә сүнәр-сүнмәс кенә фонарь яна. Минем инде караңгыга күзем күнеккән, яктыдан чыккан кеше мине күрмәсә дә мин — эттәй күрә идем. Барып безне алдым. Мин айный башладым, ләкин кулымда без белән бүрәнәне тишеп чыгарлык көч сизеп, каным котыра иде. Тегермәндәге кеше чыгып, мине күреп калса, аның да җанын алырга әзер идем. Нуриман озак юанмады. Өчәүләп чыктылар. Фидаил исерек иде, йомышын йомышлады да, кире кереп китте. Кузьма тегермәнгә кереп, анда хатын кеше икән, шуның белән сөйләшә башлады. Мин әкрен генә Нуриман артыннан киттем. Ул авыз эченнән генә җырлап кайта. Калганы нәрсә, тиз инде: бер кулым белән авызын кысып, яңагыннан каерып тоттым, икенчесе белән йөрәгеН айкап алдым. Тун тиресе генә мытырдагандай булды. Ыһ итеп кулы белән йөрәген тотты. Шулай тартышып үлгәнен көтеп тордым. Эше беткәч, якасыннан гына сөйрәп, тегермәннән ерак түгел генә җирдә суга илтеп салдым. Безне шайтан таяклары эченә ыргыттым. Мин мәетне агып китмәс дип уйлаган идем. Анда таррак та, тирәнрәк тә шул, әкрен-әкрен агып, безнең авыл башына ук килеп туктаган... Бу, бер яктан әйбәт тә булды, чөнки халык: Кузьмалар үтереп тә, гаебен безнең авыл кешеләренә япсарыр өчен, монда китереп ташлаганнар икән, дип сөйләделәр. Ә инде шайтан таягы эченнән Кузьманың безен дә тапкач, тикшерүчедә бернинди шик калмады...

Мәсьәлә ачык иде инде. Шулай да, Баһау карт сөйләп туктагач, тикшерүче: «Сораулар бармы?» дип ни өчендер миңа карады. Мин түзем кычытып:

— Инде кеше үтергәнне дә яшермәгәнне сыер суйганны гына яшермәссең, дип уйлыйм, әйт әле: чибәр җиңгинең сыерын син суйдыңмы?— дип сорыйсы иттем.

— Мин!— диде ул һәм, гәүдәсен турайтып, миңа кадалды, борынына кадәр тураеп киткәндәй булды.— Әле дә үкенәм: нигә сине шул чакны ат өстеннән генә сугып төшердем икән... Атаң кебек, йөрәгеңә без генә тыгып аласы булган да бит...

Конвойга аны алып чыгып китәргә куштылар.

Шул ук төнне Вахитов абый квартирасына шалтыратып, Баһауның үз үлеме белән үлгәнен хәбәр иттеләр.

Мин икенче көнне үк авылга кайтып киттем. Юматов абый сугышка китеп үлгәч, үзенә шуннан башка егет тапмыйча, кияүгә чыкмый калган зур апам белән әнием карчык мине елап каршы алды. Мин аларны сагынып кайтсам да, тизрәк кайтуымның сәбәбе — Баһау картны ялгыш әти янына күмеп куймасыннар, дигән уй иде. Аны бөтенләй икенче читкә — яз көне су җыела торган, элек-электән ялгыш, кара гомер кичергән мәетләр янына күмделәр. Безнең әтинең инде кабере җир белән тигезләнгән. Бөтен зиратында быел ике кеше күмелгән булып чыкты: берсе — абыйсы үтергән Хәмзә, икенчесе — аларның атасы, минем әтине үтергән Баһау карт кабере иде. Шулай — соң булса да ул да үз җәзасын алды. Ләкин — бик соң!.. Әтидән соң егерме ел буе һава сулагач, кояш күргәч...

1978

-----------

## Клара Булатова

### Беренчеләр идек

Без Әлмәттә беренчеләр идек,
Беренчеләр идек без монда.
Асфальт юллар җәйдек, өйләр салдык,
Шәһәр салдык яшьлек юлында.

Төзүчеләр клубында кичен
Яңгырап тора иде гармуның.
Яшьләр — кызлар шунда җыела иде,
Эштән кайткач онытып аруын.

Шоферлар да безнең, ташчылар да
Дәрт иде соң җырга-биюгә.
Төн уртасы җитми, уен бетми
Һичкем китми иде өенә.

...Бер өздереп җибәр әле, дустым,
Яшьлек кайтсын гармун моңында.
Без Әлмәттә беренчеләр идек,
Беренчеләр идек без монда.

●

Сез өч егет идегез,
Сөлек кебек идегез.
Хәзер кемгә дә сер түгел:
Өчегез дә сөйдегез.

Яраттыгыз, җан аттыгыз,
Телдән әйтми йөрдегез,
Сез ул чакта әллә тыйнак,
Әллә куркак идегез.

Хәзер хисне чылбырларлык
Куркаклык беткән инде.
Сүз-гайбәт тә берни тормый,
Тик... яшьлек үткән инде.

●

Июнь ае. Табигатьнең шундый ае;
Гомереңнең атып килгән якты таңы.
Яшьлегеңнең дулкын ярыр, канатланыр,
Җирне-күкне иңләр-кочар, очар чагы.

Июнь ае. Яшәешнең шундый чоры,
Синең алда иксез-чиксез өмет җире,
Синең белән ярыша-исә хыял җиле,
Синең җанда — сөю тулы җырлар иле.

Рәисә Ишморатова

# СҮЗ

хикәя



Фатих, ике сәгать чират торганнан соң, битен, маңгаен сөртә-сөртә, аэропорт кассасыннан чыкты да, кызу-кызу атлап тулай торакка кайтып китте. Аны шатлык хисе биләп алган. Аяк атлавы да, сулыш алулары да җиңел, рәхәт. Инде самолетның вакытында очуын, һаваларның бозылмавын гына теләргә калды. Быел, гомумән соңгы елларда, һава шартлары гомергә күренмәгәнчә кылана: я артык эссе, коры, яндыра, көйдерә, я кирәгеннән артык яңгыр коя, салкынайта, җил, буран чыга. Бабайлар да хәтерләми мондый көйсез, тотнаксыз елларны. Синоптиклар, мондый хәлләрне йөз елга бер генә кабатлана, диләр. Көзнең килүе дә адәм көткәнчә булмады. Октябрь аеның башыннан ук җиргә ак кар төште. Кешеләр: «Эрер әле бу кар, кояшның җылы нурлары кинәт туңып китүдән саклар», дип өмет иттеләр. Ләкин кар ябалак-ябалак булып ява бирде, җир өстен томалады. Кояш болыт астына кереп югалды. Көннәр суынганнан суына барды. Кешеләр өсләренә кышкы пальто, башларына җылы бүрекләрен киеп куйдылар.

Фатих шактый туңа башлаган кулларын пальто кесәсенә тыгып, кызу-кызу атлады. Сөмбелә соңгы хатында, кинәт суыклар башланудан зарланган, кырда чөгендер, бәрәңгеләр җыелып бетмәве турында борчылып язган: «Укучыларым белән мин дә кырга колхозчыларга ярдәмгә чыгам», — дигән...

Сөмбеләгә бәгелеп, авыр эшләр эшләп йөрергә ярамый бит хәзер. Авылга өч көнгә кайтам, үзем дә кырга эшкә чыгармын әле, дип уйланып алды Фатих һәм янәшәсендә Сөмбеләнең сулышын, тәненең җылысын тойгандай булды.

Әгәр Сөмбелә ялгышмаган булса, дүрт ай бит. Фатих уң кулының дүрт бармагын бөгеп куйды. Бәлки җан да кергәндер инде. Бүген ноябрьның икесе. Ул тагын бармакларын бөкте. Биш, алты, җиде, сигез, тугыз... Апрель башлары... Сәгатенә күз төшерде: Тагын егерме минуттан өченче дәрес башлана. Самолетка билет артыннан йөреп дәресләрне калдырган иде ул.

Бүлмәгә керү белән өстәлдәге хатларга күзе төште. Берсе туган авылыннан, апасы язган, икенчесе...

Фатих сул як читенә ландыш чәчәкләре төшерелгән конвертны кулында әйләндергәләде. Конверт тышында хат иясенең адресы язылмаган. Кичә генә Казаннан җибәрелгән. Фатих конвертны ачмый гына тумбочка өстенә куйды да, апасының хатын укый башлады:

«Фатих, туганым!

Хатны алу белән тизрәк кайтырга тырыш. Әни каты авырый. Кизүфәләндер, тиз үтәр дип, баштан сиңа язмый торган идем, рәтләнми. Көн саен кирегә китә бара. Сине бик көтә, күрми үләм инде, ди. Сырхау хәлен белеп булмый, туганым, зинһар кайта күр!.. Бу хәбәрне Сөмбеләгә язмый тор, яме!.. Әни Сөмбеләне дә бик сагына, бик күрәсе килә, шулай да сырхау икәнен белсә, бик кайгырыр. Аңарга кайгырырга, нервничать итәргә ярамый, үзең беләсең, туганым. Хуш. Кайт, яме!

Апаң Әминә».

Хатны кулында тотып, баскан урыныннан кузгала алмый уйланып торды Фатих. «Әни үлсә апа ялгыз калачак. Ничек чыдар апа бу олы хәсрәткә. Ә мин, мин нишләрмен?»..

Ничек сагынып, өзгәләнеп көтә иде әнисе Фатихның бер генә көнгә ялга кайтканын. Көнозын, аннан ярты төнгә кадәр сөйләшеп утырыр иде Фатих әнисе белән. Әминә апасы, әнине ялгыз калдыра алмыйм, дип әлегә кадәр кияүгә дә чыкмый бит. Фатих ун класс тәмамлап армиягә китте. Армиядән кайткач ул авылда калып эшләргә, читтән торып укырга теләгән иде. Әминә апасы аның авызын да ачтырмады:

— Мин сау-сәламәт чакта әни өчен дә, йорт-җир өчен дә борчылма. Казанга кит, укы, — диде. — Укып бетергәч, эшкә авылга кайтырсың, өйләнерсең. Шул чак мин дә кияүгә чыгармын, — диде апасы чын күңелдән.

Ул бары тик минем тормышым өчен генә яшәде, әни белән миңа ярдәмен күрсәтте. Үзен кайгыртырга, үзе өчен яшәргә вакыты калмады. Ә хәзер апа ялгызы...

Фатих икенче конвертны ачты.

«Фатих дус!

Сәлам сиңа. Шаулап, гөрләп килүче Октябрь Революциясе көне белән тәбрик итәм. Иң яхшы теләкләремне язам. Шул урында кинәт кулым калтыранды. Язаргамы, юкмы, дигән сорау килде күңелемә. Бәйрәм көннәрендә күңелсез хәбәр язып кәефеңне бозам. Сине яхшы белгәнгә, ихтыяр көченә ия булуыңа, тирән акыллы, һәрбер вакыйгага җитди карый алганыңа ышанып, всеж язарга булдым. Мин сине үзем дус дип саныйм. Кайчандыр синең белән сердәш тә идек. Хәтерлисеңме, пединститутгагы Мөнҗия белән булган мәхәббәт мажаралары?.. Хәзер менә уйлап та куям, бәлки әле Мөнҗиягә өйләнсәң бәхетлерәк булыр идең. Озын сүзнең кыскасы шул: мин күптән түгел синең хатының Сөмбелә яши торган авылда булдым. Сөмбеләне күрергә дип квартирасына бардым. Вакыт шактый соң иде инде. Менә шунда коточкыч хәл күрдем. Сөмбелә үзе яши торган йортның караңгы почмагында бер иргә сыенып басып тора... Мине күргәч алар берберсеннән читкә тайпылдылар. Мин ул кешене дә танып алдым. Мәктәп директоры Әюпов Мөҗип иде. Районга кайткач мәктәп директоры турында кайбер мәгълүматлар алдым. Хатын-кыз артыннан чабарга ярата, энергияле, чибәр. Директор буларак та яхшы эшли, тарих фәне укыта. Класска кергәч, иң яраткан эше матур кызларга күзен майландырып утыру икән. Сөмбелә белән дуслыклары күптән дәвам итә икән... Менә шул, Фатих дус, хәзергә хатка исем-фамилиямне куймыйм, всеж аңла, бу хат изге теләктән чыгып язылды. Син яшь бит әле, мөгез тагып йөрергә, дим...»

Фатихның күз алдында хәрефләр йөгерешеп, бер-берсен куышып йөри башладылар. Тагын, тагын нәрсәләрдер язылган иде. Ул артык

укый алмады. Хатны йомарлап кесәсенә салды, дәрескә соңга калганын аңлап, тиз генә чыгып китте.

Дәресләр тәмам булгач аның янына группаның старостасы килде:

— Йөзең көл төсле, күзләрең тонган, нәрсә булды, авырыйсыңмы?..

Эх!.. Шул авыр минутта барлык эч пошуларыңны сөйләп ташлыйсы иде, күңелең бушап калыр иде. Кешегә сөйли торган хәлмени. «Сының катса да серең бирмә», дигәннәр бит. Ир кеше җиңел генә ачылып китә алмый шул.

— Ашказаным авыртып борчып тора, — диде Фатих староста белән янәшә атлап.

— Мин сине «Акчарлак»ка чакырмакчы идем... Бүген абзаңның туган көне. Бер-ике иптәш белән генә барып утырырбыз дигән идем.

— О!.. Котлыйм, дускай, котлыйм! — дип Фатих старостага кулын сузды. Хөрмәтләп чакыргач, бармый булмый, сәгать ничәгә?..

— Әйдә, хәзер үк киттек!..

Бусы чын ирләрчә иде. Ресторан. Өстәлгә ничәдер шешә эчемлек куеп дуслар белән гәпләшеп утыру. Кайгы-хәсрәтне онытып тору өчен иң зур дәва. Шунда инде бик авыр чишелә торган мәсьәләләр җиңел генә чишелеп тә куя. Хәсрәтләр дә онытыла. Фатих бер-ике рюмка коньяктан соң җиңеләеп киткәндәй булды.

— Рәхмәт кенә яусын старостага, иң кирәкле чакта туган бит... Башка вакытта чамасын белеп кенә эчә торган Фатих бераз арттырып та җибәрде. Иптәшләре янында көлеп-шаярып утырырлык хәлгә килер өчен генә. Үзендәге күңелсезлекне кешегә белдереп аларның кәефләрен бозу мактаулы эш түгел бит. Хәзер аның йөзе алсуланып киткән. Күзләре дә очкынланып бик сөйкемле булып, зур булып ачылганнар. Күпмедер вакытка эчпошыргыч хәлләрдән котылыуына ул үзе дә нык шат иде. Ярты төн якынлашканда гына тулай торакка кайттылар. Староста яши торган бүлмәнең ишеген ачып керсәләр шаккаткыч хәл күрделәр. Бүлмәнең уртасына ике өстәлне бергә куеп, өстенә газеталар җәйгәннәр. Нәрсә генә юк өстәлдә. Авылдан кемгәдер каз килгән, тавык, йомырка, кортлы май, барсы да өстәлгә менеп тулган. Ак аракы, сыра, кызыл аракы.

Староста белән бергә укучы студентка кызлар өсләренә иң матур күлмәкләрен киеп юбилярны көлә-көлә каршы алдылар:

— Безне, кызларны ресторанга чакырмадың, иптәш староста, менә без сине үзебез чакырып, туган көнеңне үткәрергә булдык, — дип, әле берсе, әле икенчесе старостаның битеннән чуп-чуп үптеләр... Җырлап-биеп таңны аттырдылар яшьләр...

Үз бүлмәсенә чыгып тумбочка өстендә яткан апасының хатын күргәч Фатихның йөрәге «жу» итеп китте. Ничек әле ул әнисе янына кайту турында бөтенләй уйлап та карамаган?.. Ул хатны алып староста бүлмәсенә ашыкты.

— Әйттем бит, йөзең көл күк, дип, ашказаным, имеш. Әнә сәгать алтыда Арча поезды китә, шуның белән китеп бар. Әни, әни инде ул. Барлык эшне ташлап аның янына кайтырга кирәк, — дип сөйләнеп калды староста, Фатих бүлмәсенә чыгып киткәндә.

Күкрәк кесәсендәге йомарлап тыгылган теге хат та Фатихның тәнен яндыра, көйдерә башлады.

Нишләргә? Тагын бер кабат хатны укып карарга иде, булмый. Кулга да тотасы килми. Ертып ташларга... Юк!.. Хат ул имзасыз булса да хәбәр... Шактый гына күләмдә эчелгән, аракы ми күзәнәкләрен томалаган. Башта тоташ томан шул ук зәңгәрсу томан күзләрне дә әлҗе-мәлҗе китерә. Аяк-куллар җеп белән бәйләп асып куйган шикелле, хәлсезләнеп калганнар. Уйларның һич очына чыгып булмый, буталалар...

«Әйтәм аны Сөмбелә һаман саен директорны мактый, талантлы кеше, бигрәк тә яшь кадрларга игътибарлы, ди...» Директорның яхшы кеше булуы, шул яхшы җитәкче эшләгән мәктәптә Сөмбеләнең эшкә урнашуына Фатих элек бик шатланган булса, хәзер, шул директор аның чибәр хатыны белән шухри-мухри уйнап йөри икән. Утсыз төтен булмый, без капчыкта ятмый, абзыкаем. Әйе, әйе... Ул тәрәзә төбендәге конвертны алып, кесәсендәге имзасыз хатны конверты-ние белән бергә шунда салды. Нәрсәдер исенә төшеп, хатны кире алды да, кәгазьнең бер як читенә үз сүзләрен дә өстәп, конвертны ябыштырды. Тышына Сөмбеләнең адресын язды. Тагын беравык конвертка карап торды: «Җибәрергә кирәк, җибәрү хәерле. Сизенми димәсен әле... Мине яхшы белүче язган. Казаннан. Юк, җибәрмим...»

Ул караватында ятар урынын туздырып ташлады. Мендәрен кабарткандай булды. Пинжәген салып урындык башына элде... Аны йокы басты, озын гәүдәсе җилдә тирбәлгән агачтай селкенгәләп куйды. Ул сирәк эчә, иптәшләре, син эчә дә белмисең, бер рюмка эчсәң, чөгендер күк кызарасың, телләрең бутала, гәүдәң чайкала, дип, аңардан көләргә яраталар. Ә бүген ресторанда ул бер рюмка белән генә калмады. Тулай торакка кайткач, кызлар сыеннан да баш тартмады. Әнә күрше бүлмәдә акрын гына музыка ишетелә. Туган көн бәйрәме дәвам итә иде.

«Старостаны юалар... Ә нигә мин әле бик иртә компаниядән аерылдым, нигә әле миңа тагын бераз буталмаска»,— дип уйлана-уйлана Фатих пинжәген иңенә салды да, ава-түнә атлап бүлмәдән чыгып китте. Тик ул музыка тавышы килгән бүлмәгә түгел, ә урамга, тулай торак ишеге янагында эленеп торган почта тартмасына таба атлады. Кулындагы хатына бераз карап торды да, кеше-фәлән күрмәгәе, кулымнан хатны тартып алмагае дигәндәй кабаланып, тартмага төшереп җибәрде. Аңа кинәт җиңел булып китте. Күкрәк кесәсендә иртәдән бирле йөрәкне көйдереп торган авыр нәрсәдән котылды ул. Салмак атлап бүлмәсенә керде. Тагын бер сәгатьтән Арча ягына, әнисе янына бара торган поездны да онытып караватына йөзтүбән ятып йокыга китте.

*
* *

Агачлардагы яфраклар саргаерга да өлгерми, яшел килеш ак карга төренделәр. Бик уңган колхоз җитәкчеләре дә һич көтелмәгән һава шартларына әзерлексез булып чыкты. «Алга» колхозының бәрәңге белән чөгендердән тыш барлык культуралары да җыйналып беткән иде. Кырда җыелмый калган чөгендергә колхоз бөтен көчен куярга тырышты. Кыйммәтле чималны хәзерләү пунктына эшкәртеп озатуда авыл халкы — пенсионерлар, укытучы, укучылар катнашырга тиеш булды. Сөмбелә сигезенче класс җитәкчесе, соңгы дәресе тәмамлангач үз классына керде. Укучыларга карап куе кара керфекләрен сирпеп елмаеп куйды:

— Өйләрегезгә кайтыгыз, ашап эчәргә бер сәгать вакыт җитәр дип уйлыйм. Өс-башларыгызга җылырак киенегез. Син, Наҗия, — диде ул икенче партада утыручы сары чәчле, борын очларына әз генә сипкел сибелгән кызга җитди итеп карап, — капрон оек киеп киләсе булма яме! Кичә мин сине, туңасың, дип кайтарып җибәрдем. Бүген инде алдан әйтеп куям, җылы киен.

Сөмбелә класстан укучылар чыгып беткәнне көтте дә ике тәрәзәнең дә форточкасын ачты. Башын артка салып тирән итеп сулу алды. Чуалган уйлары кинәт ачылып киткәндәй булды. Ул, өстәле янына урындыкны тартып утырды да, ике кулын да эченә куйды. Тын гына,

бөтен дикъкатен биреп тыңлый башлады. Кул астындагы кыймылдауны бөтен әгъзалары белән сизәсе, аның сулавын колаклары белән ишетәсе килде. Менә эчтә бер дулкын сизелде. Тагын!..

«Җаным, бәгърем! — Сөмбелә аскы иреннәрен тешләде, күзләренә шатлык яшьләре тулды.— Фатих, кайт инде тизрәк, кайт! Бәбиең йөри башлады бит, Фатих!»

Фатир хуҗасы, колхозның сыер савучысы Салиха апа, Сөмбеләне ишек алдына кадәр каршы чыгып алды. Аның кулында конверт иде.

— Биеп җибәр әле, алтыным, яле! Менә!

Салиха апа конвертны кулында уйнатты. Сөмбелә ишек яңагына сөялде. Аның зур коңгырт күзләре очкынланды, озынча ябык йөзе алсуланды.

— Салиха апа җаным, рәхмәт... Биеп торырга вакыт юк, чөгендер эшкәртергә механизаторлар янына барабыз. Кичкә яме, биермен дә, җырлармын да. Әйдә кичкә минем белән клубка, Салиха апа.— Ул Салиханың иңеннән кочаклады. — Анда бүген соңгы репитиция, бәйрәм концерты бик шәп булырга тиеш. Фатих исән-сау кайтса, аяында ул уйнар, мин җырлармын...

Сөмбелә хатны күкрәгенә кысты.

— Ишеттеңме, Салиха апа, бәйрәм концертында син беренче рәттә утырырсың, мин сиңа карап кына җырлармын...

Кайчакларда бик кирәк булган хатлар, ниндидер сәбәпләр аркасында, ике көн киләсене, атналар буе хуҗалары кулына килеп эләгә алмыйлар. Ә бу, эчендәге ак кәгазьнең һәр юлында кеше гомерен кыскарта торган агулы сүзләр язылган хат, икенче көн дигәндә иясенә килеп керде. Үзе белән никадәр кайгы-хәсрәт, бәхетсезлек алып килде ул.

Салиха апа ашыгып өстәлгә ашарга әзерләде. Мич башыннан Сөмбеләнең йон оекбашын, киез итеген китереп куйды:

— Иртәгә бишесе, кайтыр инде Фатих име, алтыным,— дип сөйләп китте Салиха апа мөлаем күзләре белән Сөмбеләгә карап.— Мунчаны юып чыгардым, казанына тутырдым. Үзе күренү белән миченә ут төртеп җибәрәсе генә калды. Чырасына кадәр телеп куйдым, Теге, вакытлы-вакытсыз кычкырып йөдәткән әтәчне тотып аягын бәйләп куйдым.

— Әй, Салиха апа, җаным! Мәшәкатьләнәсең дә соң. Әнә бәрәңге Фатихка.

— Бәрәңгене ярата ул, — дип көлеп куйды Салиха. Сөмбелә тәрәзә кырыена басып хатны укый башлады. «Ә?» дип куйды. Хатны кулында әйләндергәләде, кәгазь читенә язган коточкыч сүзләрне дә укыды:

«Әй, Сөмбелә, Сөмбелә, мин бит бала көтә идем. Ә хәзер... Минем баламмы соң ул? Кая безнең бала, ә? Барысы да бетте! Синең янга кайтырга алган билетымны ертам бу минутларда...»

Аптырап, ни дияргә белми торараш күк басып калды. Салиха апа чынаякларга чәй ясады, хуш исләре бөтен бүлмәгә таралган итле бәрәңгене мичтән алып өстәлгә китереп куйды.

«Әй, раббем, көч бир, көч... ничек кенә өстәл янына барып утырыйм? Ичмасам, Салиха апа бер генә минутка, мин бераз аңыма килгәнче чоланга чыгып керсен иде...»

Сөмбеләнең касыгына нәрсәдер килеп тыгылды, күз аллары караңгыланды. Өйдәге барлык нәрсәләр зыр-зыр әйләнәләр. Чыжлап торган самаварның кайнар суы Сөмбеләгә ага түгелме соң, аның аякларын, беләкләрен яндыра бит.

— Утыр, алтыным, ризык суына. Ашап эчкәч бераз ятып тор, синнән башка да эшләрләр әле анда. Авылда бер кеше дә калмаган, барысы да чөгендер басуында...

Сөмбелә мич артындагы бит югычтан сөлгегә салкын су агызып муен тирләрен сөртте.

«Сиздермәскә, Салиха апага гына сиздермәскә, борчыла башлар...» Сөмбелә өстәл янына килеп утырды да кайнар чәйнең иреннәрен, авыз эчен яндырганын да сизми ашыгып эчә башлады.

Унсигез яшьтән бик яратып кияүгә чыгып, өч көн генә ир белән торып калган хатын иде Салиха апа. Ире беренче көннәрдә үк сугышта һәлак булды. Аннан туган улы, Инсаф, ун яшькә җитеп, суга батып үлде. Әнисе Сәгыйдә карчык биш ел буенча урын өстендә сырхаулап ятты. Аны җирләде. Егерме биш ел өзлексез фермада сыер сауган Салиханың тәрәзәләре кояшка каратып салынган алты почмаклы матур өенә соңгы елларда, кайгылы, шомлы хәбәрләр килми иде әле. Һаман шатлык та шатлык. Салиха апа тырышып эшләгәне өчен макталды да макталды. Бүләк өстенә бүләк килде. Әле күптән түгел генә Казаннан ерак та түгел, Васильево санаториена барып, дәваланып, сәламәтлеген ныгытып кайтты. Әшен дә икеләтә көч белән эшли башлады. Ике ел инде күрше авыл кызы укытучы Сөмбелә фатирда тора. Сөмбеләне ул үз кызыдай якын күрә, ярата. Сөмбелә дә апаем, җаным, дип, өзгәләнеп кенә тора.

Мәктәптә генә түгел, авылда да Сөмбеләне бик нык хөрмәт итәләр. Фатихы да яхшы кеше. Инде менә бәхет өстенә бәхет дигәндәй. Сөмбеләнең карынында мәхәббәтнең беренче чәчкәсе. Әле ул бик кечкенә, яшь ханымның зифа тәнендә бөтенләй сизелми дә. Авыл акушеры Гөлинә Әхмеровна гына белде ул чәчкәнең анда шытып ятуын. Салиха апа белән өйгә килеп сөйләшеп утырды ул:

— Син олы кеше, Сөмбелә Закировнага күз-колак була күр. Яшь кеше аны-моны уйламый, җилкенчәк була, авыр әйберләр күтәрмәсен, таеп егыла күрмәсен, алай-болай берәр нәрсә сизенсәң, үземә әйтә күр...

Сөмбеләнең күңелсез хат алуын төшенгән Салиха апа, тиз генә ашаган итте дә, бераз эшләрем бар иде, дип, өстенә пинжәген киеп, өйдән чыгып китте. Ул ишегалдыннан беркая да китмәде. Мунчага керде дә, тәрәзәнең пәрдәсен төшереп, бер читен эз генә ачык калдырып Сөмбеләнең өйдә нишләп йөрүен күзәтә башлады. Сөмбелә караваты куелган стена буе мунча тәрәзәсеннән аңа ачык булып күренеп тора иде.

Сөмбелә ике кулына башын салып озак утырды. Урыныннан кузгалырлык хәле юк иде аның. Ныклабрак уйларга да көче җитмәде. Аяклары хәлсезләнгән, зиһене дә томан белән капланган кебек.

Мәктәптән кайткан киемнәрен дә алыштырмыйча кырга эшкә барырга чыкты Сөмбелә. Салиха апа аның юлын бүлде:

— Алтыным; Сөмбелә, нишләвең бу, шулай җиңелчә киенеп эшкә бармыйлар инде, күр, аягыңда капрон оек, сап-сай туфлиләр. Бу разна арасында балчыкка батып, салкын тидерерсең.

Сөмбелә яше тамарга торган күзләрен тутырып өй хуҗасына карады. Карады да «ә» диде. Аннан, чалыш-чолыш атлап, төркем булып үзенә таба килгән сигезенче класс укучыларына таба китте.

Салиха апа өйгә кереп хатны эзләде. Сөмбеләнең карават янына килеп, мендәрен күтәреп карады. Хат шунда иде. Салиха мендәренең кырыен күтәргән килеш хатка карап бераз уйланып торды да, тәрәзә янына барып, таш юл салынган урамга карап тора башлады. Идарә бинасы, культура йорты түбәсенә бәйрәмне каршылап кызыл байраклар элингән. Урамнан берәм-берәм генә кешеләр уза. Әнә сөзәк кенә тау өстенә калын булып кар болыты агыла. Карлар өстендә кешеләр төркеме. Алар карлы-бозлы җир белән аралашкан чөгендерне тазартып машиналарга төйиләр. Сөмбеләләр төркеме дә шул кырга китте. Ябалак-ябалак кар ява башлады. Җир өсте агарган-

нан-агара барды. Тик Сөмбеләнең күңеле генә аклыкны күрми, аңа җир генә дә түгел, бөтен кешеләр кара күңелле булып күренә иде хәзер. Ефәктәй коңгырт озын чәчле, зифа буйлы, кешеләрне, табигатьне өзелеп сөйгән, тау чишмәсе тавышын хәтерләтеп көлә белгән, саф күңелле яшь ханымга, берничә айдан ана булырга җыенган кешегә, пычрак яла ягылды.



* * *

Алтмыш километр җирне электричкада, тагын шулкадәр араны автобуста узып, төш якынлашканда Фатих авылына кайтып керде. Ул туган-үскән авылына айга бер мәртәбә кайтмый калмый. Кайткан саен авылны җентекләп, беренче күргән кешедәй карап, күзәтеп йөри.

Бер кайтканда авылның кырыенда гына, бөкшәеп утырган иске өй урынына, түбәләре шифр белән ябылган алты почмаклы өй салынган була. Икенче кайтканда, икенчесе. Узган айны дүрт йөз урынлы культура йорты ачтылар. Ә бу кайтканда яңа пекарня бинасының түбәләрен ябалар иде. Анысын инде Фатих күрмәде. Ул, башын түбән иеп, бераз бөкрәя төшеп, каршысына килгән кешеләрне дә күрмичә, эленке-салынкы атлый бирә. Ачык чырайлы, үзен һәр җирдә бик тыйнак, әдәпле тота белгән Фатихның шундый күңелсез кыяфәтен күреп берәү дә гаҗәпләнми. Авыл халкы аның белән бергә хәсрәт кичерә. Изге күңелле ананың, гомерен шул авылга, колхоз төзелешенә биргән кешенең, үлем белән көрәшеп ятуы, туганнарын гына түгел, бар кешенең дә күңелен телгәли иде.

Фатих ике тәүлек әнисе яныннан китмичә утырды. Өченче тәүлектә ана вафат булды. Үләр алдыннан Фатих белән Әминәгә:

— Мин үлде дип җыламагыз,— диде.— Яшәдем, ачысын да, төчесен дә татыдым дөньяның. Рәхәт чагым да, михнәтле чагым да булды. Иң зур шатлыгым, бәхетем сез, ике балам, күз нурларым һәйбәт, кешелекле булдыгыз. Тик оныгымны гына күрә алмыйм. Кыз булса, Фирдәүсә, ир бала булса Фәнис исеме кушыгыз,—диде. Кыз булса, алтын йөгертелгән саф көмеш беләзекләрен бүләк итәргә кушты. Сөмбеләгә киленемә, дип, чын ахак муенсасын бирде.— Зинһар, улым, хатының белән тату яши күр. Сөмбеләң һәйбәт кеше, улым. Аңа мең рәхмәт, мине хөрмәт итте, әнкәй, дип өзгәләнеп эндәшә белде. Апаң Әминәне олылый белде. Авыз ачып сүз әйтмә, кул күтәреп сукма, разый түгелмен.— Әнисе сөйләгәндә Фатихның йөрәге урыныннан чыгып китәрдәй булып сикерде, күңеле пәрә-пәрә килде. «Әгәр әни белсә, исерек килеш, хатны Сөмбеләгә җибәргәнне, хатны гына түгел, үз кулы белән нәрсәләр язганын белсә, ярый әле белмәде». Ул әнисен күмеп кайткач барысын да апасына сөйләде. Апасы елыйелый шешенеп беткән күзләрен озак кына куллары белән томалап башын аска иеп утырды да:

— Картлар белеп әйткәннәр, хәсрәт ялгыз йөрми, дип. Тагын бер хәсрәт килә икән башыбызга,— диде.— Аннан элгечтәге Фатихның пальтосын алды да, энесенең иңсәсенә салды.

— Бар, хәзер үк кит, бер сәгатьтән автобус була.

— Нишлисең син, апа, энинең өчен дә үткәрмичә?..

— Беләсеңме син нахак сүз ишетү нинди авыр икәнен, үлем белән бер бит. Үлгән кеше артыннан үлеп булмый, сәламәт кешене үтермәскә кирәк. Әгәр син кайтмасаң, белмим, Сөмбелә белән нәрсә булыр, нечкә күңелле кеше бит ул синең хатының,— дип, Әминә Фатихны өйдән автобуска озатып җибәрде.

*
* *

Сөмбелә төне буе авырып чыкты. Температурасы күтәрелде. «Башым сызлый»,— диде. Салиха апасы аның аягына грелка да куйды, бал болгатып кайнар сөт тә эчерде. Капка яки лапасларда берәр шыгырдау ишетсә, Сөмбелә, мендәреннән башын күтәреп, тавышка колак салгалады. Менә генә Фатихы кайтып керәр шикелле тоелды аңа.

— Иртәгә ялт итеп кайтып җитәр әле Фатихың, иреннәрен колагына кадәр ерып, килеп керер әле ишектән, менә күрерсең, — дип сөйләнде Салиха апа.

Иртәгесен беренче дәрес, унынчы классларда, Сөмбелә фәне — география дәресе иде. Укыту бүлеге мөдиреннән ничек кенә булса да үз дәресен башка фән белән алмаштыруларын үтенеп, Сөмбелә почтага йөгерде. Бер сәгатьләп көтеп, телефоннан авыл хуҗалыгы институтының тулай торагы белән тоташты. Дежурныйның өч минутта Фатих бүлмәсенә барып килүе өч сәгать кебек тоелды аңа. Нәрсә әйтер, табарлармы аны, дип куллары, аяклары дер-дер калтыранды.

— Бүлмәләрендә берәү дә юк,— диде аңа дежурный.

— Зинһар, бик үтенәм, Фатих Хәмидуллин кайткач авылга, хатынына шалтыратсын, яме! Зинһар. Яхшылыгыгызны беркайчан да онытмам.

Бөек бәйрәм хөрмәтенә мәктәп, культура йорты яннарында якты утлар кабынды. Алдынгы колхозчылар, механизаторлар рәсеме эленгән мактау тактасына куелган лампочкалар аеруча якты яналар. Культура йортына халык җыйнала башлады. Читтән килгән кунаклар да, үз авылдашлары да, иң башлап шул мактау тактасы янында басып үзләренең ата-аналарының, туганнарының йөзләренә карап торалар. Мактау тактасында Сөмбелә белән Салиха апаның да рәсемнәре бар. Урамда гармун моңнары яңгырады. Өй саен кунак. Шәһәрдән дә кайталар, күрше авыллардан да киләләр. Тик Сөмбеләләр өендә генә моңсу тынлык. Эчне пошыра, күкрәкне кыса торган тынлык. Сөмбелә өйдә берүзе караватында ут шикелле кызышып ята бирә.

Нинди көтелмәгән хәл булды соң әле? Шатланып бәйрәм көннәрен көтте. Мәктәптәге иң яхшы укучыларны, авыл яшьләрен җыйнап, бәйрәм кичендә чыгыш ясарга зур концерт оештырылды. Сөмбелә үзе дә җырлаячак иде. Фатих: «Син җырларсың, мин баянда үзем уйнармын, берәр көн алдан кайтып репетиция ясарбыз»,— дигән иде бит. Нигә соң Сөмбелә шулай сыгылып төште әле. Ул андый йомшак түгел иде бит. Чыдам, сабыр иде... Әнисе үлгәч бик каты кайгырды, күп елады, шулай да урын өстендә авырып ятмады бит... Әллә эчтәге кечкенә генә кеше аның тәнендә шундый нык үзгәрешләр кузгатты микән? Нигә соң әле аның эче авыртып-авыртып куя? Башы чүкеч белән суккандай доң-доң итеп тора. Колак эченә көчле мотор куйганнармыни, нидер шаулый, гүли...

Күңеленең бик тирән бер җирендә Сөмбелә оялу хисләре сизде. Фатихы өчен оялды, йөзе кызарды. Уйламаска тырышты. Фатихында бит ул һичбер төрле җитешсез як тапмый иде. Бу хәлне ничек аңларга соң? Ул бит бик җиңел уйлаучан, үзенең хатынының холкын-фигылен белмәгән, белсә дә аңларга теләмәгән әхлаксыз ирнең эше. Берсе артыннан берсе шундый сораулар туудан йөдәп бетте Сөмбелә. Ничек аңларга инде моны, ә? Бер-береңне белү өчен ирле-хатынлы булып яшәгән өч ел гомер генә аз икән. Димәк, аның Фатихы көнчел, җиңел уйлаучан... Ул караватында бәргәләнде, иреннәрен кан чыгарлык итеп тешләде.

Кулына зур гына төргәк күтәреп бәйрәм кичәсеннән Салиха апа кайтып керде.

— Мәктәп директорының докладын тыңладым да, өйгә йөгердем. Ашыккач бүләкне дә беренче итеп бирделәр. Менә кара, алтыным.— Ул целлофанга төргән стена сәгате алып Сөмбелә каршысына килеп басты.

— Рәхмәт төшсен инде, эшләгәннең кадерен беләләр, ичмасам. Эшләмәгән җиреңнән эшләрсең, билләһи. Алтынкаем, мәктәп директоры докладында сине дә бик мактап әйтте.— «Сөмбелә Закировнаның классы мәктәптә иң алдынгы класс, узган уку чорында бер генә укучы да тәртип бозмаган, бер генә укучы икеле билгесе алмаган. Сөмбелә Закировна укытучыларның да, ата-аналарның да хөрмәтен яулады», ди. Шулай дигән иде, әй кул чапты халык, күземә яшь килеп тыгылды. «Үзе кая, нигә бәйрәмгә килмәгән?» — дип йөдәтеп бетерделәр, алтынкаем, нәрсә дияргә дә белмәдем... Авырый дип, әйтәсе килми, кеше ышанмаслык бит билләһи... Кайчан синең авырганың бар, ходай сиңа сәламәтлекне мул итеп биргән... Нәрсә генә булды соң бу...

Шыгырдап капка ачылды.

— Әнә кайтты, кайтты,— дип Сөмбелә кызуланып урыныннан кузгалды. Салиха капкадан керүчегә каршы чыкты. Кулына кечкенә чемодан тотып Гөлинә Әхмәровна кереп килә иде.



*

* *

Сөмбелә тагын кызарып чыкты. Ул уңайсызланып кына идәнгә аякларын куйды. Гөлинә ашыкмый гына пальтосын ишек төбендәге элгечкә элде, зәңгәрсу мохер башлыгын салды. Стенага беркетеп куйган кечкенә генә көзге каршысына килеп чәчен рәтләгәндәй итте. Көзгедә Сөмбеләнең йөзенә күз төшерде. Нәрсә булган? Ике көн элек кенә пешеп торган кура җиләгедәй хатын сулып калган, ни бу?.. Аннан ул Сөмбелә янына килеп, ярым елмаеп.

— Чөгендер эшкәртергә баргач салкын тидергәнсең, мөгаен. Мин сиңа әйттем бит, йөрмә, дидем. Анда синнән башка да эшләүчеләр күп. Тыңламыйсың син, һаман үзеңчә.— Гөлинә шулай диде диюен, ләкин Сөмбеләнең авыруы салкын тиюдән түгел, ә ниндидер зур күңелсезлек булудан икәнен яхшы сизенде ул. Кинәт күтәрелгән кан басымы шул турыда сөйли иде.

— Сез дә Гөлинә Әхмәровна, бәйрәм тантанасын калдырып монда килдегезме? — диде Сөмбелә оялып кына.

— Сине бит, Сөмбелә, президиумга сайлаганнар. Карыйм, син анда юк. Мөҗип Галиевичтан сорыйм, ул да җилкәләрен сикертә: «Бәйрәм тантанасына хәзерлекне Сөмбелә оештырып йөрде, үзе күренми, көндезен дәреслар үткәрде», — ди. Шуннан чыктым да, синең янга йөгердем инде...

Гөлинә Әхмәровна Казанда туып үскән, медицина институтын тәмамлап, Казанның беренче гинекология клиникасында тәҗрибә узган, ә эшкә шушы авылга килгән иде. Аңарга Казанда калырга да мөмкинлек бар иде. Тик ул үзенең мәхәббәте белән аерылышасы килмәде. Сөйгән егетен, пединститут студенты Әюпов Мөҗипне шушы авылның унъеллык мәктәбенә тарих укытучысы итеп җибәрделәр. Бишел узып та китте. Хәзер аның ире Әюпов — мәктәп директоры, ә үзе ул — Гөлинә Әхмәровна авыл кешеләренең хөрмәт иткән докторы.

Алар авылга килгәндә ике катлы мәктәп бинасына нигез салына гына башлаган иде. Узган ел яңа мәктәп өлгерде. Әюповны мәктәп ди-

ректоры итеп куйдылар. Яңа мәктәпне җитештерүдә бөтен мәшәкатьне үз җилкәсендә күтәрде ул. Гөлинә дә кул кушырып утырмады. Колхоз яшьләре көче белән агачтан гына булса да амбулатория, шунда ук балалар тудыру бүлмәсе төзелде. Махсус дәвалану таләп ителмәгән авырулар хәзер үз авылларында, үз «больницаларында» ятып дәваланалар.

— Нәрсә булды, ә? — дип Гөлинә Әхмәровна Салиха апага сорау белән карады. Салиха нәрсәдер әйтергә теләде. Күзләре Сөмбеләнең мендәренә текәлде. «Шунда бит бөтен гаеп, авыруның сәбәбе шул хатта гына бит, ничек аңлатырга соң». «Бәлки Сөмбелә үзе докторга сөйләр әле, хатта нәрсәләр язылганны әйтер», — дип уйлады ул.

Гөлинә Әхмәровна тиз генә урыныннан торды да пальтосын кия башлады. Сөмбелә аның кинәт кенә китүеннән куркынып калды. Аның ялгызы гына каласы килми, монда аңа хәзер әллә ничек куркыныч, әчпошыргыч иде.

— Гөлинә Әхмәровна!..

— Әү, Сөмбелә... Тыныч кына ятып тор, акыллым. Мин хәзер Мөҗип Галиевич янына барам. Машинасы белән сине амбулаториягә алып китәрбез. Анда ятып торырсың. Мин дә синең янында...

— Гөлинә Әхмәровна!.. Миңа бик авыр. Сез миңа операция ясагыз...

— Операция?.. Ниткән операция?..

— Бала кирәкми, тумасын ул... — Сөмбелә үксеп елап җибәрде. Гөлинә калтыранып куйды. Уң кулының учы белән Сөмбеләнең башын тотты.

Гөлинә юлдагы тигезсез җирләргә аягы таеп ничә мәртәбәдер сөртенде, егылып тез башын бирттерде. Культура йортының сәхнә артындагы бүлмәсенә узып алдагы рәттәге кешеләрне карады. Ире колхоз председателе белән янәшә утыра, концерт тыңлый. Сәхнәдә сыер савучы Тәслимә залны яңгыратып «Кәккүк» көен җырлый. Җыр кешеләрне рәхәтләндерә. Гөлинә, җыр тәмам булу белән Мөҗип Галиевичны бүлмәгә чакырып килүләрен үтенде дә үзе, өстендәге киемен дә салмыйча, йомшак диванга утырып, башын кулларына куйды:

— Нәрсә булды, кая югалдың син, Гөлинә?..

— Утыр әле...

Мөҗип Галиевич хатынының йөзенә карап, нindidер мөһим бер хәл барлыгын сизенде. Тантана беткәнче үк Гөлинәнең залдан чыгып киткәнен ул күрми дә калган иде. Концерт башланыр алдыннан аны эзләп тә тапмагач, эче пошып, бер ялгызы залга кереп концерт тыңлый башлады. Ул аяк өсте басып хатынына карап торуын дәвам иттё.

— Мөҗип, яшерми генә әйт әле, Сөмбелә Закировнага мәктәптә берәр күңелсезлек булдымы әллә?..

— Күңелсезлек?.. — Мөҗип иңбашын сикертеп куйды.

— Каты авырган ул, баламны тудырасым килми, ди...

— Ә?.. Куркытма әле, Гөлинә. Нәрсә бу? — Мөҗип куллары белән үз-үзен кочаклап Гөлинәгә якынрак килеп басты.

— Үзең ишеттең, Гөлинә акыллым, докладымда аны яхшы яктан телгә алдым. Урыны президиумда... Мөгаен, салкын тигәндер аңа. Кичә кырда укучылары белән бик каты эшләп йөри иде. Игътибар иттем әле, аягында юка оек, үзен дә әйтер идем... — Ул бераз уйланып торды да: — Больничный биргән булсаң, эштән азат иткән булсаң, ярамадымы? — дип хатынына шелтәле караш ташлады Мөҗип.

— Сүз кәрәштереп торуның файдасы юк хәзер... Алып кил машинаңны, амбулаториягә китерим... Кан басымы бик югары. Кинәт күтәрелгән. Салкын тиюдән түгел бу, түгел...

* * *

Ишектән Мөҗип белән Гөлинәнең килеп керүен күргән Сөмбелә өстендәге одеялы белән башыннан ук томаланды.

— Сөмбелә, менә без сезне алырга килдек, — диде Гөлинә, ә үзе бүлмәдән Салиха апаны эзләде. — Салиха апа, киендерергә ярдәм итегез әле.

Салиха апай өйгә кермәгән иде әле. Гөлинә, Мөҗипкә, Сөмбелә белән сөйләш, дигән мәгънәне аңлатып ымлады да, өйдән чыгып китте.

Абзар кырыенда Салиха апа басып тора иде. Гөлинә аның янына килде.

— Салиха апа, әйт инде, нәрсә булды Сөмбеләгә?

— Салкын тигәндер. Яланаяк кар өстендә йөргәч, капрун оек кигән кызларны мин яланаяклылар, дим. — Салиха апа башындагы шәлен рәтләгәндәй итте, ишеккә сөяп куйган агач көрәкне икенче җиргә алып куйды.

— Мин бит доктор, Салиха апа. Барысын да белергә кирәк миңа, аңлыйсыңмы, әйтәләр бит, чирен яшергән үлгән, дип. Диагнозны дөрес куярга кирәк бит...

— Ни дим, үзем дә йөдәдем, җылыйм да җылыйм. Төне буенча ут кебек янды, әллә ничә аспирин эчте.

— Менә монысы ярамаган. Аңа күп дару эчү ярамый. Ире нишләп соң бәйрәмгә кайтмаган, белмисеңме? — дип сынаулы карап сорады Гөлинә, әйтерсең лә Фатихның кайтмавына Салиха апа гаепле иде.

Чөгендер дию буш сүз ул. Сөмбелә андый вак-төякка гена бирешә торган җанмыни? Тик менә ничек инде кеше серен фаш итәргә кирәк. Авыз күтәреп. Гомере буе Салиха апа кеше тормышына тыкшынып, кирәк-кирәкмәгәнне тикшереп, гайбәт чәчеп йөрмәде. «Кеше күңеле карурман, анда керсәң, әйләнеп чыга алмый интегерсең», — диләр бит. Хәзер белә, Сөмбеләне урын өстенә еккан хәсрәт, аның баш очында, мендәре астында, тик аны ничек әйтергә соң?.. Гөлинә Әхмәровна Салиха апаның менә-менә бер шөбһәле хәбәр әйтергә теләгәнен сизенде:

— Салиха апа, Сөмбеләнең кан басымы көчәйгән. Кан басымы күтәрелү йөкле хатыннар өчен куркыныч икәнен беләсеңдер инде... Ахры, бик каты борчылган ул... Үзең беләсең инде, Салиха апа, кеше сүзе кеше үтерә, дигән мәкаль дә бар. Әллә берәр күңелсез хәбәр ишеттеме икән?

Салиха апа Гөлинәгә күзләрен тутырып карады, шәлене кырые белән авыз читен сөртеп алды.

— Ничек итеп кеше серен... Сөмбелә миңа рәнҗер бит... Баш очындагы мендәр астында хаты бар, иреннән. Фатихын бәйрәмгә көтә иде. — Салиха апа тагын нәрсәдер әйтергә теләп иреннәрен тибрәндереп беравык басып торды, бите шәле белән томалап китеп барды. Гөлинә өйгә кергәндә Мөҗип Сөмбеләнең караваты янында утыра, Сөмбелә күзләрен йомган хәлдә авыр гына сулап ята иде. Ак ефәк кофтасы эченә яшеренгән түгәрәк күкрәкләре бер күтәрелә, бер төшә.

Ишек тавышына Сөмбелә күзен ачты, башын борды. Гөлинәгә карап елмаерга теләде, янында Мөҗип Галиевичны күргәч, хәлсез генә тавыш белән:

— Нигә килдегез, Мөҗип Галиевич, хәзер үк китегез, ярамый, ярамый сезгә минем янда утырырга,— диде. Мөҗип Галиевич та, Гөлинә дә Сөмбеләне саташа дип уйладылар.

Хатыны Сөмбеләне киендерә башлагач, Мөҗип чыгып китте. Гөлинә авыру Сөмбеләне ашыктырмады, өстәл янына барып басты да ридикюленнән нәрсәдер эзли-эзли, аның хәрәкәтләрен күзәтә башлады.

Хатны алырмы-юкмы... Аны хатның эчтәлеге кызыксындыра иде. Сөмбелә кыяр-кыймас кына кулын мендәр астына тыкты. Ничәдер секунд күзләрен йомып хәрәкәтсез калды, йөзендә газаплану, үртәлү билгеләре хасил булды. Ак конвертны ул кулына йомарлады. Урамнан өйдәгеләрне ашыктырып машина сигнал бирде. Сөмбелә белән Гөлинә җитәкләшкән килеш ишек алдына чыктылар, болдырга басып тирән сулу алдылар. Саф һава икесенең дә күңелен күтәреп, рәхәтләндереп җибәрде.

*
* *

Больницаның ак җәймәле караватына яткач та тәнендә җиңеллек сизмәде Сөмбелә. Борынына дару исләре кереп, еш-еш төчкерә, йөткерә башлады.

«Күрәсең, чөгендер салкыны чыга үзеңнән»,— диде Сөмбеләгә укол ясап йөргән Гөлинә Әхмәровна.

— Гөлинә Әхмәровна, үтенеп сорыйм, кирәкми миңа бала.

Гөлинә Әхмәровна Сөмбелә янына килеп утырды, аның кулын үзенең йомшак, җылы учына алды.

— Ни өчен, нәрсә булды?.. Фатих белән шулкадәр тату, дус яшисез. Бала сезнең мәхәббәтегезне тагын да көчәйтер, беренче баланы тапмаган аналар гомерлеккә авыру булып кала...

— Фатих мине яратмый, ышанмый ул миңа,— диде авыр көрсенеп Сөмбелә. Аның бу сүзләрен ишеткәч Гөлинә тәмам коелып төште. Димәк, үзара мөнәсәбәтләре яхшыдан түгел... Сөмбелә һаман әле кулында йомарлап тоткан конвертны Гөлинәгә бирде. Гөлинә конвертны беравык кулында тотып торгач:

— Рөхсәтме, укырга ярыймы?— дип Сөмбеләнең күзләренә карады. Сөмбелә ризалык билгесе итеп башын селекте дә одеялы белән томаланды. Гөлинә икенче бүлмәгә чыгып үзенең эш өстәле артына утырып дикъкать белән хатны укый башлады. Укыды, күз аллары караңгыланып, буыннары йомшарып, хәлсезләнеп китте ул. «Коточкыч, коточкыч бит»,— дип пышылдый иде аның иреннәре... Нәрсәләрнедер, ниндидер сүзләрне, ниндидер вакыйгаларны хәтерләргә тырышты. Мөҗип ничәдер мәртәбә Сөмбеләне мактаганын исенә төшерде ул.

«Шулкадәр ягымлы, йомшак күңелле булса да булыр икән, кешелекле, талантлы укытучы. Һәр ата-ана, һәр укучыга бер тигез мөнәсәбәттә була белә. Әти-әнисе укытучылар икән, яшьтән, бала чактан алган тәрбия бу»,— дигән иде аның Мөҗибе. Әйе, әйе, Гөлинә тышкы кыяфәте белән Сөмбеләгә караганда ямьсезрәк тә бит. Йөргәндә ул аягын бераз сөйрәтебрәк атлый. Муенының уң ягын зур кара миң ямьсезләп тора.

— Гөлинә Әхмәровна!.. Ай, әчем...— Сөмбеләнең тәнен көзән җыерып алды.

Тагын укол кададылар.

— Тынычлан, Сөмбелә акыллым, син каты борчылгансың, борчылу кешенең кан басымын да күтәрә, йөрәген дә начарлата, тынычлансаң, барысы да бик тиз узар...— Ә үзенең башы чүкеч белән суккандай шаулый, авырта башлады. Күңелсез уйлар бөтен зиһенен биләп алды аның.

Студент чаклар. Ул — медицина институтында, ә Мөҗип педаго-

гия институтында укый. Ял көне алар икәү Арча кырындагы ял паркына чаңгы шуарга килделәр. Тирә-юнь искиткеч матур. Алар берберсеннән күзләрен ала алмый чаңгы шуалар. Кинәт... зифа гәүдәле кыз чаңгысы-ние белән тау астына очты. Егылды. Аның артыннан кар бураны күтәрелеп калды. Кыз тәгәри-тәгәри озак барды. Моны күреп торган егет шунда ук кыз артыннан сикерде. Яман хәл сизенеп, халык җыйналды. Мөҗип аңын югалткан, аягына баса алмаслык хәлдә биртелгән Гөлинәне кулына күтәрде... Гөлинә больницада алты ай ятты. Мөҗибе буш сәгатьләрен гел аның янында үткәрә иде. Гөлинә больницадан таякка таянып чыкты. Шуннан ул аксаклабрак йөри торган булып калды. Гөлинә сәламәтләнеп җиткәч, алар өйләнештеләр. Мөҗибе аңар:

— Сөйкемле күзләреңә гашыйк мин, мәрҗән кебек тигез булып тезелеп киткән ак тешләрне күрсәтеп көлеп җибәрсәң, бөтен дөнья яктырып, сафланып киткәндәй була, Гөлинәм,— дигән иде.

Юк, юк, бер түгел, унлаган Сөмбеләләр дә үзләренә карата алмаячак Мөҗипне... Гөлинә урыныннан торды, стенадагы көзге каршына килеп, чәчен рәтләде, аннан икенче бүлмәгә кереп ишек янагына сөялде. Күзләрен тутырып Сөмбеләгә карады:

«Их, Сөмбелә, Сөмбелә Закировна, артык йомшак икәнсез, сыгылып төштегез. Сез бит карыныгыздагы бала өчен дә, ирегез өчен дә җаваплы бу очракта. Үзегезнең вөҗданыгыз саф икән, нигә дөреслек өчен көрәшмәскә?! Беренче карашка, әле генә тормышка аяк басып килә торган, яшь, тәҗрибәсез кеше сез, ә кайбер якларыгыз кешеләрне көнләштерә дә башлаган иде. Игътибарга лаек булмаган кешеләрдән көнләшмиләр бит. Шул турыда уйландыгызмы?» дип сөйлиләр иде аның акыллы, сөйкемле күзләре...

— Су бирегезче, Гөлинә Әхмәровна...

— Хәзер чәй кайнап чыга, Сөмбелә. Икәүләп чәй эчәрбез... Сөйләшербез, аңлашырбыз... Дөрес түгел, Сөмбелә, дөрес түгел бит, нәрсә генә уйлап чыгармыйлар бу усал кешеләр?!.— диде Гөлинә Сөмбеләнең ике иңен дә кочаклап. Ә үзенең башында бу минутта икенче уйлар иде.

— Нишләргә, хатны Мөҗипкә күрсәтергәме? Борчылыр, хурланыр. Эшенең иң күп чагы...

Бүлмәгә чәйнең хуш исе таралды...

*
* *

Йокыга талган Сөмбелә караваты янында Гөлинә күзләрен бер ноктага текәгән дә тирән уйга чумган, шул вакыт ишек шакыдылар. Аяк очларына басып бүлмәгә Мөҗип керде һәм шыпырт кына:

— Хәле ничек?— дип сорады.

— Хәзергә ярый. Тынычлык кирәк аңа.— Гөлинә иренең талчыккан йөзенә карап торды да, кулыннан җитәкләп диярлек икенче бүлмәгә алып чыкты.

— Бик тиз иренә хәбәр итәргә кирәк, Мөҗип!

— Тулай торакларына шалтыратырга теләгән идем дә, телефон эшләми, каядыр повреждение.

— Иртәгә иртүк районга барып шалтырат!

— Бәйрәм көн, кемне тотасың инде анда. Нигә ул кайтмады икән соң, самолетлар да вакытында очтылар.

Таң атуны хәбәр итеп әтәч кычкырды.

— Бар, өйгә кайт, Мөҗип, бер-ике сәгать йоклап ал.

— Ә син, син ничек бер ялгызың, үзең дә авырыйсың бит, Гөлинә, йөзең кардай, күзләрең төссез.. Нигә сестраны җибәрдең?

— Яшь кеше, бәйрәм итсен инде, өйләре тулы кунак.

Мөҗип өстендәге пальтосын салып урындык башына куйды:

— Бәйрәм көн хакына кара-каршы утырып чәй дә эчә алмадык. Председатель өенә чакырган иде.

Гөлинә иренең иңенә кулын салды. Мөҗип аны көчле беләкләре белән нык итеп кочты, күзләреннән үпте.

— Бәйрәмнәр котлы булсын, шатлыклы булсын, Гөлкәем!

— Шулай булсын, Мөҗип!

Алар, дару исләре аңкып торган кечкенә генә бүлмәнең ишек яңагына сөялеп, бер-берсенә сыенышып басып тордылар. Ярым ачык ишектән икенче бүлмәдә йоклап ятучы Сөмбеләнең тыныч кына сулавы ишетелә иде.

— Мөҗип, нигә җир өстендә начар кешеләргә дә урын бар икән? Өстебезгә утлы пулялар яумый, өстәлебез тулы ризык, эшсез калу куркынычы юк. Теләсәк эшлибез, теләсәк укыйбыз. Кеше булган кеше нигә дип шулкадәр түбәнлеккә төшә микән?

Гөлинә башын иренең киң күкрәгенә куеп үкси башлады. Мөҗип хатынын үзеннән читкәрәк этәрде, аның яшьле күзләренә текәп карады.

— Нигә әле син шундый эчпошыргыч сүзләр сөйлисең, ә?..

Эчке бүлмәдән Сөмбеләнең ыңгырашкан тавышы ишетелде:

— Ай, башым, башым... Гөлинә Әхмәровна, Фатихның башына суктылар, минем дә...

Сөмбелә йокы аралаш саташа иде.

*

* *

Салиха апа Сөмбеләгә яңа сауган сөт китергән. Сөмбеләнең сөтне тәмләп эчкәнен дулкынланып, шатланып карап тора ул.

«Болай булгач сәламәтләнә, тамагына аш үткәч, сырхау кача ул, җиңелә ул»,— ди үз эченнән генә. Амбулатория ишеге төбенә әле бер, әле икенче хатын килә. Алар кулларындагы кечкенә генә төргәкне Гөлинә Әхмәровнага сузалар.

— Үзен күрсәтмәсәгез, зинһар менә шушы тәмле, әле генә пешеп чыккан бәлешемнән авыз иттерсәгез иде,— ди берсе.

— Әле генә пешкән свежий йомырка бу, Гөлинә сеңелем, хәзер үк ашасын, кайнар килеш ашасын,— ди икенчесе.

Кулларына чәчкәләр тотып, сигезенче класс укучылары килгән.

— Гөлинә апа, Сөмбелә Закировнаны бәйрәм белән тәбрикләр идек. Янына керергә ярамаса, тәрәзәгә килеп үзе күренсен!— диләр.

Врач Гөлинә Әхмәровна ике кулын кардай ак халатының кесәләренә тыккан да, ишек төбендә басып торучыларга сокланып карый. «Нинди яхшы күңелле кешеләр сез!»— дип уйлый эченнән.

— Рәхмәт, барыгызга да бик рәхмәт. Сөмбелә Закировнага бер нәрсә дә кирәкми, аның хәле яхшы. Кичкә өенә кайта ул.

Салиха апа кинәт урыныннан сикереп торды:

— Абау ла, Фатих ич тәрәзә яныннан узып китте. Кайткан ич. Безне эзләп йөридер балакай. Абау ла!..— дип бүлмәдән чыгып йөгерде. Сөмбелә кызуланып урыныннан кузгалды, өстенә күлмәген кия башлады.

Ачык калган ишектән Фатих тавышы ишетелде:

— Гөлинә Әхмәровна! Сөмбеләне монда диделәр.

— Сез?— диде Гөлинә Әхмәровна, дулкынланган тавыш белән.

— Кайта алмадым шул, минә самолетка алган билетым да калды. Авылда әнием үлде. Аны күмдем дә поезд белән килдем...

— Әкрен, зинһар... Чишенегез... Хәзер инде хәле яхшы...

Алгы бүлмәдән Сөмбеләнең ыңгырашкан тавышы ишетелде. Гөлинә Әхмәровна, аның артыннан Фатих бүлмәгә керделәр. Сөмбелә кинәт сыгылып төшкән, егылмас өчен ике кулы белән караватына тотынган иде. Ул авырлык белән генә:

— Фатих, әнкәй үлдемени? — диде. — Их, әнкәй!.. Ай, башым!

Гөлинә Әхмәровна аның кан басымын үлчәде... Моннан бер сәгать кенә нормага килә башлаган кан басымы кинәт каты сикереш ясаган иде.

— Фатих, бүлмәдән чыгыгыз, — диде Гөлинә калтыранган тавыш белән.

— Сөмбелә, акыллым, бәгърем! — Фатих хатынын караватка күтәреп салды. Аның маңгаеннан, күзләреннән үпте.

Гөлинә нык тавыш белән:

— Сестра! — диде.

Тәбәнәк буйлы, алсу йөзле яшь кенә сестра докторның күз карашын аңлады. Күзләрен чытырдатып йомган, иреннәрен тешләгән Сөмбеләгә карап алды да, кайнатылган инструментларын бүлмә уртасындагы өстәлгә китереп куйды. Фатих ава-түнә бүлмәдән чыгып китте.

Күпме вакыт узгандыр, Гөлинә хәтерләми. Берничә айдан якты дөньяны күрергә тиешле нарасыйның мәңгегә юкка чыгуын гына белә ул. Бик көчсез иде шул әле ул җан, нахак бәлага, вөҗдансызлыкка каршы тора алмады.

*
* *

Урамда дулап-дулап кар ява. Юеш кар бөртекләре тәрәзә пыялаларына бәрелеп, өйдәге тынлыкны бозалар. Мәктәп директоры Мөҗип Әюпов квартирасының бер бүлмәсендә тонык кына ут яна. Ярты төн узган булса да Мөҗип Галиевич, Фатих, Гөлинә өстәл янына утырганнар. Алларындагы аш та, чәй дә суынып беткән. Аларны рәтләп ашаучы да, эчүче дә юк.

— Имзасыз хатлар гасырлар буе язылып килгән. Дөньяда әшәке җаннар җитәрлек. Аның мәкерле юха еланнары, икейөзлеләре, Ватанын дошманга саткан хаиннары бар. Саф кешеләргә яла ягып, имзасыз хатлар язышып көннәрен юатучылар бар. Шундыйларның кайбере, кызганычка каршы, безнең арабызда да яши.

Мөҗип Галиевич алдындагы чынаяктан суык чәйне иреннәренә тидереп куйды. Киң булып үскән кара кашлары җыерылып килеп, бер-берсенә кушыла язганнар. Ул бөтен гәүдәсе белән урындыкка салынып утырган Фатихка озак карап торды. Кече яшьтән спорт белән шөгыльләнгән Фатихның төз, нык гәүдәсе шәлперәеп калган, эчкә баткан серле күзләре яртылаш йомык, битен сакал-мыек баскан...

— Әгәр кыяфәтең шул хат аркасында шундый ямьсез хәлгә килгән булса, Фатих, ант итәм, мин сине өемнән куып чыгарырга тиешмен, — диде Мөҗип сабыр гына. — Ләкин синең икенче хәсрәтең бар — әнием... Утыз яшькә җитеп килә торган ир, берничә айдан югары белемле агроном булып әшкә китәсе кеше, бала атасы буласы кеше, ничек шушы шакшы хатка ышандың? — Ул кыза барды. — Ир белән хатын бер-берсенең холкын, фигылен белмимени? Шундыймыни синең хатының? Караңгы почмакларда чит ирләргә сыенып йөри торган хатыннар гаилә кормыйлар, әшләмиләр, укымыйлар. Сөмбелә шундыймыни?! — Ул Фатихка ачулы караш ташлады. — Ә минем турыда шу-

лай начар уйларга ни хакыгыз бар сезнең? Минем дөньяда берәү белән дә алыштырмас хатыным бар, балаларым... Мин егет чакта да караңгы почмакларда тормадым, белдегезме? — Ул бу минутта ярсудан үзен өзгәләп ташларга әзер кебек иде.

— Гафу итегез, Мөҗип Галиевич...

Мөҗип уң кулын Фатихка селкеде.

— Гаиләдә бер-береңә ышанмый яшәүдән дә зуррак бәхетсезлек юк. Бер-береңә ышанып яшәгән ир белән хатын тормышын имзасыз хат хуҗасы да, башка, көнчел, хөсетчел кешеләр дә боза алмый... Мөҗип әллә ничә кат укыган хатны алып, Фатих янына ук килеп басты:

— Хәтерләргә тырыш әле, Фатих, Мөнҗия белән булган мәхәббәт маҗараларыгызны кем белә иде?!..

— Уйлыйм инде, күп уйладым. Берәү дә белми. Ул бит бары дусларча аралашу гына иде.

— Сөмбелә Закировна белә идеме?..

— Мин аңарга барын да сөйләдем.

Мөҗип Галиевич кинәт урыныннан торып китеп бераз йөргәләп алды. Аннан Гөлинәнең иңбашларыннан кочаклап:

— Беләсеңме, хатны кем язган? — диде.— Мин таптым аны. Ул — Сөмбеләнең дусты — Һаҗәр Уразмәтова... Әйе, әйе... Уразмәтова!

Гөлинә яшен бәргәндәй урыныннан сикереп торды.

— Ни сөйлисең, Мөҗип! Үз мәктәбеңдәге, үз коллективыңдагы кешегә бәла ягарга ничек батырчылык итәсең?

— Беләм, әйбәт түгел. Мин җитәкләгән коллективта шундый әхлаксыз кешенең эшләве... Җитмәсә әдәбият укытучысы...

— Аңарга Сөмбелә Закировна нинди әшәкелек эшләгән? Акылыңа кил, Мөҗип!

— Әшәкелек эшләгән очракта да имзасыз хат язып кешене түбәнсетергә ярамый, турыдан-туры әйтергә кирәк, кычкырып, халык алдында, кирәк икән трибунадан чыгып сөйлә...— Мөҗип озак кына хатка карап торды да: — Мәгез, укыгыз... «Всеж» дигән сүзне бертуктаусыз бездә кем әйтә? Һаҗәрме?.. Икенчедән, бу айларда безнең авылга бер генә чит кешенең дә килгәне булмады. Уразмәтова узган айда, сеңлемне кияүгә бирәләр, дип Казанга китеп өч көн торып кайтты.

Фатих директорның күзләренә инәлеп карады:

— Чыннан да, нәтиҗә ясарга ашыкмагыз. Мин дә бит ашыгып нинди авыр хәлгә калдым. Мин уйлыйм әле, хәтерләргә тырышам, бәлки башка кешедер.

Иренең дулкынлануын, артык дәрәҗәдә кызып китүен күреп, Гөлинә нишләргә дә белмәде, ялгыша бит, Мөҗип ялгыша, дип уйланды ул. «Кичә Культура йортында Һаҗәр бәйрәм концертында нинди матур итеп Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе»н укыды. Юк, юк, ышанмыйм. Әдәбиятка якын кеше андый түбәнлеккә төшмәс, язучылар, әдәбият фәнен укытучылар алар иң нечкә күңелле кешеләр бит. Һаҗәр Сөмбеләнең карынында бала йөрткәнен дә, матур гаилә корырга теләвен дә белә. Шулай булгач нигә, нинди максаттан чыгып ул аның бәхетен җимерергә теләр».

— Уразмәтова әдәбиятны күп укый, дип ничә мәртәбә сөйләгәнең бар, Мөҗип. Син кызма әле...— Ул иренең кулларын сыйпады, ничек кенә булса да аны тынычландырырга, мәсьәләне якты акыл белән чишәр өчен, иренә ярдәм итәргә тырышты.

Мөҗип озын буйлы, киң җилкәле ир. Йөргәндә бераз иңсәләрен бөкерәйтеп йөри, уйланып утырганда, киң маңгаена тузгып төшкән куе кара чәчләрен бармаклары белән сыпыргалап утырырга ярата. Хәзер ул, киресенчә, иңнәрен турайтып, башын югары күтәрде.

— Үз фикеремнән кайтмыйм. Уразмәтова фәнен яхшы белә. Тик үзе белгән фәнне йөрәгеннән уздырмый. Коры уза аның дәресләре. Салкын канлы ул.— Аннан Мөҗип бераз уйланып торды да: — Бик еракта яшеренгән җылылык, йомшаклык та бар аның үзендә. Тик аларны ул кирәгенчә файдалана алмый,— диде.

Гөлинә, иренә текәлеп, иреннәрен тибрәтте, нәрсәнедер әйтергә теләде. Мөҗип аңлады аның күз карашын.

— Беләм, Һаҗәрнең яхшы якларын да, җитешсез якларын да беләм. Тик белә торып, күрмәмешкә салышып йөрүемне кичерә алмыйм бүген. Әллә ничә кат аның белән кара-каршы, күзгә-күз карап сөйләшергә дә әзерләндем... Һаман вакыт җитмәде,— диде Мөҗип.



*

* *

Бу минутларда мәктәп квартирасының бер бүлмәсендә мамык мендәрләргә чумып Һаҗәр йоклый иде. Йокысы тынычсыз аның, баш очында мамык мендәр түгел, әйтерсең лә таш тутырган киндер капчык. Аяк очларына ни өчендер бозлы шешәләр куйганнар. Әнә идәндә канлы су. Анда сап-сары яфрак йөзеп бара. Яфрак кинәт кечкенә малайга әверелә.— Коткар, коткар! — ди ул, җептәй нечкә кулларын Һаҗәргә суза. Һаҗәр балага таба үрелә... Һаҗәр суга төшеп китә.

— А-а!..— дип кычкырып, үз тавышына куркынып уянып китә ул.— Нинди әшәке төш!.. Ул, ут кабызып, сәгатенә карады. Иртәнге өч тулып киткән.

Ярыйсы гына йоклап алганмын икән, дип сөенеп уйлап алды. Югыйсә, Сөмбелә авырый башлаганнан бирле, йокысы качты аның. Бөтен тәне тынычсызлана, башы авырта. Амбулаториядә эшләүче сестра килеп: «Сөмбелә Закировна сезне чакырган иде»,— дип әйтеп китте. Ләкин Сөмбелә янына барырга үзендә көч таба алмады ул. Зәңгәрсу кримпленнан теккән халатын урындык башыннан тартып алып иңнәренә салды, аның җиңнәренә кулларын тыгып үз-үзен кочаклап, аякларын бөкләп караватына утырды.

— Нигә чакырды икән? Неужели белделәр, нишләргә?.. Менә ике ел инде, Сөмбелә бу авылга килгәннән бирле, алар дус булып йөриләр. Һаҗәр бирегә моннан өч ел элек Казан педагогия институтының әдәбият бүлеген тәмамлап килгән иде. Беренче елны үзен ул коллективта бик кыюсыз тотты. Аның көлеп, шаярып сөйләшкәне бик сирәк була иде. Башкаларга да, шул җөмләдән Сөмбеләгә да ачылып, үз тормышы турында сөйләми иде. Сөмбеләне эчкерсез булуы өчен ярата. Сөмбелә дә барлык серләрен, хәтта үзе генә белергә тиешле булган серләрен дә яшерми Һаҗәргә сөйли. Һаҗәр һәрвакыт Сөмбеләгә:

— Син, дускаем, бик бәхетле бит,— дия иде...

Кинәт ул ачылып китте. Егерме биш яшьлек кызның күңелендә мәхәббәт хисе уянды. Ул яшь егет, оста баянчы, авыл советы председателе Фазылны ярата башлады. Фазыл да Һаҗәргә тартылды. Ничәдер мәртәбә алар Культура йортында янәшә утырып спектакль, картина карадылар. Ничәдер мәртәбә Фазыл Һаҗәрнең мәктәптә дәресләрен тәмамлап чыгуын көтте. Ул көннәрдә укучылар Һаҗәрнең хисләнеп шигырь укыганын, әдәбият турында кызык, мавыктыргыч итеп сөйләүләрен күңел биреп, кызыксынып тыңлап утыра башладылар.

Ләкин көтмәгәндә Һаҗәрнең зур зәңгәр күзләренә күләгә төште. Озын кара керфекләр арасында иртә таңда чирәмнәргә төшкән чыкны хәтерләтеп яшь бөртекләре җемелдәде. Йөзендә елмаюның эсәре дә калмады. Педсовет утырышында иптәшләре аның белән сөйләшергә теләделәр:

— Һаман йөзеңне кара көйдереп йөрү безгә дә күңелсез бит, Һаҗәр Бәдриевна, кайгы-хәсрәтең булса безнең белән уртаклаш. Сөйләшербез, ярдәм итәрбез... Һәркемнең үзенә күрә хәсрәте була. Барысы өчен дә йөз каралтып йөрү килешмидер, бигрәк тә аның тәэсире хезмәтеңә зарар китергәч, яхшы түгел бит,— диделәр.

— Анысы инде минем гадәтем, сезнең тәрбиягә бирелми торган, тумыштан калган җитешсезлегем,— дигән иде шул чакны Һаҗәр. Аның шул сүзләре дөрес идеме, түгелме, иптәшләре артык төпченеп тормады. Тик көннәрнең берендә Фазыл авылны шаулатып туй ясап, күрше авылы китапханәсендә эшләүче Сара исемле кызга өйләнде. Сара белеме белән дә, кыяфәте белән дә Һаҗәргә карата кайтышрак иде.

Мөҗип Галиевич Фазылның туена бара алмады. Икенче көнне ул, эшләре тәмамлангач, Фазылны үз кабинетына чакыртты.

— Синең бу кыланышыңны ничек аңларга, Фазыл дус,— диде ул бик җитди итеп.— Укытучы авылда иң дәрәҗәле кеше. Ата-аналар алдында, яшьләр, укучылар алдында да. Халыктан яшермичә, Һаҗәр артыннан йөрдең, русчалатып әйтсәк, ухаживать иттең, инде икенче кызга өйләнеп туй ясап йөрисең. Мин синең бу эшеңне аңлый алмыйм,— диде. Директор сөйләгәндә Фазыл кинәт күңелсезләнде, күзләренә моң тулды. Ул күзендәге кара кысалы күзлеген бер салды, бер киеп куйды. Кесәсендәге кулъяулыгы белән түгәрәк йөзен сөртте. Уңайсыз иде аңарга бу минутта.

— Сүзегез дөрес, Мөҗип Галиевич. Күңелле хәл булмады. Ухаживать иттем, конечно, ярата да башлаган идем кебек... Өйләнәм, дип аны карчыкка да сөйләндем. Но кадалып кына китәсеңме? Матурлык туйда кирәк, акыл гомергә кирәк, дигән мәкаль бар бит. Вот шул, беләсезме, төсе-кыяфәте бик яраттырды. Характеры, холкы харап кына бит, Мөҗип Галиевич... Көнли бит, парень, шундый көнли... Свиданиегә берничә минутка соңга калып килсәң, кайда булдың, нигә соңладың, кыз кешене көттереп тору әдәпсезлек икәнен белмәдеңме, ди. Уйлап карагыз инде, безнең эштә кая инде сәгатьләп, минутлап йөрү ди. Берәр хатын-кыз белән көлеп, шаярып сөйләшсәң, икешәр-өчәр көн кара көеп үпкәләп йөри. «Ничек оялмадың, мине кимсеттең, кай җире артык аның миннән», ди. Мөҗип Галиевич, гомерем минем хатын-кызлар белән эшләп үтә бит. Иртән сәгать алтыда ишек төбенә килеп басалар алар. Кайсысы белән ачуланышып сөйләшәсең, кайсысы белән, әлбәттә инде, көлгәләп сөйләшеп аласың. Кешеләр бит... Шуннан, уйланып йөрдем-йөрдем дә... юк инде мәйтәм, матур кызга өйләнәм, дип, күрәләтә гомерне харап итеп булмый дидем...

Йөргән егетеннән генә көнләп калмады Һаҗәр, «дустым-сердәшем» дип йөргән Сөмбеләдән дә көнләште. Узган уку елы чыгарылышында иң яхшы нәтиҗәләрне биргән Сөмбелә классын Волгоградка экскурсия путевкасы белән бүләкләгәч, педсовет утырышында Һаҗәр зур үпкә белдергән иде.

— Минем класс кай ягы белән Сөмбелә Закировна классыннан ким? Йөз процент өлгереш, тәртип тә йөз процент...

Директор:

— Җәмәгать эшләрендә, үзешчән түгәрәкләрдә кайсы класс укучылары күбрәк катнаша? Сөмбелә классымы? Спорт ярышларында кем классы узды...— дигәч, Һаҗәр:

— Бигрәк вакланасыз инде, иптәш директор, укый торган фәннәрен яхшы үзләштергәч, шул җитмимени!— дигән иде.

РОНО мөдире укытучыларның август киңәшмәсендә, район күләмендә яхшы укытучылар рәтеннән Сөмбелә фамилиясен әйткәч, Һаҗәр үз-үзен өзгәләде: «Дөрес түгел, мәктәп директоры Сөмбеләне яклый. Укытучы буларак түгел, матур хатын булганы өчен ярата ул

аны», дигән нәтиҗәгә килде. Ул мондый минутларда директорны да, РОНО мөдирен дә, Сөмбеләне дә дошман күрде. Көнләшү хисе аны кулларына каләм алырга, нахак сүзләр язарга этәрде. Казанга, абыйсы кызының туена баргач, төн утырып хат язды, аны икенче көнне абыйсының малаеннан күчертте. Һәм бәйрәм көннәрендә почта ящигына салырга кушты.

Һаҗәр башын тотып карады. Ут кебек кызу, тәне калтырый. «Белмәсләр лә, кем тикшереп йөри аны. Всеж хат Казаннан җибәрелгән. Анда миллион кеше».— Ул үзен акларга да, юатырга да тырышып карады. Тик күңеле юанмады, тынычланмады. Караватыннан төшеп, яланаяк идәнгә басты. Тәне буйлап салкынлык узды, рәхәт булып китте. Стенадагы көзгә каршына килеп кыйгач кара кашын чәнти бармагы белән сыпырып алды. Чия шикелле кызыл, кабарынкы иреннәрен тешләде. Фазылның, бигрәк матур син, Һаҗәр, дигән сүзләре ишетелгәндәй булды. Ул колакларын куллары белән томалады. Әйтерсең лә Фазыл аның янында баскан да, әкрен генә сөйли: «Нигә син һаман үзең турында гына уйлыйсың, үзеңне бөтен кешедән өстен куярга яратасың». Нишләргә? Ул текәлеп-текәлеп көзгегә карады. Йөзе агарган, күзләре кып-кызыл... «Уф!»... дип тирән итеп сулыш алды да, тез асларына җиткән озын чәчләрен ике кулы белән җыйнап ашыга-ашыга баш өстенә өяргә тотынды.

*

* *

Дәрес башланганын хәбәр итеп звонок шалтырады. Унынчы класс укучылары дәфтәр-китапларын парта өстенә куеп, Һаҗәр апаларының кызу-кызу атлап класска керүен, каш астыннан гына укучыларга карап алып, «Исәнмесез», дип эндәшүен көтеп калдылар.

Биш минут, ун минут та узды. Укытучы класска кермәде. Мәктәп буйлап Һаҗәрне эзләделәр. Квартирасына кеше җибәреп кайтардылар. Ишеге бикле иде. Колхоз идарәсе дежурные:

— Һаҗәр апагызның кулына кечкенә генә чемодан тотып, автобус тукталышына таба киткәнен күрдем,— дигәч кенә, класска икенче фән — математика укытучысы кереп дәрес алып бара башлады.

«Димәк, намусы уянган, үзенең коллегалары белән күзгә-күз карап гаебен танырга көче җитмәгән. Качкан...» — Шулай дип уйлады директор, ләкин бик нык эче пошты. Зур булмаган коллективта укытучы дигән олы исем йөрткән ике кеше характерлары белән сынаттылар. Берсе, тормышында беренче кыенлык килү белән, көрәшергә үзендә көч таба алмады, югалып мәлҗерәп калды. Балаларны бик кечкенәдән тормыштагы каршылыклар белән очрашканда кыю булырга, көрәшергә, чыдам булырга, җиңәргә өйрәтәләр, ә Сөмбелә Закировна?.. Икенчесе — иптәшенә нинди зур күңелсезлек эшләде. Директор күзләрен чытырдатып йомды, тирән итеп сулу алды.

Телефон шалтырады. Районнан РОНО мөдире икән:

— Мөҗип Галиевич, узып киткән бәйрәмнәр белән тәбрик итәм сезне.

— Зур рәхмәт. Сезне дә тәбрик итәбез.

— Минем янга Уразмәтова килде әле,— диде мөдир.

Мөҗип Галиевичның тәне эсселе-суыклы булып китте. Мөдирнең дә борчылганы әллә кайдан сизелеп тора. Директор: «Нәрсә дип барган инде, әләкләргәме, әллә үзенең гаебен сөйләп бирергәме?.. Ичмасам гаебен ачып салса, намусын бөтенләй югалткан кеше түгеллеген күрсәтер иде»,— дип уйлап алды.

— Вакытыгыз бармы? Безгә килеп китсәгез яхшы булыр иде,— диде РОНО мөдире.

*
* *

Сөмбелә янында утырган Фатихка карап елмаерга тели. Аның күзләре эчкә баткан, иреннәре яргаланган.

— Фатих, сөйләш инде, берәр сүз әйт инде...

— Гафу ит, Сөмбелә, гомерем буена җитәрлек гыйбрәт булды бу. Гаебем зур минем.

— Ә мин... үз баламны үзем саклый алмадым. Җебеп төштем. Сугыш елларында минем яшьтәге кызлар-егетләр нинди авыр фаҗигаләрне башларыннан кичергәннәр. Ә бу бит, бер уйласаң, чүп, түбән җанлы, тар холыклы бәндәнең кеше тормышына кадаган агулы энәсе. Мин шул энәне дә алып ыргыта алмадым. Шул түбән җанлы кеше алдында җиңелеп калдым. Аны күпмедер бер вакытка шатландырдым. Моның өчен үземне беркайчан да гафу итмәячәкмен,— диде Сөмбелә яшь аша.

Фатих хатны Сөмбеләнең дусы, сердәше булып йөргән Һаҗәр язганын әйтмәде. Гөлинә Әхмәровна аны бу турыда нык кисәтеп куйган иде.

*
* *

РОНОда Мөҗипне бүген зур сөйләшү көтә. Кешеләр язмышы өчен җавап бирүдән дә авыр җаваплылык бармы икән? Ул — партоешма секретаре, мәктәп директоры — җавап бирергә тиеш. Аның колагында РОНО мөдиренең беренче соравы яңгырап алды:

— Ни өчен Һаҗәр Уразмәтова имзасыз хат язу түбәнлегенә төшкән?

— Ни өчен?..

Машина йомшак кына тирбәлеп алга йөгерә. Юлның як-ягында әле карга күмелеп бетмәгән уҗымнар күренә. Ерак та түгел тракторлар гөрелди. Мөҗип район үзәгенең яңа салынып беткән йорт түбәләрен, югарыга чөелгән телевизор антенналарын күрә. Ә башында һаман әлеге уйлар...

— Ни өчен, ни өчен?..

Хәзергә төгәл генә җавап бирә алмый әле. Ләкин дөрес җавапны табарга тиеш ул.

1978 ел

------------

## Салисә Гәрәева

### Гаҗәп матур бер җәй җәйләдем

Гаҗәп матур җылы җәй җәйләдем:
Каен чугын башка бәйләдем,
Ат эчердем елга уртасында,
Эчтем җәйнең салкын әйрәнен —
Гаҗәп матур бер җәй җәйләдем!

Серкәләнгән арыш арасыннан
Зәңгәр гөлләр җыйдым бер учма;
Тар басмада ак сөлгеләр юдым,
Ак бауларга элдем, кер учлап.
Син елмайдың миңа, гел очрап...

Гаҗәп матур җылы җәй җәйләдем —
Якты көннәр туды нәүбәтләп;
Көннәремә шатлык юлдаш иде.
Ә төннәрем ялгыз булмас иде —
Иҗат иттем янып, әйбәтләп.

Гадәттән тыш хәлләр кичермәдем.
Җырга ялган хисләр күчермәдем —
Яхшылыкка гына әйдәдем;
Җырлап-көлеп үтте бәйрәмем —
Гаҗәп матур бер җәй җәйләдем!

●

Станокта токарь — татар кызы
Деталь ясый: чарлый, сыр сыза...
Станогы кызның кулларына
Буйсына да, өзелеп җыр суза.

Корыч йомычкалар сары бөдрә,
Ялганышып, ургып агалар.
Станокның тигез гөрләвеннән
Туып тора тагын яңалар...

Йомычкалар авыр пресс белән
Кысыла да, китә мартенга.
Ә бераздан алтын-сары булып
Кояш чыга мартен артында.

## Тау түбәсендә

Урманнарга керәм, тауга менәм:
Шушы гүзәллеккә ни бәя!
Таулар түбәсендә — илләр иркен,
Турая бил, сулыш киңәя.

Кыяларга бөркет оялаган —
Аяк басмас җирдә оясы.
Уйлар олы монда, үзеңне дә
Горур бөркет итеп тоясың.

●

Ак ташларга басып күлгә төшәм,
Кайнар, яссы ташка утырам;
Тау битендә нарат кәүсәсенә
Көмеш чүкеч бәрә тукран...

Җәлләмичә язмыш бирә торды
Шатлыкны да, авыр йөкне дә;
Барыр юлым — якты бәхет юлы
Ничә елга икән, күпмегә?

Ерактагы таулар арасыннан
Күке саный калган елларны,
Күл суына карап искә алам
Шаулап үткән гомер елгамны...

Үткән еллар күзгә моң салмаган,
Эшләнәсе эшләр — тау кебек.
...Чал дулкыннар өелеп ярга килә —
Ак атларга менгән яу кебек!..

●

Әнкәй кочагына сыенып үстем —
Кулларының тоеп җылысын;
Әнкәй кулларында ятимлекнең
Сизмәдем мин салкын сулышын.

Әнкәй кулларына сыенып үстем,
Күңеленең тоеп аклыгын,

Васыять итеп алдым юлларыма
Сабырлыгын аның, сафлыгын.

Әнкәй күзе белән тәүге тапкыр
Матурлыгын ачтым кешенең,
Бөеклеген тойдым Ватанымның,
Кирәклеген тойдым эшемнең...

## Гел син күңелләремдә

Кешенең ел дәверендә
Яраткан вакты була:
Язмы, көзме? Синең кайчан
Күңелең якты була?

Бәлки сиңа ак кар яуган
Январь киче кирәктер?
Бәлки көздер? Көз тауларда
Учак уты көйрәтер...

Җемелди кояш нурлары
Гөрләп аккан суларда;
Зәңгәр апрельләрдә бәлки
Иркен сиңа суларга?

Күбәләкләр гөлчәчәккә
Сер сөйләгән җәй аен,
Июньнең серле төннәрен
Сөясеңдер, мөгаен?

Бәлки сиңа һәр фасылның
Якындыр кояшлары?
Миңа калса, тоям җирдә
Бер генә кояш барын:

Яз да, көз дә, җәй дә, кыш та,
Көндез дә, төннәрен дә
Кояш кебек нур балкыткан
Гел син күңелләремдә!..

## Бикә Рәхимова

### Көләргәме, еларгамы?

Ятка серем мин сөйләдем —
ятның гаме миндә түгел.
Колагына керер, чыгар —
сүзең сөйлә, ачыл-түгел.

Дуска серем мин сөйләдем.
Дустым өчен мин бер генә,
Уенда аның мин генә,
мин генәдер гел телендә.

Серем китте дөнья буйлап,
уңга иңләп, сулга иңләп.
Бушандым дип шатланганчы,
тагын басты мине исәп.

Телеңнең биге бозылса,
артык кайгы килә башка.
Сабак алдым үткәннәрдән —
инде минем дустым... башка.

### Сораулар

— Син, әни, хатларны әтигә
кайтмасын белгәч тә
ник яздың?
— Син, әни?..
— Ник, әни?..

Әнием киткәч тә башларын күтәрде
кәкре муенлы сораулар.
Үкенеч ялкыны төтенсез — күренми,
сыешмас гел эчкә — урын тар.

Бу сораулар шундый — булмый икән тыеп,
туры-туры бастырык — өндәү куеп.
Кузгалмагыз әле сез дип боерык бирсәң,
куялар боерыкның башын борып.

Әнигә мин бирмәгәнмен сорауларны
җавапларыннан куркып.
Шуны белдем торып-торып.

●

Ыгы-зыгы, вак мәшәкать бөтен бер
гомерне сорый.
Дәрьясына ташлап, йомычкадай безне
тормыш болгый.
Бер тын калып, йолдызларга ашарга да
ирек куймый.
Барлыгыңны сыгып суырудан нәфсе
бер дә туймый.

Бәхетле, бәхетсез минутлар туктамыйча
очып үтә.
Эх, үткәрсәң иде аларны, тизләгез! дип
этә-төртә.
Әкрен акса вакыт, бер арасы калыр иде
бөек эшкә.
Мондый бәхет хыяллансаң да кермәс тик
хәтта төшкә.

Бөек эшләр дип хозурланып мин уйлаган
бер арада,
каршыдагы биек өй тезелеп менгән
кай арада?
«Рәхмәт сиңа, туган, бөек эшең өчен», —
мин сүз куштым.
Бер төзүче егетнең зур, көчле
кулын кыстым.

------------

## Илсөяр Ганиева

### Шатлыгым

Йөрәгемдә заман уты ургый...
Көннәремә бәхет чолгана,
Бар байлыкны иңнәремә салдым,
Авырлыгын аның сорама:

Алып кайттым җырларыма салып
Моңга чумган урман карашын,
Шау чәчәкле, сандугачлы язын,
Саф һавалы сихри даласын.

Күкнең зәңгәр төсен җырга салдым,
Чулпан йолдызының нурларын,
Чишмәләрнең көмеш моңы белән
Хисләрнең иң изге, зурларын.

Томан таралгандай сүнә барды
Ярлы хисләр, дөнья ваклыгы.
Заман ялкынында янган саен
Балкый бара яшәү шатлыгы...

●

Нечкә тойгы, хисләр, күмелгәндәй,
Җирәндәрәк кала сүзләрдән:
Сүзсез генә эзлим — карашлардан,
Сүзсез генә эзлим — күзләрдән.

Нәрсәнедер күптән югалттым күк,
Эзли күңел, һаман ашкына.
Йөрәк тавышыңны? Юк, табалмыйм,
Акты микән кушылып ташкынга?!

Югалттым да эзлим, ахры, тәүдә
Бәхет сипкән күзләр булдымы?
Кабатланмас талир тәңкә тавышың
Йөрәгемә чыңлап тулдымы?

Утлар йотып һаман эзлимен мин,
Югалттыммы назлы кулыңны —
һич табалмыйм — утта көйдеме соң?
Кемнәр җуйды кайтыр юлыңны?..

Җаным тынмас, мәңге эзләрмен мин,
Бәлки бер табармын — күзләрдә;
Яшәвемнең яме бәлки шулдыр:
Яшәвемнең яме — эзләүдә.

------------

## Ибраһим Салахов

# МӘХӘББӘТ КАРТАЯМЫ?

ПОВЕСТЬ

> Мәхәббәт,
> Ул үзе иске нәрсә,
> Ләкин
> Һәрбер йөрәк аны яңарта.
>
> Һ. Такташ.

I



Пассажир поезды кечкенә генә бер разъездга туктады. Уртадагы вагоннарның берсеннән өстенә соргылт плащ, башына шул ук төстәге фетр эшләпә кигән бер кеше төште. Аның сул кулында сары күн саквояж, уң кулында башы ярым ай рәвешендә кәкре бамбук таяк иде. Пассажир төшеп бераз торуга, тепловоз сузып кычкыртты да кузгала башлады. Буферлар бер-берсенә бәрелеп чыңладылар. Тәгәрмәчләрен шакылдатып поезд китте. Пассажир, тимер юл буенда баскан килеш, бер ялгызы калды.

Инде көн уртасы — төш вакыты булуга да карамастан, эңгер-меңгер чак кебек. Күк йөзен соргылт болытлар каплап алган. Җитмәсә, көзге иләмсез, салкын яңгыр сибәли. Аяк асты пычрак, тайгак.

Поездан төшеп калган пассажир, кулындагы саквояжын юл буенда аркылы-торкылы яткан иске шпалларның берсе өстенә иплән куйды да, плащын каккалады, җиңнәрен, чабуларын тарткалап тигезләде, якасын, галстугын төзәтте. Аннан, эшләпәсен салып, перчаткасы белән суккалап, кырпуларын төзәтте. Чал чәчләрен сыпырып, эшләпәсен яңадан киеп куйды.

Үзе буйга уртача булса да, чандыр гәүдә аны ярыйсы ук озынҗыйнак итеп күрсәтә иде. Яңгыр һаман әле сибәләп торуга да карамастан, юлаучы нигәдер китәргә ашыкмады, тирә-якка каранды — кемнедер эзләгәндәй булды.

Әмма разъезд тирәсендә һичбер җан иясе күренми — бушлык, эч пошыргыч юеш тынлык. Тимер юл полотносыннан читтәрәк, барак рә-

вешендә, озын итеп, бүрәнәдән бурап салынган, такта белән тышланган һәм сарыга буялган бер катлы өй. Ул күзгә яңгыр белән чыланып, бүртеп, каралып — үзе болай да шыксыз, соргылт тирә-якны да карангылатып, күңелсезләндереп тора. Йорт алдындагы кечкенә бакчада үскән ялгыз нарат та картайган, түбәнге ботаклары сынган, имгәнгән. Күзгә салкын җилдә акрын гына тирбәлә, шыгыр-шыгыр килеп шыңшый. Нәкъ шул нарат кырыннан такта басма — тротуаруза. Ул тимер юл полотносы белән разъезд башлыгы өен — поездларга чыга торган ишекне тоташтыра. Нәкъ шул басмадан, ашыкмыйча, салмак адымнар белән тимер юл хезмәткәрләре формасын кигән озын буйлы бер кеше атлый. Аның уң кулында саргылт төстәге кечкенә флаг. Бу, мөгаен, разъезд башлыгыдыр. Менә ул да ишектән кереп югалды. Тирә-як тагын буп-буш калды. Җил көчәйде.

Ниһаять, безнең пассажир да саквояжын кулына алып кузгалды — сул аягына аз гына аксап, таягына авыша төште, әле яңа гына разъезд башлыгы кереп киткән өйгә таба атлады.

Нәкъ шул мизгелдә йортның аргы ягыннан яшел пальто һәм шундый ук төстәге шәл бөркәнгән хатын күренде. Ашыга иде ул. Кинәт нәрсәгәдер абынды — егыла язып чайкалып китте. Әмма йөрешен акрынайтмады, киресенчә, атлый-йөгерә, саквояжлы пассажирга таба якынлашты. Араларында нибары ике-өч адым калгач, икесе дә кинәт туктап калдылар. Ир кеше саквояжын һәм таягын игътибарсыз гына җиргә төшерде, үзе, нигәдер башын күтәреп, күзлек аша үрелеп карады. Әйтерсең бу хатынны танырга тели иде. Шунда хатын кискен хәрәкәт белән башын артка ташлады, шәле чишелеп китте.

Тынлык. Бары шыбыр-шыбыр яуган яңгыр тавышы һәм карт наратның шыгырдавы гына ишетелә.

Ниһаять, ир кеше бер адым алга атлады һәм ишетелер-ишетелмәс кенә итеп:

— Газизә... — диде.

Хатын йокысыннан уянгандай сискәнеп-калтыранып куйды. Аннан алар бер-берсенең кочагына ташландылар. Бер авыз сүз дә әйтелмәде. Бары тик куллар гына сөйләште. Бераздан хатын башын күтәрде — кулларын ычкындырып, күз яшьләрен сөртте, аннан тагын ир кешене кочып алды һәм еламсыраган тавыш белән пышылдады:

— Ильяс... чыннан да синме бу?.. Рәхмәт... рәхмәт, җан кисәгем, мине эзләп килгәнсең...

## II

Хатын-кызлар монастыре ишегалдындагы кафедраль соборның гөмбәзләренә асылган барлык эреле-ваклы кыңгыраулар тирә-юньгә сөрән салып берьюлы даңгылдый-чеңгелди башладылар. Тышта гына түгел, монда, монастырь хөҗрәсендә дә (студентларның тулай торагы), алар колакны тондыралар, күңелгә шом салалар иде.

Ильяс, башын мендәр астына тыгып, одеял белән уранып та карады. Әмма чиркәү чаңы колактан китмәде, һаман саен:

— Даң-доң! Чең-чең! Даң-доң!

— Фу! — Ильяс, колагы тонып, ачуына чыдый алмыйча одеялын читкә ташлады да торып утырды, — әллә инде бу монашкалар акылдан шашалар. Болай да баш чатный иде... Уф, алла!

Ул, башын, чигәләрен ике кулы белән кысып, янадан урынына ауды.

— Нәләт төшкерләре! Шайтан алгырлары! Тфу!!

Нәкъ шул вакытта хөҗрәнең ишеге ачылды һәм өсте газета белән ябылган алюмин миски күтәреп яшь кенә бер кыз керде. Таушалган соры пальтодан, башында озын колаклы куян бүрек. Куллар ялангач —

кызарганнар. Кыз мискине хөҗрә уртасындагы озын, керләнеп, каралып беткән өстәл өстенә куйды да кулларын уа башлады.

— Уууу... нинди суык. Килеп җиткәнче кулларым өзелеп төшә язды... Уф!..

— Газизә! — Ильяс гаҗәпләнеп кызга карады: — Син? Кайдан? Нәрсә соң ул мискидә?

— Нәрсә булсын ди, кичке аш. Ә менә бусы,—кыз, пальто кесәсеннән газетага төрелгән кечкенә бер төргәк чыгарып, миски янына куйды, — бүгенге икмәгең. Мин юри сиңа бүген... кибән башын калдырдым. Ул бит тәмлерәк, ә син авырыйсың.

— Минем ашыйсым килми... Температура.

— Җүләр! — Кыз уттай кызарып күшеккән кулларын тагын бер кат уды да, мискине өстәл кырыена, Ильясның караваты янынарак этте:

— Аша, суынуын суынгандыр да инде... Кичен салкын, көндез алай ук түгел иде әле. Монда да җылытып алыр урын юк, ә?

Ильяс һаман әле аптырап карый, мискигә үрелми иде.

— Нәрсә, миңа төбәлдең? Әнә үзеңә кара, өч көндә әрвах төсе кергән. Танырлык түгел. Еще ашамыйм дигән буласың. Әйдә, ал кашыгыңны, ну. Әйт тизрәк, кашыгың кайда? — Кыз елмайды, — мендәр астындамы? — Мискине тагын да этә төште,— әйдә, бераз йөрәк ялгап ал, аптырап утырма Будда төсле.

— Газизә! — Ильяс, матрац астыннан алюмин кашык алып газета белән сөртте дә, өстәлгә якынрак шуышып утырды. — Син дә инде... Болактан монда, монастырьга хәтле, миски күтәреп килгәнсең, ялан кул. Шундый суыкта! Бармакларыңны өшетсәң?!

— Ярар, күп сөйләнмә, — кыз кулларына өреп алды, — мин бит бүген курста дежурный, шуның өчен китердем. Ә минем кулларымда синең эшең булмасын. Аңладыңмы?

— Юк, аңламадым, — Ильяс елмаерга уйлаган иде, әмма барып чыкмады. Инде атнага якын грипп белән авыру, авызга бер валчык та ризык алмау, тулылыгы болай да чамалы гәүдәне ярыйсы ук бушаткан, Газизә әйтмешли, әрвах төсенә керткән иде. Елмаю урынына күмкүк иреннәр бары тик еламсырап җәелделәр генә:

— Синең бит бик әйбәт, дебет бияләйләрең бар иде, алар кайда?

— Бар иде дә, очтылар.

— Ничек очтылар?

— Өченче көнне Сара белән печән базарына үзебезгә кирәкле вак-төяк алырга барган идек. Шунда кесәдән чәлдергәннәр. Ярар, миндә эшең булмасын, үзеңне кара, аша, дим. Мин кулларымны өшетә язып китердем, син һаман кәнфитләнәсең.

— Ярый, ярый, — Ильяс икмәкне сындырып капты, ашны ашый башлады.— Рәхмәт. Башладым.

Борщ дип аталган сыек кәбестә суы инде суыну түгел, бозлана да башлаган иде. Ильяс башта Газизәнең күңеле булсын дип кенә капкалый башлаган иде, ашыйсы чынлап килгән икән, ныгытып тотынды.

— Әй, онытканмын да, — Газизә пальто куенына кыстырган дәреслекләрен чыгарды. — Менә, бу сиңа. — Ул калын бер дәфтәрне өстәлгә, Ильясның алдына куйды, — өч көнлек лекцияләрнең конспектлары. Минем почерк алама, ничек тә сукаларсың, яме.

— Ярый... Танырмын, барыбер тик ятам. — Ильяс ашый-ашый гына җавап бирде. — Алама, имеш, син минем почеркны әйт... Исерек таракан үрмәләгән төсле.

Газизә инде аңа карамый, бүлмә-хөҗрә эчен җентекләп күзәтә иде. Үзе тар, үзе озынча, әмма биек иде бүлмә. Озынча, тар тәрәзәләр. Хәзер алар бозланып катканнар, урам күренми дә. Инде күптәннән агартылмаган, саргайган, урыны-урыны белән штукатуры да кубып төшкән

дымлы стеналар. Менә шул стеналар буенда, салам матрац өстенә юка гына соры одеяллар ябылган, кәрлә мендәрләр аунаган дүрт карават. Хәзер алар буш.

— Кара әле, Ильяс, — Газизә бүлмәне карап-тикшереп бетереп, аңа таба борылды, — сезнең малайлар кайда соң? Лекцияләр әллә кайчан бетте. Син япа-ялгыз ятасың?

— Кайда булсын, — Ильяс борщның яртысын ашап, мискине этеп куйды. — Чиркәүгә киттеләр, бүген бит пасха. Может әле кулич та алып кайтырлар.

— Кулич! — Газизә кычкырып көлеп җибәрде. — Ул бит чукындырылган була. Син шуны ашыйсыңмы?

Ильяс иңнәрен генә сикертеп куйды, белмим, янәсе.

— Ярар, кулич көтеп, ураза тотып утырма. Алдыңдагын ашап бетер. Иртәгә тагын китерермен, обедка.

— Кирәкми, иртәгә, может, үзем техникумга барырмын.

— Юк, юк, — Газизә кулларын селкеде, — грипп... Алай иртә кузгалырга ярамый. Кайтарып алуы бар. Мин техникум врачына әйтермен иртәгә. Бәлки ул үзе килеп дару бирер... Деррр... — Газизә калтыранып китте. — Кара, сездә нинди суык, өшеп киттем. Син, син одеялыңа уран, яхшылап, яхшылап.

— Мич сүнгәндер, утыннар чи бит.

— Кая, синдә шырпы бармы?

— Хәзер, — Ильяс матрац астыннан шырпы алып Газизәгә сузды. — Мә, малайлардан яшерәм... Тәмәке тартырга алалар да, мич кабызырга да калмый.

— Тукта әле мин ул мичегезне әфсенләп кыздырыйм...

Газизә шырпыны алды да җиңнәрен сызганып, сөйләнә-сөйләнә коридорга, мичне кабызырга чыгып китте. Ул арада тагын чиркәү кыңгыраулары котырындылар:

— Даң-доң, Чеңгел-чеңгел, Дзаң-дзаң!

## III

— Ничек, Газизә, кичә сиңа ошадымы?

— Мин хәйран калдым. Такташ абый ничек матур сөйли үзенең шигырьләрен, ә? Мишәр акценты бигрәк килешеп тора үзенә, әйе бит, Ильяс? Шигырь җанланып китә. Менә, тыңла әле, мин Такташ абыйның үзе төсле мишәрчәләп укыйм.

Газизә, әз генә тамагын кырып, Ильяска иелә төшеп укый башлады.

Ак каенга асылып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым.
Менгән саен җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күрәлдем...
Ә син менәлмәдең,
Калдың,
Югалдың...

— Кара, әллә инде син үзең мишәр туфрагыннанмы? Ата мишәрләрчә укыйсың бит.

— Кит, булмас! — Газизә, Ильясның култыгыннан кулын тартып алып, читкәрәк тайпылды.

— Минем туфрагымда синең ни эшең бар? Мин Урал кызы.

— Бетте, бетте,— Ильяс кызны тагын култыгыннан алды.

— Инде әрләшмичә генә кайтыйк, яме? Киләсе атнадагы әдәби кичәгә мине тагын да алып барырсың, яме, Ильяс?

— Ә үзең кичә мәдәният йортына барыйк, дип чакырганда ничек кәҗәләндең, бармыйм да бармыйм, имеш.

— Мин оялдым.
— Кемнән?
— Үзем дә белмим.— Газизә, башын аз гына кыңгыр салып, Ильяска сыенды.— Мин бит белмәдем.
— Нәрсәне?
— Анда шундый олы шагыйрьләрнең буласын. Такташ, Туфан, Кутуй, Кави Нәҗми... Минем өчен алар йолдызлар кебек бик еракта гына яналар иде.
— Ә хәзер?
— Хәзер мин аларны үз күзләрем белән күрдем. Берсеннән-берсе шәбрәк сөйли шигырьләрен! Ә шулай да, берсе дә Такташ абый кебек матур, музыкаль тавыш белән сөйли алмый, әйе бит?
— Сезнең мишәр теленДәме?
— Кит, чукынган! — Кыз, егетнең кулыннан ычкынды да, Проломный урамына таба йөгерде. Ильяс аны көчкә куып җитте, кочаклап туктатты, Газизә, талпынып, ычкынырга тырышты.
— Җибәр! Мин бүтән синең белән кайтмыйм... Мишәр дә мишәр. Әнә трамвай да килә.
Алар җитәкләшеп йөгерә-йөгерә урам аша чыктылар. Шалтыр-шылтыр килеп трамвай узып китте.
Ильяс белән Газизә тагын култыклашып, бер-берсенә сыенып, үргә — Чернышевский урамына (хәзерге Ленин урамы) күтәрелә башладылар.
Акрын гына тәңкә кар ява. Баганаларда янган электр лампочкалары тирәсендә ак күбәләкләр тирбәлә. Аннан алар урам ташларына сыргылалар. Аяк астында әйтерсең алмаз кыйпылчыклары җем-җем итә— атлап басарга кыймыйсың... Яңа кар исе борынны кытыклый.
Егет белән кыз менә шушы күперен яткан карлардан ашыкмыйча гына атлап, сөйләшмичә, бер-берсенең йөрәк тибешен тыңлап Чернышевский урамына күтәрелделәр. Пассаж кырыеннан Черек күлгә төштеләр. Банк урамына килеп чыктылар һәм монастырьга таба атладылар.
Алар биек таш стеналарга якынлашканда күктә тулган ай күренде, тирә-як яктырып китте. Әйләнә-тирәдә мәрмәр йортлар һәм асыл ташлар сибелгән урамнар...
Ильяс белән Газизә, зур тимер капкадан монастырьның ишегалдына кереп, уң як собор янындагы өч катлы корпус — кызлар тулай торагының ишек төбендә тукталдылар. Бер-берсенең кулларыннан тотышып, озак кына сүзсез тордылар. Ниһаять, тынлыкны Газизә бозды:
— Я, җитәр. Мин инде керим.
— Тагын аз гына, бик аз гына торыйк инде. Төн шундый матур!
— Матурын матур да... Минем әле бер кочак эшем бар бит. Лекцияләрне карап чыгарга кирәк. Кызларга су җылытып куярга кушып киткән идем. Әй, онытканмын да, яле, егет, миңа якынырак кил әле, — Газизә Ильясны үзенә тартып алды һәм пальто төймәләрен ычкындырып күлмәк якасына үрелде.— Яле, яле, айга таба борыл.
— Тукта әле син, нишләвең бу? Әллә мине буарга җыенасыңмы?
— Буам! — Газизә кычкырып көлде дә ике куллап Ильясның муенын кысты, аннан артка чикте. — Күлмәк якаң керләнгән. Хәзер үк бүлмәңә кайтып сал да, күлмәгеңне миңа китер. Юып мич кырына элармен. Иртәгә хәтле кибәр.
— Нигә шул хәтле ашыгыч?
— Күп сөйләмә, мин бит синең шефың. Иртәгә, санитар тикшергәндә, күлмәгең керле булса ояты кемгә?
— Шефка.
— Вот, шулай булгач. Бер көнне Миңнебикәне ничек кызарттылар? Мине дә— шулай оятка калдырырга җыенасыңмы?

— Син әле тиз генә кызармассың.
— Кит, җүләр, әллә минем җаным юкмы? Ярый, хуш.

Газизә әйтеп тә бетермәде, Ильясның кулын ычкындырып корпусның ишегенә таба йөгерде, барып җиткәч, борылып кычкырды:

— Ильяс, ятып йоклама, күлмәгеңне тизрәк китер!

Егет әллә ишетте, әллә ишетмәде, баскан килеш кузгалмыйча урынында калды.

Тулган ай хәзер кафедраль соборның иске алтын тәресе өстендә асылынып тора. Еракта йолдызлар җемелдиләр. Монастырь эчендәге биек-биек корпуслар, чиркәүләр күгелҗем сөремгә төренеп тын калганнар. Капка буендагы өч корпус тәрәзәләрендә әле ут яна. Ә аргы баштагы зур корпуста — дөм караңгы. Анда монашкалар. Алар, мөгаен, чиркәүдә кичке гыйбадәттәдер.

Тирән тынлык.

Ильяс озак кына уйланып торды да, кинәт йокыдан уянгандай, сискәнеп башын күтәрде. Һәм капка якка, ирләр корпусына таба атлады.

Ай, моңаеп, аны артыннан озатып калды.

## IV

Икенче көнне кичен, техникумда лекцияләр тәмамлангач, Ильяс, киемнәрен гадәттәгечә алданрак алыр өчен, түбәнге катка — вестибюльгә йөгереп төшеп бара иде. Баскыч төбендә чак кына Газизәне төртеп екмады.

— Бәй, нишләп монда торасың?

Газизә җавап бирмәде, сүзсез генә профком бүлмәсе ишеген үтеп, стенага сөялде, башын кыңгыр салды һәм авыр сулап куйды.

— Әллә елый инде? — Ильяс аптырап Газизәнең янына ук килде, үрелеп йөзенә карады. Күзләре кызарган. Битендә яшь тамчылары. — Нәрсә булды? Ник дәшмисең, ә?

Газизә иңнәрен селкетеп, тагын бер кат үкседе дә стена якка борылды. Профком бүлмәсеннән көлешә-көлешә бер төркем студентлар чыктылар да баскычтан югары катка менеп киттеләр. Ә өстән түбәнге курс студентлары тыпыр-тыпыр төшеп, этешә-төртешә вешалкага таба йөгерделәр. Ильяс нишләргә белмичә аптырап калды, кием алу кайгысын да онытты.

Газизә һаман стенага борылган килеш тора. Үкси. Ильяс, нишлим икән дип икеләнеп торды да, кызга таба атлады, аны култыгыннан алды һәм аулак почмакка алып китте. Газизәнең терсәге дерелди иде. Алар коридорның иң очына — караңгыга, бозланып каткан тәрәзә янына килеп туктадылар.

— Әйт, ни булды? Ник елыйсың? Әллә стипендиядән төшерделәрме?

— Юк.
— Авырыйсың?
— Юк.
— Өеңнән берәр хафалы хәбәр килдеме әллә?
— Юк.

— Фу! — Ильяс ачуланып Газизәнең башын күтәреп күзләренә карамакчы булды, кыз ялт тәрәзә якка борылды, ычкынып китәргә омтылды.

— Җибәр дим, җибәр!
— Әйт, ник балавыз сыгасың?
— Ильяс!
— Әйтсәң җибәрәм.

— Уф алла...— кыз кинәт хәлсезләнеп егетнең күкрәгенә башын салды һәм еламсыраган тавыш белән, өзеп-өзеп сөйли башлады:
— Әле генә профкомда әрләшеп чыктым.
— Ни өчен?
— Аңларга теләмиләр. Олыларны укытыр өчен мине әллә кая, Яңа бистәгә билгеләгәннәр. Кичә барган идем, укыта торган өйләрен көчкә таптым. Бүлмә тулы сакаллы абыйлар, әниемнән олы апалар.
— Ул бит, Газизә, кайда да бер. Шуның өчен дә ул наданлыкка каршы көрәш инде.
— Мин аларны әйтмим, абыйлар да, апалар да әйбәтләр. Тырышып-тырышып укыйлар.
— Шулай булгач.
— Тукта әле, бүлдермә. Менә анда берничә егет бар. Гел миңа бәйләнеп кенә торалар. Теңкәмә тиеп беттеләр инде.
— Син игътибар итмә, укытуыңны бел.
— Итмә, имеш,— Газизәнең иңнәре тетрәнеп куйды,— дәрес беткәч кайтырга дип чыксам, теге икесе, озатабыз дип, юл бирмиләр. Авызларыннан аракы исе аңкып тора. Капка алдына бастылар да чыгармыйлар.
— Шуннан?
— Шуннан бер дәү абый — наверное грузчик — килеп чыкты да егетләрнең якаларыннан кысып тотты. «Молокосослар, нигә безнең мөгаллимәгә бәйләнәсез?» дип, икесен ике якка этеп җибәрде, мине трамвайга хәтле озатып куйды. Бүген инде анда барырга куркам. Алар бүген тагын килерләр.
Газизә, шәлен төзәтеп-тартып бәйләде дә, тәрәзә төбенә таянды.
— Әле профкомга кереп, башка кварталга күчерегез дигән идем, председатель: «Болай да укытучылар җитешми, баш катырып йөрмә!» дип кычкырды.
— Шуңа еладыңмы?
— Еламыйни...— Газизә ачуланып тәрәзәгә үк борылды,— сиңа көлке. Җыен хулиган арасына барып кара, үзе төнлә.
— Тукта, мин хәзер Габделхәй белән сөйләшеп чыгыйм әле,— Ильяс профком бүлмәсенә таба кызу-кызу атлады, бераз киткәч борылып кычкырды: — Газизә, беркая да китмә! Мин хәзер.
Газизә, яулыгы белән күзләрен сөртеп, коридор буенча бер әйләнергә өлгермәде, профком бүлмәсеннән атылып-бәрелеп Ильяс чыкты.
— Эш пеште, рәтләдем. Әйдә киемнәреңне алабыз.
Алар вешалкага барып пальтоларын киделәр дә урамга чыктылар. Салкынча һава җиңеләйтеп, егәрләндереп җибәрде. Ильяс Газизәне култыгыннан алды. Аяк астында кар шыгырдый. Урамда инде фонарьлар да кабынган. Машиналар сирәгәйгән. Күбесе җәяүлеләр — йөгерә-атлаучы, шау-шулы студент халкы. Чаттан борылгач, Ильяс өзелгән сүзне ялгап алып китте:
— Синең күршедәге кварталда укыта торган өченче курс студенты Галимҗан авырып киткән. Габделхәй шуңа күрә тиресенә сыеша алмый йөри икән. Ул кварталга мин барырга булдым. Шулай килештек,— инде ул бистәгә бергәләп барырбыз.
Газизә нигәдер адымын акрынайтты:
— Ә шулай да, Ильяс, мин куркам.
— Кемнән?
— Кемнән булсын, теге хулиган егетләрдән. Алар бит икәү. Җитмәсә, аю сынлы тазалар. Әллә нишләүләре бар.
— Әйдә, әйдә,— Ильяс Газизәне тагын да үзенәрәк тартып, тизрәк атлап китте,— мин дә камырдан әвәләгән түгел.
Ул нигәдер костюм кесәсен капшап куйды.
Усиядә крючник булып эшләүче Гарәфетдин аганың тар, әмма

озыннан-озынга сузылган коридор сыман бүлмәсе укучылар белән шыгрым тулы иде. Монда, Газизә әйтмешли, кара, җирән, хәтта чал төшә башлаган сакаллы абыйлар һәм шул ук чамадагы, йөзләре җыерчыклана башлаган битле апалар җыелган. Алар гөр килеп, тавышланып, нәрсә турындадыр бәхәсләшәләр иде, ишектә Ильяс күренүгә тынлык урнашты.

— Хөрмәтле шәкертләр, бүген бездә яңа мөгаллим, — диде түгәрәкнең старостасы итеп сайланган җирән сакаллы бер агай, Ильяска утырырга урындык куеп, бераз тайпылды да, шәкертләргә күз дә кысып алды. — Шауламагыз, хәзер ул арт сабакларыгызны укытыр...

— Ха-ха-ха...

— Ничево, без хәзерләнеп килдек.

— Арт як юеш түгел, аллага шөкер...

— Кит җүнсез, мөгаллим алдында ни сөйлисең.

— Мин... ни... дөресен әйтәм. Сабагымны хәзерләп килдем. Бир һәвтиягеңне, хәзер шатырдатып укып чыгам.

— Җитәр, җитәр! — Староста тагын тавыш бирде. — Сабакны башларга бирегез. Мөгаллим әфәнде, башлагыз. Безнең халык бераз мутрак инде ул.

— Ярый, алайса, иптәшләр, дәресне башлыйк, — дип, Ильяс аш өстәле өстенә куелган кунача хәтле генә кара тактага акбур белән латин хәрефләрен яза башлады. Тактадагыны кабатлап алыйк. Сез дә язсгыз, иптәшләр. Аннан китаптан күнекмәләр укырбыз.

Ике сәгатьтән соң Ильяс үз дәресен тәмамлап, күрше кварталга, мәчет каршындагы иске бер йортка Газизәне алырга килде. Караңгы коридордан кагыла-сугыла барып, бер ишекне ачты. Бәхеткә каршы, нәкъ эзләгәне — уку бүлмәсе икән. Газизә бер төркем апалар, үзенең укучылары белән сөйләшеп тора иде. Ильясны күргәч, алар белән хушлашып, ул ишеккә таба атлады.

Алар караңгы ишегалдыннан нәрсәләргәдер абына-сөртенә чыктылар да тар гына бер тыкрыкка борылдылар. Бер җирдә дә ут әсәре күренми. Караңгы. Җитмәсә, чокыр-чакыр. Бары тик пәрдәләре төшерелмәгән тәрәзәләрдән генә ара-тирә саргылт шәүләләр төшә. Шулар гына сукмакны бераз ишарәлиләр. Бара торгач ул шәүләләр дә сүнде. Инде бары каралтылар буйлап чамалап-капшанып барырга гына калды. Ильяс, алай-болай чокырга төшеп китмәсен дип, Газизәне тагын да үзенәрәк кыса төште.

Үткән-сүткән кеше дә күренми, бигрәк буш тыкрык.

— Ничек соң? — күңелсез булмасын дип, ахры, Ильяс сүз башлады — шәкертләрең дәресләрен хәзерләп килгәннәрме?

— Беләсеңме, Ильяс, мин хәйран калам. Көне-төне авыр эштә йөргән биш-алты бала ата-анасы булган олы кешеләр, сөялләнеп беткән кулларына карандаш алып, тырышып-тырышып язалар, күзлекләр киеп укыйлар. Бер-берсенә булышалар, хаталарын төзәтәләр. Кайвакытта көләселәрем килеп китә. Чак кына тыелып калам.

— Юк, Газизә, көләргә ярамый, киресенчә, аларның шулай ихлас укуларына сөенергә генә кирәк.

— Ну-ка, тәти егет, тукта әле!

Бер-берсенә иелеп сөйләшеп килгән егет белән кыз имәнеп киттеләр, каршыларында ике ир кеше басып тора, авызларында папирос.

— Сезгә ни кирәк? — Ильяс Газизәне бераз артка тартып, алга чыкты. — Ни йомыш?

— Син, тәти егет, әтәчләнмә, менә бу кызны калдыр да, үзең табан ялтырат,— диде алда торган озын буйлысы.

— Бу кызда эшегез булмасын.

— Мин сиңа яхшылык белән әйттем бит, этәчләнмә дип. Мин, брат, вакланырга яратмыйм. — Ул уң кулын кесәсенә тыгып нидер капшады. Артта торган юантыгы Газизәгә таба атлады.

— Әнкәй! — Газизә җан тавышы белән кычкырып җибәрде. Шул арада күрше өй тәрәзәсеннән төшкән яктыда кинәт пычак ялтырап китте.

— Ну, китәсеңме, падла!

— Хәзер... мин сезне...

Ильяс артка чигенде һәм кесәсеннән браунинг чыгарып, пычак белән килгән колга буйга төбәде.

— Ташла пычагыңны!

— Гайфи!

Ильяс чак борылып калды, аның нәкъ баш өстеннән олы бер таш кисәге чыжлап үтте дә каршы капкага барып бәрелде. Шундук шартлатып браунинг аткач, ут күренде, төтен исе аңкыды.

— Падла!

Тегеләр икесе ике якка чапты. Озын буйлысы абынып егылды, ләкин, ничектер бик тиз сикереп торып, каршыдагы капкага кереп югалды.

Газизә, хәлсезләнеп, Ильясның кулына ауды.

— Уф алла, — Газизә монастырь капкасыннан кереп, кызлар корпусы ишек алдына килеп туктагач кына телгә килде. — Уф алла... Кайтып җиттекме, юкмы?

Ул әле һаман калтырана, өзек-өзек сулый иде.

— Инде беттем дип уйлаган идем. Кара әле, Ильяс, — Газизә пышылдап кына эндәште, — ул ата торганны каян алдың? Андый куркыныч әйбер йөртүеңне миңа да сиздермәдең бит, ә?

— Җүләр, нинди куркыныч булсын, ди. Ул булмаса мине чәнчеп тә китәрләр иде.

— Анысы алай... Ә шулай да каян алдың? Аны бит теләсә кемгә бирмиләр.

— Ну да, бирмиләр. Мин аны кул куеп алдым.

— Әйт инде, — Газизә тагын Ильясның күкрәгенә сыена төште, — әйт, кемнән алдың?

— Әй, син дә инде, кемнән дә кемнән? Ул булмаса хәзер үзеңне күрер идең... Мин бит аны берәүгә дә күрсәтмичә, гел янымда йөртәм. Үткән кыш мине Акташ районына практикага җибәргәннәр иде бит.

— Анысын беләм.

— Белсәң, шул. Анда мине Ильтән-Бута дигән бер керәшен авылына укытучы итеп билгеләделәр. Нәкъ теге шау-шулы колхозлашу чоры. Бераздан мине Акташка, райкомга чакырып, үземне шул авылга колхоз оештыру буенча райком вәкиле итеп тә билгеләделәр. Мин инде мәктәптә укыту өстенә, авылда колхоз оештыру эшенә дә тотындым. Ул арада иптәш Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» мәкаләсе чыкты. Безнең колхоз таралды да китте. Безне тагын райкомга чакырдылар. Колхозларны таратуда астан эш йөрткән кулакларны раскулачивать итәргә куштылар. Андый корткычлар Ильтән-Бутада да бар иде. Мин авылга кайту белән җыелыш җыеп, шундыйларның берничәсен раскулачивать итәргә һәм авылдан куарга тәкъдим керттем. Җыелыш тәкъдимне кабул итте. Менә шул төнне мәктәпкә кайтып (мин аның бер бүлмәсендә тора идем) укучыларның дәфтәрләрен тикшерергә генә утырган идем, кинәт тәрәзә пыялалары чәлпәрәмә килеп коелды. Ут сүнде.

— Әбәү! Аттылармы?

— Таш ыргытканнар. Мичкә барып бәрелде.

— Ярый әле, үзеңә тимәгән...

— Менә шул вакыйгадан соң район милиция башлыгы мина, вакытлыча дип, шул нәмәстәне бирде,— Ильяс кесәсендәге браунингны каплап куйды.

— Акташтан киткәндә аны кире сорамадылармы?

— Беләсеңме, Газизә, дөресен әйткәндә, кайтырга ашыгып, аны тапшыру бөтенләй онытылган. Казанга җиткәч кенә исемә төште.

— Ярый ла шулай гына үтсә.

— Үтәр, менә бүген нинди кирәге булды.

— Анысы алай да, — Газизә Ильясны каты итеп кочты, — ярый әле, тегеләрнең берсенә дә тимәде... Әллә нинди бәлагә очрар идең.

— Беләсеңме, — Ильяс, нелә төште, акрын гына пышылдады, — дөресен әйткәндә, мин атарга да уйламаган идем... Теге, артта торганы таш ыргыткач ничек курокка басканымны да сизми калдым.

— Аллага шөкер, — Газизә Ильясның кулын кысты да кочагыннан чыкты, — ярар, бер бәладән котылдык. Инде иртәгә ул бистәгә бармыйк. Тагын әллә ниләр эшләүләре мөмкин.

— Ярар, профком белән сөйләшермен.

— Хуш.

Кызлар корпусының биек авыр ишеге шыгырдап ябылды. Чиркәүдән кара күләгәдәй берничә монашка чыкты.

## V

Зәңгәр күл. Нарат урманы. Кайдандыр ерактан бормаланып агып килгән кечерәк кенә инеш. Урман эчендә бүрәнәдән бурап, такта белән тышланган, яшел, күк, сары буяуларга буялган ике катлы йортлар —коттеджлар.

Зәңгәр күл ярында да асты таштан, өске каты агачтан салынып, такта белән тышланган зур, матур йорт тора. Тәрәзә яңаклары, карнизлар матур өлгеләр белән бизәлгән һәм акка буялган. Ерактан, наратлар арасыннан, бу йорт балкып, күлгә төшеп барган мәһабәт аккош булып күренеп кала. Йортның югары катында балкон, ул бөтен дүрт якта да бар. Өске кат бүлмәләрнең барлык ишекләре шул балконга чыга. Моннан матур күренешләр ачыла.

Тын, җилсез көннәрдә зәңгәр күл тылсымлы бер көзге булып, күзләрне камаштырып җәйрәп ята. Суы саф, чиста. Төбендәге вак ташлар, камышлар, зураеп күренә — кулыңны суз да ал! Кайнар шук студентлар үз исемнәрен, бигрәк тә сөйгән кызларыныкын камыштан, тал чыбыгыннан үреп күл төбенә ташлыйлар. Ул исемнәр зәбәрҗәт сыман нурланып шунда ята. Карагыз, көнләшегез, онытмагыз!

Әйтүләренә караганда, күл буендагы бу йортлар революциягә кадәр Казан сәүдәгәре Апанаевның җәйге дачасы булган. Хәзер инде ул Казан педагогия техникумы карамагындагы учхоз — уку-тәҗрибә хуҗалыгы.

Һәр язны кар китү белән монда студентлар килә. Алар көзге укулар башланганчы шушында торалар, җир сөрәләр, иген чәчәләр, яшелчә утырталар, печән чабалар, урып-җыялар, кыскасы, барлык авыл хуҗалыгы эшләрен башкаралар. Хуҗалыктан алынган уңыш студентлар өчен өстәмә ризык була. Учхозның студентлар өчен файдасы зур. Беренчедән, кыш буе монастырь хөҗрәләрендә яткан студентлар көнетөне уку, ачлы-туклы торудан соң гүзәл табигать кочагына чыгып, эшләп, туйганчы ашап ял итәләр. Икенчедән, студентлар ашханәсе казанына арзан бәяле он, ярма, бәрәңге, яшелчәләр өстәлә. Өченчедән... Хәер, ул турыда сүз соңрак булыр.

Ә хәзергә:

— Даң-доң!

— Даң-доң!
Йорт алдындагы баганага эленгән рельс кисәгенә дежур студент тимер таяк белән ике тапкыр сукты. Урман чыңлап китте.
— То-рыр-га!
— Подъем!
— Физ-за-ряд-ка!
— Даң-доң!
Дачаларның тәрәзәләре, ишекләре ачылды һәм майка-трусик кигән егетләр-кызлар йөгерешеп спорт мәйданына тезелә башладылар һәм хәйран калдылар. Бер төн эчендә дачадан дачага сузылган сукмакларда алма агачлары, сиреньнәр, күл ярларындагы шомыртлар дәррәү чәчәк атканнар, тирә-якка хуш ис таралган. Дәрт, егәр, рәхәт бирә торган тылсымлы хуш ис!
Физзарядкага тезелгән студентлар бу шифалы, хуш исле һаваны сулап туя алмыйлар, авыз-борыннары белән генә түгел, әйтерсең бөтен тәннәре белән сулыйлар.
— Бер-ике-өч!
— Бер-ике-өч!
Яшьлек яз белән очраша һәм тулып ташый.
Нинди бөек могҗиза син, табигать!

— Бригадир Салихов! — диде учхоз директоры, озын буйлы, баһадир сынлы, колагына җитә язган кара мыеклы Әхмәт ага. Студентлар аны Тукайның «Кисекбаш»ындагы цирк батырына ишарәләп Кара Әхмәт дип йөртәләр иде. Иртәнге аштан соң рельс бәйләнгән багана янындагы мәйданга, эшкә барырга җыенган студентлар янына килеп туктады да, Ильяска төбәлеп: — Син, егет, үзеңнең бригадаңны тегермән буасы артындагы кырга бәрәңге утыртырга алып бар, — диде. — Ә башкалар — минем белән парникка! Киттек!
— Әхмәт абый, ә көрәкләр, чиләкләр, — диде Газизә, алгарак чыгып, — тагын, кичәге кебек, учхоз буйлап завхозны эзлибезме?
— Эзләмәгез, туташ, мин монда — диде, җир астыннан калыккандай Газизәнең нәкъ артыннан килеп чыккан тәбәнәк, юан, кысык күзле шадра Шәйдулла. — Әйдә, подручком алып барам үзеңне.
— Ха-ха!
— Кит, шадра пәри! — Култыкларга үрелгән завхозны этеп җибәреп, Газизә читкәрәк тайпылды.— Үзебезнең егетләр дә җитәрлек. Теләңә салынма, бар чиләкләреңне чыгар!
— Туташ, — диде завхоз, директорның инде ярыйсы ук ераклашуын күреп, шадра ул, җан кисәгем, йөрәк яндыра.
— Я, беренче бригада, тезелегез! — диде Ильяс, бер-ике адым алга атлап.
Кызлар чыр-чу килеп тезелештеләр. Тагын команда яңгырады:
— Смирно! Шагом марш!
Бригаданың кузгалып китүе булды, кызлар бердәм, көр тавыш белән җыр да башладылар:

Без кабызган утлар сүнмәс алар,
Сүнмәс алар хәтәр җилләрдә.
Без кабызган утлар якты янар,
Якты янар хезмәт иләндә.

Иртәнге саф һавада җыр авазлары урман өстенә, зәңгәр күл өстенә күтәрелде һәм еракка-еракка канатланып очты. Шатлык, яшьлек дәрте таралды.

Без кичә алмаган юк кара урман,
Без җиңә алмаган дошман тумаган;
Безнең байраклар котлыйлар алар,
Котлыйлар алар хезмәт бәйрәмен.

Ераклаша барган җыр урман эченә кереп сүнде.

## VI

— Әйдә, Газизә, бераз ишегалдында йөрик әле,—диде Ильяс, отбой кыңгыравы шалтырап, танцы бетеп, студентлар бүлмәләренә тарала башлагач. — Бүген мин дежурный бит.

— Әбәү, терсәгемне авырттырасың, — Газизә кулын тартып алды,— син дежурный дип, мин төн буе йокламыйча йөримме?

— Ә мине жәлләмисеңме?

— Жәллим, — Газизә кычкырып көлде дә, кызларга ияреп, залдан чыга башлады, — хәерле төн.

— Иптәш Гайнуллина! — диде Ильяс, юри тавышын күтәреп. — Сез ашханәдә дежурный, эшегезгә барыгыз!

— Бар инде, бар, — кызларның берсе Газизәне Ильяска этәрде, — өзелә бит бригадирыбызның үзәге, бар...

— Жүнсез, — икенче кыз да Газизәнең юлына аркылы төште, — бар, бар, бригадирсыз калдырасың бит безне.

Кызлар, гөрләшеп көлештеләр дә, Газизәне калдырып, дачаларга таба йөгерештеләр.

— Рәхмәт дусларыңа, — диде Ильяс һәм Газизәнең беләгеннән кысып елмайды, — алар булмаса каласы да түгел идең, ә?..

— Әбәү, кадеремне җибәрепме?

— Бәямне төшерепме, диген, булмаса.

— Кит, мин закладка салган малмы әллә.

— Ал яулык, зәңгәр шәл, — Ильяс «Зәңгәр шәл» көенә көйләп тә алды, — үтә гомерем бигрәк җәл...

— Кара, син әле җырчы да икәнсең, белми идем.

— Нәрсә, әллә мине төшеп калган малай дип уйлыйсыңмы?

— Өстә, өстә, мин бригадир да диген...

— Ярар... Әнә Сәрби апа залны ябарга килә, киттек.

— Ярый, только озак түгел... Аннан кереп ятармын. Хәзер үк йокым килә, иртәгә ял көне түгел бит...

Алар, залдан чыгып, сукмак буенча күлгә таба атладылар. Наратлар өстеннән моңаеп кына ярым тулы ай карады. Ниндидер бер кош үксеп куйды — мөгаен, төш күрәдер...

— Ильяс, — яшел чирәм өстендә Ильяска сыенып утырган Газизә дерелдәп куйды. — Мин туңам... Китим... Әнә ай кая авышты. Инде таң атарга да вакыт җитәдер. Бигрәк озак утырдык.

Ильяс дәшмәде, өстендәге костюмын салып кызның җилкәсен каплады, әйбәтләп төрде һәм үзенең кочагына тартты.

— Менә шулай утыр, йокла, яме. Мин кузгалмыйм.

Газизә башын Ильясның күкрәгенә салды да күзләрен йомды.

Ай болытлар арасына кереп югалды. Тирә-як караңгыланды. Озакламый болытлар таралдылар да ай гына яктырып килеп чыкты... Ә Газизә инде йоклап та киткән. Сабый балалар төсле ишетелер-ишетелмәс кенә мышнап, рәхәтләнеп йоклый. Ильяс бер кулы белән аны аркасыннан кочкан килеш сокланып йөзенә карады.

Озынчарак тулы йөз. Бит алмалары алсу. Киң маңгайга зәңгәр яулык астыннан бер тотам соргылт чәч төшкән. Шулар битне кытыклаган, ахрысы. Газизә йокы аралаш кына аларны сул кулы белән каерып җибәргән булды. Яулык арткарак тартылды, чәч тузгый төште. Кечерәк кенә борын, күперенке, алсу иреннәр сулыш алган саен селкенеп куялар.

Әле косметика һәм маникюр тимәгән гади, саф сылулык, масаюны белми торган керсез, гамьсез, гүзәл яшьлек. Шул яшьлек хәзер үзенең өмете кочагында онытылып, сөенеп йоклый. Әле аларга барысы да ал-

су, матур булып күренә. Язмышның яшенле, күкрәүле көннәре әле аларга билгесез.

Кинәт Газизә үксегәндәй итеп өзек-өзек сулады да Ильяснык куенынарак сыенды, бите ачa төште, нигәдер елмайды. Ильяс ул иреннәргә иелде дә кинәт туктап калды, тартынды. Бигрәк тәмле йоклый... Уятырмын... Ул Газизәнең иңеннән шуып төшкән пинжәкне япты, аны үзенә кысыбрак кочты һәм нигәдер башын күтәреп тирә-якка күз салды.

Бу ни бу? Бөтен тирә-як алсу. Наратлар да, әле генә ак фонтан булып утырган шомыртлар да, хәтта зәңгәр күл үзе дә алсуланып яна.

— Әллә инде төш күрәм?..

Ильяс көнчыгыш якка карады. Таң!

Нинди матур, гүзәл син, туып килгән якты көн. Каядыр күтәреләсе, очасы, гизәсе килә... Яшисе, бик озак яшисе килә... Газизә белән бергә тормыш корасы килә.

Көнчыгыш инде кызарганнан-кызара бара. Зәңгәр күл әйтерсең яна... Әнә, яр читендә алсу көймә, нәкъ әкиятләрдә тасвирланган төсле, алсу басмага бәйләп куелган алсу көймә.

Ильяс нигәдер бик озак шул көймәгә карап торды, уйланды. Менә ул сак кына Газизәне кочаклады, аннан җай белән генә тезләреннән чирәмгә төшерде, пинжәге белән төрә төште. Газизә күзләрен дә ачмады, изрәп йоклый бирде. Ильяс аяк очларына гына басып ярдан күтәрелде, урман эчендәге үзе торган корпуска таба йөгерде. Озакламый ул ике ишкәк һәм мандолина күтәреп кире Газизә янына килде.

— Газизә, — Ильяс аның башын акрын гына күтәреп тезләренә куйды, — Газизә!

Рәхәтләнеп, мышнап йоклый. Алсу иреннәр... Ильяс шул иреннәргә иелгән генә иде — керфекләр калтыранды, күзләр ачылып китте. Йокы сарылган йөз кинәт нурланып яктырды. Бит алмалары кызарып — янып китте. Бөтен йөз балкыды.

— Әбәү! — Газизә күзләрен йомып ачты да сискәнеп торып утырды. — Йоклап киткәнмен бит... — Муенына ук шуып төшкән яулыгын чишеп алды, тузган чәчләрен бармаклары белән генә артка тарап ташлады. — Әбәү! Таң да аткан ич! Оят! Оят! — Ул чәбәләнеп сикереп торды:

— И алла, бүлмәдәге кызлар инде ни әйтерләр?..

Ильяс аны кочаклап алды.

— Газизә, кара әле мин нәрсә алып килдем?

— Кайда?

— Менә ич, пинжәк өстендә.

Газизә яулыгын бәйли-бәйли Ильяс күрсәткән якка карады һәм гаҗәпләнеп кычкырып җибәрде:

— Мандолина! Анысы нәрсәгә тагын?!

— Хәзер әнә теге басма буендагы көймәгә утырабыз да, яңа көнне каршылыйбыз. Мин мандолинода уйныйм, син...

— Әйе, шул гына җитмәгән, — Газизә, Ильясны этеп җибәреп, күлмәк итәгенә ябышкан үлән, чүп-чарларны кагып төшерде дә китә башлады, — әле бусына да җавап бирәсе бар. Оятсыз. Киттем.

— Тукта, — Ильяс аның юлын бүлде, кычкырып көлде, — семь бед, один ответ, диләр бит руслар. — Газизәне ул, күтәреп алып, ярдан түбән, басмага таба алып китте, суга шыбырдап ком коелды. Урман эчендә ниндидер кош уянып тавыш бирде.

Ишкәкләр, асылынган ике канат шикелле, кыймылдамас булып калды. Көймә тын күл өстеннән үз агышы белән йөзә. Күл өстендә — шау чәчәккә күмелгән ярлар, кырлар өстендә — моң. Чылтырап аккан салкын чишмә сыман мандолина моңы һәм тылсымлы кош булып таң нурларына таба очкан җыр — саф мәхәббәт көе яңгырый.

Зәңгәр күзең, күз керфеген
Тибрәндереп карама,
Күз каравың ук шикелле
Йөрәгемә кадала.

Медиатор кылларга кискенрәк орынган саен моң көчәя, тавыш тагын да яктырак булып кабына.

Әй, бөдрә чәч, зәңгәр күз,
Әйтмәм, бәгърем, авыр сүз.

Таң нурлары сүнделәр. Балкып кояш күтәрелде. Кошлар уянып матур, сихри җырларын башладылар. Чәчәк таҗындагы алмаз тамчылар, салават күперенең барлык төсләрен җыеп балкыды.

Мандолина, акрын гына дерелдәп аккорд бирде дә, «Таң алды» көенә күчте. Газизә үзе дә сизмәстән шуның моңына кушылды:

Таң — таң ата, чулпан калка,
Чулпан таңны уята.
Сызылып таңнар аткан чакта
Җырлата да, елата...

Ильяс ишкәкләрне алды да инде ярга ук килеп терәлгән көймәне аргы башка, шау чәчәккә күмелгән шомыртларга борды. Вак кына дулкыннар күтәрелде. Алар көймәгә сак кына сугылдылар.

Ильяс мандолинаны үзе утырган утыргычның кырыена куйды да бер генә атлап алга Газизә янына күчте, аның иңнәренә кулын салды.

— Инде болай гына җырла әле, яме?

— Кит, җүләр, бөтен төнне тиле кеше төсле күл өстендә җырлап үткәрдек. Инде кызларга да торырга вакыт. Көймәне тизләт, кеше-кара күргәнче бүлмәләребезгә керик, ичмасам, әллә ни уйларлар...

— Хәзер, — Ильяс ишкәккә үрелгән булды да, ялт борылып Газизәне кочаклады, иреннәренә үрелде.

— Кит, оятсыз! — Газизә, гадәтенчә, тайпылып калмакчы иде, көймә чайкалды да Ильяс утырган якка кыйшайды. Чупылт... Икесе дә суга аудылар. Мандолина нәрсәгәдер бәрелеп чыңлап китте. Газизә җан тавышы белән кычкырды:

— Әб-әүү... батабыз!

Чаң тавышы ишетелде.

## VII

Икенче көнне иртәнге аштан соң Ильяс үз бригадасын эшкә алып барырга дип тезеп торганда, әллә кайдан Кара Әхмәт йөгереп килеп чыкты. Тирләгән, мышнаган.

— Әй, бригадир, кара' әле, — диде ул килеп җитәр-җитмәс, тыны кысылудан туктап, тотлыгып, — бүген бригадаңны үзем генә алып чыгармын. — Килеп җитеп маңгаендагы борчак-борчак тирләрен сөртте.— Әле генә техникум директоры звонить итте. Ильяс Салихов тиз генә кайтып миңа күренсен, ди.

— Нигә икән? — диде Ильяс гаҗәпләнеп, — кызу эш вакыты бит...

— Әйе, эш вакыты, тик директор бик кисәтте. Димәк, ашыгыч эш,— ул кулы белән күпер ягына ишарәләде. — Әнә тегермәнче Педер дәдә ат җигә. Ул техникумга он алып барырга җыена. Тизрәк. Китеп бармасын. Йөгер!

Кара Әхмәт гадәтенчә мыегын рәтләп күпертергә кереште. Кызлар колактан-колакка нидер пышылдап, көлешергә тотындылар.

Ильяс әле һаман кузгалмыйча аптырап, икеләнеп тора иде. Нигә бу кадәр ашыгыч чакыралар икән? Әллә әти-әни авырып китеп телеграмма суккannармы? Аның карашы ничектер кызлар арасында тыгыз-

ланган Газизәгә төште. Менә ул кызлардан аерылып читкәрәк чыкты да Ильяска таба берничә адым атлады һәм туктап аңа күзләрен тутырып карады. Үзе нигәдер кызарды. Иреннәре кыймылдап киткәндәй булды (әллә инде Ильяска гына шулай тоелдымы?). Ильясның да аңа сүзе бар иде кебек. Нәрсә? Үзе дә белмәде. Ә күзләр, зур зәңгәр күзләр, шундый моңсуланып карыйлар... Күңел нәрсәдер әйтергә тели, ә тел әйләнми...

Гаҗәп бит ул кеше күңеле! Иллә сизгер дә соң! Сүз белән генә түгел, ымлап та күпне әйтә ул. Әмма күп очракта без бу ымга колак салмыйбыз һәм соңыннан үкенәбез, гомер буена үкенеп бетә алмыйбыз.

Бу нәкъ менә Ильяс белән Газизәнең күз карашлары бер-берсенә омтылган, нәрсәдер әйтергә теләгән мизгел, язмышның — мәхәббәтнең хәлиткеч борылышы... Әмма алар икесе дә моны сизмәделәр, бер генә сүз булса да әйтеп калырга җөрьәт итмәделәр.

Ә кирәк иде, бик кирәк иде ул сүзнең әйтелүе.

— Ильяс, әнә Педер дәдә атын җигеп күпергә дә чыкты... Тиз бул... ни катып калдың? — диде кара мыек инде хәл кергән тавыш белән боерып һәм шундук кызларга карап елмайды: — Ә сез, гүзәлләрем, әкренләп кузгалыгыз.

— Җыр беләнме, Әхмәт абый, — диде чая кыз Хәдичә, Газизәгә күз кысып, — озатабыз бит.

Газизә дәшмәде, кызлар арасына кереп югалды. Ильяс, бригада белән хушлашты да, инде күпердән үк чыгып барган Педер дәдәгә таба йөгерде. Кызлар күмәкләп җыр башладылар.

Отряд урман эченә кереп югалды. Ә җыр һаман яңгырады.

— Иптәш Салихов, — диде Ильястан күп булса өч-дүрт яшькә генә олырак булган комсомолның өлкә комитеты секретаре, — сез үткән кыш Акташ районында эшләдегезме?

Ильяс бераз аптырап, каушап калды: «Әллә браунингны эзлиләр инде. Нәрсә дип җавап бирергә?»

— Сез минем сорауны төшенмәдегез әллә, иптәш Салихов?

— Ә...—Ильяс сискәнеп урындыктан тора башлады.

— Утырыгыз, утыр... Нигә борчыласыз? Мин сезне Акташ районында укыткан һәм колхозлашу буенча райком вәкиле булып эшләгән дип ишеткән идем.

— Әйе, — диде Ильяс, каушавын әле дә тыя алмыйча, — эшләдем.

— Бик әйбәт,— секретарь елмайды,— кайсы авылда эшләдегез?

— Ильтән-Бутада.

— Монысы яхшы. — Секретарь урыныннан торып кабинет буенча арлы-бирле йөри башлады. Юнгштурм үзенә килешеп, төз, матур гәүдәсенә сыланып тора, хром итекләр атлаган саен шыгыр-шыгыр итәләр. — Акташ партия комитеты сезгә яхшы характеристика бирде. Колхозлашу эшендә тырышып эшләде, диелгән. Менә безгә нәкъ шундый иптәшләр кирәк тә, — итекләр тагын шыгыр-шыгыр итеп ишеккә таба киттеләр, кире кайттылар. — Без хәзер авылда эшләп тәҗрибә алган бер төркем комсомолларны авылларга җибәрәбез. Булышырга. Шул җөмләдән сезне дә күздә тотабыз.

— Мин бит әле техникумны тәмамламадым. Госэкзамен калды.

— Анысын беләбез, — диде секретарь, Ильясның җилкәсеннән инде бөтенләй дусларча кочып — беләбез, техникум директоры белән сөйләшеп килештек. Сез анда яхшы укучыларның берсе саналасыз икән. Учхозда бригадир да, — дип мактап куйды.

— Шулаен шулай да бит, — Ильяс инде бөтенләй тынычланып, уйлап бик җитди эндәште. — Миңа диплом алырга кирәк бит.

— Анысына кайгырма, Ильяс. Диплом булыр. Ә менә хәзер безнең авылларда эш начар, — секретарь, кырыслана төшеп, урынына барып утырды. Мангаена тузып төшкән коңгырт чәчләрен бармаклары белән тарап артка ташлады һәм төбәлеп Ильяска карады. — Кулаклар коткы тараталар. Колхозлар тарала башлады.

Урманнарда ара-тирә бандит шайкалары күренә. Кулаклар анда яшьләрне тарталар. Безнең бурыч: яшьләрне кулак коткысыннан тартып алып колхоз ягына күчерү. Менә шуның өчен өлкә партия һәм комсомол комитеты сезнең кебек сыналган яшьләрне авылларга җибәрергә, андагы активка булышлык күрсәтергә карар кабул итте. Шуны тормышка ашыру йөзеннән без менә сезне дә чакырырга мәҗбүр булдык. Шул ук үзегез эшләгән Акташ районына, хәтта Ильтән-Бута авылына комсомол оештыручысы итеп командировать итмәкче идек.

— Кайчан?

— Бүген. Хәзер үк. Билетлар алынган. Син ялгыз түгел. Акташка унҗиде кешелек отряд озатабыз. Чистайга хәтле пароход белән. Анда сезне акташлылар каршы алыр.

Ильяс каядыр ашыкты һәм үзе дә сизмәстән аягүрә басты.

— Яхшы, — диде ул. Нәрсә яхшы, үзе дә төшенмәде.

Биек йортлары, Кремле, Сөембикә манарасы белән чайкалып, томанга уралып Казан артта калды. Бары тик Сөембикә манарасы гына озак күренеп торды, ахырда ул да югалды. «Тукта әле... Бу ни булды, ә? Нигә мин авылга китәргә ризалык бирдем. Ник әле мин зәңгәр күлне ташладым? Җүләр!..» Күңел икеләнде, сызланды. Ильяс, аптырагач, каютасына керде дә чемоданнан беркемгә дә күрсәтми яшереп, саклап йөргән клеенка тышлы дәфтәрен алып яза башлады:

> Пароход китте,
> Ә күңелем калды.
> Күңелем калды синдә өзелеп...

## VIII

Ильтән-Бута Акташ районының иң чигендәге салам түбәле, тәбәнәк өйләрдән торган кечкенә бер керәшен авылы. Шундый ук тузгантаралган каралтылар, җил капкалар. Бары тик авыл уртасындагы иске чиркәү мәйданында гына такта түбәле зур берничә өй, биек урыс капкалар масаеп торалар. Бу йортларның хуҗалары да заманында авылны дер селкетеп, канын эчеп яшәгән байгуралар — поп Сергей, кибетче Митри дәдә һәм шикле бер кәсеп белән кинәт баеп киткән бертуган Иван, Петька һәм Симон Тукмаковлар.

Ильяс монда һәр ызбаны, анда кем торганны яхшы белә. Әмма бу авыл аны шикле бер кырыслык белән каршылады. Дөресен әйткәндә, аны монда бер кеше дә каршы алмады. Ильяс Акташтан монда хәтле базарлы авылга баручы бер татар егетенә утырып килгән иде. Шуңа күрә аңа авыл башындагы каберлек янында төшеп калырга туры килде. Агай керәшен зиратындагы аркылы-торкылы сугылган агач тәреләргә, җимерелгән чардуганнарга кырын күз белән генә карады да күк алашасын куды.

— На-на, мур кыргыры, нәрсә керәшен тәреләренә исең китте? На! — һәм үзе авыз эченнән генә ниндидер бер дога да укып алды. Ильяс чемоданын күтәреп авылга таба атлады.

Урамнар буш. Хәтта бала-чага да күренми. Бары тик берничә кәрләшкә эт кенә әллә кайдан килеп чыктылар да, нечкә әче тавыш белән өрә-өрә, Ильясны мәктәп мәйданына хәтле озата бардылар. «Булма-

са, мәктәпнең бер бүлмәсендә генә торып торырмын», дип уйланып килгән иде яшь укытучы. Әмма үзенең бер кыш гомерен биргән мәктәбенә килеп җитүгә аптырап калды.

Бу ни бу? Әллә инде урамны ялгышканмы? Юктыр, ничек ялгыштырырга, авылда ни барысы өч урам. Әнә, каршыда бөкрәеп, җиргә сеңеп барган иске чиркәү, аңда — мәһабәт тополь. Мәктәп урынында бары көл өеме, кирпеч ватыклары һәм тырпаеп торган кисәүләр.

Ильяс авыл советында да кеше очратмагач, үзе фатирда торган Натүк түтәй өенә китте.

— Школны әйтәсеңме, ул җанды бит, улым.

— Нишләп?

— Нишләп дип, пуҗардан... Яз башы иде. Иртәнчәк, инешкә суга барыйм дип көянтә-чиләкләремне күтәреп чыксам, исем-акылым китте. Пуҗар, школ җанып ята. Тирә-күршеләр чиләкләр белән су ташый, сибеп азапланалар. Мин дә инешкә йөгердем...

Түтәй мич алдына куйган самаварның торбасын алып берничә мәртәбә бик каты өрде. Самавар җанланып сызгыра башлады. Әй аллам, Христос, мин әйләнеп су белән килгәнче, школның стеналары җанып җимерелеп төшкән ие... Үзе дә, мескен, бик иске иде шул. Чиркәү белән бер яшьлек иде бит. Минем атайлар салган.

— Нишләп янды икән, түтәй? Әллә мичтә ут-мазар калган булганмы?

— Әллә тагын,— Натүк түтәй, кулын селтәде дә, гөҗләп, кайнап чыккан самаварны җилтерәтеп сәкегә җәелгән шакмаклы ашъяулык өстенә китереп утыртты. Зур-зур телемләп ипи кисте, кечерәк чүлмәк белән каймак һәм дүрт-биш йомырка китереп куйды. — Әйдә, утыр, энем. Карының ачкандыр... Иртән дәдәңә пешергән йомыркалар ие. Ул урманга утынга китте. Бүген бөтен авыл шунда... Утыр, утыр. Оялма, аша. Каймагына житеш, менә кашык.

— Ә шулай да, — Ильяс чәй эчә-эчә һаман сораулар бирде, — нидән янды икән мәктәп. Тиктомалдан булмас.

— Әй, энем, дөньялар бозылды. Алладан да, поптан да курыкмыйлар. Бигрәк бозылды халык... Син аша, аша, энем, йомыркасын ал. Үзеңне сагынып, дәдәң белән искә алып та утырдык әле күптән түгел, килеп яхшы иткәнсең.

Ильяс Натүк түтәйләрдә кунды да, иртән көтү белән торып, җәяүләп кенә Акташка — райкомга китте.

Райком секретаре Афанасьев озын буйлы, ябык, караңгы чырайлы кеше иде.

— Тирә-як урманнарда бандитлар йөри, — дип башлады ул сүзен.— Халыкны колхоздан өркетергә тырышалар. Төп эш хәзер яшьләрне кулаклар йогынтысына бирмәү. — Секретарь арыган, кызарган күзләре белән Ильяска төбәлде. — Менә эш нәрсәдә.

— Ә аны, иптәш секретарь, ничек башларга соң? — Ильяска тир бәреп чыкты. — Ильтән-Бутада бер егет, бер кыз күрмәдем. Былтыр бит алар күп иде. Кичке укуга йөриләр иде...

— Алар әле урман эшендәдер, тиздән кайтырлар. Ә сиңа, иптәш, бу елны да яшьләрне укытырга туры килер.

Ильяс аптырап калды:

— Кайда укытырга?

— Мәктәптә.

— Мәктәптә? — Ильяс гаҗәпләнеп аңа карады. Әллә инде Ильтән-Бутадагы мәктәпнең януын белми? Секретарь елмайды, караңгы чырае яктырып китте.

— Беләм, иптәш Салихов, яхшы беләм мин Ильтән-Бута мәктәбенең януын, — ул авыр итеп көрсенде, йөзе тагын караңгыланып кит-

те. Аннан озак итеп, буылып йөткерде, борылып авызын яулыгы белән сөртте. Ильяс уңайсызланып башын түбән иде.

— Ул пожар шундагы кулаклар эше.

— Шулай булгач яшьләрне кайда җыярга соң?

— Менә нәрсә, иптәш Салихов, — диде секретарь, үз-үзе белән генә сөйләшкәндәй итеп, — мин сезнең тәрҗемәи хәлегез белән таныш. Сезнең әтиегез балта остасы. Димәк, балта эшен күреп үскәнсез.

— Әти белән өй бурарга да туры килгәләде.

— Бигрәк тә яхшы. Менә сезгә Ильтән-Бутада яңа мәктәп салуны үз кулыгызга алырга кирәк. Ул бер үк вакытта мәктәп тә, клуб та булыр. Без монда районо, райфо белән сөйләшеп, төзү сметасын әзерләп куйган идек инде. Сез бик вакытлы килдегез. Авыл халкы хәзер шул төзелешкә агач әзерләүдә. Сезгә дә шунда барырга кирәк булыр. Бурага яхшы бүрәнәләр сайларга кирәк.

— Әйе, ә кайчан барырга соң урманга?

— Бүген. Лесничий Иван Петрович хәзер райисполкомда. Әйдә, мин сезне таныштырыйм.

Алар икесе дә урыннарыннан кузгалдылар.

## IX

Язгы иртәләрнең берсендә син ашыгыч эшең белән боз өстеннән елганың аргы ягына чыгасың. Инде эшең бетеп, төш вакытында өеңә кайтырга дип киредән ярга килсәң дә хәйран каласың... Бозлар яргаланып, берсе өстенә берсе күтәрелеп, тыгызлана баралар һәм инде син басып торган ярга үреләләр. Язгы ташкын ярларга сыеша алмый гүләп, шаулап килә.

Кайда инде ул хәзер елга аркылы чыгулар. Юл киселгән. Көтәргә кирәк. Ташкынның тынганын, елганың бозлардан арынганын көтәргә. Күпме көтәргә кирәк соң? Бер көн? Өч көн? Бер атна?!.

Ниһаять, бозлар чәлпәрәмә килеп, ватылып таралалар. Елганың бите ачыла. Ул тынычлана. Син хәзер я көймә белән, я паром белән елганың аргы ягына — үзең теләгән якка чыгасың. Көндәлек тормышта ул шулай җиңел генә хәл ителә. Ә язмышта? Кешеләр язмышында да шундый хәтәр кичүләр була бит.

Кайчакта кеше ничектер тыныч кына, гамьсез генә үтеп китә ул кичүне. Чөнки ул әлеге хәлиткеч-хәтәр адымнарны атлаганда, үзенең кире кайтуы турында һич тә икеләнми. Әмма үтүе була, күпер җимерелә. Кире кайтасы юл өзелә.

Күпмегә?

Ильяс язмышында да шундый көтелмәгән хәл булды. Ул теге кояшлы язгы иртәдә зәңгәр күлдән Казанга чыгып киткәндә Газизәне шул ук кичне кайтып күрәчәгенә, тагын төнозын икәүләп сандугачлар моңын тыңлаячагына аз гына да шикләнмәгән иде. Ә чынлыкта ул кичү хәлиткеч борылыш булган. Ә бит нәкъ шул хәтәр мизгелдә Газизәнең күңеле нидер сизенде. Ул Ильяска нинди бик кирәкле сүз әйтергә теләп, аңа таба берничә адым да атлады, югыйсә. Ә Ильяс төшенмәде, игътибар итмәде, ашыкты. Хәзер инде менә яңгырлы көз. «Инде күп тә калмады, тиздән мәктәпне салып бетерәбез. Балаларны укыта башлаганчы, бер атнага булса да, Казанга — Газизә янына сөйләшергә кайтып килергә кирәк. Бәлкем... Бу «бәлкем»не әле Ильяс кычкырып әйтми — тирән сер итеп саклый, уйланып кына йөри иде. Чыннан да, бәлкем Газизә бу мәктәпкә укытучы булып та килер... Килер микән?

Соңгы вакытта көннәрнең шыксызлануына, көне-төне туктаусыз яңгыр явуына да карамастан, Ильяс үзенең бригадасын эштән туктатма-

ды, киресенчә, мәктәпне тизрәк салып бетереп, Ильтән-Бута балаларын яңа мәктәпкә җыярга ашыктырды. Бергәләп урман кискән, бүрәнә чыгарган унҗиде егет (арада Ильясның былтыргы укучылары да бар иде) аның белән бергә балта чабалар. Инде бура буралган, түбә такта белән ябылган, түшәм ышкыланып түшәлгән. Бары ишек-тәрәзә яңакларын утыртасы, рамнар, ишекләр куясы гына калды. Зур дүрт бүлмәле, якты тәрәзәле мәктәп тиздән үзенең шау-шулы укучыларын каршы алачак.

Иләктән иләгән сыман вак кына, эчпошыргыч яңгыр сибәли иде ул иртәне. Ильяс аңа карамыйча, башкалардан алданрак килеп, тышкы ишек яңагын утыртырга кереште.

— Ходай ярдәм бирсен! — Берәү тамак кырды.

Ильяс балтасын куеп башын күтәрде. Авыл Советы председателе Матвей дәдә кулына нниндидер кәгазь тоткан килеш басып тора.

— Рәхмәт. Мәктәп эченә кер, — диде Ильяс ишектән читкәрәк китеп.— Әйдә, әйдәгуз, Матвей агай.

— Юк инде, улым, кереп тормыйм. Менә,— ул кулындагы кәгазен сузды, — райвоенкоматтан сиңа бер кәгазь. Син инде кул куй да бир. Почта ашыктыра. Районга соңга калам, ди.

Ильяс бераз аптырап кәгазьне алды да укып чыкты. Ильяс чакыру кәгазенә кул куеп, түбәнге өлешен ертты да, авыл Советы председателенә кире бирде.

Матвей дәдә сул аягына аксап пычрак урам буенча каядыр ашыкты.

Икенче көнне райвоенкоматтагы медкомиссия Ильясны Кызыл Армия сафында хезмәт итәргә яраклы дип тапты. Ә өченче көнне аны инде үзе кебек бер төркем такыр башлы егетләр белән Әфган чигенә, ком читләренә озаттылар.

Казан еракта калды. Казан гынамы?! Газизә калды. Беренче саф мәхәббәте калды.

Поезд кузгалып киткәч Ильяс вагонның өстәге сәкесенә менеп почмакка ятты да, куен кесәсеннән кечкенә генә бер фото чыгарды. Газизә аны Ильяска соңгы хатында җибәргән иде.

Вагоннар шык-шык итә. Буферлар зыңлап куялар. Ильяс, һаман фотога карап, пароходта язган шигырен аз гына үзгәртеп кабатлый:

> Поезд китте, алып китте мине,
> Ә күңелем калды,
> Күңелем калды, синдә өзелеп...

## X

Юк, җиңел булмады солдат хезмәте Ильяска. Бигрәк тә ил чигендә, ком читләрендә, шәфкатьсез сәмум-әфган искәндә. Иртәдән кичкә хәтле баш өстендәге кояш миләрне кайната. Бүрек хәтле генә дә күләгә табып булмый. Ком, ком, ком барханнары. Мич төсле янып кызган ялангач таш кыялар һәм күченеп йөргән ком таулары.

Шундый шартларда пулемет станнары, мылтык, кирәк һәм башка солдат кирәк-яраклары күтәреп йөгерергә, эссе комга күмелеп ятарга, янып торган текә таш кыяларга тырмашып менәргә, төшәргә кирәк. Тәннәрдән шыбырдап тир ага һәм тоз булып сылана. Иреннәр чатнап ярыла. Тел авызга сыймый диярлек. Флягадагы су — НЗ. Ул ахыр чиктә, котылгысыз очракта гына махсус рөхсәт белән эчелә. Ә көндәлек өйрәнүләрдә суга сусаган тән тоз белән капланудан сыкрап чатный, яргалана. Су сорый ул. Ә су юк.

Берничә көннәргә сузылган маршлар, марш-походлар, өйрәнүләр һәм төннәрен, тревога белән торып, чик бозучыларны, контра-бандитларны куу. Кышын Әфганстан ягыннан сәмумнан да яман суык үзәкләргә үтә торган җил исә башлый, ком барханнарын күтәрә. Ә солдат һаман хезмәттә.

Менә шундый шартларда хезмәт итте кече командир Салихов Ильяс. Бу частькә килгәнче ул алты айлык кече командирлар мәктәбен тәмамлаган иде. Авыр иде солдат хезмәте. Әмма җилләр шашынган күз ачкысыз кара төннәрдә дә якты минутлары була иде аның. Ул — Газизәдән хат килгәндә!

Шакмаклы дәфтәр битенә шәмәхә карандаш белән тезелгән вак кына хәрефләр. Ә аларда шундый татлы, йөрәккә якын сүзләр...

Ильяс хатка карап Газизә белән сөйләшә. Казармадагы иптәшләре ишетмәсен дип, күңелдән генә сөйләшә ул.

— Син көтәрсеңме минем кайтканны?

— Көтәм, көтәм, җан кисәгем. Мин бит хәзер Саба районында укытучы булып эшлим. Хезмәт срогың тулгач бирегә кайт, яме. Монда бик матур болыннар, кырлар. Бергә күңелле булыр, әйе бит, Ильяс?

— Әйе, әйе, җаным, күңелле булыр. Хезмәт срогым тулу белән...

Кинәт бөтен казарманы сискәндереп быргы тавышы яңгырый.

— Тревога!

Хат шунда ук гимнастерка кесәсенә яшерелә. Командир пирамидадагы мылтыкка ташлана һәм, отделениесен тезеп, команда бирә.

— Плацка!

Солдатлар дагалы итекләре белән каты баса-баса казарманы дер селкетәләр. Ә быргы һаман әле кычкыра, күңелләргә шом сала, ашыктыра.

— Тизрәк! Тизрәк! Чикне бозганнар.

## XI

— Әйе, Газизә Гайнуллина бездә ана теле укытты. Яхшы укытучы иде.

— Хәзер кайда?

— Анысын инде әйтә алмыйбыз, иптәш командир. Бу ел язын, нәкъ имтиханнар алдыннан кинәт кенә авырып китеп, больницага кергән иде. Йөрәк авыруы белән.

— Шуннан?

— Шуннан май башында туганнары килеп алып киттеләр.

— Кая?

— Кем белә инде... Мөгаен, дәваланыргадыр. Ул бит үзе Урал ягыннан иде... Мин ул вакытта Казанда идем, шуңа күрә кая алып китүләрен әйтә алмыйм, кадерле иптәш.

Саба район мәгариф бүлеге мөдиреннән Газизә турында алган бар мәгълүмат шушы иде.

Инде нишләргә соң? Ильяс Әфган чигеннән Татарстанның бу кечкенә район үзәгенә очып кайткандай килгән иде бит. «Көтәрмен, сагынып көтәрмен», дигән иде Газизә, зарыгып көттергән хатларында. Ә үзе — көтмәгән.

Кайда ул хәзер? Ничек табарга?

Ильяс, Сабадан кире Казанга кайтып, техникумда бергә укыган кызларны эзләп тапты да Газизә турында сорашты. Әмма алар да аның кайда булуын ачык әйтә алмадылар. Бары тик Газизәнең техникумдагы ахирәте Зифа гына, аптырагач:

— Ул бит Урал ягыннан. Мөгаен, туганнары шунда алып киткәннәрдер, — диде.

Урал зур ул! Азия белән Европаны икегә аерып тора. Эзләп кара аннан Газизә исемле бер кызны...

Ильяс Казанда бер атна торды. Бер-ике тапкыр Болак буендагы техникумда, аннан элекке тулай торакта — монастырьда булды да Газизәнең эзләрен таба алмагач, туган ягы Казагыстанга кайтып китте.

## XII

— Ой-бай, хуш килдегез жолдас Ильяс Салихов, югары чыгыңыз,— дип партиянең Күкчәтау шәһәр комитеты секретаре Ильяс кабинетка керүгә урыныннан торып, өстәл артыннан чыгып, ике кулын биреп күреште. Бу урта яшьләрдәге, тулы гәүдәле, киң битле, кысык күзле казакъ иде. Стена буендагы урындыкны өстәл янына китереп куеп Ильяска урын күрсәтте. Үзе урынына утырып сүзен дәвам итте:

— Мин сезнең армиядән кайтуыгызны ишетеп, көтеп тора идем. Безгә какраз татар мәктәбенә педагог, конкрет әйткәндә, директор кирәк.

— Иптәш секретарь, — Ильяс нигәдер урындыгын өстәлгә тартыбрак утырды, мин бит әле учетка басарга гына килгән идем. Әле ял да итмәгән.

— Ой-бай,— секретарь кычкырып көлеп куйды, бите тагын да җәелә төште, ап-ак тешләре күренде. — Ялны алдагы елда икәвемез бергә алып Бурабайга барып кымыз эчәрмез. Хәзер җомышны башлау кирәк... Ал, шулай килештек, — диде дә торып Ильясның кулын кысты. Ильяс аптырап калды.

Секретарь әйтү белән генә канәгатьләнмичә, Ильяс белән бергә кабинеттан чыгып, яшел мәктәпкә — тыштан яшелгә буялганга Күкчәтау халкы аны яшел мәктәп дип йөртә иде — барды, эчтән-тыштан җентекләп карап чыкты. Күп кенә тәрәзәләрнең капкачлары бер генә тупсада эленеп тора. Кайберләре җирдә аунап ята. Тәрәзә пыялалары ватык. Парталарның да күбесе каерылган. Мичләрнең морҗалары җимерек. Гомумән, монда күп нәрсәне буярга, сыларга, төзәтергә кирәк иде.

Менә сиңа ял урынына бер муенга ике камыт. Ильтән-Бутада да мәктәпне яңадан салды, ә монда тизрәк ремонт башларга кирәк. Инде август башлана. Ярый әле балта осталары эзләп йөрисе булмады.

— Андый вак-төяк ремонтны үзебез генә башкарырбыз. Пыяла-мазар куярга рамчы Рәхимнең дә кулы буш,— диде әтисе Газизулла, улының солдаттан туры өйгә кайтып үзе янында урнашуына куанып.

Икенче көнне үк мәктәптә балта чапкан, кадак каккан тавышлар ишетелә башлады һәм беренче сентябрьгә ремонт эшләре төгәлләнеп, аның — кайчандыр Ильяс үзе укыган мәктәпнең — ишекләре ачылды. Укучыларны яңа директор үзе каршылады. Кирәкле укытучылар да табылды. Тарих белән географиядән генә кешеләр юк иде. Ул фәннәрне директор үзе алып барырга булды. Ә китап, дәреслекләр һәм башка уку-укыту әсбапларын Ильяс Казаннан алдырган иде.

Эшләр җайланды. Әмма Ильясның үз күңеле тыныч түгел иде. Көндезләрен эш белән, укытучылар-укучылар белән мавыгып, уйланырга вакыт калмый. Ә кичләрен-төннәрен? Озын төннәрдә керфегенә йокы кунмады.

Күңеле һаман сагына, эзләнә иде. «Кайда икән ул хәзер? Авырыймы? Бәлкем?.. Юк, юк. Ул исән! Әмма минем өчен исәнме ул? Бәлкем ул инде башка кеше кочагындадыр? Онытырга! Онытырга кирәк. Бөтенләйгә!» Ильяс әле унга, әле сулга борылып ята. Күзләрен йома... Ә күз алдында һаман Газизә. Башын аз гына кыңгыр салып, моңсу

гына карап тора һәм ишетелер-ишетелмәс кенә эндәшә: «Ильяс, мин сине мәңгелек дус дип уйлаган идем. Ә син?»

Ильяс үзе дә сизмәстән кулларын суза:

— Газизә!..



### XIII

«...Ниһаять, мин аякка бастым. Озак, елдан артык авырганнан соң. Йөрәк чире белән. Башта больницада яттым. Аннан Кавказда, Кисловодск шәһәрендә дәваландым. Ванналар алдым һәм нарзан эчтем. Менә шуннан соң гына йөри башладым. Кисловодскидан кайтып бераз ял иткәч, сине эзләп Казанга бардым. Техникумда бергә укыган иптәшләрдән сораштым. Ахирәтем Зифа сине былтыр күргән икән. Әйтүенә караганда, син дә мине эзләгәнсең. Рәхмәт онытмавыңа. Менә Зифадан алган адрес буенча сиңа хат язам. Белмим, сине эзләп табармы? Тапсын иде.

Сагындым, Ильяс, үзеңне бик сагындым. Күрәсем килә. Мин бит хәзер Уралда, әниләрдә торам. Безнең авылдан ерак түгел тимер юл уза. Кечкенә генә разъезд да бар. Бәлкем син, Ильяс, килеп тә чыгарсың. Көтәм. Паровоз тавышын ишеткән саен, әллә ул киләме, дип, разъезд юлына карармын.

Сагынып, кайнар сәлам белән: Газизәң».

Бу көтелмәгән хатны алуга Ильяс аптырап калды. Сөенү. Ашкыну. Ашыгу — барысы да бергә калкып чыкты. Ул көнозын үзен әрләп йөрде... «Оятсыз! Ул авырган, үлем белән яшәү арасында җәфаланган. Ә мин?.. Мин аны әллә нинди, Газизәнең уена да килмәгән гөнаһларда гаепләдем. Көнләштем. Каргадым. Мин гаепле. Гафу ит, гафу ит мине Га-зи-зәм. Мин синең турыңда бер вакытта да, бер вакытта да начар уйламадым. Теге икеләнүләрем дә, бары тик артык яратудан, артык сагынудан, сагыштан... Кичер, кичер мине, кадерлем, яме. Мин бүген үк, хәзер үк синең яныңа очам. Синең кочагыңа атылам. Шатлыгым, якты өметем минем, җан кисәгем, Га-зи-зәм...»

Ильяс шул ук көнне вокзалга йөгерде. Иртәгесе көнгә билет алды.

Билетын кесәсенә салып, тынычланып, вокзалдан чыккач кына Ильяс дөньяны ап-ачык итеп күрде. Бу ни хәл? Кайдан килгән бу хәтле гүзәллек? Вокзал каршындагы бакчада сиреньнәр шау чәчәктә. Хуш ис борынны яра, исертә.

— Тукта әле, кайчан мин моны күрдем соң? Кайда?— Ильяс бакчага кереп ап-ак чәчәккә күмелеп утырган куаклар астындагы урындыкка утырды. Энҗе чуклар аның баш өстендә тирбәләләр. Ул иркенләп, киң итеп сулыш алды. Нинди матур бу дөнья! Башта бер уй, бер кайгы, бер гамь юк. Нинди рәхәт! Ә шулай да? Кайда, кайчан күргән идем соң мин мондый чәчәкләрне, нурга күмелгән дөньяны?..

— Әйе, әйе.— Ул шатлыгыннан кычкырып куйды һәм шунда ук, кеше-кара ишетмәгәе дип, тирә-якка каранды. Юк икән. Әйе, истә... Зәңгәр күлдә. Газизә белән көймәдә йөргәндә. Менә табигать тагын чәчәкләргә күмелгәндә, мин аның кочагына атылам...

Төн юлга җыену, чемоданны тутыру, ашкыну, сагыну белән йокысыз үтте. Зарыгып көткән таң атты да, алтын нурлар Ильяс бүлмәсенең тәрәзәсенә төште. Бүлмә яктылык, шатлык белән тулды.

Берничә сәгатьтән Ильяс вокзалдан чемоданын күтәреп кире кайтты.

Бу — кояшлы иртә — бөек фаҗиганең башлану көне иде. Илгә сугыш килде.

Поезд инде өченче тәүлек ашыга.
Кояш кызарып ерак офыкка төшеп бара. Шәфәкъ яна. Болытларга кан тамчылары тама сыман.
Поезд Урал тауларын урап узып, Ильяс зарыгып көткән разъездга якынлашты. Йөрәк элеккегә караганда да катырак, ешрак тибә башлады. Күңел ярсыды. Ильяс чыдый алмады, аягүрә басты, ишеккә аркылы салынган бастырыкны да шәйләмичә алга үрелде, кемдер арттан килеп тотты.
— Җуләр, төшеп китәсең бит.
Ильяс аны ишетмәде, ишек киртәсенә бәрелеп туктап калды.
...Менә ул разъезд. Арлы-бирле ауган кап-кара шпаллар, рельслар. Әнә алда озын һәм бердәнбер өй — разъезд өе. Сары буяуга буялган. Каршыдагы бакчасында ялгыз яшь нарат үсә. Әнә — сары йорттан кулына саргылт флаг тоткан тимер юлчы киемле бер агай чыкты. Полотнога җиткәч флагын аз гына алга сузды да туктап калды. Әнә, йорт артыннан тагын берәү йөгерә... Хатын-кыз! Күк күлмәк, кызыл косынка, кулында төенчеге дә бар...
— Га-зи-зә!
Ильяс чак кына вагоннан сикереп төшмәде, күкрәге белән ишек бастырыгына ятты, бар тавышына кычкырды:
— Га-зи-зә!!
— Ильяс!..
Косынка ялкынланып янды, якынлашты. Буферлар чыңлады. Тәгәрмәчләр элеккегә караганда да ашыга төшеп, катырак шакылдадылар. Кызыл косынка абына-сөртенә полотнога күтәрелде, составка якынлашты, кулын болгады, әче тавыш белән кычкырды:
— Иль-яс!..
Һәм нәрсәгәдер абынып егылды.
Поезд аның саен шакылдап, чыңлап ашыкты.
Дежурный саргылт флагын төшереп, разъезд өенә таба борылды. Өй буенда яшел ялкын булып яшь нарат һәм полотнога егылган кызыл косынкалы кыз калды.
Поезд канлы шәфәкъка кереп югалды.

## XIV

Дүрт ел буена ут, кан, үлем дәрьясы эчендә йөргән лейтенант Салихов Ильяс сау-сәламәт калды.
Бүген 1945 елның 9 мае. Берлин. Җимерелгән рейхстаг хәрабәләре алдында аның танкы сакта тора. Тирә-якта әле һаман ут, төтен, сирәк булса да шартлаулар һәм автоматтан атулар ишетелгәли.— Әллә инде котылудан өмет өзгән фашистлар ата, әллә инде җиңү шатлыгыннан тыела алмыйча безнең солдатлар Берлин күген тишкәләп күңел ачалар?
Лейтенант гранит, мәрмәр хәрабәләргә бер мәл карап торды да, гаҗәпләнеп үз-үзен капшаштырып куйды. Ничек исән калган ул?
Снаряд кыйпылчыклары аның сул кулын, уң аягын ике тапкыр «ялап» үттеләр. Шартлау дулкыныннан очып һушыннан язды — контузия алды. Госпитальләрдә ятты. Күпме иптәшләре монда килеп җитә алмады, бу җиңү өчен юл салып үзләре ярты юлда ятып калдылар. Әле кичә генә соңгы тапкыр атакага күтәрелгән иптәшләрнең дә күбесе хәзер юк. Нинди фаҗига? Ә Ильяс Салихов сау-исән.
Җылы яз. Хәрабәләр арасыннан яшел агачлар күренә. Монда да бәлки каядыр читтә шомыртлар, сиреньнәр, акацияләр чәчәк аткандыр. Ильяс тагын чәчәкләргә күмелгән язны, зәңгәр күлне күз алдына китерде һәм авыр итеп көрсенде. Газизә! Кайда икән ул хәзер? Ул да сагына микән зәңгәр күлне? Күрешербезме икән тагын?..

Кинэт Ильясның уйларын бүлеп быргы тавышы колагын ярды.
— Тревога!
— Тревога!
Прага баш күтәргән.
Прага ярдәм сорый.
Лейтенант Салихов экипажы танкка кереп утырды.
Кузгалырга! Курс — Прага!
Танк калтыранды, чылбыр табаннар чинап куйды һәм Т—34 корыч колоннага кушылды.
Боргаланып сузылган юлның ике ягында — мәһабәт каштаннар. Алар да шау чәчәктә.
Үрләр, таулар, урманнар, елгалар ашыгып артта кала бара. Әнә алда тагын ука булып ялтырап яткан елга һәм бөкре күпер. Колонна шуны узарга тиеш. Лейтенант Салиховның танкысы да күпергә килеп керде һәм... күпер, кинәт күккә күтәрелгәндәй, бөтен тимер рәшәткәләре, бетон балкалары белән үрә басты. Танк бер күтәрелде дә бар гәүдәсе белән упкынга шуышты.
Өченче ел дигәндә Ильяс култык таякларына таянып госпитальдән чыкты, вокзалга барып билет алды һәм туган шәһәре Күкчәтауга кайтып китте. Эчке бер дулкынлану һәм түземсезлек белән туган йортының ишеген шакыды Ильяс.
Кайдадыр абзар эчендә булса кирәк, эт өрде. Ләкин эндәшүче булмады. Ильяс инде катырак шакырга тотынды. Ишеккә берничә тапкыр култык таягы белән дә бәргәләде.
— Кем анда?
Өйалдында ут кабынды һәм ишек ачылды.
— Сез кем?
Озын буйлы, түгәрәк йөзле ят бер апай ишек ачты.
— Сезгә кем кирәк?
Әйтерсең аның өстенә салкын су койдылар. Ильяс калтыранып, чайкалып китте, ишек бусагасына тотынып калды. Нәрсәдер әйтергә теләгән иде дә, әйтә алмады, бугазына төер утырды.
Абына-сөртенә бусаганы атлады. Газизулла абзый улын күргә ашыгып сәкедән төште дә кочаклыйм дигәндә генә кинәт туктап калды, үксеп елый башлады. Өчесе дә сәке кырыена утырдылар. Өйне кара кайгы басты.
Иртәгесен Ильяс култык таякларын шыгырдатып акрын гына зиратка таба атлады. Көн кояшлы, җылы иде. Төнлә аз гына кар сибәләп үткән. Бөтен тирә-як энҗе бөртекләре чәчелгәндәй җемелди.
Зират шәһәр читендә, күл артында иде. Озак атларга туры килде. Култык аслары авырта башлады.
Күл буена җитәрәк, бәхеткә каршы, бер машина Ильяс янында туктап калды:
— Әйдә, абый, утыр! Кая барыш?
— Зиратка.
Яшь шофер егет Ильясны кабинага күтәреп утыртышты да нәкъ зират капкасы алдына китереп төшерде.
Зират өстендә ялангач усак, каен агачлары. Ауган, кыйшайган кабер такталары. Әнә, яшел чардуган янында, әле каралырга өлгермәгән кабер тактасы. Очы ярым ай рәвешендә уелган. Ильяс шунда таба атлады. Атасының әйтүенә караганда, энисенең кабере шул булырга тиеш. «...Садыйк кызы Маһиҗамал фаный дөньяны бакый дөньяга рәхмәт әйләде». Бу сүзләр гарәп хәрефләре белән тактага уелган һәм яшел буяуга буялган.
Ильяс кабер алдына, изге туфракка — көрткә тезләнде. Баш иелде. Битне кайнар яшь тамчылары чылатты.
Җанга якын туган ана да, сөйгән яр да юклыктан күңел әрни.

## XV

Ильясның эшләре җайлы гына башланып киткән иде. Шәһәр мәгариф бүлеге аны яңадан үзе эшләгән мәктәпкә директор итеп билгеләде. Сугыш елларында мәктәп бинасы, аның эчке җиһазлары ярыйсы ук тузган-таушалган иде. Эшне тагын ремонттан башларга туры килде.

Директорлык вазифасын үтәү белән бергә ул тарих, тел-әдәбият фәннәреннән дә дәрес бирә башлады.

Өйдә дә тынычлык. Газизулла абзый һаман әле үзенең балта эшендә. Әмма хәзер инде элекке кебек өйләр салып йөрми, сугыш вакытында күчеп килгән бер заводның столяр цехында эшли. Үзен мактыйлар, бүләкләр, өстәмә паеклар да алып тора. Үги анасы Рабига да: «Улым, өс-башың каралмаганмы?»— дип сорап кына тора, барсын да вакытында юа, үтүкли. Аш-суга да бик оста, тырыш, пөхтә хатын. Үги дип бер дә зарланырлык түгел.

Инде тынычлап яшәргә дә була иде. Көтелмәгән бер хәл Ильясны бөтенләй чыгырыннан чыгарып ташлады.

Эшләреннән бераз арыганрак арада ул Газизәнең элекке адресы белән (адрес китаплар актарганда килеп чыкты) Уралга хат язды һәм зур түземсезлек белән җавап көтте. Һәр кич мәктәптән кайтышлый капка баганасына беркетелгән почта ящигын карый, барлык газета-журналларны бит-битләп актарып чыга — хат эзли.

Тора-бара әллә өмете өзелде, әллә күңеле суынды — ул инде хат көтми башлады. Бер кичне исә һич уйламаганда ящиктан бер конверт килеп чыкты. Эче жу итеп китте Ильясның. «Аңардан»... Йөрәк дөпдөп тибә. Әллә ничек башы әйләнгәндәй булды, тәне бер эсселәнеп, бер суынып алды.

Бу ни бу?

Ильяс хәлсезләнеп койма буендагы кар түшәлгән урындыкка чүкте, шактый таушалып, ертылып, әллә нинди штамплар сугылган конвертны әйләндереп-әйләндереп карады.

— Бу... Бу бит минем хат. Нигә ул кире әйләнеп кайткан?— «Адресат выбыл» дигән штампны ул инде кырык кабат укыса да, нигәдер мәгънәсенә һаман төшенә алмый иде.

Якында гына буылып эт өрде. Ильяс сискәнеп китеп аягүрә басты, көрткә чәчелгән газета-журналларны җыйды.

— Улым... әллә авырып киттеңме? Чыраең качкан,— диде үги анасы Ильяс ишектән кергәч.

Ильяс эндәшмәде, үз бүлмәсенә узды һәм караватка ауды. Үги ана аны чәй эчәргә ике-өч тапкыр чакырса да, Ильяс, башым авырта дип, чыкмады.

Икенче көнне кичен Ильяс үз гомерендә беренче тапкыр салмыш баш белән кайтты.

— Син шаулама, карчык, эшендә берәр җайсыз хәл булгандыр,— диде Газизулла абзый, улының мондый хәлдә кайтуына борчылып. Дөрес, аның үзенең дә кайвакыт салгалый торган гадәте бар, ә менә директор улының сәрхуш булуы бер дә ошамады... Әмма сүз кузгатмады. «Баш төзәтер дә басылыр...» дип уйлады. Әмма эш «баш төзәтү» белән генә очланмады шул, еш кабатлана башлады. Хәтта аны урамнан култыклап алып кайтулар да булды. Ата аптыраудан чыннан борчылуга күчте.

## XVI

Партиянең шәһәр комитетында коммунист Салихов Ильясның персонал эше каралды һәм аңа каты шелтә бирделәр. Эчүдән туктамаса, партиядән чыгарып, эшеннән алыначагы турында нык кисәттеләр.

Соңгы сүзен әйткәндә Ильяс беркемгә дә карамады. Әллә инде карап та күрмәде. Көчкә-көчкә генә: «Инде эчмәм», диде дә тиз генә урынына чүкте. Бу вәгъдәне ул күз буяр өчен түгел, чын күңелдән, үз-үзен тиргәп, вәгъдәсендә торачагына ышанып әйткән иде. Әмма бюро утырышыннан чыгуга аны нинди дер бер сәер өермә бөтереп чолгап алды сыман — күңеле тулды, елыйсы килде.

Булдыра алган кадәр ашыгып баскычтан төште, ике катлы агач йорттан чыгып тиз генә чаттан борылды. Ул әле үзенең кая барасын да белми, бары тик кем дә булса арттан килеп кайгыны уртаклаша башламасын дип качарга гына ашыга иде.

Көн болытлы, кар яумый, җил юк. Менә ул шәһәр бакчасының көрткә баткан эскәмиясендә утыра. Нигә — үзе дә белми. Баш өстендә ялангач топольләр шыгырдый. Якында гына саескан такылдап үтте. Күңелсез. Ильясның күңеле асты-өскә килә. Тәне бер кызып, бер суынып ала. Иелгән башны һәм күңелне бер генә уй бораулый: нишләргә?

Менә кинәт күңел икегә — ике Ильяска бүленгәндәй булды һәм ике Ильяс үзара бәхәсләшә-ызгыша башладылар.

Ильяс I. Оятың бармы? Үзең укытучы, балалар тәрбияләүче, үзең зәм-зәм кабып мәсхәрә була яздың. Теге чандыр, кискен тавышлы хатын бюрода бик дөрес янады бит: сине тәрбияләп маташырга түгел, директорлыктан да куарга кирәк.

Ильяс II. Әйдә, куыгыз.

Ильяс I. Нәрсә, карап торырлар дисеңме әллә, куарлар да шул. Инвалид дип тормаслар.

Ильяс II. Тукта, тукта, син минем авырткан җиремә басма.

Ильяс I. Әһә... Туры әйткән туганына ярамыйммы? Алай булгач, эчмә. Моңарчы эчмичә йөрдең, үлмәдең бит.

Ильяс II. Җитәр! Тукта! Баш катырып һаман бер чүбекне чәйнисең. Синнән башкалар чәйнәгәне дә җитәрлек. «Эчмә дә эчмә!» Ә беләсеңме ник эчәм?!

Ильяс I. Я, әйтеп кара.

Ильяс II. Син көлмә!

Ильяс I. Бер дә көлмим. Я, әйт аракы белән дуслашуыңның сәбәбен?

Ильяс II. Беренчедән, мин эчкече түгел. Йөрәк янганга чыдый алмыйча гына капкаладым.

Ильяс I. Ха-ха! Бу, иптәш, яңа аргумент түгел. Барлык алкоголиклар да йөрәк янганнан эчә.

Ильяс II. Җитте. Син тагын көлә башладың. Кешечә итеп күңелне бушатырга бир әле.

Ильяс I. Бетте, бетте. Ләм-мим. Әйдә бушат күңелеңне бушатырлыгы булса.

Ильяс II. Их! Белмисез хәлне, белмисез... Ильяс тагын көрсенеп куйды. Мин бит инде утыз алтыда. Үзем һаман буйдак. Кордашларымның инде өйләнерлек уллары, кияүгә бирерлек кызлары бар. Менә, брат, эш нәрсәдә...

Ильяс I. Сине кем тота, өйлән. Кызлар беткәнмени? Аларга буең җитмәсә, менә дигән тол хатыннар бар. Йорт-җирләре белән.

Ильяс II. Өйлән дә өйлән... Ул сиңа тун алу түгел. Аны да киеп карап, сайлап алалар.

Ильяс I. Хәләлеңне үзең белеп син дә сайла. Кем каршы тора.

Ильяс II. Их... Белмисез... Күңел! Күңелгә якыны кирәк аның. Менә шундый җан теләгәне юк бит, җан теләгәне...

Ильяс I. Ә Газизә?

Ильяс II. (авыр итеп сулады. Кесәсеннән папирос чыгарып кабыз-

ды. Бер суырды да карга ташлады. Ул пышылдап сүнде). Менә бар хикмәт тә шул Газизәдә инде. Бар өметне баглап язган хатым җавапсыз кайтты бит.

Ильяс I. Беләм. Димәк, Газизә юк. Ул кияүгә чыккан.

Ильяс II. Булмас! (Ачуыннан сикереп торды, тирә-якка каранды. Ялангач агачлар һәм усак башында кара карга). Ярый әле берәү дә юк. Юкса, бу эчеп юләрләнә диярләр иде. Булмас! Булмас...

Ильяс I. Тукта әле, синең ул Газизәне күрмәгәнеңә ничә ел булды?

Ильяс II. Ничә ел дип... Чыннан да ничә ел? Минем бит ул турыда уйлаганым да юк! Әйдә исәплик. Мин — Ильтән-Бутага кайчан киткән идем? Утыз беренчедә. Димәк...

Ильяс I. Димәк, унҗиде ел. Юләр, инде Газизәнең унҗиде яшьлек баласы бардыр. Ә син һаман аны көтәсең.

Ильяс II. (кычкырып җибәрде). Безнең арага кермә! Ул көтәм дип сүз бирде, фронтка да язды...

Ильяс I. Их, син мәҗнүн... Кайсы кыз көтәм дип вәгъдә бирми. Ә үзе чибәррәк берәүгә очраса ябыша да чыга.

Ильяс II. Молчать! (Уң кулы кемнедер этеп җибәргәндәй ачулы селтәнде.) Газизә андыйлардан түгел...

Ильяс I. Тукта әле, син бит, брат, ник эчә башлавыңны сөйләргә булган идең. Ә үзең әллә нинди биш былтырга, кысыр мәхәббәткә кереп киттең.

Ильяс II. Их... (Тагын авыр көрсенде.) Төшенмисез күңелне. Бар хикмәт тә шунда бит. Йөрәк яна. Сагыштан. Менә шул ялкынны бераз басар өчендер... Кайгыдан...

Колак төбендә бер тавыш яңгырады:

— Иптәш Салихов, бу сезме?

Ильяс сискәнеп башын күтәрде. Каршында өстенә яшькелт телогрейка кигән, башына ак мамык шәл ябынган бер хатын басып тора иде. Урта буйлы, тулы гәүдәле, кап-кара күзләр. Куе кара кашлар. Әз генә сипкелле түгәрәк йөз. Нечкә иреннәр. Әллә инде чегән хатыны. Ильяс башта аны ничектер танымый торды.

— Әллә танымыйсызмы?

Кара күзләр зураеп ачылдылар. «Мәдинә! Укытучы Мәдинә!»

Ильяс каушап сикереп торды.

— Исәнмесез, Мәдинә...— Ул ни әйтергә белми аптырап торды.— Менә бер иптәштән кайтып килә идем...

— Бәй, сез калтырыйсыз. Туңдыгызмы әллә. Әйдәгез, безгә. Менә бу бакча каршында гына бит. Бүлмәмне дә күреп чыгарсыз. Чәй эчәрбез. Җылынырсыз. Әйдәгез.

— Рәхмәт, рәхмәт. Мин әле генә...

— Юк, юк. — Мәдинә Ильясның култыгыннан алды. — Нинди эш ул, өй каршына килеп кермичә китү. Мин үпкәләрмен дә. — Мәдинә керсез, самими бер елмаю белән елмайды. — Әйдәгез, киттек.

Ильяс нишләргә дә белмичә урыныннан кузгалды. Кар шыгырдады. Усак башындагы карга бер каркылдады да, очып китте.

«Кайдан килеп төште соң бу таракан минем ашка?» — дип уйлады Ильяс.

## XVII

Еш булмаса да казакъ далаларында да күлләр очрый. Кырыйларында башка күлләрнеке кебек биек ярлар, таш кыялар яки таулар булмый. Алар ачык, алар җәйрәп ята — күксел күктәге тулган ай диярсең. Шуңа күрәдер казакъ халкы дала күлләрен айдын күл — ай күле дип атый.

Миңа еш кына шундый айдын күл буйларында утырырга туры килә. Карыйм да шул җәйрәп яткан сихри көзгегә хәйран калам. Аның көмеш йөзендә бер җыерчык, бер сыр да юк — тип-тигез һәм якты. Үзе үтәдән-үтә күренмәле, чиста-саф. Көмеш тәңкәле чабаклар, алтын канатлы кызылканатлар, кара күләгә шикелле чуртаннар ялт-йолт итеп уйнаклап уза. Күл төбендәге вак ком кызгылт, саргылт, яшькелт мәрҗәннәр булып балкыйлар. Анда көндезен кояш, төннәрен ай коена, йолдызлар тирбәлә. Әллә чыннан да бу күл мәшһүр Әбугалисинаның тылсымлы көзгесеме икән дип гаҗәпләнеп, сокланып карап торасың айдын күлләргә! Ә шулай да бер вакыт...

Ә бер вакыт кинәт айдын күлнең дә йөзе караңгыланып китә, җыерчыклана, сыры була. Аннары дулкыннар калкып күтәрелә. Башта бик вак булсалар да, озакламый алар ак чалмалы авыр дулкыннарга әвереләләр. Сискәнеп уянган дала юлбарысы төсле күл ырылдыйыңгыраша һәм үкереп яктан-якка ташлана башлый.

Ильясның да күңеле кайчандыр дала күле кебек тыныч, гамьсез иде. Рәхәт иде. Ә хәзер? Ә хәзер ул яраланган җәйрән кебек тыпырчына...

Ильяс үз-үзен күпме әрләмәсен, сүкмәсен, барыбер «җан җылысын» өенә алып кайтып булса да капкалый әле. Кайчак елый, җырлый, мандолина чиртә. Ә кайчак бакча каршындагы кечкенә өйгә борыла...

Мәдинә нәкъ сугыш башланыр алдыннан Алма-ата педагогия институтын бетереп Көкчәтауга килгән. Татар мәктәбендә рус теле һәм әдәбияттан дәрес биргән. Партия эшендәге бер казакъ егетенә кияүгә чыккан булган. Ул сугыштан кайтмаган. Балалары юк. Мәдинә хәзер дә шул ук фәннәрдән дәрес бирә. Җәмәгать эшләренә җанын бирүче, ачык йөзле, мөлаем мөгаллимә ул.

Ильяс кичләрен аның тәрәзәсен каушап кына чиртә. Мәдинә тиз генә чыгып капканы ача. Өендә чәен хәзерли, якты чыраен күрсәтә. Ильяс мандолина уйный, Мәдинә җырлый. Бик үк көчле булмаса да, йөрәк тавышы белән җырлый ул... Ә Ильяс үзе уйный, үзе Мәдинәнең җырларын тыңлый, үзе еракта Газизәсен өзелеп сагына.

## XVIII

Буранлы кичләрнең берсендә, Ильяс, укучыларын өйләренә таратып эшләрен бетергәч, кабинетын ябып тышкы ишекләрне бикләде дә, өенә кайтып китте. Әмма шәһәр бакчасына җиткәч ул гадәтенчә мәчет ягына — үз өйләренә таба борылмады, бакча эчендәге сукмак буенча туры китеп, Мәдинә тәрәзәсе янына туктады. Шакыды. Мәдинә йөгереп чыгып капканы ачты. Һәм бу төнне Ильяс шул капкадан кире чыкмады.

Тора башладылар. Никах та, туй да булмады. Ул турыда уйланмады да. Дөресен әйткәндә, икесе дә бу кушылуга риза иделәр. Бергә күңеллерәк тә, тормыш алып баруы да җиңелрәк тоелды.

Ә мәхәббәт?

Аны берсе дә инде уйламады шикелле. Мәдинәнең мәхәббәте башланыр-башланмас сугыш кырында калган. Ә Ильясныкы? Ильяс аныын үзе дә белми. Ул, кабул булмаган дога сыман, җир белән күк арасында эленеп калды. Ул хәзер нәкъ шул югалган гыйшыктан арыну юлын эзли иде. «Өйләнгәч онытылыр. Мәдинә кемнән ким? Буйга-сынга Газизәдән артык булмаса... Ә карлыгандай кара күзләре кемне генә сихерләмәс. Ә шулай да?..»

Мәҗлес шикелле бер нәрсә дә булмады дип әйтеп булмый. Укытучылар үз инициативалары белән (Ильяс белән Мәдинәгә әйтмичә генә) үзара сөйләшеп мәктәпнең бер классында шимбә көн кич туй мәҗлесе оештырдылар. Аш-су хәзерләп алып киленгән иде.

Заманы-вакытына күрә мәҗлес дигән бу нәрсә матур гына оешты-рылды. Артык мул булмаса да ризыгы-ние, эчемлекләре, хәтта музы-касы да бар иде. Гадәттәгечә, әүвәл кушылучы парны тәбрикләп касә-дәге тамчылар белән ныгытылган сүз әйтелде. Аннан телләр үзеннән-үзе ачылып китеп көлешә, сөйләшә, сыйлаша-сайраша башладылар. Соңгарак, битләр инде шактый алсулангач, җыр башланды. Аны таль-янка белән мандолина күтәреп алып көчәйтеп җибәрде.

Бер дә уйламаганда нәкъ туйга охшаган мәҗлес башланды да кит-те. Кыстамыйча сыйландылар. Һич ялындырмыйча татарча, казакъча, русча көйләделәр.

Яңа ир белән хатын бу планлаштырылмаган мәҗлескә чын күңел-дән сөенеп — Мәдинәсе җырлап, Ильясы мандолина уйнап табынны тагын да шаулатып, җанландырып кына җибәргәннәр иде... Шулай була бит ул хәерсез, көтелмәгән бер хәл Ильясның күңелен тагын ас-тын-өскә китереп ташламасынмы.

Вакыт инде төн уртасыннан авышкан. Кайбер кунаклар кайтырга да җыена башладылар. Шунда шактый кызган, шуңа тагын да мату-рая, чаялана төшкән яшь укытучы Фәридә:

— Туктагыз әле, матуркайларым, мин яшь кияү белән кушылып бер җырламыйча китмим, — дип тыпырдап биеп Ильяс каршына килеп басты. — Әйдә, җизни, чиерттер, өздер мандолинаңны!..

Китәргә җыенганнар да ишек төбеннән кире борылдылар. Ильяс мандолинасын тагын кулына алды, кылларга бер-ике тапкыр чиртте дә елмаеп Фәридәгә карады.

— Нинди көйгә, балдызкай?

Өстәл артында утыручыларның берсе ашыгып әйтте:

— «Зәңгәр күзләр» көенә.

Башкалар да аны күтәреп алдылар.

— Әйе, әйе, «Зәңгәр күзләр»не.

Кайсыдыр утка май салды:

— Балдызыңның күзләре дә зәп-зәңгәр бит... Өздер әле бер.

— Шулаймы? — Фәридә шукланып, көлеп, Ильясның алдына ие-леп күзләрен — якты, зәңгәр күзләрен ачты. — Кара, җизни, күр минем күзләрне... Гашыйк була күрмә.

— Ха-ха!..

Фәридә тамагын кырып инде җырларга да хәзерләнгән иде, шунда Ильяс кинәт калтыранып, туңып китте. Куллары, бармаклары дерелдә-де. Медиаторы төшеп китә язды.

— Әйдә, әйдә, җизни, нәрсә кәнфитләнәсең? Тамак суынганчы җыр-лап калыйм, — дип ашыктырды Фәридә.

Медиатор кылларга кагылды. Бармаклар бер югары, бер түбән төш-теләр — ә көй чыкмады...

— Фу, эллә инде артыграк киткән, музыкант абый....

Ильяс уңайсызланып башын түбән иде. Кыллар кинәт өзелердәй бу-лып чыңлап алдылар да аккорд яңгырады. Көй табылды. Фәридә шун-да ук югары тавыш белән җыр башлады:

Зәңгәр күзең, күз керфегең
Тибрәндереп карама,
Күз караваң ук шикелле
Йөрәгемә кадала.

Кушымтаны мәҗлестәгеләр барсы бергә күтәреп алды. Бүлмә яң-гырап китте.

Әй, бөдрә чәч, зәңгәр күз,
Әйтмәм, бәгърем, авыр сүз.

Кыллар дерелдәде дә дерелдәде, өзелеп китәрдәй булып чыңла-ды. Бармаклар ашыгып эшләде. Бөтен мәҗлес дөньясын онытып җыр-га кушылды.

Ильясның күңеле тәмам дулкынланып ташты. Күз алдында зәңгәр күл, алсу таң, алсу шомыртлар һәм алсу чәчәкләр шәүләсе көлде һәм шул чәчәкләр арасында берәү йөри... Ул — Газизә...

— Мин... Мин хыянәтче...

Кыллар чынлап яңгырадылар да, өзелгәндәй булып, кинәт тындылар. Ильясның күзләрендә яшь бөртекләре күренде. Ул, мандолинасын урындыкка ташлады да, ишегалдына йөгереп чыгып китте.

— Әйттем бит, — дип кычкырып калды Фәридә, — җизнәкәй артыграк төшергән. Җырлап бетерергә дә бирмәде.

## XIX

Ниһаять, моңа кадәр бик биектә, күренер-күренмәс кенә, ымсындырып йөргән бәхет кошы көтмәгәндә үзенең искиткеч матурлыгы белән балкып күз алдына килеп басты. Ильясның түбәсе күккә тиде. Чыннан да моннан артык сөенеч, бәхет булырга мөмкинме соң?

Ул кабинетында айлык укыту-тәрбия эшләре буенча мәгариф бүлегенә җибәрәсе отчетын язып бетереп өенә кайтырга кузгалган иде, телефон шалтырады. «Кайсы башны катыра тагын», дип, сукранып трубканы алды:

— Алло, алло, тыңлыйм. Әйе, әйе, Салихов. Бик начар ишетелә, катырак сөйләгез әле. Нәрсә? Сөенче? Нинди сөенче? Нәрсә? Нәрсә? — Ильяс урыныннан сикереп торды, телефон трубкасын өстәлгә куйды. Гаҗәпләнеп тирә-якка карады, тагын трубканы кулына алды: — Сез кем? Кайдан сөйлисез? Больницадан. Чынмы?.. Кызым бар?!

Ильяс трубканы куеп бүлмә буенча арлы-бирле йөрде һәм туктаусыз кабатлады: — Кызым бар! Минем кызым бар! — Ул нигәдер көлде, яңадан өстәл янына туктады. Аннан тиз генә киенеп урамга чыкты.

Зәп-зәңгәр төн. Ай юк. Кара бәрхет күктә йолдызлар! Алмаз кыйпылчыклары. Җиргә зәңгәр нур бөркиләр. Ильяс ашыга, аяк астында кар шыгырдый. Әллә инде җиргә дә алмаз кыйпылчыклары сибелгән.

«Дөнья, син нинди гүзәл!» Нигәдер йөгерәсе, канатланып очасы, әнә теге якты йолдызларга хәтле очасы килә! Кычкырасы, җырлыйсы килә. Күңел ташып дулкынлана. Их, яшисе, бик озак, бик озак яшисем килә!..

Дөнья! Бүген җир йөзендә миннән дә бәхетлерәк кеше бармы? Юк! Юк! Бүген иң бәхетле кеше мин, ишетәсезме, иң бәхетле кеше! Минем кызым бар. Ниһаять, утыз сигез яшькә җиткәндә мин үземнең дәвамны күрәм!

Ильяс аксый-йөгерә больницага таба ашыкты. Ә күктәге йолдызлар бер нигә дә гаҗәпләнмичә, тыныч кына җемелдi иде.

Бер атнадан соң Ильяс күршеләреннән ат-чана алып тау башындагы больницага барды һәм Мәдинә белән үзенең кечкенәсен — җир йөзендәге иң гүзәл кызларның берсен өенә алып кайтты.

— Ильяс, кызыбызны кем диярбез икән?

Ильяс бу турыда уйламаган да икән бит әле.

Мәдинә кызын имезеп караваттагы мендәргә салды да елмайды:

— Кызыбызга нинди исем кушарбыз дим.

Ильясның колагына кемдер пышылдагандай булды, тәне кызышып китте һәм ул әйтеп салганын үзе дә сизмичә:

— Газизә кушыйк, яме? — диде.

Мәдинә ризалыгын белдереп башын какты.

## XX

Кайвакытта кеше тормыш юлында бер ялгыш адым, тик бер адым гына ясый һәм бу адым аны һәлакәткә китерә, гомерлек газапка дучар итә.

Менә Ильяс та ашыгычлык белән шундый бер адым ясап ташлады, хәзер инде үкенеп бетә алмый. Әмма эш узган, үкенүдән ни файда?

Аның кечкенәсе көннән-көн үсә, матурая бара. Үзе әнкәсенә охшаган — түгәрәк йөзле, шомырт күзле, кара кашлы. Елмаеп кына тора. Елмайганда Газизәнең дә битендә нәкъ шулай «мәхәббәт чокыры» уела иде бит... Теле дә тиз ачылды — «әттә, әннә» дип кенә тора. Газизәдән дә сылурак кызчык бар микән җирдә?!

Мәктәптән кайтып керүгә Газизә әткәсенең муенына килеп сарыла, үбә, кочаклый. Нинди татлы, ләззәтле ул сабый баланың, үз баланның керсез, саф мәхәббәте!

Ә менә ничек газаплы икән ул шомырт күзле, алсу иренле, иркә кызны — үзеңнең бердәнбер өметеңне иркәләү?

Ильяс кызының ефәк чәчләреннән сыйпый да, башын түбән ия. Җүләр мин. Акылсыз мин. Мин бит инде сүнеп барган утны үзем кабыздым, төзәлеп килгән яраны яңадан ачтым... Танкта янып госпитальдә ятканда, һәр иртәне янына ак халатлы, мөлаем йөзле шәфкать туташлары килә иделәр дә:

— Нихәл, иптәш лейтенант, тазарасыңмы?— диләр иде. Аннан Ильясның кулындагы, аякларындагы, аркасындагы бинт-марляларны тәнне рәхимсез авырттырып сүтеп алалар иде. Күзләрдән яшьләр атыла, утлар сибелә. Ул чак кына елап җибәрми. Бар түземен җыя да, соңыннан кан саркырлык итеп иреннәрен тешли.

Анда, госпитальдә, бинт-марляларны җәрәхәт тизрәк төзәлсен өчен алыштыралар. Шуңа күрә шәфкать туташлары артык шәфкатьле булганга рәхимсез эш итә иделәр. Ә монда? Монда бит ярага мин үзем кагылып торам. Төзәтү чарасын күрмим.

— Ильяс! — Аш бүлмәсеннән Мәдинә дәште, Ильясның авыр уйларын бүлде. — Урамга чыгып Газизәне алып кер әле. Уен дип ашавын да онытты... Мин пилмән салам. Озак йөрмәгез!..

Ильяс авыр. сулап куйды һәм эшләпәсенә үрелде. Их! Менә шулай урамга чыгып кына чакырып алсаң иде Га-зи-зә-не... Нигә күңелгә кадала торган бу хәнҗәр исемне куштым икән кызыма?

## XXI

Алма-Атаның опера һәм балет театры бинасында менә инде икенче көн профсоюзларның республика конференциясе бара. Ильяс — Күкчәтау өлкәсеннән делегат.

Бина зур, вентиляторлар да эшләп тора, әмма халык күп, зал шактый тынчу иде. Ярый әле Ильяс чыгышы белән бүгенге утырыш тәмамланды.

Театрдан чыгуга фонтан янында торып бераз тын алды да Ильяс, якындагы бер ашханәгә кереп, зур бер савыт дуньган токмачы ашады. Дөресрәге, ашый алмыйча интегеп бетте. Билбау буе нечкә токмач кашыкта тормый, шуып төшә дә китә, төшә дә китә. Ә үзе бит — теленне йотарлык ризык иде.

Аның гостиницага кайтасы килмәде. Ничек инде шундый чакта бүлмәдә бикләнеп утырасың, тышта саф һава, әле генә яңгыр явып узган. Арыклар, асфальт тротуарлар буйлап күбекләнеп су ага. Алатау бозларының суы.

Ильяс урам буйлап бераз түбән төште дә бер скверга кереп аулаграк аллеяларның берсендәге ялгыз урындыкка килеп утырды. Монда күләгә. Дымсу. Чәчәкләр исе дә урамдагыга караганда көчлерәк сизелә. Утыруга бөтен тәне оеп киткәндәй булды.

Ул иртән алган «Литературка»сын кесәсеннән чыгарды да ике куллап ачты, әмма укып китә алмады, тыныч, гамьсез ялга талды.

Якында гына репродуктордан думбра моңы ишетелә. Менә думбрачы кинәт сузып җырлап та җибәрде. Нәкъ даладагы ялгыз җылкычы сыман бар күкрәгенә ирек биреп үләң әйтә. Нинди киң, нинди гүзәл ул казакъ сахрасы! Җыр һаман үсте, аннары каядыр еракка, бик еракка китеп югалып торды да кайтып тагын кабатланды.

— Гафу итегез, сез...

Ильяс сискәнеп башын күтәрде. Газетасы кулыннан төшеп китте. Каршында пөхтә генә киенгән, урта буйлы, тулы гәүдәле, түгәрәк йөзле ханым басып тора иде. Өстендә ак ефәк күлмәк, башында камыш эшләпә, кулында ябык зонт.

— Ай... газетагыз төште бит. — Ханым аны иелеп алды да Ильяска сузды. — Рәхим итәсез.

Ильяс һаман әле ни булуына төшенә алмыйча аптырап аягүрә басты: — Исәнмесез.

— Гафу итегез, сез иптәш Салихов түгелме? Утырыгыз, утырыгыз.

Ильяс утырды. Газетасын урындыкка куйды: — Сез дә утырыгыз. Гафу итегез, кем белән сөйләшәм?

— Әй алла, сез Ильяс ич, — хатын зонтигын урындыкка куйды да, Ильясны үзенә тартты, каты итеп кысты, бик озак җибәрмәде, — я, танныдыңмы?

Түгәрәк, мөлаем йөз. Зур соргылт, елмаеп карый торган бик якын, бик таныш күзләр...

Ильяс кулларын ычкындырмый торган ханымга гаҗәпләнеп карады, бар хәтерен җыйды, шул мизгелдә үзенең бөтен гомерен, дус-ишләрен күз алдыннан үткәрде.

— Юк, гафу итәсез... Хәтерли алмыйм.

— Ничек инде, — хатын Ильясның кулларын ычкындырып янына утырды. Тавышында үпкә. — Өч ел бергә укыдык, бер торакта тордык.

— Казандамы?

— Ие. Болак буенда. Педтехникумда.

— Сезнең исемегез?

— Зифа.

— Зифа! — Ильяс хатынны кочаклап алды. Аннан тиз генә кочагыннан бушатты: — Гафу ит... Гафу... Һич уйламаганда...

— Ә Газизә сине сугышта үлгән дип елап сөйләгән иде...

— Ничек? — Ильяс гаҗәпләнеп аңа текәлде. — Үлгән? Сез аны кайчан күрдегез? Ул исәнме? Кайда?

— Кырык сигезенче елны мин Казанга барган идем. Нәкъ менә хәзер сезне очраткан кебек аны Кремль янында очраттым. Бик озак сөйләшеп утырдык. Техникумда укыган барлык иптәшләр искә алынды. Менә шунда әйтте дә инде ул: «Беләсеңме, Зифа, безнең Ильяс та сугышта үлгән бит» дип. Үзе елап та алды.

— Булмас.

— Алай булмавы бик хәерле. — Зифа тагын Ильясның кулын кысты. — Менә мин хәзер тере Салиховның кулын кысам, — Газизә ишетсә ничек куаныр иде.

— Ә ул кайда соң хәзер?

— Беләсеңме, Ильяс, — Зифа бераз уйланып торды, — хәзерге көндә Газизәнең кайда торганын точно әйтә алмыйм. Мин соңыннан, илленче елны бугай, Казандагы апамнан хат алдым. Ул анда «Ахирәтең бер әфисәргә кияүгә чыгып, Ташкент ягына китте», дип язган иде. — Зифа бераз туктап торды. Авыр итеп сулады. — Ул сине теге вакытта да көтте. «Үлде дигәнгә нигәдер күңелем ышанмый», дигән иде.

Ильяс кинәт аягүрә басты. Кемнедер эзләгәндәй йөренеп алды. Аннан утырды. Кесәсеннән папирос алып кабызды.

— Ильяс, сез хәзер кайда торасыз? Монда ничек килеп чыктыгыз?

Ильяс папиросын сүндереп урындык янындагы урнага ташлады да

Зифага үзенең техникумнан соңгы еллардагы мажараларын сөйли башлады.
Алар бары көн кичкә авышкач кына аерылыштылар.

## XXII

Мәдинә йоклап киткәч Ильяс акрын гына караваттан төште, караңгыда капшанып пижамасын киде һәм аяк очына гына басып аш бүлмәсенә чыкты. (Каһәр төшкән протез берничә тапкыр шыгырдап, Мәдинәне уята язды.)
Ул ишекне сак кына ябып ут кабызды. Өстәл янына утырып кесәсеннән папиросын алды, ләкин никтер аны өстәлгә ташлады һәм пижаманың икенче кесәсеннән зәңгәр конверт чыгарды. Ачты. Аннан дәфтәр битенә гарәп хәрефләре белән язылган хат чыкты.
Хат үзе кыска, берничә юлдан гына тора иде. Әмма Ильяс аны бик озак укыды. Язылмыйча калган иң мөһим сүзләрне табып укырга теләгәндәй, һәр юлга, һәр сүзгә туктала-туктала озак уйлады. Шул арада өстәлдә яткан «Беломор»ны алып кабызды, суырды, зәңгәр төтен эчендә калды. Бераздан папирос сүнеп иренгә ябышып калды, ә Ильяс аны да онытып тагын уйга чумды.
Тышта җил. Шабырдап яңгыр ява. Бакчадагы топольләр вакыт-вакыт иелеп тәрәзә рамына, пыялаларга сугылалар. Ильяс аны ишетми, башын ике кулы белән кыскан да, ниндидер тирән борчулы уйдан арына алмый.
Кинәт бүлмә эче яп-якты булып китте. Аннан, Кукчәтау таулары җимерелеп төшкәндәй, тирә-якны, өйне дер селкетеп күк күкрәде.
— Әнкәй! — түрдәге бүлмәдә, аерым караватта йоклаган нәни Газизә җан ачысы белән кычкырып җибәрде, — әнкәй, нәрсә шартлады?!
— Йокла, йокла, кызым. — Карават кыштырдады, — курыкма, мин монда. Стена якка борыл да күзләреңне йом... Одеялыңны башыңнан ук уран. Йокла. Тагын карават кыштырдады. Мәдинә урынына ятты, ахырысы.
— Ильяс, син кайда?
— Монда...
— Тәрәзә форточкасын ябып куй әле.
— Хәзер.
— Нишләп утырасың инде җиде төн уртасында. Иртәгә беренче дәресләрең бит.
— Мин әле җыелышка доклад хәзерлим, хәзер ятам.
Тәрәзә форточкасы чыннан да ачык икән. Ильяс торып япты. Өстәлдә яткан хатны, конвертка кире салып, пижама кесәсенә тыкты. Арлы-бирле бүлмә буенча йөри башлады. Аннан протез шыгырдавын тоеп туктады. Урындыкка килеп утырды һәм шунда гына иренендә ябышып калган папиросын озак итеп суырды.
Башы тагын түбән иелде. Чәчләре агара да башлаган бу баштагы уйлар артык авыр иде, ахрысы.
Каядыр еракта тагын күк күкрәде.
Шыбырдап яңгыр коелып торды.

## XXIII

Ильяс хәзер айның башында һәм уртасында Кукчәтау почтамтына бара, пыяла барьерлар белән бүленгән, халык шыгрым тулы залның аргы башындагы «До востребования» дигән язулы тәрәзә каршына килеп чиратка баса. Вакыты житкәч, кечкенә тәрәзәгә паспортын суза. Җирән чәчле, кызыл иренле яшь кыз аңа гел елмая.

— Да, да... Сезгә бар, — ди дә тар ящиктагы хатларны ашыгып авыштыра башлый. Аннан читләре шакмаклар белән бизәлгән авиаконвертларның берсен тартып чыгарып Ильяска суза: — Рәхим итегез.

— Рәхмәт.

Ул бу хатны нигәдер көндез укымый. Бары кичен укучылар, укытучылар мәктәптән киткәч кенә, кабинет ишеген ныгытып ябып бер кат, ике кат, өч кат укый... Юк, укый гына түгел, аның һәр сүзен күңеленнән уткәрә, күз алдына китерә... Ильяс уйга бата. Үз-үзе белән сөйләшә: «Әйт әле, Газизә, син нинди хәзер? Һаман элекке кебек чаямы? Үзе хәтле улы булгач, шуклык-чаялык бәлки юктыр да... Ник син алданрак хәбәр итмәдең? Соңладың син. Инде нишләргә? Әйт, Газизә, инде нишләргә безгә?..»

Калын, соргылт кашларын күпме генә җыермасын, кабинет буенча күпме генә арлы-бирле йөрмәсен, папиросларын бер-бер артлы яндырып сүндермәсен, бу чияләнеп беткән төенне чишү серен таба алмый иде Ильяс.

Бүген ул тагын бер хат алды. Яшьлегенә кайтты...

Ап-ак чәчәкләргә күмелгән алмагачлар, шомыртлар, сиреньнәр һәм алсу нурларга күмелеп туган язгы көн. Ак томаннан ачыла барган зәңгәр күл. Күл өстендә көймә. Ул сизелер-сизелмәс кенә тибрәлә. Көймәдә иңнәренә Ильясның костюмын салган Газизә, зәп-зәңгәр күзләр, алсу иреннәр.

— Ильяс, мандолинаңны уйна әле.

— Нинди көй?

Зәңгәр күзләр яктырып китә, Газизәнең бит алмаларына таң нурлары сирпелә.

— Үзең беләсең бит, мин яраткан көйне...

Мандолина кыллары чыңлый башлый да томаннан арынган зәңгәр күл өстендә тылсымлы көй агыла. Оча, биеккә, биеккә чакыра ул. Офыктагы алсу таңда, туып килгән яңа көнгә, шау чәчәккә күмелгән язгы иртә — яшьлеккә чакыра...

Урамнан мәктәп бинасын дер селкетеп трактор узып китте. Ильяс кинәт сискәнде, «уф» дип бик авыр сулады да аягүрә басты. — Кайтырга кирәк. Мәдинә белән Газизә янына. — Йөрәккә энә кадалгандай булды. Авыртуга чыдый алмыйча, кире урынына утырды. — Нигә мин кызыма бу исемне бирдем икән? Шуны әйткән саен газапланам. Нигә?..

Йөрәкнең чәнчүе кимеде. Ильяс өстәлдәге конвертны — йөрәк җимешен — гадәтенчә, кабинетның түр почмагындагы сейфка куйды. Сейф бигә чыңлап китте. Ләкин Ильяс гаҗәпләнеп карап торды-торды да, сейфны яңадан ачты һәм куйган хатны кире алды, өстәл янына килеп утырды. Сейф ачык калды. «Тукта, ник мин бу хатларны тимер шкафка бикләп торам? Кемнән яшереп? Хатыным белән кызымнанмы? Ни өчен? Бу хатлар нинди дә булса бер хыянәтнең, җинаятьнең кара шаһитлары мәллә? Ничек тә булса фаш ителүдән куркаммы?»

Нәкъ шушы мизгелдә Ильясның акылы белән күңеле үзара бәхәскә керештеләр.

Акыл. Әйе, син куркасың, чөнки син икейөзле кеше.

Күңел. Юк, мин андый түгел, син яла ягасың!

Акыл. Тукта, тукта, артык кызма. Менә факт — синең хатының бар, кызың бар. Ә үзең һаман башка хатынны сөясең. Мәхәббәт хатлары язасың. Бу нәрсә, хыянәт түгелме?

Күңел. Ялгышасың, ул башка хатын түгел, ул минем беренче мәхәббәтем.

Акыл. Ха-ха! Мәҗнүн! Беренче мәхәббәт? Аннан соң инде күпме карлар яуды. Яшерми генә әйт әле, сиңа хәзер ничә яшь?

Күңел. Илле җиде.

Акыл. Кызыңа синең унтугыз. Син мәхәббәт хатлары яза торган Газизәнең өйләнгән улы, кияүгә чыккан кызы бар. Беләсеңме?

Күңел. (күңелсез генә). Беләм... беләм...

Акыл. Бәс, шулай булгач, сезнең арада нинди мәхәббәт булсын. Үпкән-кочкан җилгә очкан...

Күңел. Тукта, алай бик акыллы булгач, син әйт әле: мәхәббәт ничә яшьтә башлана да ничә яшьтә бетә? Әйт син миңа, мәхәббәт картаямы?

Акыл. Син үзең әйт. Гераклит нәрсә дигән?

Күңел. Син мине әллә кайчан туфракка әверелгән Юнан галимнәре белән бутама, соравыма туры җавап бир.

Акыл. Боргаланма... Ничек әйткән әле Гераклит: «барысы да ага, барысы да үзгәрә!» дигән.

Күңел. Күпме генә акыллы булма, минем сорауга барыбер җавап бирә алмадың? Дөрес, еллар үтү белән бөтен нәрсә үзгәрә. Әмма мәхәббәт, чын мәхәббәт, беренче мәхәббәт сулмый, картаймый.

Урамнан бер төркем яшьләр көлешеп-җырлап уздылар. Ильяс уйларын бүлеп аягүрә басты. Өстәлдәге конвертка карады. Озак карады. Аннары аны кискен бер хәрәкәт белән сейфка салды да шалтыратып бикләп куйды...

## XXIV

Ильясның кызы инде институт тәмамлап кияүгә чыкты. Хәзер инде Газизәнең Илдар исемле алмадай улы да бар. Ул еш кына әби-бабаларына кунакка килә һәм килгән саен бабасының чәчләрен тарап матурлый да бер үк сорауны бирә:

— Бабай, ник синең чәчләрең ап-ак. Минем этиемнең чәчләре әнә кап-кара ич?

— Матурым, бабаеңның чәчләрен буятырга акчасы юк,— ди этисе, Ильяс өчен үзе җавап биреп. Яшьләр эчләре катып көләләр.

Уза икән, туза икән яшьлек. Ә мәхәббәт? Мәхәббәт ничек?

Ильяс менә ничә еллар инде шушы сорау белән баш вата, әмма җавабын таба алмый... Мәдинә хыянәтсез дус, яхшы хатын. Ул җаны-тәне белән Ильяска бирелгән, аның өчен яна-көя, аның өчен генә яши. Ильясның өсте-башы һәр вакыт юылган, үтүкләнгән. Өйләрендә искитәрлек пөхтәлек. Аш-суга да оста. Бер вакытта да кашларын җыерып йөрми. Йөзе һаман якты.

Шундый изге хатын кочагында бүтәне турында уйлау хыянәт, җинаять түгелме? Ә бит ул күптән түгел генә төнлә саташып төш күрде: «Газизә!»— дип кычкырып эндәште.

— Ильяс, Ильяс,— Мәдинә аны тарткалап уятты,— сиңа ни булды. Нинди төш күрдең? Саташасың бит.

— Нәрсә? Нәрсә дип саташам?

— Нәрсә булсын, Газизә дип.

— Ә... Аны... Машина таптый язды...

Ильясның маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Тагын башка сүз әйтеп ташламадыммы икән?»

— Авызыңнан җил алсын! Кит, юкны юрама. Борыл да уң ягың белән ят.

Ильяс таңга хәтле йоклый алмады.

## XXV

Ильяс газаплы кичерешләр белән бик күп төннәрне шулай йокысыз уздырды. Шундый төннәрнең берсендә кулына кәгазь-карандаш

алды да ул үзенең барлык кичерешләрен, серләрен, ярсуларын ышанып бер язуга салды.

Арабызда безнең еллар ята,
Юллар ята, калын кар ята.
Шарлавыклар белән кискәләнгән
Текә ташлы, биек яр ята.
Яр ята...
Арабызда безнең таулар ята,
Кара урман ята, кыр ята.
Күңелемә сагыш һәм моң салып
Бик еракта калган җыр ята.
Җыр ята.
Эзләп чыксам да мин таба алмам,
Юллар ерак, томан ябынган,
Тик күңелемдә якты бер нур балкый —
Сөюеңнән синең кабынган.
Кабынган.
Арабызда безнең еллар ята,
Юллар ята борма-бормалы,
Кар һәм бозлар күпме ясалар да
Иң беренче сөю сулмады.
Сулмады...

Иртә белән бу йөрәк сере ерак-еракка — Памир таулары ягына очты, үзенә аваздаш күңелне эзләп очты бу юллар...

Сагынулы, сагышлы, өметле-өметсез көннәр үтә торды. Ниһаять, ай ахыры җитте. Ильяс почтамтка барды һәм беренче мәртәбә хатны почтамт залында ачып укыды.

«...Ильяс, шигырең өчен рәхмәт. Мин аны кат-кат укыдым. Инде яттан беләм.

Үзеңне күрәсем килә. Бик, бик күрәсем килә сине. Мин быел көзен Уралга әниләргә барырга җыенам. Вакытын әйтеп телеграмма бирермен. Син кил. Мин сине сугышка киткәндә озатып калган разъездда каршылармын, яме? Шунда барысын да — барысын да сөйләшербез. Юлга чыгуыңны хәбәр итәрсең.

**Газизә».**

*«Вакыт һәм кешеләр» конкурсына*

# ИЛЬИЧКА ХАТЛАР

Автордан. 1922 елның 22 декабрендә Кокушкино крестьяннары элекке авылдашлары В. И. Ленинга (Ульяновка) хат язалар. Яшь Ульянов Үшнә елгасы буенда сөргендә чакта аның белән бергә уйнап, атлар көтеп йөргән кешеләр юлбашчыга Совет власте өчен ничек көрәшүләре, аның казанышларын саклап калу өчен Кызыл Армиягә барулары, авылның һәм крестьяннарның авыр хәле турында дөресен сөйләп бирәләр.

Соңыннан шагыйрь Сибгат Хәким крестьяннар хатын шигъри юлларга сала.

Кадерле Владимир Ильич,— дип
Яңартты агайлар үз хатын,—
Җимерелде хуҗалык, урыныннан
Ат кына кузгатса кузгатыр...

Совет ат бирә дип ишеттек,
Кредитка, билгеле, бурычка.
Хөкүмәт каршында син куйсаң,
Син үзең алынсаң бу эшкә...

Хәерчелек, ачлык, наданлык Кокушкино крестьяннары өчен генә түгел, бәлки яңа төзелгән Татарстан республикасының барча авылларына да хас тормыш була. Россия, бөтен бер Россия В. И. Ленинны ат сорап борчый. Авыллар җимерелгән, халык талчыккан. Совет власте крестьяннарга җир бирә. Әмма сукаларга, иген игәргә ат юк... Балаларга белем бирү, аларны һөнәргә өйрәтү өчен йортлар да булмый.

Бу хат, Владимир Ильич каты авыру булганга күрә, «Правда» газетасының җаваплы секретаре Мария Ильинична тапшырыла һәм 1923 ел январенда газетада басылып чыга. Озакламый аның нәтиҗәләре дә күренә: хөкүмәт Кокушкино крестьяннарына атлар, яңа йортлар салу өчен бүрәнә, чәчүлек орлык бирә, авылда мәктәп ачыла.

Ленин идеяләре белән коралланган крестьяннар бүген Үшнә һәм Мишә буйларының да йөзен бөтенләй яңарттылар. Үзләре дә үзгәрде. Аларның бүген Ильичка яза торган хатларының эчтәлеге бөтенләй икенче төрле булыр, аларда В. И. Ленин тәгълиматының тантанасы, колхоз авылының, халыкның яңа, мул культуралы һәм белемле тормышы якты чагылыр иде.

Ул хатларның берничәсе мондыйрак булыр иде.

# Каһарманнарга бай без

«...1918 елда, барыбыз бер кешедәй булып. Кызыл Армиягә бардык һәм Советлар властен дошманнардан: алпавытлардан, генераллардан, капиталистлардан сакладык».

*Кокушкино крестьяннары хатыннан*

Мин — Бөек Ватан сугышы ветераны. Сугышның башыннан ахырына кадәр хәрәкәттәге армиядә булдым. Ул дәһшәтле елларның фаҗигале вакыйгаларын көндәлек дәфтәреннән актарганда, татар халкының каһарман улы легендар Брест крепосте герое майор Гаврилов батырлыгы алдында баш иям. Кокушкино крестьяннары юлбашчыга хат язганда якташлары Әлбәден авылы егете 17 яшьлек Петрны да күз алдында тотканнардыр. Беләгенә кызылармеец тасмасы бәйләгән эшче егет Казан урамнарында юнкерлар отрядларына каршы кыю көрәшә, контрреволюциячеләрнең соңгы таянычы — Кремльне штурмлый. Казанда Совет власте игълан ителүгә багышланган тарихи митингта катнаша. Бөек Октябрь революциясе көннәрендә Гаврилов кулына корал ала һәм ул Ватаныбыз дошманнарына каршы көрәштә аның тугрылыклы юлдашы булып кала. 1939 елда Фрунзе исемендәге хәрби академияне тәмамлаган офицер ак финнарны тар-мар итүдә үзен оста командир итеп таныта. Ул җиңелмәс һәм үлмәс Брест крепостен саклауда күрсәткән тиңдәшсез батырлыгы, Ватанына чиксез бирелгәнлеге һәм дошманга каршы үз-үзен аямыйча көрәшүе белән бөтен дөньяга билгеле.

Брест крепосте оборонасы совет солдатының баһадир көчен, батырлыгын һәм чыдамлыгын бөтен дөньяга күрсәтте. Буг елгасы буена урнашкан буйсынмас крепостьны саклаучыларның кабатланмас батырлыгы җир шарын таңга калдыра. Нәкъ менә шушында — чик буендагы Брестта фашизмны тар-мар итәр өчен беренче кыю удар ясалды. Крепость оборонасын оештыручыларның берсе 44 нче полк командиры майор Гаврилов була. Фашистлар көтмәгәндә һөҗүм итсәләр дә, Брестны саклаучылар бер-бер артлы гитлерчыларның атакаларын кире кагып торалар. 27 июньдә дошман танклары Белоруссия башкаласы Минскига бәреп керә, 16 июльдә борынгы рус шәһәре Смоленск яулап алына. Әмма фашист армияләренең тирән тылында, тышкы дөньядан аерылган хәлдә дә Брест гитлерчылар үтә алмаслык бастион булып кала. Азык-төлек, су бетсә дә, аны саклаучылар әсирлеккә бирелергә уйламыйлар. Стеналарга яраларыннан аккан кан белән: «Үләбез, ләкин крепостьтан китмибез», — дип язып калдыралар.

Брест оборонасының соңгы көннәрендә гитлерчылар 4 квадрат километрлы мәйданга 500 пушкадан минутына 4 мең атыш ясап торалар. Шундый авыр шартларда майор Гаврилов 1941 елның 23 нче июленә, сугыш башлануның 32 нче көненә кадәр крепостьны саклый. Ул үлемнән курыкмый. Әмма бу батыр көрәшче фашистлар кулыннан үләргә теләми. Гомеренең соңгы минутлары өчен корылган ике пистолет һәм биш граната калдыра. Гаврилов яшеренгән урынга фашистлар килеп керә. Ул аларны пистолеттан атып каршылый. Немецлар: «Русь, бирел!» дип акыралар. Аларга ул гранаталар ыргытып җавап бирә. Пистолет обоймасында өч кенә патрон кала: икесе — фашистларга, соңгысы — үзенә. Көтмәгәндә казематта көчле шартлау яңгырый, майор күзләренә ут сибелә, ул яраланып аңын югалта.

«Брест крепосте» китабының авторы Сергей Сергеевич Смирнов болай дип яза: «... Мин үзем сугышта катнаштым һәм ул дәһшәтле хәлләрне күп күрдем. Брест крепостен саклаучыларның батырлыгы бөтен күргәннәремне яктыртып җибәргәндәй булды». Йөзләрчә, мең-

нәрчә кешегә атап әйтелгән бу сүзләр, беренче чиратта, батыр якташыбыз майор Гавриловка кагыла.

Кокушкинодан ерак түгел Неялово авылы егете Василий Осиповның сугышчан юлы да бик күпләргә үрнәк. Ватаныбыз азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәштә ул тормышын да кызганмый. Советлар Союзы Герое исеменә лаек булганын да белмичә Днепр ярындагы тау башында мәңгегә ятып кала. Курск дугасындагы танк сугышында аның ике абыйсы батырларча һәлак була. Бу турыда Василий әтиәнисе Иван Ефимович һәм Анисья Сидоровна хатларыннан белә. Абыйлары өчен үч алуы турында туган авылына болай дип яза: «Соңгы бәрелештә арысландай сугыштым, гитлерчыларны мәрхәмәтсез кыйнадым, дистәләбен теге дөньяга озаттым». Бу — аның туган-үскән якларына юллаган соңгы сәламе.

Үткән ел башында 79 нчы яшендәге Петр Михайлович Гаврилов дөнья куйды. Аны, васыятендә әйтеп калдырганынча, Краснодардан үзе саклаган Брест крепостена илтеп, хәрбиләрнең борынгыдан килгән матур гореф-гадәтләре белән олылап күмделәр.

Ил үз батырларын онытмый. Питрәч районы кешеләре дә якташларының исемнәрен мәңгеләштерәләр, бүгенге яшьләрне Ватанны алар кебек бирелеп яратырга өйрәтәләр.

Каһарман дөньяга килгән авыл йортында мемориаль такта бар. Мәктәп пионер дружинасы һәм Әлбәден авылы кергән колхоз Гаврилов исемен йөртә. КПССның район комитеты һәм ВЛКСМ райкомы колхоз-совхозларның иң алдынгы кешеләре өчен аның исемендәге премия һәм диплом булдырды. Районның бер совхозына Осипов исеме бирелде.

Кокушкино ягы геройларга бай. Сугыш каһарманнарының батырлыгын тыныч хезмәт фронты солдатлары баета, дәвам итә. Сыер саву осталары, Социалистик Хезмәт Геройлары Надежда Галочкина һәм Мәрфуга Шәйхиева исемнәрен бөтен республикада яхшы беләләр. Алар Питрәч районында һәр сыердан 4—5 мең килограмм сөт саву белән танылдылар. Н. Галочкина СССР Верховный Советы депутаты итеп сайланган иде. М. Шәйхиева Бөтенсоюз халык казанышлары күргәзмәсе медальләре белән бүләкләнде.

Менә шундый алар — сугышта һәм тыныч тормыш фронтында шөһрәт казанган безнең Питрәч районы кешеләре.

**ГАЛИМҖАН КАМАЛИЕВ,**
**Советлар Союзы Герое**

Автордан. Гади крестьян малае, элеккеге сержант Галимҗан Камалиев Ленино-Кокушкинода яши. Аның исеме Бөек Ватан сугышы тарихы сәхифәләренә алтын хәрефләр белән язылган. Геройның фронт тормышыннан бер вакыйганы күзәтик.

1943 ел, 26 сентябрь төне. Сержант Камалиев һәм аның минометчылары Днепр ярында елганы кичә башлау вакытын көтеп тора. Боерык алуга, укчылар отряды белән бергә алар Днепрның көнбатыш ярына чыгып авыр сугышка керәләр. Өстәмә көчләр бик акрын килә. Дошман елганы даими ут астында тота. Ә миномётчылар плацдармны барыбер саклап кала. Гитлерчылар чигенә, Сашиновка авылы читендәге калкулыкка менеп урнаша. Сержант мондый чакта кинәт һөҗүм итү кирәклеген яхшы аңлый. Ул автоматтан ата-ата, гранаталар ыргыта-ыргыта өскә ыргыла, шушы кыска бәрелештә дошманның җиде солдатын юк итә. Моны көтмәгән немецлар чигенергә мәҗбүр булалар. Атаканы оештыручы һәм шәхси үрнәге белән сугышчыларны алга өндәүче сержант Камалиев каты яралана. Үзенә Советлар Союзы Герое исеме бирелүен госпитальдә белә.

Сугыштан соң Галимҗан Камалиев тынычлык фронтында да командирларча булып калды. Озак еллар Ленино-Кокушкино авыл Советы башкарма комитеты председателе булып эшләде. РСФСР Верховный Советы депутаты итеп сайланды. Хәзер дә сафта: сугыш һәм хезмәт ветераннары йортында мөдир вазифасын үти.

Бөек Ватан сугышында Питрәч районыннан 5 600 кеше катнаша. Шуларның 3 500 нә Җиңү бәйрәмен күрү насыйп булмый. 2090 кеше сугышта күрсәткән батырлыклары өчен орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә. Район үзәгендә һәм авылларда сугыш корбаннарының якты батырлыгына дан җырлана. Аларның исемнәрен мәңгеләштереп, 23 һәйкәл һәм обелиск куелган.



## Мәдрәсәдән — урта белемгә

«...Без Татарстан республикасы хөкүмәтеннән авылыбызда һөнәр һәм грамота мәктәбе салдыру турында үтенәбез, ул мәктәпкә Синең энием мәрхүмәнең исемен — Мария Александровна исемен бирмәкче булабыз».

*Кокушкино крестьяннары хатыннан*

Безнең мәктәп, туган илебездән тыш, Җир шарының башка бик күп почмакларында да билгеле. Ул даһи В. И. Ленин исеме белән бәйле. Җир йөзендәге изге аналарның берсе — Мария Александровна Ульянова исемен йөртә.

Мария Александровна музее — мәктәбебез горурлыгы, аның 57 еллык тарихы бар. Әлеге музей 1923 елның 9 февралендә «Известия ТатЦИК» редакциясе хезмәткәрләре акчасына ачылган беренче совет мәктәбен искә төшерә. Музей елына бер тапкыр гыйбрәтле сабак бүлмәсенә әверелә. Чәчәкләр, өр-яңа портфельләр, әле ачылып та каралмаган китаплар, башланмаган дәфтәрләр... Бирегә Ленин, Мария Александровна, мәктәп һәм аның музее турындагы беренче дәрескә беренче класс укучылары килә. Алар мәктәпнең үткәне һәм бүгенгесе турында йотлыгып тыңлыйлар. Ике-өч парта, кара такта, шкаф һәм глобус. Нибары 12 бала. Крестьяннар теләгәнчә укытучы итеп Казаннан Ульяновларның туганы Елена Александровна Жакова чакырыла. Аны крестьяннар яхшы белә. Елена Александровна элек бирәдә Ульяновлар гаиләсе белән якыннан аралашып яшәгән була.

Еллар үтә тора, шушы кечкенә генә мәктәп киңәя, яңара, яхшыра бара. Кокушкино крестьяннарының үрнәк мәктәп булдыру турында хыялы чынга аша. Бүген безнең 540 урынлы мәктәп — хәзерге заманның югары таләпләренә һәрьяклап җавап бирә торган уку йорты. 20 кабинет уку-укыту өчен өр-яңа техник җиһазлар — телевизорлар, видеомагнитофоннар, киноаппаратлар, эпидиаскоплар һәм башкалар белән җиһазланган. Янәшәдә генә күрше авыллардан килеп укучы балалар өчен 100 урынлы тулай торак салынды. Укучылар карамагында 20 меңгә якын китабы булган китапханә, ике спорт залы, стадион, мастерскойлар, актлар залы, теплица, ашханә. Рәхәтләнеп укы, белем хәзинәләренә тирән үтеп кер!

Кокушкино крестьяннары хатын язуда катнашучы Лядов, Шаблонов, Егоровларның оныклары белемне оста куллана беләләр. Соңгы биш елда безнең 18 укучыбыз мәктәпне алтын медальгә тәмамлады. 1922 елда В. И. Ленинны барып күрү өчен акча җыя алмый интеккән кешеләрнең балалары өчен Мәскәү инде хәзер бик якын — кул

сузымында гына санала. Сәвия Галиева башкаланың тимер юл транспорты институтында укый. Күп кенә шәкертләребез югары белем алу өчен Володя Ульянов укыган Казан университетын сайлыйлар. Әлфия һәм Рөстәм Әминовлар шушы вузда белем ала. Рөстәм юридик факультетта укый. Казанның башка институтларында да Кокушкино вәкилләре байтак. Бездә тәрбияләнгән егетләр һәм кызларның күбесе Ульяновлар гаиләсе үрнәгендә тормышларын педагогия эшчәнлегенә багышлый, Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә. Розалия Юнысова шушы вуз дипломын алып кайтты һәм инглиз теле укыта. Югары белемгә ия кешеләребез тирә-күрше колхозларда ихтирам казанды.

Мәктәбебезнең укытучылар коллективында югары һәм махсус урта белемле 40 укытучы эшли. Алар районыбызның 18 авылыннан килеп укучы 540 балага белем, тәрбия бирәләр. РСФСРның атказанган укытучысы Әминә Юнысова — балаларның иң яраткан остазы. Галина Калистратовна Карпова Кокушкино җирендә туып үскән, бөтен гомере буена үзе белем алган һәм чыныккан шушы мәктәптә укыта. Бөек Ватан сугышы ветераны Иван Титович Макаров, Гүзәл Ганиева, Резеда Кичүбаева, Валентина Петровна Несмеянова, Минрахман Хөсәенов кебек тәҗрибәле педагогларыбыз белән горурланабыз.

**АРКАДИЙ КОМИССАРОВ,**
**халык мәгарифе отличнигы,**
**укытучыларның III Бөтенсоюз съезды делегаты.**

Автордан. Аркадий Александрович 1962 елда Казан университетын тәмамлый һәм 18 ел инде Ленино-Кокушкинода рус теле укыта. Аның классларында меңнән артык үсмер егет һәм кыз белем алган.

Ленино-Кокушкино мәктәбендә, аның музеенда булганда, бөтен Питрәч районы — үткәннәр һәм бүгенге көн, хәтта туар көннәр күз алдына килеп баса. Тарих фәннәре кандидатлары М. Мулюков һәм һәм З. Мифтаховның «Шәле таңнары» дигән тарихи очерк китабында язылган юлларны укыйк: «Революциягә кадәр Шәледә ике мәдрәсә була. Картларның әйтүенә караганда, аларның берсе 1870 елда ачылган. 1918 елда яңа совет мәктәбе эшли башлый. Беренче укытучылар Кәрим Нәҗмиев, Гәрәй һәм Мәликә Шакировлар...»

Гәрәй һәм Мәликә — минем әтием белән әнием. Әти якты дөньяда юк инде. Әни исән-сау, туксанны тутырып килә һәм әле дә Шәледә яши. Апаларым Зәйтүнә һәм Сәгъдәт, абыем Мәхмүт, ата-анам кебек тормышларын укытучы дигән изге һөнәргә багышлады. Аларның балалары — Илсур, Рәмзия, Рәис, Әнәс тә әби-бабайлары, әти-әниләре юлыннан киттеләр. Хәзер безнең гаиләдә педагогик белеме булган 13 кеше исәпләнә.

Әни үткән еллар турында болай сөйли: «Дини мәдрәсәгә күп авыллардан килеп укыйлар иде. Аның максаты — муллалар хәзерләү. Анда сигез ел укысалар да, Шәле кешеләреннән берәү дә мулла булып чыга алмады... Яңа совет мәктәбе ачылган еллар бик авыр иде. Балаларны укыту өчен урын бар, ләкин ата-аналар анда ир балаларны гына җибәрәләр. Кызларны ничек укытырга соң? Без, яшь совет мәктәбенең беренче укытучылары, өйдән-өйгә кереп уку-укытуның әһәмияте турында аңлатып йөрибез. Тырышлыгыбыз бушка китмәде: 15 кә якын кыз бала укырга йөри башлады. Аларның саны көннән-көн арта баруга без куанып бетә алмый идек».

Әниемнең тормыш юлы — караңгылыктан яктылыкка, наданлыктан белемгә атлаган бөтен Шәле, бөтен район биографиясе ул.

Кәрим Нәҗмиевнең кызлары Мәдинә һәм Мәрзия Кәримовалар да шушы төбәктә озак еллар укытучы булып эшлиләр. Гали Гайсаров, Габдулла Зарипов, Фатыйма Кәримова, Мөслимә Зарипова, Харис Гарипов — Кәрим Нәҗмиев, Гәрәй һәм Мәликә Шакировларның шәкертләре остазларының аң-белемгә тоткан юлын дәвам иттерәләр. Йосыф Садыйковка, педагогика өлкәсендәге хезмәтләрен олылап, Татарстан АССРның атказанган укытучысы дигән мактаулы исем бирделәр.

Районда 28 укытучының күкрәгенә «Халык мәгарифе отличнигы» билгеләре тагылган. Бүгенге колхозчы һәм совхоз эшчеләренең балалары барысы да үз авылында өлгергәнлек аттестаты алып чыга. Бер үк вакытта кулларына һөнәр белү турында таныклык бирелә. Үткән уку елында урта мәктәпне 600 егет һәм кыз тәмамлады. Шуларның дүрт йөздән артыгы авыл җирендә иң кирәкле һөнәр — тракторчы, комбайнчы, шофёр, сыер савучы, яшелчәче һөнәрләре буенча туган-үскән авылларында эшкә калды. Урта белемгә ия булучылардан 56 кеше илебезнең югары уку йортларына керде, калганнары профессиональ-техник училищеларында укый. Бүген Питрәч районындагы 37 башлангыч, сигезьеллык һәм унъеллык мәктәпләрдә 5200 бала югары һәм махсус урта белемле 445 укытучы җитәкчелегендә фән нигезләрен үзләштерә.



## Җир һәм икмәк турында уйланулар

*«...безнең якларда икмәк уңмыйча калып, ачлык килде... Атсыз — бер кулсыз: җиребез бар, шул җирне эшкәртергә әйберебез юк».*

*Кокушкино крестьяннары хатыннан*

Һәр язны, кар сулары агып беткәч, бата-чума басуга чыгам. Җир өлгерәме? Учымны тутырып, дымсу туфрак алам, иснәп карыйм. Ул минем уч төбемне кытыклый — миңа нидер сөйли кебек. Салкынча җилдә туфрак авазын бирелеп тыңлыйм. Җир-ананың уңдырышлы булуы өчен игенче аңа күпме тир түккән, изге җиребез, туган туфрагыбызның юмартлыгы хакына әти-бабаларыбыз, аларның уллары, яшьтәшләремнең никадәр каны сеңгән. Туфрак сулышыннан шуларны ишетәм мин. Җир — хәзер безнең уртак байлыгыбыз. Кайчандыр ул алпавытлар, монастырьлар, чиркәүләр, патша гаиләсе кулында иде. Ул авыр елларны картлар-карчыклар яхшы хәтерли. Шәленең имана җирләрен алпавыт О. Молотков, Е. Молостова, Л. Тилл биләмәләре уратып алган, халыкның көтүлекләре дә, урманы да юк. «Казан мөхбире» газетасының 1906 елгы 3 июль санында «Бер кеше» имзасы белән басылган хәбәр ярлы крестьяннарның кайгы-хәсрәтле тормышын күз алдына ачык китереп бастыра: «Казан өязе Колай авылы янында Молотков фамилияле бер алпавыт бик күп урманнар, җирләр биләп тора. Якын-тирәдәге авылларның җирләре, болыннары бик аз булганга, шушы боярга барып эшләргә мәҗбүр булалар. Бу бояр уртагына печән чабучыларга биш өлештән ике өлешен генә бирең, өч өлешен үзенә алып кала. Моның өстенә кеше башына 20 арба тиресне буш түктереп, дисәтинәләп печән чабарга куша. Печәнне дисәтинәләп чабып өяргә дүрт рубля ярым бирә. Мескен крестьяннар җәйнең эссе көннәрендә иртән сәгать биштән кичке сәгать сигезгә кадәр эшләп, көнгә 40 тиеннән артык төшерә алмыйлар. Бу шартларга разый булмаган кешегә печәнсез калырга туры килә. Чөнки аларның яхшы җирләрен хәзинәгә (государствога) һәм алпавытларга биреп бе-

тергәннәр. Фәкыйрь крестьяннар нишләсеннәр? Әлбәттә, шундый авыр шартларны йөкләп, боярга эшләргә ирексез булалар».

541 йортлы Шәле кешеләренең Молотковка ялланган, алпавытка тирес ташыганда арба тәртәсе сынганда да бер төп агач кисеп алырга хакы булмаган, барчасы ачлыкта һәм хәерчелектә яшәгән.

Хәзер туган авылым кешеләре җиргә үзләре хуҗа. Колхозыбызның 10 мең гектардан артык сөрү җире бар. Басуларны йөзгә якын трактор һәм комбайн иңли. Һава шартлары кырыс килгән елларны да без һәр гектардан 14 әр центнер уңыш җыеп алабыз. Дәүләткә икмәк сатуның дүрт еллык планын арттырып үтәдек. Мул уңыш үстерү остасы — бригадирыбыз Зәбир Галиуллин, СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә тәҗрибә уртаклашып, Мәскәүдән медаль тагып кайтты.

Кырларда ел буена моторлар тавышы тынмый, мул уңыш үстерү өчен көрәш бара. Аның алгы сафында — «Почет билгесе» орденлы тракторчы Хәбибрахман Кашапов. Ике улы да — Мансур белән Илсур — әтиләре кебек, трактор йөртәләр. Бу династия былтыр өчәүләп өч мең гектардан артык җир эшкәртте. Миндубаевлар гаиләсе районда комбайнчылар династиясе буларак танылды. Гаилә башлыгы Рәхим уллары Госман һәм Корбангали белән 6 мең центнердан күбрәк алтын бөртек суктырып алды.

Җирнең һәм игенченең язмышы — безнең язмыш. Игенче шатлыгы — безнең шатлык, аның катлаулы хезмәтендәге кыенлыклар — безнең борчылулар. «Россия» колхозы председателе, КПССның XXV съезды делегаты ике орденлы Иван Федорович Ларионов, Ильич исемендәге колхоз җитәкчесе Михаил Федорович Ларионов, «Заря» колхозы председателе Николай Павлович Кулаков, «Кощак» совхозы директоры Нәгыйм Бари улы Вәлиев шулай уйлыйлар, игенченең куанычлары, уй-хисләре белән яшиләр. Иван һәм Михаил—бертуганнар. Иван Федорович — күп еллардан бирле колхозга җитәкчелек итә, эшеннән аерылмыйча Казан авыл хуҗалыгы институтында укып, агроном дипломы алды. Татарстан АССРның атказанган агрономы дигән мактаулы исеме бар.

Нәгыйм Вәлиев — галим, РСФСРның атказанган агрономы. Совхоз директоры булып эшләгәндә, диссертация яклап, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алды. Доктор булырга җыена. Ул «Кощак» совхозы җәнлек үстерүчеләрнең тәҗрибәсен гомумиләштереп, хуҗалыкны халыкара аренага чыгарды. Монда үстерелгән җәнлекләрнең алтынга тиң затлы мехлары Лондон һәм Лейпциг ярминкәләре медальләре белән бүләкләнде.

В. И. Ленин, коммунизм гади эшчеләрнең хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү, бөтен җәмгыятьнең уртак милке булган икмәк, ташкүмер, һәм башка продуктларның һәр потын саклау турында чын хуҗаларча кайгырткан урында башлана, дип өйрәтте. Юлбашчы сакчыллык турында сүз алып барганда беренче урынга Икмәкне куя! Без, игенчеләр, даһиның бу сүзләрен бер генә минутка да хәтеребездән чыгармыйбыз. Җир-анабыз киләчәк буыннарга уңдырышлы туфрагы, урман-сулары, шигъри чишмәләре, сандугачлары белән калсын.

**ФӘЙЗИ САФИН,**
**Вахитов исемендәге колхоз председателе,**
**Татарстан АССР Верховный Советы депутаты.**

Автордан. Фәйзи Әхмәтҗанович Сафин — минем мәктәп укытучым. Илленче еллар сабакташларымны олы тормыш юлына чыгарды. Аның элекке шәкертләренең күбесе югары белем алды, туган-үскән як-

ларында эшли. Мәрзия Мөхәммәтҗанова — Шәле участок больницасының баш врачы. РСФСРның атказанган врачы дигән исемгә лаек булды. Рафаэль һәм Мәүлия Шәяхмәтовлар урта мәктәптә укыталар. Минзифа Әхмәтҗанова — колхозда бухгалтер, Григорий Мураткин — С. М. Киров исемендәге Казан синтетик каучук заводында инженер, Альфред Закиров озак еллар Ленин исемендәге колхоз председателе булып эшләде, хәзер «Татколхозстрой» берләшмәсе подразделениеләренең берсен җитәкли.

Фәйзи ага Бөек Ватан сугышында танкист булып катнаша. Хөкүмәт бүләкләренә лаек була. Хәзер алар янына игенчелектә уңышлары өчен алган Ленин ордены һәм Хезмәт Кызыл Байрагы ордены өстәлде. Егерме ел инде Вахитов исемендәге колхозда җитәкче. Колхоз — күп тармаклы хуҗалык. Ашлык һәм терлекчелек продуктлары җитештерүдә бөтен Татарстанда дан тота. 100 гектар сөрү җиренә 450 шәр центнер сөт җитештерә, бу продуктны дәүләткә 25—30 мең центнер күләмендә сата.

Корыч атларны иярләп менә кая атлады ул атсыз крестьян. Аларның һәркайсы бүген дистәләгән аттан да көчле. Беләкләрендәге көч белән түгел, белеме белән көчле бүген колхозчы. Питрәч районы игенчеләре кулында хәзер 800 дән күбрәк трактор, 300 дән артык комбайн, 500 ләп йөк автомобиле бар. Икенче төрле әйткәндә, авыл хуҗалыгында эшләүче һәр кеше 16,1 ат көченә тиң энергетика куәте белән коралланган! Шундый иҗади фикерияләре соңгы дүрт елда Питрәч кошчылык фабрикасындагы барлык эшләрне автоматлаштырдылар һәм механикалаштырдылар. Чагыштырып үтик: 1935 елда районда 66 вак авыл хуҗалыгы артеле була, аларның һәркайсына уртача 962 гектар сөрү җире, бер трактор, унҗидесенә бер машина туры килә, һәр артель 5 сыер асрый. Бүгенге көндә районда 15 колхоз һәм 9 совхоз 120 мең гектардан күбрәк җир били, фермаларында 10 мең баш савым сыердан елына 250 мең центнердан күбрәк сөт савыла.

... Кокушкинога җәен-кышын, язын-көзен бертуктаусыз халык агыла. Даһи хатирәсенә ил сукмагы өзелми. Иксез-чиксез илебезнең төрле ягыннан, чит илләрдән В. И. Ленин музей-йортына, Питрәч районы хезмәт ияләренең бүгенге тормышы, эшләре белән танышырга киләләр. Аларның һәркайсы бөек юлбашчыбызның кооператив планын тормышка ашыру нәтиҗәсендә колхоз строеның бөек тантанасын гаять зур көч белән тоя.

**МӘГЪСУМ ГӘРӘЕВ.**




## ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

**А. М. Җәләлов,**
тарих фәннәре кандидаты

# ТАҢ АТКАНДА

## Җирдә яңа сулыш



Авылда социалистик үзгәртеп коруларның төп юнәлешен билгеләп, В. И. Ленин: «Таркау алып барылган авыл хуҗалыгын җәмәгать хуҗалыгына әверелдерү һәм аңа эре, гомумдәүләт производствосы формасы биреп, гомуми һәм бертигез хезмәт повинносте нигезендә хезмәт продуктларын бөтен хезмәт иясе халыкның бертигез һәм гадел файдалануына күчүгә... ирешү»[1] бурычын куйды. Ул колхоз төзелеше программасын эшләп кенә калмады, аны тормышка ашыру юлларын да билгеләде, кооперативлаштыруның төп принциплары, формалары һәм ысулларын һәрьяклап җентекле нигезләде.

В. И. Ленин авыл хуҗалыгын үзгәртеп коруның хәлиткеч шарты итеп илне индустрияләштерүне гамәлгә ашыру, эре промышленность булдыруны санады. Бары тик менә шулар гына авыл хуҗалыгы производствосының материаль-техник базасын төзүнең, аны социаль-экономик реконструкцияләүнең нигезе була ала иде. Халык хуҗалыгын электрлаштыру, культура революциясен тормышка ашыру, эшчеләр сыйныфы һәм хезмәтчел крестьян союзын ныгыту, Коммунистлар партиясенең социалистик төзелештәге җитәкчелек һәм юнәлеш бирү ролен көчәйтү, В. И. Ленин күрсәтеп үткәнчә, колхоз төзелешенең уңышын хәл итә торган әһәмиятле шарт иде. Коммунистлар партиясе бөтен совет халкын Ленин күрсәтмәләрен тормышка ашыру өчен көрәшкә күтәрде.

Күп милләтле дәүләтебезнең бердәм семьясында барлык халыклар авыл хуҗалыгын социалистик үзгәртеп коруның ленинчыл планын тормышка ашыруга лаеклы өлеш керттеләр. Яңа тормыш коруда Татарстан АССР хезмәт ияләре дә актив катнашты.

Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр Казан губернасы патша Россиясенең типик аграр районнарыннан берсе иде. 1917 ел башында авылда яшәүче халык

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, т. 28, 165—166 б.

саны күләме 91,5 процент тәшкил итте, шулар арасында ярлылар—57, урта хәллеләр—30, кулаклар—13 процент. Татар крестьяннары аеруча авыр шартларда яшәде. Хәерчелек, ачлык, авырулар, социаль һәм милли изү, политик хокуксызлылык—аларның күпчелеге Октябрь революциясенә кадәр әнә шундый язмыш кичерә.

Бөек Октябрь, 1917 елның 26 октябрендә Советларның II Бөтенроссия съездында кабул ителгән Җир турындагы Ленин декреты хезмәт ияләренең ерак гасырлардан килгән хыялларын тормышка ашырып кына калмады—ул социалистик игенчелеккә күчү өчен объектив шартлар бирде. Алпавыт җирләрен һәм монастырь биләмәләрен тартып алу нәтиҗәсендә Татарстанның хезмәтчел крестьяннарының җире 714 мең гектарга җитте. Татарларга, чувашлар, марилар, мордва һәм башка халыкларга беренче тапкыр рус крестьяннары белән тигез дәрәҗәдә җир бирелде. Совет Россиясенең башка өлкәләрендәге кебек Татарстанда да авыл хуҗалыгын социалистик үзгәртеп корулар башлана.

## Беренче буразналар

Бездә дә беренче күмәк хуҗалыклар Бөек Октябрь җиңүеннән соң ук барлыкка килә. Мәгълүматлар шуны раслый. Беренче күмәк хуҗалыклардан Бөгелмә өязендә Ютазы станциясе янында төзелгән коммунаны атап китәргә мөмкин. Ул 1918 ел язында оештырыла. Аны коммунист Самуил Николаевич Лыков һәм шушы якларда туып үскән берничә фронтовик оештыра.

Беренче күмәк хуҗалыклар рәтенә Казан өязендә Карл Маркс исемендәге (Каймар авылы), «Надежда» (Кульсеитово авылы), «Красный луч» (Киндери авылы); Роза Люксембург исемендәге (Кишмәт авылы) коммуналарны, Спасс өязендәге «Товарищ Ленин» (Аграмаковка авылы) коммунасын, «Сокол» (Иске Нохрат авылы) авыл хуҗалыгы артелен, Лаеш өязендәге «Рассвет» (Карадуле авылы) коммунасын, Мамадыш өязендә «Красная звезда» (Чаксы авылы) коммунасын, «Краса природы» (Әбде авылы) коммуналарын, Көшкәтбаш, Нырты артельләрен, Чистай өязендә «Красный овраг» (Максимково авылы) артелен кертергә мөмкин.

1918 елның җәендә һәм 1919 елның башында татар авылларында да беренче күмәк хуҗалыклар оештырыла башлый. Шуларның берсе—Тәтеш өязенең Иске Барыш коммунасы турында аның председателе һәм оештыручысы Мөхәммәтша Мостаев тутырган анкетада түбәндәге мәгълүматлар хәбәр ителә: 1919 елда 18 кешеле өч крестьян—Мөхәммәтша Мостаев, Сәләхетдин Баһаветдинов, Хәсәнҗан Мостаев һәм укытучы Гатаулла Хәбибуллин гаиләләре 18 дисәтинәдән артык җиргә берләшеп бөртекле ашлык чәчә. Аларның 3 аты, 3 сыеры, 7 сарыгы, 1 бозавы, 1 кәҗәсе, 32 кош-корты булган. Җирне 3 сабан, 2 сука һәм 2 тырма белән эшкәрткәннәр. Икмәккә булган үз ихтыяҗларын гына канәгатьләндереп калмыйча, алар дәүләткә 101,5 пот бөртекле ашлык, 13 поттан артык бәрәңге тапшыралар.

1919 елның 1 июлендә булган мәгълүматларга караганда, татар авылларында барлыгы 6 күмәк хуҗалык булган. Ә шул елның 1 октябрена Казан губернасында рус, татар, чуваш, мари, мордва крестянnарыннан торган 66 күмәк хуҗалык исәпләнә.

Күмәк хуҗалыклар оештыру хәрәкәте башланган вакытта ук интернациональ составлы колхозлар барлыкка килә. Кулакларның каршылыгын җиңеп, Гусиха волостеның Аграмаковка авылы (хәзер Куйбышев районы) рус һәм татар крестьяннары Ленин исемендәге коммунага берләшә. Чистай өязендә төзелгән «Раскрепощение» коммунасында рус һәм чуваш милләтле ярлы крестьяннар иңгә-иң торып хезмәт итә.

Беренче күмәк хуҗалыклар, коммуналар, артельләр җирне берләшеп эшкәртү ширкәтләре рәвешендә төзелә. Авыл хуҗалыгын социалистик күмәк хуҗалык итеп коруда башта коммуна түгел, ә авыл хуҗалыгы артельләре зуррак нәтиҗәләргә ирешә. Татарстан АССРга кергән өязләрдә 1921 елның 1 мартына, мәсәлән, 94 колхоз, шул исәптән 14 коммуна һәм 80 артель исәпләнә. Ягъни аларның саны, 1919 елның октябре белән чагыштырганда, 2,5 тапкыр арта. Бу хуҗалыкларның 5,5 мең дисәтинә җире һәм 4 мең ярым кешесе була.

Күмәк хуҗалыкларның уңышлары тирә-юнь авыл крестьяннарына зур психологик

тәэсир ясый. Җирле матбугатта («Революция байрагы» газетасы) күп тапкыр Арча волостендагы «Роза Люксембург» коммунасы турында сөйләнелә. 1919 елның 30 декабренда аның производство эшчәнлеген яктырткан күләмле мәкалә чыккан. Моннан җиде кеше фронтка киткән, яралану сәбәпле өчесе хезмәткә сәләтсез калган, бары дүрте генә эшкә яраклы саналган. Ләкин батыр коммунарлар рухи төшенкелеккә бирелми. Авыл хуҗалыгы продукциясе үз ихтыяҗларын да канәгатьләндерә һәм дәүләткә ярдәм итә алырлык күләмдә дә җитештерелә. Алар кызыл фронт һәм ачлык кичергән Петроград файдасына 20 пот бөртекле ашлык, 42 пот бәрәңге, 102 пот кәбестә, 39 пот ит тапшыралар.

Әлбәттә, колхозларның беренче уңышлары артык зурдан булмый. Чөнки акча юк, авыл хуҗалыгы кирәк-ярагы бик аз. Советларның 1920 ел декабренда үткәрелгән кантон съездына Алабуга кантон башкарма комитеты докладында җиде хуҗалыкның егәре бик аз булу күрсәтелә: эшкә яраклы 145 кешенең 37 аты, 24 сукасы һәм сабаны була. Билгеле, бу хәлдә җир эшкәртү гаять авыр.

Күмәк хуҗалыкларда хезмәтне оештыру да тиешенчә булмый әле. Бригадалар юк, эш нормалары билгеләнмәгән, хезмәт җитештерүчәнлеге түбән. Керем гаиләдәге җан башына карап бүленә. Шуңа карамастан, колхозлашу хәрәкәте торган саен киңрәк җәелә, яңа тәҗрибә белән баеый бара.

Беренче колхозларны В. И. Ленин югары бәяли. Күмәк хуҗалыкларның үсеш нәтиҗәләрен тикшереп һәм йомгаклап, 1918 елның маенда алар тәҗрибәсе «...безгә җирне җәмәгать булып эшкәртүгә күчүнең хәзер дөрес, чын социалистик масштабта куелганлыгын күрсәтә һәм шуңа тулы ышаныч бирә»,[1]—дип яза юлбашчы. Аннары ул: «Вак ялгыз крестьян хуҗалыкларыннан җирне җәмәгать булып эшкәртүгә күчү озак вакыт таләп итә, һәм ул һич тә тиз генә эшләнә алмый»[2],—дип күрсәтеп үтә.

Якты, культуралы мул тормышка беренче буразна салып, авылда социалистик үзгәртеп коруны башлап җибәргән коммуна һәм артельләр кырыс граждан сугышы елларында да ныгырга омтылдылар һәм шуның белән алар үзләренең тормышчанлыкларын раслады.

## Күмәкләшү

1925 ел ахырына күмәк хуҗалыклар саны биш тапкыр диярлек артты. Ләкин аерым крестьян хуҗалыклары бөртекле ашлыкны төп җитештерүчеләр булып кала бирде. Икмәккә һәм башка туклану продуктларына ихтыяҗ гаять зур иде. 1926 елда чәчүлекләр мәйданы һәм тулай продукция сугышка кадәрге дәрәҗәдән артса да, товарлыклы ашлык, 1913 ел белән чагыштырганда, ике тапкыр кимрәк җитештерелде.

Авыл хуҗалыгының акрын үсү сәбәпләре аның шәхси вак товарлыклы крестьян хуҗалыкларына нигезләнгән булуы белән аңлатыла. Алар Татарстанда 500 мең чамасы исәпләнә; шуларның 110 меңгә якыны ярлыларныкы, 360 меңнән күбрәге урта хәлле крестьяннарныкы һәм 20 меңгә якыны кулак хуҗалыклары була. Шуларның 62 проценты гына җирне үз инвентаре һәм аты белән эшкәртә ала, калганнары зур калым түләү бәрабәренә эш коралын кулаклардан алып торырга мәҗбүр. 100 меңе исә бөтенләй атсыз.

В. И. Ленин бу халәттә вак хуҗалыклар бөлгенлектән, мохтаҗлыктан чыга алмаячак диде. Күмәк рәвештә социалистик җитештерүгә күчү генә фән, техника казанышларын киң куллану өчен уңай шартлар бирә, хезмәт җитештерүчәнлегенең үсеше өчен зур мөмкинлекләр ача ала иде.

ВКП(б)ның XV съезды (1927 елның декабре) тарихка күмәкләштерү съезды буларак кереп калды. Таркау крестьян хуҗалыкларын берләштерү беренче чираттагы бурыч итеп куелды. Шуннан соң колхоз төзелешендә яңа чор башланды. Авылда булган социалистик үзгәрешләр 1928 елның 8—9 январенда үткәрелгән Татарстан колхозчылары съездында да ачык чагылды. Докладларда һәм фикер алышуларда күмәкләшү хәрәкәтенең киңәя һәм үсә баруы күрсәтеп үтелде. Бу яктан алганда Алабуга

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 28 т., 352 бит.
[2] В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 28 т., 346 бит.

районының «Красная Кырында» колхозы председателе Михаил Королев чыгышы кызыклы: «Акрынлап җирне күмәк эшкәртүгә күчтек. Күршеләргә бу кыргый хәл булып күренде. Моның булганы юк, берни килеп чыкмас диделәр. Ләкин үзебезнекен иттек. һәм күмәкләшү җиңде. Җирне бергәләп эшкәртү файдалырак икәне ачыкланды. Җиде басу оештырдык. Сортлы чәчүлек орлыкларын булдырдык. Ниһаять, трактор алдык! Уңышларыбызны күргән күршеләр безгә өйрәнергә килә башладылар. Крестьяннарның 200—300 кешелек экскурсияләре булды. Басуларыбызда читтән килеп кызыксынучылар бетеп тормады. Бездән үрнәк алып, Ильин пучинкәсе, Янсыбай авылы да күп басулы ысул белән эшләүгә күчте».

1928 елның 1 октябрена Татарстанда колхозлар саны 333 кә җитте.

Совет дәүләтенең тоташ күмәкләшү өчен күрелгән чараларында авыл хуҗалыгын житештерү средстволары белән тәэмин итү аеруча әһәмиятле иде. Машина, техника елдан-ел арта бара. 20 нче еллар башында республикадагы тракторлар берничә генә булса, 1928 елда аларның саны 128 гә җитә. Аларның крестьяннарга тәэсире гаять зур була. Авылларда беренче куәтле корыч атларны алулар хакында кызыклы документлар сакланып калган. 1924 елның көзендә Чистай кантонының Нуркеево авылына трактор кайта һәм беренче бураэнаны сала. Аңа меңнәрчә кеше иярде. Шатлыктан кемдер көлде, кемдер елады. Беркем дә күзен сабаннан алмады. Кешеләрдәге сокланү һәм шатлык хисен язып бирерлек түгел. Кызганыч, шатлыктан гаҗәпләнгән, авызлары ерылган, кайсыларында курку чагылган бишмәтле, сакаллы кырыс игенчеләрнең йөзләрен төшереп алырга фотограф юк иде»,—дип язып калдырган безгә шушы вакыйгаларның бер шаһиты.

1929 ел ахырына илебез авылларында инде 70 меңнән артык трактор эшли. Социалистик индустрияләшүдәге уңышлар авыл хуҗалыгын күмәкләштерү өчен яхшы шартлар әзерли. Шәһәр һәм авылның яңа экономик нигездә бер-берсенә ярдәме эшчеләр сыйныфының хезмәтчел крестьян массалары белән бердәмлеген тагын да ныгытты.

1929 елның көзеннән авылда яңа чор башланды. Крестьяннар инде авылы-авылы, волостьлары, районнары белән күмәкләшергә керештеләр. Урта хәлләр дә кузгалды.

ВКП(б) Үзәк Комитетының «Коллективлаштыру темплары һәм дәүләтнең колхоз төзелешенә ярдәм итү чаралары турында»гы 1930 ел, 5 январе карары белән, сыйныф буларак, кулакларны тәмам бетерү нигезендә авыл хуҗалыгын бердәм күмәкләштерү политикасы билгеләнде. Бу карар ленинчыл кооперативлаштыру планының теоретик положениеләрендәгечә эшләнде. Партия һәм хөкүмәтнең ленинчыл кооператив планын гамәлгә ашыру чараларын Татарстан хезмәт ияләре зур рухлану белән каршыладылар. Республикада 1930 елның башында колхозлашу мәсьәләсе каралмаган бер генә авыл да калмый. Авылларда партия оешмалары житәкчелегендә күмәкләштерү мәсьәләләре тикшерелгән җыелышлар үткәрелә. Күмәкләштерүнең максатлары, бурычлары һәм формалары турындагы доклад тыңлаганнан соң Чаллы районының Балтач авылы крестьяннары: «Без, гражданнар, колхоз оештырырга телибез. Авыл хуҗалыгын хәзерге кебек шәхси тәртиптә алып бару киләчәктә мөмкин түгел»,—диган карарга килә. Нәтиҗәдә республикада 1930 елның январенда гына да 500 дән артык яңа колхоз оештырыла. Районнарда барлык җир колхоз карамагына күчә. Кулаклар сөрелгән, тоташ күмәкләшү барган авылларда байларның малы, машиналары һәм башка авыл хуҗалыгы кораллары, хуҗалык корылмалары колхоз милке итела.

Коммунистлар партиясе авыл хуҗалыгындагы социалистик үзгәртеп коруларны эшчеләр сыйныфы белән хезмәтчел крестьяннар союзына таянып гамәлгә ашыра. ВКП(б)ның ноябрь (1929 ел) Пленумы карары нигезендә эшчеләр сыйныфының иң яхшы 25 мең вәкиле авылларга җибәрелә. Татарстан районнарына 400 дән артык кеше килә—аларның 244 ең Мәскәү, 44 ең Баку һәм 100 дән артыгын Казан промышленность предприятиеләре җибәрә. Егермебишмеңчеләр Татарстанда колхоз төзелешенең аеруча җаваплы урыннарын житәкләде, 200 дән артыгы колхоз председателе булды. Республикабыздагы беренче алдынгы колхозларның уңышлары В. П. Әхмәдуллин, Х. Б. Бәдретдинов, П. Г. Матвеев, Л. П. Плетнев кебек егермебишмеңчеләр эшчәнлеге белән бәйле. Алар авылларга эре производство оештыру тәҗрибәсе алып килде, ударниклык хәрәкәтен башлап җибәрде, предприятиеләрнең колхозлар белән ярдәм-

ләшү элемтәләрен ныгытуга булышлык итте. Ленинның шәһәрнең авылга ярдәм итү фикере тагын да үстерелә. Казанда авыл хуҗалыгын күмәкләштерүгә булышлык итүнең республика җәмгыяте төзелә.

1930 елның мартында Норлатта (Октябрь районы) Татарстандагы беренче машина-трактор станциясе барлыкка килә. Аннары Тәтеш, Теләнче Тамак МТСлары оеша. Алар язгы чәчү чорында колхозларга нык ярдәм итә, авыл хуҗалыгын социалистик үзгәртеп коруга зур этәргеч була.

Н. И. Идиятуллин (Алабуга районының Тукай исемендәге колхозы), В. А. Әхмәдиев (Әгерҗе районының Чапаев исемендәге колхоз), Ф. З. Җамалиев (Буа районының «Коммунизм» колхозы), Ш. Б. Бикмөхәммәтов (Арча районының «Авангард» колхозы), А. П. Парков (Бондюг районының «Красный партизан» колхозы), Ф. Х. Хафизов (Яңа Писмәнкә районының «Уңыш» колхозы), Н. Е. Воробьев (Тәкәнеш районының «Красный крестьянин» колхозы) һәм башкалар—исемнәре колхоз хәрәкәте тарихына кереп калган кешеләр бар да коммунистлар һәм комсомоллар, авылдагы активистлар, элеккеге кызылармеецлар, эшче сыйныф вәкилләре—егермебишмеңчеләр була.

## Соңгы көрәш

Тоташ күмәкләшүгә күчү белән бергә, кулакларга каршы соңгы һәм хәлиткеч көрәш башлана. Чөнки алар социалистик төзелешкә рәхимсез каршылык күрсәтәләр. 1929 елның соңгы биш аенда һәм 1930 елның январенда, тулы булмаган мәгълүматларга караганда, алар җәмәгать милкенә 150 тапкыр ут төртәләр. Авылларда һәр атнаны берничә янгын чыга. Буа районының Лаптевка авылында, мәсәлән, булышлык итү комиссиясе членнары хуҗалыкларын, Чистай кантонының Иске Әлмәт авылында авыл Советы председателе йортын яндыралар. Буа районының «Октябрь», Бөгелмә районының «Якты күл» колхозларында авыл хуҗалыгы машиналары һәм трактор юкка чыгарыла. Күмәкләшү өчен көрәштә кулаклар каршылыгыннан Татарстанның илледән артык улы һәм кызы һәлак булды. Күбесе коммунист һәм комсомол. Алар арасында Казан районының Чебакса авылы партия ячейкасы секретаре, колхоз оештыручы Федор Беркутов, Арча районының Югары Мәтәскә авыл крестьяннары комитеты председателе Шәфигулла Хәмидуллин, Олы Шемякино волостеның Аллабирде авылыннан комсомол кыз Фатыйма Газизова, беренче председательләр—Алабуга районының Черкас авылыннан Федор Гуляев, Рус Акташы авылыннан Николай Чумаков, Чаллы районының «Маяк» колхозыннан Филипп Пушкарев бар. Көрәшчеләрнең якты истәлеген мәңгеләштерү йөзеннән бу колхозлар алар исеме белән атала.

Район җир бүлекләре мәгълүматларына караганда, 1930 елның 10 апреленә Татарстанда 13 меңнән артык кулак хуҗалыгы бетерелде, аларның авылда социалистик төзелешкә каршы корткыч көрәше бастырылды. Бу—республика хуҗалыкларының 2,9 проценты. СССРдагы һәм башка социалистик илләрдәге крестьян хуҗалыкларын күмәкләштерү тәҗрибәсе авылда социалистик үзгәртеп корулар дәвамында кулакларны бетерүнең гомуми тарихи закончалык һәм объектив зарурлык булуын күрсәтте.

## Иң туры юл

КПСС Үзәк Комитеты, Совет хөкүмәте милли республикаларга тоташ күмәкләштерүне үткәрүдә зур ярдәм күрсәтә. Партия Үзәк Комитетының «Татарстан партоешмасының торышы һәм эше турында»гы 1930 ел, 23 май карарында республиканың хуҗалык исәбе һәм милли үзенчәлекләре нигезендә күмәкләштерү үткәрергә, халыкларның тугандаш һәм интернациональ дуслыгын һәрьяклап ныгытырга тәкъдим ителә. Бу елларда республикада партия Үзәк Комитетының пропаганда группалары эшли, Бөтенроссия старостасы М. И. Калинин, В. И. Ленинның сеңелесе М. И. Ульянова килә. Татарстан партия оешмасына күренекле партия һәм совет эшлеклеләре, партия Үзәк Комитеты вәкилләре М. М. Хатаевич, М. О. Разумов, А. К. Лепа җитәкчелек итәләр. Партиянең төп бурычы өчен көрәштә милли активтан җитәкче кадрлар — республика

совнаркомы председателе К. А. Абрамов, партия өлкә комитетының икенче секретаре Б. А. Абдуллин, игенчелек халык комиссары Г. И. Искәндәров һәм башка күп кенә җитәкче кадрлар үсеп чыга һәм чыныга.

1931 елда республикада 16 яңа машина-трактор станциясе төзелә. Алар 789 дана, ягъни булганнан ике ярым тапкыр артыграк трактор алалар. МТС директорлары итеп колхоз төзелешендә актив катнашучы коммунистлардан А. Большаков (Чаллы), П. Ананьев (Бөгелмә), Н. Жернаков (Чистай), Г. Хәбибуллин (Октябрь районы), А. Гарифуллин (Актаныш) кебекләр билгеләнә. Машина-трактор станцияләре элекке күмәк хуҗалыкларны ныгытуга һәм яңа колхозлар оештыруга булышлык итәләр.

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының 1930 ел, 10 август карары нигезендә Татарстанда 46 авыл районы оештырыла. Җитәкчеләр итеп партия эшенә бирелгән, халык арасында оештыру тәҗрибәсе зур булган коммунистлар билгеләнә. МТСларда, совхозларда һәм колхозларда партия ячейкалары төзелә. Алар авылларда партия эшен үткәрүнең терәк пунктларына әверелә. 1931 елда гына да партия членнары һәм членлыкка кандидатлар итеп авылда 8 меңнән артык кеше алына. Авыл партия оешмалары саны бер елда ике тапкыр диярлек арта.

Беренче бишьеллыкның төп бурычлары—илне аграр илдән индустриаль илгә әверелдерү, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү бурычы уңышлы үтәлгәч, авылда яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләр барлыкка килде, Татарстан авылларының йөзе үзгәрде. 1932 ел ахырына барлык чәчү мәйданнарының 77,5 проценты социалистик секторныкы иде. Чәчү мәйданнарын киңәйтү, аларның структурасын яхшырту, агротехникасын үстерү өчен зур мөмкинлекләр ачылды. Нәтиҗәдә 1932 елда, 1929 ел белән чагыштырганда, дәүләткә ике ярым тапкыр күбрәк икмәк тапшырылды. Колхозлар һәм совхозлар барлык тулай продукциянең 70 процenttан артыграгын һәм игенчелектәге товарлыклы продукциянең 80 процентын җитештерделәр. Социалистик терлекчелекнең дә ныклы нигезе булдырыла. 1932 ел ахырына республикада 150 мең баш чамасы мөгезле эре һәм вак терлеге булган 1500 дән артык товарлыклы ферма исәпләнә.

ВКП(б) ҮК һәм ҮКК январь (1933 ел) Пленумы карары нигезендә республиканың барлык 46 МТСында һәм 13 зур совхозында политик бүлекләр оештырыла, алар хуҗалык һәм политик җитәкчелек үзәгенә әверелә һәм 1933 елдан башлап 1934 ел дәвамында Татарстанда колхоз строен ныгытуда зур эш башкара.

1933 елда республиканың барлык колхозларында даими производство бригадалары төзелде, күмәкләшкән хуҗалыклар язгы кыр эшләрен үткәрүдә илебездә беренчелекне алуга ирештеләр. 1933 елның 11 маенда СССР Үзәк Башкарма Комитеты Председателе М. И. Калинин Татарстан колхозчы-ударниклары делегациясе белән очраша. Әңгәмәдә «Авангард» колхозы колхозчысы, Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты члены Гарифә Мостафина, «Новая жизнь» колхозы бригадиры Семен Ильин, «Алга» колхозы председателе, егермебишмеңче Исмәгыйл Ибраһимов, «Красный бор» колхозы председателе Степан Еврюжихин һәм башкалар катнаша. М. И. Калинин бөртекле ашлык хуҗалыгы һәм терлекчелекнең торышы, чәчү мәйданнарының структурасы һәм үзгәреше, төрле тармакларның үзара нисбәте белән кызыксына. Күп нәрсә күмәк хуҗалыкның җитәкчесенә бәйле, ди М. И. Калинин. Яхшы җитәкче булган урында эшләр дә яхшы бара, начар җитәкчеләрнең эшләре дә начар. Бүген дә зур яңгырашка ия булган хаклы сүзләр.

Күмәкләштерүне тәгәлләүдә һәм авыл хуҗалыгын социалистик үстерүдә үзәктә һәм урыннарда үткәрелгән колхозчы-ударниклар съездлары гаять зур роль уйнады. 1933 елның 15 маенда Казанда колхозчы-ударникларның беренче Бөтентатарстан съезды эшли башлады. Анда авыл хуҗалыгының 3 меңгә якын алдынгы кешесе катнашты. Делегатлар Бөтенсоюз старостасы М. И. Калинин чыгышын аеруча зур игътибар белән тыңлады. Ул Казан районының «Заветы Ильича» һәм Арча районының «Авангард» колхозларына барды, анда авыл Советлары, артель идарәләре эше белән танышты, колхозчылар белән дусларча әңгәмәләр үткәрде.

Колхозчы-ударникларның икенче Бөтентатарстан съезды (1933 елның көзе) авыл хуҗалыгы елына йомгак ясады һәм авылда социалистик үзгәртеп коруларны тагын да дәвам иттерү бурычларын карады. Татарстан хезмәт ияләрен В. И. Ленинның сеңелесе М. И. Ульянова котлады. «Әгәр Татарстан быел шундый зур уңышларга ирешкән икән, ул моңа, барыннан да элек, крестьяннар аңында колхоз юлы—социализм

юлының бердәнбер дөрес юл икәнлеге торган саен үсә барганга күрә ирешкән»[1],— диде ул.

Безнең колхоз һәм совхозлар илебез өлкәләре, крайлары һәм республикалары арасындагы социалистик ярышта җиңеп чыга. Атлар һәм терлек саны арта башлый. Колхозчылар бер хезмәт көненә уртача 6—7 килограмм ашлык алалар. Алдынгы колхозларда хәтта 12—16 килограммга кадәр ашлык бирелә.

Авыл хуҗалыгы производствосында, колхозлар, совхозларны ныгытуда һәм дәүләт алдындагы йөкләмәләрен үтәүдә ирешкән уңышлары өчен СССР Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы 1934 елның 3 гыйнварында Татарстан АССРны Ленин ордены белән бүләкләде.

Икенче бишьеллык чорында илебездә авыл хуҗалыгын тоташ күмәкләштерү тәгалләнде. 1937 елда Татарстанда 3836 колхоз исәпләнә иде. Алар крестьян хуҗалыкларының 91,1 процентын берләштерде һәм чәчү мәйданнарының 99,4 процентын биләп торды.

Ленинчыл кооперативлаштыру планы тантана итте. Колхоз строе җиңү белән күп милләтле совет крестьяннары үзләренең уңышлы рәвештә социализм юлыннан бара алачакларын эштә исбат иттеләр.

Нык үскән социализм шартларында колхозлар совет крестьяннары өчен коммунизмга баганалы юл булып тора, дип билгеләп үтте колхозчыларның III Бөтенсоюз съездында Л. И. Брежнев. Шуңа күрә совхозларны һәм агро-промышленность комплекслар төзү белән беррәттән, колхозларны тагын да ныгыту, үстерү Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәтенең әһәмиятле бурычы булып кала.

---

[1] «Красная Татария», 1933, 4 октябрь.

# Укучының күңел дәфтәренә

**Башкорт мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Ил кадерен белмәгән — башын җуйган,*
*җир кадерен белмәгән — ашын җуйган.*
*Җире байның иле бай.*
*Өйрәнү — үзе һөнәр.*
*Сәнәкне көрәккә саплый.*
*Ботка пешә мае белән, эш эшләнә җае белән.*
*Ашыңны биргәндә кашыңны җыерма.*
*Ачу — дошман, акыл — дус, ачуыңа акыл куш.*
*Уңмаган бала — башыңа бәла.*
*Күп сүзнең азы яхшы, аз сүзнең үзе яхшы.*
*Олыларны олыласаң, үзеңне олыларлар.*
*Тауга каршы таш атма.*
*Тәртәгә кермәгәнне киртәгә кертеп булмый.*
*Алганга алтау да аз, биргәнгә бише дә күп.*
*Атлас суда батмас.*
*Бүре буранда котыра, тиле урамда котыра.*
*Дөньяның җае — каймакның мае.*
*Җан тартмаса — тән тартмый, тән тартмаса — кан тартмый.*
*Казанның карасы, яманның бәласе йога.*
*Яман юлдаштан таяк яхшырак.*
*Шәригать ул — чи тире: тарткан саен сузыла.*

# ҖИР УЛЛАРЫ

*Журналист блокнотыннан*



Совхоз менә-менә уракка чыгарга тора, ә «Колос» кебек куәтле өч комбайнга утырырга кеше юк. Мирсәяф Мөхсинов инде ничәнче тапкыр: «Әллә көчне сынап караргамы?» — дигән уйга килә. Комбайнда эшләмәсә дә, ул барлык төр машинаны яхшы белә — мастерской мөдире ич. «Ә уттай эш өстендә монда кем калыр?» Мирсәяф уйларыннан арынып өлгермәде, янына совхоз директоры Легендар Мириханов килеп туктады.

— Әллә берәрсенә утырасыңмы? — диде директор.— Игеннәр нык уңды, урак җиңел булмаячак.

Мирсәяф үзенең дә шул турыда уйлап торуын әйтте: «Карап карыйк».

Директор исә аңа күңелендә йөрткән икенче уен да әйтеп салды: бер звено оештырып, шуны җитәкләсәң иде.

Мирсәяф бу тәкъдимгә дә күнде.

Вакытны озакка сузмыйча, ике яңа комбайнга кеше эзли башлады, күңеленнән совхоздагы бөтен кешене барлап чыкты. Иң башта сарык караучы-көтүче Павел Иванович Забавинга тукталды. Ул, терлекчелектә яхшы эшләве өстенә, техниканы да биш бармагы кебек белә. Сарык йоны алучылар конкурсында ил күләмендә җиңеп, дан алган чаклары булды. Урак җитүгә, комбайнга утыра торган гадәте дә бар иде. Павел Иванович шатланып ризалашты. Аннары Малик Хафизов белән сөйләшү булды. Аның белән дә уртак фикергә килделәр. Совхоз дирекциясе тагын тәҗрибәле комбайнчылар Мәсгут Шәрипов, Леонид Дениваров һәм Леонид Калашниковны бирде, ашлык ташу өчен кирәк кадәр шофер билгеләде. Калашников Казагыстан кырларында да эшләп кайткан, иген урып-җыюда «азау теше чыгарган» оста. Шулай итеп, яңа урып-җыю транспорт звеносы барлыкка килде. Һәркем үзе кулай күргән кешене ярдәмче итеп алды. Забавин хатыны Зинаида Ивановна белән бергә чыгарга булды. Ә Мирсәяф унынчы класста укучы улы Ленарны күндерде.

Мөхсиновлар — нәселе-нәсәбе белән механизаторлар. Игенчеләр. Апасы Тәслия уникe ел комбайн йөрткән. Энесе белән абыйсы Рәис һәм Варис совхозның алдынгы тракторчылары — җир сөрәләр, чәчәләр. Хәзер менә Мирсәяфнең үз улы да механизатор булып җитлегеп килә.

Бер көнне алар кыр корабларын басу кырыена чыгарып куйдылар. «Миронов — 808» сортлы көзге бодайның урып, камылга салынган теземнәрен суктыра башларга тиешләр иде дә, тагын бераз җилләсен әле дип, бер көн сабыр итәргә булдылар. Иртән исә, чык кипкәнне көтәләр. Соңыннан алар бу көн һәм иртәнге сәгатьләр өчен бик үкенделәр. Тик кайтарып алып булмый иде инде. Гомумән, чык кип-

кәнне көтеп, иртәнге сәгатьләрне вак-төяк эш белән уздырган бик күпләр көзгә таба терсәкләрен тешләрдәй булды.

... Ниһаять, бер-берсенә хәерле юл теләп, кыр казларыдай тезелешеп, алтындай тасмалар чакрымнарга сузылган бодай җиренә кереп киттеләр. Басу күңелгә якын гөрелтегә күмелде. Беренче бункерларның тулуын көтә торган шатлыклы минутлар. Мирсәяф кабинадан тирә-якка күз салды: җир өсте тулы байлык. Алтыннан да кадерлерәк ашлык. Тизрәк җыеп алырга иде. Комбайнның барышын кызулатасы килде. Ләкин ярамый. Машина бер көй белән эшләргә тиеш. Ул теземнәрне ялмап, алга, офыкка таба юл тота.

Кызганычка каршы, беренче шатлык бик тиз сүнде. «Колос»лар бер-бер артлы дүртесе дә туктап калды. Бөртекне суктырып бетерми, салам тыгыла, тапшыру тартмасы сафтан чыга... «Нива»лар эшли торды, ә «Колос» комбайнчылары бер тирәгә җыелды, әле бер, әле икенче комбайнны тикшереп карадылар.

Сүз китте, «Колос»ларны заводта яхшылап көйләп, эшләтеп карап җибәрмиләр. Һәр җирдә зарланалар, чиләнәләр. Кайсыдыр үзәк газетада укыган бер мәкаләне исенә төшерде, заводны нык тәнкыйтьләгәннәр иде анда. Менә монда китерәсе иде үзләрен, урдырып, суктырып карасыннар иде.

Аннары тын калдылар, машиналарны ныклап актарырга тотындылар. Көн дә, төн дә сизелмичә узып китте. Комбайннар яңадан иген кырларын иңләргә тотынды. Ике-өч көн дигәндә шактый мәйданның игенен урып-җыеп, берсеннән-берсе уздырып, нормаларын арттырып үти башладылар. Ашлыкның төшеме яхшы, бункерлар тиз тула. Шоферлар да, комбайннарга тоткарлык ясамас өчен, машиналарын җитезрәк куалыйлар. Ял итү дигән нәрсә онытылды. Алар, комбайн темпына ияреп, шул кадәр кызу йөрде— Миңнәхмәт Галиуллин унике чакрым арадан ындыр табагына берүзе ике комбайн ашлыгын ташып өлгерде.

Менә совхозның партком секретаре Рафик Нурмөхәммәтов һәм директор Легендар Мириханов звеноны урып-җыюда ирешкән беренче уңыш белән тәбрикләргә килде. Мирсәяф комбайнына ярышта җиңүчеләргә бирелә торган кызыл вымпелны беркеттеләр. Директор, шатлыгын уртаклашып, көзге бодайның гектардан 35 әр центнер чыгуын әйтте. Кыска гына киңәшмә булып алды. Мирсәяф директорга төнлә дә эшләргә исәпләүләрен белдерде.

Шушы көннән соң совхоздагы урып-җыю ярышы киңрәк колач алды. Комбайнчылар суктыруны төнлә ут яктысында да дәвам итте. Әлбәттә, бу җиңел эш түгел. Җир өстен, тезмәләрнең әйбәт җыелуын, саламның яхшы суктырылуын, бөртекнең калмавын үткен күз белән күзәтергә, комбайн узелларын фонарь уты яктысында тикшерергә, көйләргә, майларга туры килә иде. Мирсәяф бу эшләргә күбрәк улы Ленарны йөгертте. Үзе дә, кабинадан ара-тирә төшеп, саламны җентекләп тикшерде. Бөртек сугылып бетәме? Фонарь уты белән комбайн узган җирне дә карап чыкты: башаклар калмыймы? Җитәкче буларак, башка комбайнчылар янына да барып, хәл-әхвәл белешеп, эшләүләрен күзәтеп килгәләде.

Унтугыз-егерме август көннәре алар өчен аеруча истәлекле булды. Звено членнары, алдан сүз куешып, уракны тизләтү өчен 38 сәгать тоташ эшләп, 196 гектардан 6915 центнер ашлык суктырып алдылар. Бер комбайн белән уртача 1152 центнер ашлык суктырылган иде.

Районда гына түгел, республика күләмендәге рекорд иде бу!

Мөхсиновларның хезмәт батырлыгы турында, алар үрнәгенә ияреpгә чакырып, республика газеталары язып чыкты.

Алар янына партиянең Азнакай райкомы беренче секретаре Әнвәр Бәдретдинович Баһаветдинов килеп җитте. Уракны тиз тәгәлләү өчен

кешеләрнең шулай фидакарь эшләве, урып-җыю агрегатлары арасындагы социалистик ярышны Мирсәяф Мөхсинов кебек коммунистларның әйдәп баруы райком секретаре өчен зур шатлык иде. Кыр вагоны янына җыелдылар.

Менә алар, көн батырлары. Секретарь берәм-берәм һәркайсына күз йөртеп чыкты. Карашы Мирсәяфтә тукталды. Ул аны яхшы белә. Ремонт вакытларында мастерскойга еш туктала иде. Чандыр гәүдәле, бик житез хәрәкәтле, кешеләргә һәр вакыт елмаеп карый торган сөрмәле күзле Мирсәяф эше белән дә, җыйнаклыгы белән дә бик охшый иде Әнвәр Бәдретдиновичка. Менә ул сүзсез генә басып тора. Майланган комбинезоны кояшта ялтырый. «Тартыла төшкән, нык тартылган», — дип уйлады секретарь. Ул һәр комбайнчының кулын кысып, хезмәттәге батырлыклары белән җылы котлады, һәркайсына яңа уңышлар, сәламәтлек һәм гаилә бәхете теләде, партиянең район комитеты һәм район Советы башкарма комитетының котлау хатларын тапшырды.

Кырда уздырыла торган мондый җыелышлар кыска булучан. Һәр кешене ашыгыч, кичектергесез эш көтә. Бу юлы да шулай булды.

Мирсәяф бәхетле көннәр кичерә. Ул киләчәктә нинди зур авырлык, мәшәкать һәм борчу көтүен сизенми иде әле.

Көзге бодайны һәм арышны сугып бетереп, борчак җиренә күчтеләр. Борчак җиргә сыланган. Башта җыйдырта алмыйча иза чиктеләр: балчык ияргә, шнек тыгыла, борчак бункерга күтәрелми. Туктадылар, бик озак уйлашып, сәбәбен эзләп, комбайн янында басып тордылар. Һәм борчак иләген люгка, шнек башларына куярга кирәк дигән нәтиҗәгә киленде. Ындыр табагыннан тиз генә иләк алып килделәр. Башта Мирсәяф үзе шулай эшләде. Суктырып карадылар. Әйбәт булып чыкты. Аннары барлык комбайннарны да шулай көйләделәр.

Борчак урагы кызып киткәндә генә яздан башлап туктаусыз яуган, игеннәр өлгергән чорда гына бераз сулыш алдырган яңгыр яңадан коеп түгәргә тотынды. Аның кайчанга кадәр, күпме явасын, әлбәттә, беркем дә белми. Мөхсиновчылар көннең рәтләнүен көттеләр-көттеләр дә, өметләрен тәмам өзеп, яңгырлы көннәрдә дә, бераз яумый торган араны эләктереп, эшли торган булдылар. Аякларда резина итек, өстә плащ яки кожан. Кара күз диярсең. Баштагы темпны да, сыйфатны да сагынып сөйләргә генә калды. Борчак нык коела. Шулай да мондый шартларда җыеп алган кадәренә риза буларга туры килә. Гектарга егермешәр центнер борчак чыгып барды. Начар уңыш түгел. Тик ашлыкны ташуы кыенлашты, машиналар басуга керә алмыйлар, керсәләр дә чыгуы кыен.

Директор, туңга сөрүдәге тракторларны алып, ашлык ташучы машиналарны тарттырырга билгеләде. Төнлә эшләп булмый башлады.

Бу авырлыкның башы гына булган икән әле. Иң кыен хәл язгы бодайны уруга керешкәч башланды. «Мәскәү — 35» сортлы бодай ишелеп уңган, башаклары эре, тук.

Совхозда утыз комбайн бар. Барысы да бодай басуында. Инде тезмәгә салмыйча, турыдан-туры да урырга мөмкин. Әмма комбайнчылар бары берничә көн эшләп калдылар. Анысында да яңгыр астында, комбайннарны тракторлар белән тарттырып. Җир шул хәтле изрәде, инде чылбырлы тракторлар да бата. Бата да, бер урында тирбәнеп, кире үгездәй үкереп, тик тора.

Туктарга мәҗбүр булдылар. Күк йөзен кара болыт каплаган. Сикеребрәк үрелсәң, болытларга кул тияр кебек. Механизаторлар, машиналарын басуда калдырып, юлдагы пычракны көч-хәл белән ерып, авылга таралды. Дәвамлы, көчле яңгырлар астында мескенләнеп калган бодай басуы Мирсәяфнең бар булган кәефен кырып бетерде.

Башакларын шулай түбән салындырып күпме утырырлар? Беренче карларга хәтлеме?

Мирсәяф һәм аның хезмәттәшләре өчен эчпошыргыч, җан әрнеткеч көннәр башланды. Күкнең әйтерсең түбә тишелде: яңгыр чиләкләп кенә яумый, ә болыты белән үк җиргә төшеп куна кебек иде. Дөрес, кайбер көннәрдә, кешене алдау, үртәү өчен юри эшләгәндәй, берничә сәгатькә туктап алгалады. Мирсәяфләр басуга, машиналары янына барып җитүгә, яңадан коярга тотына.

Суытканны, җир катырганны көтә башладылар...

Өченче октябрьда мин Азнакай районына бару өчен самолетта Бөгелмә аэропортына очтым. Кар явып, җир катырганга өч көн инде. Урып-җыелмаган язгы бодай республиканың көнчыгыш районнарында күбрәк иде. Бер сәгатькә сузылган бөтен юл буена күктән кырларны күзәтәм: Лениногорск, Әлмәт районнары җирләренә килеп кергәч, ап-ак кар өстендә әкәм-төкәмдәй салмак кына шуышкан комбайннар төркеме, алар эзеннән барган автомашиналарны күрү чиксез сөендерде. Эшлиләр бит, уралар, рәхмәт төшкерләре! Әти-әниләрнең революциягә кадәр кайсыдыр елны кар яугач урак белән иген урганнарын сөйләгәнен хәтерлим. Ә монысы, быелгы ишесе, кышкы салкында машина белән уру тарихта беренче тапкыр иде. Дөрес, сәеррәк күренеш, җир ак юрганын ябынган, ә урак бетмәгән, киресенчә, аеруча кайнар төс ала. Ул көннәрдә күп кенә район комбайнчылары, азнакайлылар исә аеруча, җәй көне дә булмаган темп белән эшләделәр.

Ә шулай да кеше көчле!

Менә Бөгелмә элеваторы. Агылып ашлык килә. Автомашиналар чиратының очына чыкмалы түгел. Бер яктан, күңелле, куанычлы күренеш булса, икенчедән, аяныч хәл иде бу. Безнең элеваторлар, кызганычка каршы, урып-җыюның киеренке көннәрендә ашлыкны кыска арада кабул итеп өлгерә алмыйлар...

Азнакайга караңгы төшкәч кенә килеп төштем. Район партия комитетының беренче секретаре бүлмәсе электр утыннан ялт иткән, ә Әнвәр Бәдретдинович үзе, зур өстәленә таратып куелган күп санлы кагәзьләрнең әле берсенә, әле икенчесенә күз төшереп, тиешле саннарны карап, колхоз җитәкчеләре, партия оешмалары секретарьлары белән радио аша киңәшмә үткәрә. Районның урып-җыю штабы начальнигы буларак, ул көндезге нәтиҗәләргә анализ ясый, төн өчен бурычлар билгели, кайда нәрсә эшләргә кирәген һәр хуҗалык җитәкчесенә бәйнә-бәйнә аңлата: барлык комбайннар төн буе эшләсен, ашлыкны ачык һавада калдырмаска, сушилкаларны тәүлек буе туктатмаска, ашлык ташу өчен нефтьчеләрдән күп кенә машина китте — эшләрен токтарламаска... Секретарь кешеләрне якын, үз итеп, аталарча кайгыртып сөйли. Төнлә эшләүчеләрнең барысы өчен дә бер, кирәк икән ике тапкыр кайнар аш оештырырга, ә җитәкчеләргә төп эш урыннарында, игенчеләр янында булырга киңәш итә. Аның орышып, шелтәләп әйтүе дә ягымлы: «Җаныкаем, муеныңда башың бар лабаса, беренче ел гына эшләвең түгел, нәрсә уйлыйсың?!»

Чират Вахитов исемендәге совхозга килеп җитте. Телефонда директор Мириханов иде.

— Яхшы эшлисез. Егетләрегезгә безнең исемнән рәхмәт әйт. Карагыз аны, бодай иртәнгә урып-суктырып бетерелгән булсын. Районда байтак бодай тамырда әле. Бөркетләреңне иртәгә үк «Урманай» һәм «Никитинский» совхозларына җибәр. Сорауларың, үтенечләрең юкмы? Ярый, уңышлар сезгә!

Хуҗалык җитәкчеләре белән сөйләшеп бетергәч, Әнвәр Бәдретдинович:

— Атна-ун көнлек эш бар әле, — диде. — Ә менә Вахитов исемендәге совхоз бу төндә тәмамлаячак. Хәзер ул дәүләткә планнан тыш

кына да егерме меңенче центнер ашлыгын тапшыра. Тамак ялгап алам да, шунда китәм. Барырга теләмисезме?

Бергәләп юлга чыктык. Секретарь юлда район хуҗалыкларында карабодайдан һәм язгы бодайдан югары уңыш җыеп алынуы турында сөйләде:

— «Мәскәү — 35» сортлы бодай район кырларында әле яңа игелә, бары җиде мең гектарда. Ә үзен яхшы яктан танытты. Сентябрь ахырына хәтле туктаусыз яуган көзге яңгырлар астында утыруына карамастан, ул сөрлекмәде, егылмады, бөртеге дә бозылмады. Гектардан 30 ар центнер уңыш чыга. Менә нинди бодай баш булачак безнең кырларда!

Ул көннәрдә сугыла торган ашлык, әлбәттә, үтә дымлы иде. Районда аны саклау өчен күп төрле чаралар күрелгән. Хәтта «Сельхозтехника» берләшмәсе, автотранспорт предприятиесе гаражларына хәтле ашлык салынган, үлән оны ясаучы АВМ агрегатлары да ашлык киптерү өчен файдаланыла.

Басу юлыннан секретарь «газигы» элдертә генә. Әче җил сызгыра, җәяүле буран себерә.

— Вахитов совхозы кырларына кердек, — диде секретарь.

Тиздән кырларны фара утлары белән балкытып, кар астыннан яртылаш кына күренеп торучы бодай басуында әкрен генә үрмәләүче комбайннар төркеме күренде. Туп-туры шунда юнәлдек.

Машинадан чыгуга, тәнгә салкын йөгерде. Әнвәр Бәдретдинович бер комбайнның түбәсендә ут яктысында бигрәк тә кызыл булып җилфердәүче флагны абайлап алды.

— Мирсәяфнеке, әйдә шунда, — дип, алга атлады.

... Мирсәяф Мөхсинов белән икенче тапкыр ноябрь урталарында партиянең район конференциясендә очраштык. Ул — совхоз коммунистларыннан делегат иде. Бик ыспай костюм кигән, ак күлмәгенең изүен ачып җибәргән—егетләр кебек. Миңа аның әле генә кырык яшь тутыруын, биш бала атасы икәнен әйткәннәр иде. Бүген аны танымассың да. Хезмәт шулай яшәртә кешене. 1978 елгы урып-җыю алдынгылары турында сөйләгәндә докладчы Мирсәяф исемен дә атады. Аның җитәкчелегендәге алты комбайннан торган звено 2279 гектар мәйданнан 60 мең центнер ашлык суктырып алган. Барлык комбайнчылары да, урып-җыюның авырлыгына карамастан, социалистик йөкләмәләрен арттырып үтәгәннәр. Ә үзе, комбайнга беренче тапкыр утырса да, улы Ленар белән 12.600 центнер ашлык суктырган. Аның фамилиясе ишетелгәч, залдагылар дәррәү кул чапты.

Мирсәяфнең киләчәккә планнары белән кызыксындым.

— Быел авыр булды. Алдагы елда уракка чыгарга исәп тотмыйсызмы?

— Түзеп булмас, — диде ул.

Ул сүзендә торды. Игеннәрнең өлгерүен дүрт куз белән көтте. Дирекция аны тагын звено җитәкчесе итеп куйды. Бу юлы инде Мирсәяф звеносы карамагына алты «Колос» комбайны бирделәр.

Узган уракта ул комбайнын өр-яңадан сүтеп җыйды диярлек — аның ышанычсыз урыннарын да, яхшы якларын да белә. Улы Ленар быел үзенә бер комбайнда чыкты, Мирсәяф үзенә ярдәмчесе итеп икенче улы Данирны алды. Оясында ни күрсә, очканда да шул, ди халык.

Алар тагын җиңде: үзләренең хезмәт елъязмаларына 50 мең центнерны өстәделәр. Иң куанычлысы шул булды: басуда бер учма иген дә калмады, совхоз дәүләткә 56 мең центнер ашлык озатып, быелгы планын шулай ук арттырып үтәде.

**МӨДӘРРИС МОСТАФИН.**



*Мин — Октябрь Норлатыннан. Урта мәктәпне тәмамлагач, укытучыларым: «Казанга укырга кит»,— дигәннәр иде. Түбән Камага киттем. Төзелеш кранында эшләдем. Казанга килеп, университетның тарих-филология факультетын тәмамладым. Хәзер «Азат хатын» журналында эшлим. Хикәяләрне байтактан язам. Укып караган кешеләр ике төрле фикердә. Берәүләр өнәп бетерми, икенчеләре: «Күбрәк яз», — диләр. Язармын, ахры.*

**Фәния Хуҗиәхмәтова**

# ШУЛАЙ БУЛА ИКӘН

хикәя



Авылга мин сирәк кайтам. Туу белән күңелемә язылган ике сүздән торган шул исем поездга утырта да, очраган бер баганага сәлам бирдереп тәүлек ярым әйләндерә-әйләндерә йөртә дә, Таллы Күлгә алып кайта. Әнигә дә, этигә дә ул кадәр якын түгел инде ул авыл. Алар анда килгәннәр дә күпмедер еллар эшләп кенә киткәннәр. Миңа якын, туганнарыма якын. Без бу авылда туганбыз, бу авылның инеш суы белән битебезне юганнар, бәби мунчасы керткәннәр. Шунда башлап тәпи йөреп, зур дөньяга чыгып киткәнбез. Сирәк булса да кайтам мин авылга. Кайткан саен дулкынланам. Нинди үзгәрешләр булды икән? Күз күрмәгән бала-чага и күбәйгәндер инде? Яшьтәшләрем ил хуҗасыдыр?

Картларны әйтәм, кайберәүләре үткән кайтуда ук бәхилләшеп калганнар иде, йөрәкләре сизгән булса, кайберәүләре инде юктыр да.

Авылга кайтып җиткәндә беренче булып зират күренә. Поезд белән кайтсаң да, самолет белән очсаң да авылга туры юлдан, зират

янынпан җәяү керәсе. Алдан ук шуннан үтәсен уйлап, сумка өстенә генә куелган яулыгымны алып ябынам. Кулларны артык селкемичә, икәү булсаң, сөйләшмичә узарга кирәк. Кулларыңны болгый-болгый, каты басып тиз генә үтсәң, мәетләрнең җаны кузгала, диләр. Җаны булгач, ничек мәетләр инде ул? Аларга да тынычлык кирәк, аларны да онытмаска иде.

Болар минем әтием өйрәткәннәр. Җаныма сеңгән, каным белән тамырлардан ага, һичничек оныта алмыйм. Теләсәм-теләмәсәм дә шулай эшлим.

Уйларым үземнән узып авылга йөгерә, җаныма тынгылык бирмәгән бик күп сорауларга тизрәк җавап табасы килә.

— Нәҗия апаның шәле һаман ак микән?

— Җилдән туган Ихласы ниндирәк икән?

— Җәүдәт абыйны үлгән дигәннәр иде?

— Фатыйма апа инде кемнәр белән йөрешә икән? Якын кешесе юктыр авылда, шуңа, күп уйлап тормыйча, өч кызының берсенә китеп бала карый торгандыр.

...Зурлар ни әйтсәләр, шуңа ышанып, сиңә ничә яшь дисәләр, биш бармакны күрсәтеп йөргән чак. Нәҗия апа килеп керде. Әни белән зур якта озаклап сөйләшеп утырдылар. Бүлмә ярыгыннан күземне ала алмый карап тордым. Әни аны озата киткәч, әти кайтып керде, мин кычкырып елый башладым.

— Нәҗия апаны әнилеккә алып кайт, ул да минем әни булсын,— дип еладым. Әти ни эшләргә белмәгән бер кыяфәттә:

— Ник?— диде.

— Аның шәле матур, ап-ак,—дидем.

Шул елны әтием әнигә дә ак шәл алды. Ә миннән:

— Әниеңнең шәле матурмы?—дип сорады.

— Нәҗия апаныкы матуррак,—дидем. Салкыннан алсуланып кергән йөзенә, ап-ак тешләренә, шомырт-кара чәчләренә бигрәк килешә иде шул ак шәле, хәтта әниемнән дә матуррак булып күренгән иде ул.

Минем абыйларым, апам, энем дә бар. Җырлар да күп беләм, әби әкиятләр дә өйрәтә, уйнарга дусларым да күп. Өч йорт аша гына Ихлас тора, ул үзе генә. Никтер аны малайлар яратмый. Урамга чыгар хәле юк, «җилдән туган, җилдән туган» дип үртиләр. Бервакыт әнидән: «Мин нәрсәдән туган?»— дип сораган идем, ул: «Сине чәчәкләр арасыннан таптык, энеңне әтиең бәкедән алып кайтты»,— диде.

— Ихласны каян?

Әни дәшми.

— Җилдән алып кайтканнармы?—дим.

Сорашырга ярамый, ахры, әни ачулана. Күрше әбидән дә сорап караган идем.

— Күп белмә, тиз картаерсың,— диде.

Ихласны уенга кертмәгәч, мин дә кызлар, малайлар белән уйнамыйм. Безгә анысы — икәү дә күңелсез түгел. Көндез еш кына куян тотарга йөрибез. Бер көнне шулай икебезгә дә бик каты эләкте. Авылдан ерак киткәнбез дә, арыганбыз, аннан ятып йоклаганбыз. Бөтен авыл белән төн буе эзләгәннәр. Шушы көннән Нәҗия апа Ихласның уенчык мылтыгын алып яшергән дә, башка күрсәтмәгән. Мылтык булмагач, ничек куян тотасың ди — урманга бару да куркыныч.

Ихлас урамга беренче чыкса, безнең тәрәзәгә килә дә:

— Тамчы там, тамчы там...— ди. Тагын әле ул мине Кояш дип атый, мин аңа Ай дим. Кызлар — Кояш, малайлар — Ай...

Беркөнне шулай:

— Әйдә, тизрәк, бер нәрсә күрсәтәм, — ди, үзе тирләп-пешкән. Әби бер вакыт Ихласның да, минем дә исемне кертеп табышмак әйткән иде. Менә ул:

Матур кыз суга бара,
Беләзеге төшеп кала.
Ай күреп кала,
Кояш төшеп ала.

Озак уйласак та, җавабын таба алмадык. Ихлас үзем табам дигән иде. Әллә шуны тапкан микән?

Тотыныштык та су буена йөгердек. Ул шундый ашыга, әйтерсең пароход килгән дә, шуны күрми калабыз. Җилдәй тиз йөгерә, мин көчкә җитешәм. Яр буена җиткәч туктады да:

— Ант ит! Ихласның әтисен күргәнемне беркемгә дә әйтмим, әйтсәм — телем корысын, әпәй орсын, җир йотсын, дип әйт, ди. Ул нәрсә әйтсә, мин, ихтыярсыз, шуны кабатлыйм. Ярдан түбән төшсәк — исем китте. Инеш суы уйный-уйный дәфтәр бите кебек тигез иткән ком өстендә бик зур ат күрәм.

Ихласның элек тә күп рәсемнәр ясап күрсәткәне бар иде. Ләкин мондыйны, председатель Замир абый җигеп йөри торган «Алмаз» төсле атны беренче күрүем. Ялларына нык ябышып бер абый утыра. Мин сокланудан тынсыз калып тик торам. Ихлас теге абыйның итекләреннән сыйпый, ишетелер-ишетелмәс кенә «әти» дип пышылдый.

Аның тавышы тынлыкны чайпалдыра. Аннары миңа борылып:

— Таныйсыңмы, бу минем әти! Җилдән җитез атына утыртып мине дә урам әйләндергәне бар, — ди.

Мин кызыгып та, көнләшеп тә:

— Ихлас, әйт әле әтиеңә, мине дә бер утыртсын! — дип ялынам.

— Сине утыртыр, башка малайларны утыртмас, чөнки алар мине әтием юк, дип үртиләр...

— Соң син аларны әтиеңә әйт.

— Әләкләшергә ярамый. Әни шулай ди.

Ул көнне беренче тапкыр бәбкәләрне сакламадым, алар инде үсеп үзләре генә йөрерлек булдылар. Аларга да, миңа да ирекле көннәр башланды. Төштән соң Төбәктән куе болыт килеп каты яңгыр яуды. Казларны эзләп су буена барган идек, тагын исебез китте. Ихласның әтисен аты-ние белән бергә яңгыр суы агызып әллә кая алып киткән. Юк, юк Ихласның әтисе. Башка булмаячак та. Дустымның бер дә елаганын күргәнем юк иде, ул сулкылдап елап җибәрде. Минем дә елыйсы килде, кызгансам да, күзләремнән яшь чыкмады. Елый алмау тагын да авыррак икән. Аякларны суга тыгып, басмада бик озак утырганбыз, ахры, әни эзли төшкән. Шуларны сөйләргә дип авызымны гына ачкан идем, Ихлас бик каты итеп чеметеп алды. Ихлас та минем кебек югалып калса, аңа биргән антымны бозып, харап булган булыр идем.

Уракка төшәр алдыннан әни ипине гел бәрәңгедән генә диярлек пешерә. Табак тутырып бәрәңге уа да шуңа учлап-учлап санап кына он куша. Менә хәзер дә җилпучны кага-кага он җыйды. Иләгәнен карап тордым да:

— Әни, ник иләп торасың, барыбер бөтенесе төшеп бетә бит,— дим.

Әни:

— Мин гомерем буе он иләүче булып эшләр идем, — ди. Ул үзе укытучы булып эшләде, эшен бик ярата иде.

Җәүдәт абый керде. Әти белән газета кисәге ялый-ялый тәмәке төреп озак сөйләштеләр. Ул тракторчы, безгә бик еш керә.

— Синең, Фатыйх, киләчәк алда. Улларың үзе бер колхоз, бер дә борчылма, әллә кемнәр булырлар әле,—ди. Үзе бер сүз әйтә дә уфтана. Ник алай сөйли икән? Аннан тын калып торды да: — Фатыйх дус, хатыннан яшереп кенә бер биш чиләк арыш кертеп куйыйм әле. Янасы өлгергәч тә алып чыгармын.

— Җәүдәт, килешмәгәнне кыланма, Фатыйман ни әйтер?

— Үзең сорамыйсың, мин ничек тә әйтергә белмим, җаен тапмыйм. Иртән көтү куганчы тутырам да кертәм, турыдан, бакча аша гына. Миндә барыбер икмәк кадерен белмиләр. Бүген әнә, кибет янында Фатыйма оялмыйча нәрсә әйтеп тора ди бит. Мичтән түгәрәк ипине алам да, турыдан гына тавыкларга тәгәрәтеп җибәрәм. Мул чакта ак ипи ашаучылар белән йөрешәм, ярлы чакта ачлар да ярар, дип әйтеп әйтә, ди. Мин дә яшим инде. Нәселемне сакларга бер улым да юк, булганы — үземнеке түгел, Наҗиянеке.

Мин шул вакыт, нәрсәдер аңлагандай, сискәнеп киттем. Кичке салкын үзен сиздереп куйды. Үзем дә белмичә бик каты төчкереп куйдым.

— Сабый бала төчкерүе дөрескә була,—диде Җәүдәт абый. Әти исә мине йокларга куып кертте. Сүзләрен башка тыңлый алмадым. Тыңлыйсы калган, бик калган икән. Хәзер инде кем бар да, кем юк.

Мин еш кына бер төш күрәм. Сөенечле-шатлыклы көннәремдә бер дә үзгәрмичә гел шул төш кабатлана: Маяковскийга да, Алып батырга да, Җәүдәт абыйга да охшаган бер абый, безгә, бала-чагаларга, ап-ак күмәч тәгәрәтә. Йөгерә-йөгерә ак күмәч тотабыз. Тотабыз да чишмә суына манып, рәхәтләнеп ашыйбыз...

Авыл үзгәргән. Йортлар матур, урамнар киң, кешеләр һаман шул — бөтенесе танышлар. Наҗия апа элеккечә үк матур. Күңелемдә беренче тапкыр матурлык, соклану хисе уяткан кешегә туйганчы карап тордым. Шәле һаман ап-ак, бите һаман алсу. Гомер буе иген иккән. Әби белән бабасы узган елда үлгән. Наҗия апа аларны гел үзе тәрбияләгән. Утыздан узгач, бер малай табып үстергән. Бергә куян куып йөргән дустым Ихлас, хәзер инде председатель — аның малае.

Ә менә Җәүдәт абый кинәт кенә вафат булган. Яхшы күңелле кеше иде, гүргә иңдерергә әтием үзе төшкән, авыр туфрагы җиңел булсын.

Кайткан-кайткан инде, тагын кайчан кайтылыр әле дип, иртәгә китәсе көнне генә, бүләккә биреләсе иясез яулыкны алып, Фатыйма апа янына да кереп чыктым. Ул да ак шәл ябынган, ләкин бер дә килешми үзенә. Кызлары чыннан да читкә китеп беткәннәр. Бик чакыралар ди. Вакыт-вакыт бик китәсе килә икән авылдан. Наҗия Ихласы булмаса, әллә китәр дә идем, ди Фатыйма апа. Көе-моңы — койган да куйган Җәүдәтем. Аяк атлавына хәтле әтисе. Кәефе бик әйбәт булганда, төнлә турыбыздан акрын гына җырлап уза. Тавышы тынганчы тыңлап торам.

Җырлыйдыр Ихлас, кәефе дә әйбәттер, бу көннәрдә бигрәк тә. Иген үстерә ул, колхозны җитәкли.

Фатыйма апа сөйли дә сөйли. Мин аның бик күп сүзен ишетмим дә кебек. Бала чагым ул сөйләгәннәр белән бергә бутала. Төшемдә безгә таба ипи тәгәрәтүче кеше — Җәүдәт абый икән. Атка атландырып комга Ихлас ясап куйган кеше дә —ул. Фатыйма апа чәй эчәргә кыстый. Мин аның мичтән алып тавыкларга ипи тәгәрәткәнен күз алдыма китерәм. Кинәт бала чактагыдай өзелеп ашыйсым

килеп китә. Яратмыйм икән бит аны, күрәлмыйм. Бүләккә яулык тоткан булып нигә килеп кердем соң әле монда? Сугыштан соңгы авыр, бер телем ипине дүрткә бүлгән елларда нигә ул тавыкларга бусага аша ипи тәгәрәткән? «Чәй эчик?» диме? Юк, анысы булмас.

— Эчеп тормыйм, Фатыйма апа, рәхмәт,—дип урынымнан кузгалам.

Наҗия апа янына кереп тагын бер сөйләшеп утырам әле, тәмләп чәй эчәрбез. Шулай була икән ул. Авылдашлар бала чакта күңелгә ничек кереп калсалар, хәтердә һаман шулай саклана, еллар гына үзгәртә алмый икән аны.

## Флюра Низамова



*1953 елда Башкортстанның гүзәл табигатьле Кыдаш елгасы буенда — Ярмәкәй районының Иске Шах авылында туганмын. Биектау чишмәләренең, Бүләк урманнарының серле моңы кечкенәдән үк күңелемә сеңә барды — җыр-моңга, шигъриятькә бала чактан гашыйкмын. Поэзиягә аңлы мөнәсәбәтем Чаллы төзелешендә эшләү һәм Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә уку дәверендә ныгып формалашты.*

*Үземдә иң элек күрергә теләгән сыйфатларым — эчкерсезлек һәм гражданлык. Классиканы һәм бүгенге көн шагыйрьләрен өйрәнәм. Чордашларымнан Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт иҗатларын яратам дисәм, башкалар үпкәләмәс, шәт.*

●

Кояш нурын эчәр өчен көннәр җитми.
Гүзәллекне иңләр өчен күзләр җитми.
Җирнең ямен җырга салып мактар өчен
Хисләр күп тә, бераз гына сүзләр җитми.

Бәйрәм булса, аллы-гөлле күлмәк җитми.
Гашыйк булсаң, белдерергә йөрәк җитми.
Бергә булсаң, тик бер җылы сүзе җитми,
Аерылсаң, китек җанга терәк җитми.

Дусларыңда ялгышмаска акыл җитми;
Иске акыл яңа көнгә тагы җитми.
Тәҗрибәләр килә соңга калып кына —
Яңа баштан башлар идең — яну җитми.

Җитми вакыт — ае җитми, көне җитми,
Вакыт чиген тартып-сузып йөгер — җитми.
Яшәү дигән бу давыллы хәрәкәттә
Үз-үзеңне табар өчен гомер җитми.

●

Чукый да чукый күгәрчен,
Зәңгәр бозны тишмәкче;
Боз астында ялтыраган
Җимне эзләп төшмәкче.

Туктама гына, кошкаем,
Җитәрсең җимгә тиздән!

Үземнең дә күңелемә
Йөрүем азык эзләп.

Күгәрченем, минем дә бар
Томшыктан каннар тамган...
Бозлар чукып, ташлар ватып,
Хакыйкать эзлим җанга.

## Табыну

Мин генәме табынучы
Тик берәүгә дөньяда!
Минем кебек иләсләнеп
Янучылар күп алар.

Тик минем табыну үзгә,
Тик минем денем башка.
Сәҗдә кылмыйм,
Мәҗүсиләр
Табынгандай Кояшка.

Табынам үзем тапканның
Иң асыл җәүһәренә;
Баш идерә алган көчнең
Җаныма тәңгәленә.

Меңнәрне каратучылар
Дөнья хәтле булса да,
Рухымны рәнҗетәсем юк,
Кемнәндер түбән санап.

Синең хәтта Кояшкача
Алып менгән җырларың —
Күңелемнең үзем ачкан
Бер бөеклеге бары.

Горурлан:
Табынам сиңа,
Илһам бирүче Аллам!
Тик онытма —
Аллаларны
Мин үзем сайлап алам.

●

Хөрлек кирәк, имеш, сиңа,
Чикләнмәгән ирек.
Яратасың. Җаныңны шул
Ирексезли кебек.

Аһ, бу җепнең-бәйлелекнең
Миндә икән очы.
Өзәр идең, очар идең —
Җитми генә көчең...

...Яратасың. Җаныңны шул
Ирексезли кебек.
Юк, теләмим андый сөю.
Сиңа миннән — ирек,
Сиңа миннән — ирек!

●

Үпкәләмим сиңа. Кирәк түгел.
Үпкәләүдән өстен акыл бар;
Синең язмыш —үзең язган язмыш
Сыймаса да гәрчә акылга.

Үпкәләргә мөмкинмени ташка,
Бәгырьсез дип аны гаепләп?!.
Сөйгән булмаса да, яр тапкансың —
Уңышыңа, әйдә, кәефлән!

Уйна да көл. Тук һәм рәхәт яшә,
Томалап куй бар вөҗданыңны.
Үпкәләү юк. Тик аз гына җәллим
Үлә барган мескен җаныңны...

●

Син китергән ачы әрнүләрем
Көннән-көнгә һаман ташый торды.
Рәнҗешләрем төенләнде бүген,
Бәгыремә бүген таш утырды.

Кайчан гына сырхау күңелемә
Иң шифалы дару булалырсың? —
Юк, соң инде,
Хәзер көннән-көнгә
Мине дәваларга соңарырсың.

Синең янда гына йөрермен күк,
Кул сузымы кадәр җирдә генә.
Тик син түгел, башка берәү килер,
Сихәт булып талган йөрәгемә.

...Соңарырсың. Чабып килерсең бер,
Рәнҗеш ташын теләп эретергә:
Ул көн булыр минем кояшлы туй,
Соңгы соңаруың — нәкъ бер көнгә...

●

Иң авыры димим бу елымны,
Каһәрләмим әле, —
Я дәгъвәләп килер икәү кичкән
Бәхет мизгелләре.

Иң ачысы димим бу яшьләрне,
Туеп яшәвемнән, —
Оят булыр күкрәгеңә тамган
Шатлык яшьләремнән.

Иң әрнүле димим бу язмышны,
Тиңләп кара төнгә, —
Я хыянәт булыр син кабызган
Якты өметемә.

## Фоат Садриев

# Ә ЕЛГА ҺАМАН АГА...

ХИКӘЯ

Елгада боз кузгалган көнне Әхмәтша картның биле кузгалды. Ә ул бер кузгалса — өч көнсез урыныңнан торам димә. Ишегалдында тырт-тырт сикереп уйнаучы сарык бәрәннәренә карап утырды-утырды да, Әхмәтша карт көч-хәл белән киенә башлады.

— Йөрмә инде, я бөтенләй аяктан егылырсың, — диде карчыгы, аның өчен ут йотып.

Әхмәтша карт дәшмәде. Бөкрәеп билен тоткан килеш, карчыгына бер карап алды да өйдән чыкты.

Тышта күзне ачып булмый, кояш нурлары кадала. Менә ят инде шулай баздагы бәрәңге кебек дөнья күрмичә. Әхмәтша карт кулын каш өстенә куеп, язгы табигатькә текәлде. И-и, әкәмәт, дөнья кайнап тора лабаса. Казлар кыңгылдаша, тавыклар кытаклый, агач башларында, өй кыекларында кош-корт чыр-чу килә. Колак төбендә генә бер бал корты безелди... Тагын кырыкмаса-кырык төрле шатлыклы тавыш, хәрәкәт һәм нур көлтәләре. Шулар һәммәсе бергә кушылып, сабый чактан ук искиткеч таныш, һәр ел сагынып көтеп алынган язгы гөжелдәне хасил итәләр. Аңарда йөрәкне иркәләүче мәңгелек хәят дулкыннары, аңарда яшьлек дәртләре, һәркемне әсир итәрлек бинираһая көч, илһам һәм елмаю... Әллә инде яшь бөре исеннән, әллә йомшак канатлы җил кытыклавыннан, Әхмәтша картның борыны йомшап китте...

Эх, яшь чаклар! Мондый көнне Әхмәтша өйдә ятар идеме соң? Өйалды ишеген дә ябарга онытып, атыла-бәрелә йөгереп чыгар иде дә...

Әхмәтша картның биле әз генә җибәргән кебек булды. Ул гәүдәсен турайта төшеп, капка төбенә чыкты.

Ә урамга чыккач, сиңа бу мәшәкатьле дөньяның берние дә күренми. Шул мизгелдән язның үзенә әверeләсең. Син — челтерәп агучы гөрләвек, син — шул гөрләвектә елтыраучы кояш, син — шаян җил, син — зәңгәр күк, син — шул күктә очар кош. Әллә кай арада иптәш малайлар җыела, китә шау-шу, китә бәхәс, китә сикереш-чабыш. Шау-гөр килеп — өйдә елга буена.

Әхмәтша карт тыкрык буена җиткәнен сизми дә калды. Ни гаҗәптер, хәле җиңеләеп киткәндәй булды, адымнары ешая төште

кебек. Ул арада күзләрен чагылдырып елга күренде. Яр буенда халык шактый. Елга ярларыннан чыгарга җитеп ташыган, җәелгән... Ул ага да ага. Суларга ятып бозлар килә. Берәүләре зур, берәүләре кечкенә. Бәрелешеп ватылалар.

Әхмәтшалар бәләкәй чакларда да гел шулай иде. Ярның әнә теге сөзәк урыннарында ул заманнарда да яшь таллар үсә иде. Учларына, кесәләренә тал песиләре җыярлар иде дә, кемнеке күпме икәнен санарлар иде. Аннары чабаталарны салып бәрәләр, китә төрле уен: шәмәйле дисеңме, кәллүкле, кәшәкәле, чыгырлы дисеңме — берсе дә калмас иде. Ашау-эчү онытыла. Табан аслары кичкә ут булып яна. Чебиләгән кул-аякларны көч-хәл сөйрәп, эт булып арып кайтып авасың.

Ә инде үсеп егет булгач, су буйларының бөтенләй башка, кичке сихри серләре ачылды. Язлар җитеп, ашъяулык кадәре кара җир күренү белән, авыл яшьләре кача-поса шунда җыелалар иде. Карлар китеп, беренче яшел үлән борын тəрткәч, агачлар балавыз яшел төс ала башлагач, су буена чыгучы егетләр-кызлар күбәя, кичке уеннарга ямь өстәлә. Әхмәтша күптән күзе төшеп йөргәненә — Бибигайшәгә шушында беренче сүз катты. Их, ул чаклар!.. Бибигайшәнеке кебек орчыктай бөтерелүче җиңел нәфис сын, нечкә бил, шаян нур сибеп торучы зур шомырт күзләр тагын кемдә бар иде икән авылда? Булмагандыр. Шуның өстәвенә Бибигайшә кашгарый таҗы төсле ап-ак тигез тешләрен күрсәтеп елмая-елмая да егет-җиләннең һушын ала. Әхмәтша да төшеп калганнардан түгел иде түгелен. Дөрес, ир-ат хатын-кыз кебек күз камаштырырлык чибәр булмый инде ул, шулай да аның алыптай җилкәсе, озын буе, дәрт һәм тәвәккәллек сирпеп торучы киң маңгае кызларның күзен шактый вакытка туктап, төбәлеп калырга мәҗбүр итә иде.

Кыскасы шул: бер көнне кичке уенда Әхмәтша Бибигайшәгә якынайды да колагына: «Дөньяда бер фәрештә бар, төшләремә кереп йөдәтә», — диде. Тегесе көлде. Икенче көнне Әхмәтша гел аның тирәсендә бөтерелде, тагын бер көн үткәч, үзенең кечкенә энесе артыннан мәхәббәт хаты язып җибәрде. Шул көнне кичке уеннан соң алар икесе төбеннән яшь үсентеләр чыккан менә бу өянке янында бик озак тордылар. Шушындый ук җилле яз иде, көмештәй тын иде ул кич. Боз киткән, су буенда бакалар бәйрәм ясый, җыр суза, тавыш бирә. Җитмеш җиде төрле кош сайрый. Кайдандыр елгага шопырдап су төшә. Өянкенең әле сагыздан да арынып бетмәгән саргылт-яшел яфраклары арасыннан айның көмеш нурлары коела. Дөнья яшь үлән, яфрак һәм кайры исе белән тулган. Һәм шул чакта Бибигайшәнең нәни генә йомшак куллары синең учыңда...

— Гайшә, син минем хатымны алдыңмы?

— Әгәр алмасам? — ди ул мут елмаеп.

— Алдың бит, я, әйт инде? — ди Әхмәтша чын күңелдән.

— Әгәр алмаган булсам? — Кашгарый таҗлары тагын да ныграк ачылды.

— Алмаган булсаң, хатта язылганнарны үзем сөйлим!

— Алмадым, сөйлә, — ди Бибигайшә, өянкенең кытыршы юан кәүсәсенә аркасы белән сөялеп. Үзенең ике бит очын ай үбә. Әхмәтша нишләргә белми. Аның йөрәгенә ут каба, аңа эссе.

— Гайшә. Дөньяда миңа син... синнән башка... — ди ул тотлыгып һәм аның беленнән кочакламакчы итә. Ләкин Бибигайшә «ялт» итеп өянкенең икенче ягына чыга һәм кәүсә артыннан аның:

— Ышанмыйм, алдыйсың, — дигән сүзләре ишетелә.

— Ышанмыйсың?

— Ышанмыйм.

— Ышанмасаң... хәзер суга сикерәм.

— Һи, булмасны.

— Булмасмы?!

Шулай диюгә ярдан түбәнгә оча. Бибигайшә «ах» диярго генә өлгереп кала. Әхмәтша күкрәк авызыннан салкын су ерып чыга. Чыгу белән Бибигайшә аны муеныннан кочып ала һәм кайнар иреннәре белән суырып үбә. Туңуын онытып, кызып киткән кебек була егет. Кызның йомшак иреннәре, кайнар сулышы кагылуга ул оеп ук китә. Күзләрен ачса, Бибигайшәдән инде җилләр искән була. Аның ерактан, тыкрык башыннан ук «ышанды-ы-ы-мм» дигән нәфис тавышы гына ишетелеп кала.

...Әхмәтша карт елмайды һәм башын селкеп куйды. «Яшьлек юләрлек — исәпләсәң үләрлек» дип бик дөрес әйткән шул борынгылар. Менә бит ярның ул сикергән җире. Ике метр гына бик бар. Мәхәббәт исереклегеннән дә татлырак тагын нәрсә бар икән бу дөньяда?... Җиһанда икәүдән-икәү генә каласың.

— Мине айга менгер, — ди шул чакта Бибигайшә.

— Күзләреңне йом.

Бибигайшә йома. Әхмәтша аны биленнән тота да башы тал яфракларына тигәнче күтәрә. Аннары «тып» итеп җиргә бастыра һәм маңгаеннан үбеп ала.

— Без айда, җаным. Тагын ни боерасың?

— Зөһрә кызның көянтә-чиләкләрен китер.

Бибигайшәнең иңсәсенә Әхмәтша каяндыр табып бер талчыбык сала.

— Ә хәзер йолдызларны чиләкләргә чүплик.

Һәм алар юк чиләкләргә күктәге йолдызларны көлешә-көлешә «җыялар». Аннары икәүләп тагын «җиргә төшәләр».

— Әйдә бу йолдызларны үзебезнең уртак җиргә чәчәбез, — ди Әхмәтша.

Кулларын, тубалдан орлык чәчкән төсле, колачлап-колачлап селтиләр, бөтен дөнья көмеш тамчыларга күмелгәндәй тоела, икесе дә куанышалар...

— Бу йолдызлар үсеп кояш булгач, барысын да кабат урыннарына элəрбез, ямe, Гайшә?

— Һәм җир йөзе як-якты булыр, төн бөтенләй юкка чыгар. Кешеләр безнең икебезгә рәхмәт әйтерләр.

Һәр кичне шулай нәрсә дә булса уйлап чыгаралар иде. Печән өсләре җиткәч, Әхмәтша чәчәкләр алып килә башлады. Әти-әнисеннән, абыйларыннан кача-поса гына җыя, күлмәк эченә салып алып кайта да, кичен Бибигайшәгә бирә, ә Бибигайшәнең башы күккә тия. Ул чәч толымнарына, алкаларына, беләзекләренә чәчәкләр беркетә, Әхмәтшаны да чәчәкләр белән бизи.

Алар бу җәйдә шул кадәр якынаештылар ки, бер-берсен күрми торган сәгатьләре әйтеп бетерә алмаслык сагыш, көтү, юксыну белән тула иде. Алар җырның өзәргә, аерырга ярамый торган төп моңына әверелделәр.

Ләкин үтә кайнар мәхәббәтнең ялкын очы күпләрне көйдерә, шуңа күрә аның дошманы да күп. Мәхәббәтнең баш очында гомергомергә күсәк уйный, аның барыр юлына тирән упкыннар казыла, тирә-юненә биек киртәләр тотыла. Бу юлы да шулай булды. Беркөн шулай Бибигайшә кичке уен беткәндә генә чыкты. Әхмәтшаны читкә чакырып алды. Өянке төбенә җиткәч, егетнең күкрәгенә кайнар маңгаен куйды да үксеп җибәрде.

— Безгә бергә оя кору насыйп булмаган икән лә, Әхмәтша.

Әхмәтшаның йөрәгенә пычак кададылармыни. Ул авыз ачып бер сүз дә әйтә алмады, бары тик Бибигайшәнең яшьле күзләренә генә төбәлде.

— Эти мине Хәким байның олы малаена ярәшкән. Иртәгә килен итеп төшерәләр. Тәрәзәдән качып кына чыктым...

Әхмәтшаның күз аллары караңгыланып китте, йөрәге туктап калгандай булды. Бибигайшәнең кайнар яшьләре аның күкрәген чылатты. Әхмәтша аны юата да алмады, йөрәге әйтерсең ташка әверелде...

Нидер эшләргә, ашыгырга, ашыгырга кирәк иде.

— Әйдә, — диде Әхмәтша, Бибигайшәнең кулыннан сөйрәп.

— Кая?

— Белмим.

Тыкрыктан йөгереп кайттылар. Әхмәтша үзләренең сараена кереп, җилән белән эшләпәсен киеп чыкты. Аннары Бибигайшәне ындыр артындагы печән чүмәләсе янына утыртты да үзе юк булды. Чирек сәгать чамасы вакыт үтүгә, сөлек кебек туры айгыр җитәкләп килеп тә җитте.

— Ах, Хәким бай аты ич бу!

Әхмәтша аның авызын каплады: шаулама! Атландылар да очтылар.

Иртәгә чаклы илле-алтмыш чакрым җир үтелде. Кая барганнарын белмиләр, тик шунысы ачык: мөмкин кадәр ераккарак качарга, бер-берсеннән аерылмаска кирәк иде аларга. Юлга чыгуларына атна-ун көн дигәндә көтелмәгән хәбәр — революция, хөррият чыкты. Байларга каршы эш икән дигәч, шул юлдан киттеләр. Шуннан уртак тормыш башланды. Гражданнар сугышы килеп ялганды... Яраланулар, аерылулар, яңадан бер-берсен табу куанычы, егерме беренче елны авылга кайту...

Әхмәтша карт күзләрен елганың аргы башына ук төбәде дә сын кебек хәрәкәтсез калды. Аның йөзендәге тирән җыерчыклар кояш нурларында яктырып китәләр, аларның һәркайсы бер тарих сөйли кебек...

...Гомер диген. Авылда төпләнгәненә ничә еллар үтте. Җиде баласы үсеп җитеп кеше булды. Хәзер инде бу елга буйларында оныкларының балалары йөри, әлеге өянке төбендә кайнар пышылдашалар, айга менәләрдер, йолдызлар чүплиләрдер.

— Әхмәтша, авырган көе ничек монда кадәр килдең, эзли-эзли аһлар иттем.

Бибигайшә тавышы бу. Әхмәтша карт көлемсерәп аңа таба борылды.

— Чир китте, эзе дә калмады, — диде ул.

Аннары карчыгы Бибигайшәгә текәлеп карап торды. Үзгәргән шул Бибигайшә, үзгәргән...

Әхмәтша карт карчыгына якын ук килде һәм кайнар итеп колагына пышылдады:

— Гайшә, иртәгә үк район үзәгенә барабыз.

— Ни булды, карткаем? Хәлең бик авырайдымы әллә?

— Сиңа теш куйдырабыз. Көмештән. Ә чирнең, әйттем бит, эзе дә калмады. Әллә ышанмыйсың?

Ул «дөп» итеп җиргә тибеп куйды һәм яр кырыена ук килде.

— Ышанмыйсыңмы?

Әхмәтша картның күзләрендә дәрт, тәвәккәллек уйный, Бибигайшә әбинең бәгырен яндырып ниндидер таныш дулкын үтте.

— Ышанмыйм.

— Ышанмасаң, хәзер суга сикерәм.

Әхмәтша картның шулай дию булды, карчыгының аны килеп кочаклавы булды. Ышан син ул тәвәккәл башка, тотар да сикерер...

Елга буендагыларның күбесе аларның бу сәер кыланышын аңлап җиткерми иде. Бары тик елга гына аларны аңлый, һаман ага да ага...

# ЛАЧЫН ЙӨРӘКЛЕ ЕГЕТ



Аннан соң совет халкының фашистлар Германиясен җиңүенә инде утыз елдан артык вакыт узды. Әмма изге яу кырында иңгә-иң торып көрәшкән полкташ дусларымның исемнәре күңелемдә әле һаман җуелмыйча саклана. Алар арасында татар халкының Сәлим Садыйков, Асылгәрәй Бәхтиев, Шәкүр Шәйдуллин, Тәүфыйк Яманаев, Мофазад Рәхмәтуллин, Мөхәммәт Мөхәммәтҗанов, Александр Закурин, Фалей Сәгыйров кебек куркусыз уллары да бар иде. Мин бу язмамда Мәскәү яныннан алып Прагага кадәр авыр сугышчан юл үткән шундый дусларымның берсе — Сәлим Садыйков турында сөйләмәкче булам.

Сәлим яшьтән үк очучы булырга хыяллана. Һәм көннәрдән бер көнне бу хакта ул әнисенә дә турыдан-туры әйтеп сала:

— Әни, мин очучылыкка укырга китәм.

Бу сүзләрне ишетүгә, ана, ни дияргә дә белмичә, каушап-аптырап кала. Сәлим аны юатмакчы була. Ләкин бу уеннан шунда ук кире кайта. «Кирәкми,— ди ул үз-үзенә,— ихтыяр көче зур анда. Ул мине болай да аңлар...»

Унсигез яшендә Сәлим Садыйков аэроклубны тәмамлап чыга. Ләкин сугыш вакытлыча чигенүче хәрби частьләрне каплап тору, шәһәр һәм авылларны дошман авиациясеннән саклау, совет кешеләренә күбрәк самолетлар, танклар җитештерергә, хәрби техниканы үзләштерергә мөмкинлек бирү өчен очучы-истребительләр сорый. Моны комсомолец Садыйков та яхшы аңлый һәм ул үзен очучы-истребительләр хәзерли торган мәктәпкә укырга җибәрүләренә ирешә.

Аны тәмамлагач, Сәлим Садыйков илбасарларны Мәскәүгә үткәрмәс өчен көндез дә, төнлә дә әледән-әле һавага күтәрелә, дошман белән күзгә-күз очраша, аларның самолетларына күп тапкырлар һөҗүм итә. 1942 елның 15 январенда Наро-Фоминск янындагы Калинское авылы тирәсендә фашистлар аның самолетын бик каты зарарлыйлар, очучы үзе авыр яралана. Баштанаяк канга баткан Сәлим үз территориябездәге ориентирны эзли, ләкин аны һич кенә дә таба алмый. Ул штурвалга тагын да ныграк тотына. Бу вакытта инде аның аяклары һәм бер кулы бөтенләй диярлек хәрәкәтләнми, ә икенче кулының бармаклары кара янып чыга. Әмма Садыйков бирешми. Ничек кенә булса да, машинасын идарә итәргә тырыша...

Юк, ялкынга уралган самолетның нәкъ менә шушы мизгелдә шартлавын көткәндә түгел, машинасын үзебезнең окоплар өстенә алып чыккач беренче тапкыр шул кадәр яшисе, яшисе килә Сәлимнең! Һәр секунд озын бер гомер булып тоела. Ул башы белән бортка бәрелә. Маңгаена, битенә металл салкынлыгы йөгерә, бераз җан



кертеп җибәргәндәй була. Ул, тыны беткән хәлдә, самолетны төшерү өчен уңайлы урын эзли. Һәм көтмәгәндә... карлы алан. Үз күзләренә үзе ышанмыйча:

— Җиңү! — дип кычкырып җибәрә ул. Самолет зур тизлек белән җиргә якынлаша. Аннан, агач башларына чак-чак кына бәреләсугыла, бер канатын янтайта да җиргә төшеп туктап кала...

Шактый озак һушсыз ятканнан соң күзләрен ачып җибәрүгә, Сәлим үзенә иелгән ике кызылармеецны күреп ала. Берсе аны иңеннән селки, икенчесе, җиргә тезләнеп, су эчертергә тели... Менә ул бер йотым су каба һәм терсәкләренә таянып калкынмакчы була.

— Кузгалма, кузгалма,—ди аңа су эчергән кызылармеец. — Нейтралкадан сөйрәп алып чыктык үзеңне...

Аннары госпиталь тормышы башлана.

— Мин кайчан да булса очарга яраклы хәлгә килерменме? — дип сорый Садыйков врачлардан, аларның күзләренә моңсу бер өмет һәм инәлү белән карап.

—Әлбәттә, тырышачакбыз!

Ниһаять, медицина комиссиясе көне килеп җитә.

— Я, ничек, сержант, сугышка әзерме? — дип сорый аннан полковник, шаян елмаеп.

Сәлим аңа һич нинди икеләнүсез җавап кайтара:

— Шушы минутта ук очышка әзер, иптәш полковник. Күктән башка минем өчен тормыш юк.

— Хәрби хезмәттән сез бөтенләйгә азат ителәсез...

Татарстан комсомолы вәкиле монда да медицина комиссиясеннән көчлерәк булып чыга. Ул үзен танк частена җибәрүләрен үтенә. Шулай итеп, Сәлим Садыйков танкист-техник квалификациясен үзләштерү теләгенә 1942 елда ирешә.

Аны тагын бер уңышсызлык көткән икән: яралар үзләрен бик нык сиздерә башлыйлар. Аяк һәм куллар авыр хәрәкәтләнә. Бер күзенең начар күрүе өйрәнү кырларында дөрес юнәлеш алырга комачаулый. Механик-йөртүче урындыгына утырган килеш ул, үзен тынычландыру өчен, маңгаен салкын броняга терәп торырга мәҗбүр. Андый минутларда Сәлим берни турында да уйламый. Инструктордан аның нәрсә хакындадыр сорыйсы да килә — кыюлыгы җитми.

Көннәрдән бер көнне инструктор үзе сүз башлый:

— Минем бер соравыма җавап бирә алмассызмы?

— Тыңлыйм сезне.

— Уңайсыз хәлдә калдырмассызмы мине, сержант?

Инструкторның тавышында Сәлим үзенең көченә ышанып җитмәү кебегрәк нәрсә сизеп ала. Аның маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәреп чыга. Ә курсларда инде укулар бетәргә санаулы гына көннәр калып бара. Сәлимнең сулышы кысылгандай була. Аннары ул, үзен кулга алып, чәчләрен сыпырып куя да малайларга хас беркатлылык белән:

— Мин бит комсомолец, иптәш инструктор, — ди.

— Яхшы,— дип күз кыса аңа инструктор.— Бертуктаусыз физик күнегүләр ясарга кирәк сиңа.

— Бөтенесен сез кушканча эшләрмен, иптәш инструктор!

Һәм ул әйткән сүзен җилгә очырмый. Буш вакытының һәр минутын физик хәзерлеккә багышлый. Занятиеләрдә дә аяк-кулларын, бөтен организмын ныгытуга һәм чыныктыруга ярдәм итәрлек эшләрне икеләтә көч белән башкара. Копанир казыганда исә, кем әйтмешли, экскаватор кебек эшли. Көрәк белән тәүлегенә уннарча кубометр балчык ыргыта, яна-пешә, башкалардан калышмаска, кимхур булмаска тырыша.

Копанир әзер... Аның түбе бильярд өстәледәй тип-тигез. Бер генә дә чокырлы яки калку урын күрмәссең.

— Егет икәнсең, Садыйков!— дип мактый аны инструктор.

Шундый тырышлыклары аркасында Сәлим Садыйков танкисттехниклар хәзерләү курсларын бик яхшы билгеләренә тәмамлап чыга.

1943 елның 9 августында Смоленск өлкәсенең Повлиново станциясе янында Садыйков өчен икенче зур сынау башланды. Танкисттехниктан үзйөрешле установка техникасына ул инде үзе дә өйрәнергә, башкаларны да өйрәтергә тиеш иде. Кичәге яшүсмерләрне «СУ-76»ны йөртергә генә түгел, сугыш барышында аның белән тиешенчә идарә итәргә өйрәтү өчен дә аңа күпме нәрсә белергә кирәк! Карбюратор, акселератор, фильтрлар, ягулык һәм тормоз системалары, аккумуляторлар... Батарея командирының техник частьләр буенча ярдәмчесе һәм механик-йөртүче белергә тиешле нәрсәләр санап кына бетерерлекмени?

Экипажның башка членнарыннан аермалы буларак, механикйөртүче күп кенә очракларда дошманның хәрәкәт итү тактикасын һәм көчен үзе күрми, экипаж командирының командаларын гына үти. Ә моның өчен физик көч һәм командаларны үтәгәндә җитезлек кенә түгел, сабырлык, түземлелек тә кирәк. Озын маршларда, сугыш операцияләре барышында һәм һөҗүмгә күчү өчен билгеләнгән позицияләрдә озак вакытлар буена установка идарәсе рычаглары артында утырырга туры килә. Экипажны исә моңа командирның техника буенча ярдәмчесе әзерләргә тиеш...

Ике ай эчендә инде 400 чакрымнан артыграк җир узылган. Полкта нибары бер «СУ-76» батареясы калган. Менә шул батареяга һөҗүм вакытында Кастюшко исемендәге 1 нче поляк дивизиясенә ярдәм күрсәтү бурычы йөкләтелә.

Садыйков, йолдызлар сибелгән аяз күк йөзенә люк аша карап, алда торган һөҗүм турында уй йөртә. Алгы позициягә лейтенант Фалей Сәгыйровның беренче үзйөрешле установкасы чыгарга тиеш. Бу установканың механик-йөртүчесе Мофазад Рәхмәтуллин элекке тракторчы... Шофер булып та эшләгән. Фронтта әле беренче генә елы. Сугышчан машинаны йөртә башлавына нибары бер атна. Түзми Садыйков, уйларыннан бүленә дә сорап куя:

— Сынатмассыңмы, якташ?

— Сынатмаска иде исәп...— Сәлим аның җавабын тыңлап бетерергә дә өлгерми, өлкән лейтенант Резниченконың: «Машиналарга!»— дигән командасы яңгырый.

Таң алдыннан күк йөзе кинәт караңгыланып китте, озак та үтмәде, коеп яңгыр яварга тотынды, Рәхмәтуллинга чама белән генә ориентирлашырга туры килде.

...Полякларга каршы дошман тугыз танкын ташлады һәм бөтен сул флангны иңләп алды. Миномет һәм пулемет уты уң флангны да җиргә сыенырга мәҗбүр итте.

— Төп ышаныч сездә, Сәгыйров,— диде комбат радиодан.— Пехотага һөҗүм ит...

Инде менә печән кибәннәренең соңгысы да күздән кичте. Аның артында ялгыз нарат булырга тиеш. Тукта, ни нәрсә бу? Нарат янында ук дошманның ике танкысы. Рәхмәтуллин бар булган көченә тормозларга басты. Бер мизгелгә ул үзенең кайда икәнлеген дә онытты. Снарядлар инде аның кырында ук ярыла. Үлемнән аны секундлар гына аерып тора. «Бетүебез шушымы әллә,— дигән уй йөгереп үтте Рәхмәтуллинның башыннан. Ләкин ул эшнең асылын бик тиз аңлап алды. Юк, ялгышасың! Өлгермәячәксең!..»

Ул артка чигенде һәм машинасын куаклык эченә алып кереп китте. Ләкин немец танкы зарарлаган самоходка хәрәкәтсез килеш бер урында туктап калды. Кача-поса аңа таба дошман пехотасы үрмәли башлады. Экипаж ни хәлдә? Машинага нәрсә булды? Аны коткарырга мөмкинлек бармы? Садыйковны әнә шул сораулар борчый иде. Ул әле комбатның экипажга машинадан чыгып китәргә боерык биргәнлеген белми иде.

Күктә серле ай йөзә. Куаклыктан ишетелгән кыштырдауларда да ниндидер сер бардыр кебек тоела. Садыйков, Митраков һәм Хәсәнов шул авазларны тыңлыйлар. Якында гына танк чылбырлары шылтыравы ишетелә. Дошман танкы зарарланган «СУ-76»га таба якынлашып килә. Менә ул борынын җиргә төртеп, бер мизгелгә тукталып калды, аннары чигенә башлады. Шунда аннан берничә немец төшеп җиргә сыенды. Аларның «СУ-76» ягына үрмәләргә ниятләүләре күн кебек ачык иде.

— Хәсәнов, каплап тор! — дип кычкырды Садыйков һәм үзе, Митраков белән бергә, машинага таба ташланды.

Люктан керә-керешкә, башта ул идарә итү механизмнарын, аннары моторны тикшерде. Болары тәртиптә иде. Ләкин Сәлим магнетоның юклыгын күрде. «Монысы әллә ни зур бәла түгел,— диде ул үз-үзенә.— Башка машинаныкын алып килергә мөмкин». Ләкин шулай уйлавы, әйтүе генә ансат иде. Өч йөз метр араны яңадан түш белән шуышып үтеп, магнето салдырып алып килгәнче аңа шактый азап чигәргә туры килде.

Ниһаять, көтелгән минутлар... Идарә итү рычагларына ике куллап ябышкан Сәлим стартерга басты һәм мотор аваз бирде. Бераздан «СУ-76» дошман пехотачыларының күз алдында акрын гына кузгалып китте. Бу минутта Садыйков бөтен игътибарын алга юнәлткән иде. Кинәт аның күзләре җирдән беленер-беленмәс кенә калкып торган нәрсәләргә текәлде. «Миналар! Алдан хәзерләнеп куелган тозак!» дигән уй йөгереп үтте аның башыннан.

«Машинаны яндырырга! — Ләкин бу фикереннән ул үзе үк кире кайтты: — Җинаять булачак бит бу!..»

Уңда да, сулда да үтә алмаслык сазлык. Гитлерчыларның берсенең дә тавыш-тыны юк. Самоходка беркая да китә алмаячак, һавага очачак дип уйлыйлар, күрәсең. Сәлим тагын берничә минут уйланып торды да катгый бер карарга килде:

— Тәвәккәллибезме?

Сүзнең нәрсә турында барганлыгын анык кына белмәсә дә:

— Тәвәккәллибез,— дип җавап кайтарды аңа юлдашы.

Садыйков машинаны йөз метр чамасы артка чигендерде. Менә хәлиткеч минут килеп җитте. Мотор бөтен көченә үкерә башлады һәм, тизлеген арттырганнан-арттыра төшеп, мина кырына ыргылды. Миналар, берсенди дә зарар китермичә, машина артында шартлап калдылар. Гитлерчылар аңнарына килеп өлгергәнче, Садыйков «СУ-76»ны үзебезнекеләр ягына алып чыкты.

...1943 елның 15 декабренда 1813 нче үзйөрешле-артиллерия полкы, 6 нчы гвардия кавалеры корпусы белән бергә, Рославль районыннан кузгалды һәм сигез йөз километрга сузылган марштан соң Сарны районына килеп урнашты. Полкка дошман тылына үтәргә һәм аның Көнбатыш Украинада төп пунктларыннан саналган Ровно һәм Дубно шәһәрләрен азат итәргә дигән боерык бирелде. Кавалериягә Пинск урманнарын һәм сазлыкларын кичү кыен иде, самоходчы-артиллеристлар дошман тылына ике йөз километр үтеп, Дубно районына килеп чыктылар.

Дубно шәһәре көнбатышка — Львовка илтә торган юллар чатына урнашкан. Иква елгасының текә ярында бик биек булып иске крепость утыра. Ул чәнечкеле тимер чыбыклар белән әйләндереп алынган. Дубноны траншеялар, тирән чокырлар ураткан, шәһәргә һәм аңа бару юлларына күп санлы орудиеләр куелган. Биредә Львов шәһәрен каплап тору өчен дошманның төп көчләре туплангән.

1944 елның 11 февраленә каршы төндә өлкән лейтенантлар Резниченко һәм Усковның «СУ-76» батареялары, кавалерия полкы белән берлектә, Хорупань авылы янындагы дошман оборонасын өзеп, Дубнога юнәләләр, төньяктан шәһәргә бәреп керәләр. Әллә ни зур булмаган совет гарнизоны Дубнода дошманның өстен торган көчләре белән утыз җиде сәгать буена аяусыз сугыш алып бара. Совет сугышчыларын юк итү өчен фашистлар бөтен көчләрен куялар. Самоходчы-артиллеристлар гитлерчыларның «Тигр», «Пантера» танклары һәм «Фердинанд» үзйөрешле установкалары белән беренче тапкыр шунда очрашалар. Лейтенант Сәгыйров экипажы, турыдан төзәп атып, дошманның өч танкысын сафтан чыгара. Экипажның снарядлары бетә. Нишләргә? Командир сугышны автоматлардан ут ачып дәвам итәргә боерык бирә. Бу бәрелештә илледән артык гитлерчы юк ителә. Пермь егете комсомолец Алеша Кудымов кул сугышына ташлана һәм, өч фашистның башына җитеп, үзе батырларча һәлак була. Сержант Яхия Хәсәнов немецларны башта кырыкилле метрга кадәр якын җибәрә, аннары автоматтан атып утызлап гитлерчыны юк итә.

Граната кыйпылчыгы Сәгыйровның иңбашын яралый. Ләкин ул атудан туктамый, танкка каршы ата торган мылтыктан ут ачып, немецларның «Тигр» танкысын сафтан чыгара.

Менә каршыда броняга төренгән җитмеш тонна авырлыгындагы «Фердинанд»лар күренә.

— Хәсәнов! Десантны юк итәргә! — дип команда бирә лейтенант туп коручыга.

Татарстанның Норма авылы егете, унсигез яшьлек комсомолец Хәсәнов автоматтан десантка ут ача. Кулына граната тоткан Сәгыйров алга шуыша һәм бераздан кара төтенгә уралган «Фердинанд» туктап кала.

Гитлерчыларның ниятен сизеп алган өлкән лейтенант Резниченко Сәгыйров һәм Каузев экипажларын коткарып калу өчен Садыйков җитәкчелегендә разведчиклар төркеме җибәрә, ә калган «СУ-76»лар белән дошманга тылдан һөҗүм итә.

Боларның бөтенесе дә шул кадәр тиз һәм оешкан төстә эшләнә, дошман сугыш кырында күп кенә яралыларын, ике пушкасын, бер бронетранспортерын калдырып чигенә. Бу сугышта татар халкының батыр уллары Фалей Сәгыйров һәм Мофазад Рәхмәтуллин һәлак булалар.

Трофей бронетранспортерның идарә итү бүлегенә кереп урнашкан Садыйков, тирә-юньдәге атыш тавышларын басарга теләгәндәй, кычкырып команда бирүен дәвам итә.

— Якынрак килсеннәр, Хәсәнов, якынрак!..
Дошман чираттагы һөҗүмгә күтәрелә.
— Атмаска! — дип боерык бирә Садыйков, ә немецлар инде якын гына. Менә алар, танкларга ышыкланып, комбат Резниченконың команда пунктына таба киләләр. Садыйковның йөзе агарына, ләкин ул тынычлыгын җуймый. Гитлерчыларның «рус капут!» дип акырган тавышлары аермачык булып ишетелә.
Садыйков, маңгаена бәреп чыккан тирләрне кул сырты белән сыпырып ала да, бронетранспортерны кабыза һәм аны дошман пехотасы өстенә юнәлтә. Яхия белән Бәхтиев бер үк вакытта автоматлардан ут сиптерәләр. Урам дошман солдатларының үле гәүдәләре белән түшәлә. Төрле яктан фашистлар уратып алган Садыйков үзенең ун коралдашы белән бойня эченә кереп урнаша. Бердәнбер котылу юлы бойня ишегеннән чыгып ычкыну, ләкин гитлерчылар ишектән чыгу юлына котырына-котырына аталар. Дошман кулына әсир төшмәс өчен, Садыйков, ничек кенә булса да, бойнядан чыгарга боера. Беренче булып, ишектән рядовой Евстафий Оленев атылып чыга, тик пуля аны шунда ук аяктан ега.
Садыйков өлкән сержант Косюковка сораулы караш ташлый.
— Я, нишлибез, разведчик?
— Мин дошманны тоткарлап торам, ә сез канализация аша... — дип, кыска гына җавап кайтара Саратов егете Миша Косюков.
Патроннарсыз калган кечкенә генә бер төркем кыю сугышчыларны Садыйков әнә шул рәвешле, беркем дә уза алмаслык булып күренгән сазлыклар, ә аннан соң Иква елгачыгы аша Иване авылына алып чыга.
Борынгы украин шәһәре Дубноны азат итү өчен барган сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен барлык самоходчы-артиллеристлар хөкүмәтебезнең сугышчан бүләкләренә тәкъдим ителәләр. Алар арасыннан Сәлим Садыйков Кызыл Йолдыз ордены, Яхия Хәсәнов һәм Асылгәрәй Бәхтиев медальләр белән бүләкләнә.
Дубноны дошманнан тәмам чистартып, Броды шәһәренә килеп җиткәнгә кадәр әле тагын бер ай буена аяусыз сугышлар бара. Татар халкының батыр улы Сәлим Садыйков, үзенең сугышчан дуслары белән бергә, гитлерчылар тарафыннан таланган, мәсхәрәләнгән җирләрне коткарыша-коткарыша һаман алга, көнбатышка карап атлый. Батарея командирының техник эшләр буенча урынбасары буларак, ул зарарланган машиналарны сугыш кырыннан алып чыга, аларны яңадан сафка кертү өчен бөтен көчен куя, шуның өстенә әледән-әле разведкага йөри, Броды шәһәре янында кавалеристларны контратакага күтәрә.
...1944 елның 20 июле. Теләр-теләмәс кенә таң беленеп килә. Солдатлар әле тирән йокыда. Көтмәгәндә бу тынлыкны телефоннан яңгыраган тавыш бүлә: «Сугышчан тревога!» Берничә минут эчендә сугышчылар дәррәү күтәрелеп, паркка, машиналары янына килеп җитәләр. Полк командирының төгәл һәм кырыс командасы яңгырый:
— Машиналарга! Моторларны кабызырга! Алга!..
Львов шоссесында 1813 нче үзйөрешле-артиллерия полкы танклар һәм кавалериянең гомуми ташкынына килеп кушыла.
Сәлим шунда, Дубно шәһәре янында, ВКП (б) членлыгына кандидатлык карточкасы алганда, Кышкы сарайны штурмлауда катнашкан элекке кызылгвардияче, корпус политбүлеге начальнигы урынбасары подполковник Федосеев әйткән сүзләрне тагын бер тапкыр исенә төшерә һәм үз-үзенә: «Сез хәзер, кече техник-лейтенант, комсомолец кына түгел, ә бөек Ленин партиясе члены, коммунист... Шулай ук безнең Армиябез дә көч ягыннан 1941 нче, хәтта 1943

нче ел белән чагыштырганда хәзер бөтенләй башка. Фашизмны тар-мар итү өчен хәзер бездә бөтенесе бар»,— дип кабатлый.

Полк урманлы һәм сазламыклы урыннардан ике тәүлек эчендә ике йөз километрдан артыграк юл үтә. Һәм менә 1941 елда гитлерчы илбасарлар басып кергән җирне безнең чик сакчыларыбыз соңгы сулышларынача саклаган Рава-Русская. Бөтен тирә-як тып-тын. Хәтта пышылдап кына сөйләшкән тавыш та әллә кайларга ишетелә. Һава саф һәм чиста. Илебезнең көнбатыш чигенә килеп җитәрмен дип хыялланган иде микән Сәлим?!

Хыялланган иде!

Ә менә туган авылы Ташкичүдән чыгып киткәндә утлы кырлар буйлап шулай дүртенче елымны атлармын һәм очучыдан үзйөрешле установкалар технигы булып алырмын дип уйлаган иде микән ул?

Юктыр, мөгаен, уйламагандыр...

Сәлимнең күз алдына мәктәптә чыгарылыш кичәсе килеп басты. Гражданнар сугышының чал чәчле ветераны, класс җитәкчесе Әмин Сөләйманов ул кичәдә үзенең шәкертләренә менә болай диген иде: «Сез мөстәкыйль тормыш юлына аяк басасыз. Ул җиңел һәм борчуларсыз булыр дип уйласагыз, бик нык ялгышачаксыз. Киләчәкне матур итү өчен бөтен көчеңне куеп тырышырга, хезмәтне яратырга, намуслы һәм көчле ихтыярлы булырга, илеңә һәм халкыңа тугрылыклы булырга кирәк».

Сугыш башлануын Сәлим әнә шул кичәдән өйләренә кайтып барышлый ишетте... Туганнары, дус-ишләре белән саубуллашып яу кырына чыгып киткәндә әнисе аңа үзенең иң изге теләкләрен теләде: «Ил-җир йөзенә кызыллык китерә күрмә берүк, улым!»

Сәлим Ленин комсомолы чакыруы һәм йөрәге кушуы буенча көнбатышка карап юл тотты, озын-озын авыр поход юлларын үтте. Менә хәзер ул Европа илләре халыкларын фашизм коллыгыннан коммунист булып азат итешәчәк, аларның җирләрендә мәңгелек тынычлык урнашсын өчен, әгәр кирәк була калса, соңгы тамчы канын да кызганмаячак.

Сәлимнең уйлары ерексездән җиргә, Октябрьга кадәр ата-бабаларының нинди шартларда гомер сөрүләренә барып тоташты. Әйе, аларның гаиләсендә җирнең кадерен беләләр, аны менә диген итеп эшкәртәләр, язгы буразналар исен иснәп ләззәтләнәләр иде.

Ул да түгел, Сәлим карт әнкәсенең, иңнәренә чиләкләр асып, коедан судан кайткан чагын күз алдына китерде. Әнә ул ничек акрын гына атлый. Өйдә бәлки аны улыннан килгән хат көтәдер. Сәлим әнкәсенең кабаланганын бер дә хәтерләми. Йортта башкалар да аңа охшарга тырышалар иде.

1944 елның 22 июлендә чикне үтәргә боерык бирелде. Бу юлы да командование Сәлим Садыйков һәм аның сугышчан дусларына мактаулы бурыч — полк байрагын чик аша озата чыгу бурычы йөкләде.

Байрак Совет Социалистик Республикалар Союзы чиге аша чыгуга, полк артиллериядән өч тапкыр залп бирде. Совет солдатлары моның белән туган җиребезнең илбасарлардан азат ителүен белдерделәр. Бу залплар бер үк вакытта фашизм табаны астында азап чигүче Европа халыкларының ирек таңы якынлашуын да хәбәр итте.

**ГРИГОРИЙ ГУРЬЕВ,**

**1813 нче «Дебреценск» үзйөрешле артиллерия һәм Кутузов орденлы 6 нчы гвардия кавалеры корпусының элекке комсоргы, отставкадагы майор.**

Салих Маннапов

# ТОРМЫШ ҮЗӘННӘРЕННӘН

*Хисам Камалов иҗаты турында уйлану*

**Тир коймыйча берни алмадым мин,**
**Холкым шундый — сөйми әзерне!**
**Барысын да нульдән башлаганга,**
**һәрбер нәрсә миңа кадерле!**

Авылда комбайнчы булып эшләүче абыем бар минем. Унсигез яшеннән сугышка алынган. Гомере буе баш күтәрми эшләгән. Бик йомшак күңелле, сабыр-тыйнак кеше. Берәр зурдан кубасы эш килеп чыкса, аның белән киңәш-уңаш итәргә тырышам. Ул ашыкмый гына тыңлар, бераз суына төшүеңне көтәр, шуннан соң инде җай белән үз киңәшен бирер. Кем әйтмешли, беркайчан да ашелләй урмас.

Беренче күрешүебездә үк Хисам Камалов ничектер әнә шул абыемны хәтерләтте. Хәзер күршедә генә яшәгәнлектән, без аның белән шактый еш очрашабыз. Я ул саф һава суларга чыккан, ишегалдында тирә-күршеләр, бала-чагалар белән сөйләшеп йөри... Я җыйнак кына эш бүлмәсендә уйга чумып утырган чагы була. Әдәби мәҗлесләрдә, редакция-нәшриятлар тирәсендә аны бөтенләй диярлек күрмисең.

Үзе кебек үк, тормыш юлы да тыйнак Хисам Камаловның. Җидееллык мәктәп тәмамлагач колхозда ат караучы булып эшли. Яше тулар-тулмас фронтка китә. Авыр сугышларның берсендә каты яралана. Унтугыз яшеннән бер аяксыз кала. Ел ярым гомерен госпитальдә уздыра.

**Госпитальдә генә аңга килеп,**
**Күзләремне ачып карадым.**
**Сумкамдагы «Павел Корчагин»ның**
**Минем белән бергә**
**Яраланганлыгын аңладым.**
**Каным китап битен тутырган,**
**Павел каны белән кушылган.**
**Бу — гомернең аныкына охшап**
**Башлануы булды шушыннан.**

Госпитальдә бер-бер артлы ике һөнәр үзләштерә: хисапчы һәм бухгалтер булырга әзерләнә. Тормышка, кешеләргә ышанычы яңара, бала чактан ук күңелендә яткан хыяллары уяна. Инде ул — Бөгелмә педагогия училищесы студенты. Аннары — Казан педагогия институты. Шуннан соң унҗиде ел Татарстан китап нәшриятында редактор

булып эшли. Беренче китапларына Х. Камалов фатиха биргән яшь язучылар гына да шул еллар саныннан артыграк.

Шагыйрь үзе дә остазлары исемен хөрмәт белән телгә ала. Әхмәт Фәйзи, Сибгат Хәким, Әнвәр Давыдов, Зәки Нури... Иҗатына һәрвакыт илтифатлы булган, үсешенә ярдәм иткән кешеләр.

Беренче шигырьләрендә — сугыш калдырган яралардан әрну-көенеч һәм яңадан сафка кайту сөенече. Шуңа күрә беренче җыентыгы да — «Яңадан сафка».

Ул көннәрдән бирле шагыйрь егерме биш-утыз еллык иҗат юлы узган, егермегә якын китабын чыгарырга өлгергән.

Аның шигырьләре һәм поэмалары тормыштагы урының, кыйблаң турында уйландыра. Шулай да Х. Камалов иҗаты артык тыйнаклыгы, оялчанлыгы беләнме тәнкыйть күзеннән күләгәдәрәк калган. Укучы да аның белән соңгара төшеп очраша төсле.

**... Яшьлек безгә чиксез дәрт бирде**
**Ватан өчен утка керергә!**
**Яшьлек**
**юлын шулай бизәде**
**Үкенмәслек итеп мәңгегә.**

*«Яну» поэмасыннан*

Сугыш дәһшәтен үз башыннан кичергән шагыйрьләр буыны... Алар өчен таяну ноктасы да күпмедер дәрәҗәдә уртак: авыл, яшьлек, фронт. Шушы җирлектә мәңгелек төшенчәләр турында уйланулар бәреләнә. Юк, җирлек димәктән, гади фон гына түгел бу. Бирегә киңрәк һәм тирәнрәк мәгънә ята: шагыйрьнең нигез-туфрагы, шәҗәрәсе, иҗат критерийлары.

Х. Камалов үзенең «бик вакытсыз килгән» яшьлеге турында искә алырга, сөйләргә яратмый. Күрәсең, ул хатирәләр гади сүзләр белән генә аңлатып бетерә алмаслык дәрәҗәдә изге дә, кагылсаң, тоташ газапка әйләнерлек иске яра сыман әрнүле дәдер. Ләкин шагыйрьнең язмышы шундый: ул иң тирәндә яткан тойгыларын да шигырьләренә сала.

Без сугыш еллары шигъриятенең бизәк өчен генә матур сүзләр белән мавыкмыйча, нинди генә ачы булса да, дөреслекне күзгә карап әйтергә омтылуын беләбез. Гаделлек һәм чынлык, йөрәк һәм вөҗдан поэзиясе. Халык рухының ныклыгын да, тирәнлеген дә гәүдәләндергән ул. Шигърияткә 50 нче еллар башында гына килсә дә, Х. Камалов үзенең язмышы белән генә түгел, бөтен рухы, иҗаты белән дә шушы чорга карый сыман.

**Миңа унсигез яшь,**
**Әле куркам.**
**Гел аталар, ай-яй кыен ла!**
**Һавада һәр чинап очкан мина**
**Башка төшәр төсле тоела.**
**Минем әле**
**Үлем күргәнем юк...**

Яшәү чиге белән үлемсезлек турында, үз бурычыңа тугрылыклы булу турында менә шулай да язып була икән. Солдатларча ачыктан ачык һәм чын күңелдән. Лаф ормыйча, күкрәк какмыйча.

Сугыш турындагы шигырьләр бүген язылган тәкъдирдә дә ихласлыгын, чынлыгын җуймый. Киресенчә, канлы һәм данлы ул көннәр ераклашкан саен, аерым нечкәлекләре бер бөтенгә укмаша барган саен, хакыйкать җетеләнә, зурая, якынрак була бара бугай. Моңа шаһәдәтнамә — үзебезнең үк шигърият: Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Зәки Нури, Нәби Дәүли... — сугыш нинди генә шартларга куймасын, һәрвакыт алгы сызыкта булган шагыйрьләребез иҗаты.

Хисам Камалов та шул заманнардан бирле чын мәгънәсендә алгы сызыкта кала. Артиллериядә ул элемтәче булган. «Сугыш алласының» күзе һәм колагы. Күз алдына да нәкъ шундый булып килә: дошманның йөрәк тамырына баскан да, «утны күчер!» дип кычкыра сыман...

«Үзара бәйләнештә хәрәкәт итү» дигән төшенчә хәрбиләр телендә аеруча мәгънәле. Җиңү үзе — ялгыз батырлар гына яулаган биеклек түгел. Алар — шул юлны күрсәтүче маяклар гына. Монда үз өлешеңә тигәнне яхшы төшенү, беренче чиратта шул бурычны үтәү мөһим. Шигърияттә дә таләп шундыйрак. Тематик киңлек, төрлелек, тулаем, уңай күренеш булса да, иңләмәстәйне иңләргә омтылу, ким дигәндә, фикри саегу һәм сүз-сурәт төссезләнү белән яный.

Баягы чагыштыруны дәвам иткәндә, Х. Камалов әле дә үз позицияләрендә кала, үз бурычын яхшы аңлый, дип расларга мөмкин булыр иде. Шагыйрь-солдат тормыш күренешләренең бик табигый, әмма башкалар күзенә чалынмаган мәгънәләрен эзли. «Барысы өчен натурлата түлим — йөрәк белән! Чыда, йөрәгем!» «Газапларга баеп, шатлыкларга саранланса да», ул язмышның якты сәхифәләрен ача, укучыны дөньяның кояшлы якларына чакыра. Без шагыйрьнең: «Утны күчер!» — дигән тавышын ачык ишетәбез һәм аңа ышанабыз.

Сүз, билгеле, Х. Камаловның окопта үткән яшьлегенә багышланган шигырьләре турында гына бармый. Гомумән, аның иҗатында сугыш темасы үзәккә куелмаган. Язылган кадәресендә дә беренче тапкыр үлем белән очрашкан яшь солдат, яки тәнендә һәм җанында калган яралар турында уйланучы лирик герой тасвирлана. Бер урында — хаталанган солдатны йолып калган замполит, икенче урында — чигенә алмаган пулеметчы... Хәтта күбрәк чигенүләр, хаталар белән мавыгу күзгә ташлангандай була. Ярсулы һөҗүм картиналары кайда? Ни өчен дошманны тетрәтүче туп тавышлары ишетелми? Бу сорауга җавап эзләгәндә Хисам Камалов иҗатының кызыклы һәм каршылыклы ягы ачыла: аны сугыш мәхшәренең тышкы күренешләреннән бигрәк кешенең иң авыр вакытта яшен яктысыдай ялтырап киткән асылын сурәтләү кызыксындыра. Шулай, сугыш — иң авыр хезмәт, «өйрәтелгән ерткыч»ның өненә кадәр барып юк итү тоташ җиңүләрдән, «ура!»лардан гына тормый. Шул ук вакытта яу кырындагы чигенүләр — рухи позицияләрне ташлау түгел әле! Соңгы исәптә, Ватан сугышының иң төп нәтиҗәсе дә — гаделлек һәм азатлык тантанасы, коммунизмның дөньяны фашизм чиреннән коткаруы. Шагыйрь күңеле әнә шундый җиңүләребез хөрмәтенә салют бирә.

Вакыйгалар давылы эчендә шәхеснең җанын ярып салу, фикерләр һәм хисләр бәрелешеннән олы фәлсәфә гармониясенә ирешү — авыр бурыч. Болытлар куера, әмма кайвакыт яшене күренсә дә, зарыгып көткән яңгыры таммый.

Х. Камалов иҗатында да булгалый торган хәл.

Иҗатының башлангыч чорында ук язылган «Яну» поэмасын тәнкыйть, нигездә, шулай бәяләгән иде. Аңа «Ватан сугышы фронтындагы эпизодларны артык субъектив планда аңлату, хакыйкатьтән читләшеп, «вакыйгалар колы» булып тасвирлау хас», дип күрсәтелде.

Бу поэмада туп тавышлары да, атакалар да, сугыш кырында бөреләнгән мәхәббәт тә бар. Ул шактый гомуми тестә — лирик геройның рәхимсез чорга туры килгән яшьлеге турында уйланулары белән башлана. Бик анык булмаган үкенеч тә, тормыш мәгънәсен аңларга тырышу да, окоп шартларында формалашып килүче ир-егетлек тә сизелә әлеге фәлсәфәдә. Шуннан соң, элемтә урнаштырганда Заһитның (төп геройның) яралануы һәм санбатка элэгүе белән вакыйгалар куера, тизләнә төшә. Поэмада шәфкать туташы Зилә белән Заһитның саф мөнәсәбәтләрен тасвирлауга зур урын бирелә. Яңадан сафка кайткан егет, командиры үлгәч, взвод белән җитәкчелекне үз өстенә ала. Беренче бәрелештә ук ул зур кыюлык күрсәтә, әмма иптәшләрен ашыгыбрак атакага күтәрә... Заһит шушы гаебен дошман белән тигезсез көрәштә каны белән юа.

Шагыйрьнең поэма нигезенә үз күзәтүләрен салуы сизелеп тора, ул иң мөһим моментларда үзен дә геройлары арасында хис итә: «Бер «юнкерс» килеп безнең өстә миналарын коеп әйләнде...» — ди. Шул ук вакытта шәхси кичерешләрнең бөтенлеген җуярга теләмәү, киң полотно тудыру максаты белән күргән-белгәнне тәфсилләп сөйләү әсәрне бер үзәккә тупларга комачаулый. Заманында әдәби тәнкыйть «Яну»ның әнә шул таркаулыгына игътибарны юнәлткән дә иде инде. Ләкин бер уңайдан шагыйрьне хакыйкатьтән читләшүдә гаепләү һәм асылда әлеге әсәрнең әһәмиятен сызып ташлау урынлы булдымы икән?

Х. Камалов беренче шигырьләрендә, беренче поэмаларында ук, ә соңрак бөтен

иҗаты белән эпик һәм лирик агымнарны төрле нисбәттә бергә кушучы шагыйрь булуын күрсәтте. Ул зур полотноның аерым эпизодлар белән генә тоныкбулып чыгуыннан, бизәкләренең метафорик сурәтләр стихиясендә калып уңуыннан шикләнә. Вакыйга-тасвирлаулар аңа геройларның эчке дөньясын ачу, «чырайлы итеп» күрсәтү максатында гына кирәк. Шуңа күрә шагыйрь хис-фикерләрен билгеле бер эзлеклелектә үсүче күренешләргә үреп-бәйләп баруны мәгъкуль күрә. Эзлеклелек дигәнебез үзе дә каршылыклардан тора, билгеле. Бу — катлаулы тормыш материалының «каршы торуы», авторның дөньяга караш һәм иҗат үзенчәлекләре белән бәйләнгән.

Хисам Камаловның күпчелек геройлары — үзе кебек үк гаҗәп дәрәҗәдә беркатлы һәм ихлас күңелле кешеләр. Алар үзләренең кылган эшләрен фәлсәфә пәрдәсе белән йомарга яки хәлиткеч адымда качып калырга тырышмыйлар, киресенчә, язмыш сынавына белә торып һәм бик табигый рәвештә керәләр. Бу табигыйлык укучының күңелен актарып ташлый. Моннан да зуррак чынлыкның булуы мөмкинме?!

> **Кем янарга туган — ул янар,**
> **Диңгезләрең, суың — ни аңар!**
> **. . . . . . . . . . .**
> **Үзе белән суны яндырыр,**
> **Дошманына ләкин баш имәс!**
> **Күкрәгендә җаны бар чакта**
> **Ул ятларны илендә йөртмәс!**

Сугыштан соң утыз ел үткәч Х. Камалов сугыш турында роман язды. Дөресрәге — сугыштагы кешеләр турында. «Һәркемнең гомере бер генә»... Аны шартлы рәвештә «Яну» поэмасының дәвамы дип тә карарга мөмкин булыр иде. «Сугышта бит кешенең бөтен ягы бик тиз беленә» дигән фикернең дәвамы дип.

Шагыйрьнең прозасында да шигърият танылып-сизелеп тора. Юк, көтелмәгән чагыштырулар, әледән-әле хискә бирелүләр рәвешендә генә түгел. Роман иң гади язмышлы кешеләрнең күңел байлыгын, кешелеклелек матурлыгын шагыйранә тасвирлавы белән җәлеп итә. Биредә сугыш, урын һәм вакыт төшенчәсен билгеләүче фон булудан ашып, үзенә күрә вакыйгаларда катнашучы затка әверелгән. Геройларның матди һәм рухи тормышлары белән баглы персонаж сыман ул.

Романны укыганда күңелгә килгән сорауларның берсе: шигърият шагыйрьгә кайчан комачаулый?

Чәчмә әсәрнең, мәгълүм ки, үз ачкычлары бар. Анда тормышның төрле яңгырашлары бергә кушыла. Алар еш кына берсен-берсе басып китәләр. Иң соңгы сүз дә авторга бирелми. Менә шул мәлдә шагыйрьлек әсәрнең табигый агышына комачаулый, кайбер характерларның эчке үсешенә ирек бирми, ышандыру көчен киметә.

«Һәркемнең гомере бер генә» — укучыларда да, әдәби тәнкыйтьтә дә кызыксыну тудырган әсәр. Аның уңышлы һәм отышсыз яклары, нигездә, дөрес бәяләнде.

> **«Шигырьдә алынган фикерне, тойгыны ниндидер бер уртак ваклаучыга китерергә кирәк була. Уртак ваклаучы дигәнем: үзең генә тойган хис, тәҗрибә, шигъри танып белүеңнән килеп чыккан әйбер. Юк, бу нинди дә булса бер дөреслекне раслау яки инкяр итү формасында гына түгел, ә бәлки теге яки бу күренешнең, кеше холыгының яңа бер мәгънәсенә төшенү, үзеңә күрә ачыш ясау шикелләрәк булуы мөмкин».**
>
> *Шагыйрьнең Марс Шабаев китабына язган сүз башыннан*

Хисам Камалов иҗатын чорларга бүлеп каравы кыен. Күргәнне һәм кичергәнне рәттән сөйли барумы бу? Әллә күңел көндәлегеме? Борчылудан һәм юатудан, сагыштан һәм шатлыктан тора аның лирикасы. Шагыйрьнең укучысы белән күзгә-күз калып эч серен уртаклашуы, мөгаен, шундый буладыр.

Бу шигъри дөньяда вакыт көчешен, тормыш үзгәрешләрен ачык тоясың, аның фараз-гөман кылудан түгел, баштан һәм күңелдән кичереп иҗат ителүенә ышанасың. Шагыйрьнең лирик герое иң авыр сынауларны кичкән, әмма көрәш сукмагыннан тайпылмаган. Беренче шигырьләрендә үк ачык билгеләнгән шушы кыйблага Х. Камалов һәрвакыт тугрылыклы кала. Бөтен иҗаты белән. Бөтен яшәеше белән. Әнисе үлемечә язылган шигырьләрендә һәм «Әнкәй истәлеге» поэмасында бу аеруча ачык: хис-тойгыларның искиткеч сафлыгы һәм тыйнаклыгы, үзәк өзгеч чынлыгы тетрәндерә.

**Белсәң, әнкәй, дошман тылларына**
**Разведкага барган чакларым,**
**Мин куркудан доган гел укыдым,**
**Җаным саклап кеше сатмадым.**

Х. Камалов шигырь-поэмаларында лирик «мин» эчке дөньясының яктылыгы һәм табигыйлеге белән сокландыра. Яңгыравыклы сүзләр, ялган күтәренкелекнең эзе дә юк. Чөнки ул иҗат фантазия җимеше генә түгел. Сүзне шагыйрь үз исеменнән алып бара. Солдатларча уяу һәм киеренке төстә. Бернинди позага кермичә. һәм күз буарга, шаккатырырга омтылмый — бары раслый, ышандыра.

Хисам Камалов иҗатына үз-үзе белән хозурлану, башкаларга акыл өйрәтү кебек сыйфатлар чит. Киресенчә, анда ниндидер дәвамлы һәм якты тойгы — үзен һәрвакыт бурычлы итеп сизү тойгысы яши.

**Гомер дәфтәремнең һәрбер битен**
**Мин актарып йөрим:**
**хаталар,**
**Укытучы кызыл кара белән**
**Төзәткәндәй, ярылып яталар...**

Шагыйрь башка кешеләрнең уңышсызлыгы өчен дә үзен гаепле хис итә. Мәсәлән, «Нишләтим соң?» шигырен генә кабат укып карыйк. «Үзе турында» сөйләгәндә ул чор сулышы, замандашлары язмышы турында уйланса, «кеше турында»—төрле язмышларны үз күңеленнән кичереп, күңеленә якын алып яза. Бу уңайдан Назыйм Хикмәтнең ачы, мәгәр туры сүзләре күңелгә килә. Тышкы дөньясы булмаган шагыйрьнең эчке дөньясы да юк, дигән ул.

Кабат-кабат канатлары каерылган сабыр холыклы һәм нечкә күңелле кеше күзләре белән дөньяга карау җиңел түгел. Аның бик тирәндә яткан көчле рухын тиз генә абайлап өлгермисең. Әнисе кебек үк: «Үзе юаш, үзе тәҗрибәсез, ничек калсын шушы мәхшәрдә?..» — дип чын күңелдән борчыласың. Сыкранулары күбрәк төсле. Икеләнүләре...

**Әллә ничек сугыш чорларыннан**
**Калган шундый гадәт — сагаю...**

Шулай да гаҗәп бит: шигырьдән шигырьгә күңелдәге образ ачыклана, зурая, куәтлерәк була бара. Аның сагышы да, шатлыгы да сафландыргыч һәм рухландыргыч ташкынга әйләнеп, безне бөтереп ала. «Сөенмәсен», «Җилләр исә...» кебек шигырьләренең һәм «Әнкәй истәлеге» поэмасының да тәэсир итү көче әнә шунда. Шагыйрьнең тавышы тоныкl, хатирәләре авыр, үкенече зур. Хәлбуки әсәрне укып чыгасың — күңелдә хәсрәтле тойгы түгел, яктылык, бары яктылык кына кала.

Әниләр үлеменнән соң язылган шигырьләр әдәбиятта шактый. Һәр очракта олы югалту үзенчә килә. Сибгат Хәкимнең «Васыятьләр» поэмасын хәтерлик. Зур иҗтимагый яңгыраш алган эчке драматизм. Киеренке кичерешләр тарихи җирлеккә күтәреп тасвирлана. Яисә Кайсын Кулиевның мәгълүм шигырьләр бәйләме. Иseме дә аваздаш — «Әнкәй истәлегенә». Фәлсәфи уйланулар. Үзәгендә — кешелеклелек һәм гүзәллек башлангычын эзләү.

Х. Камалов өчен әни образына бөтен яшәү мәгънәсе салынган. Ул аның бөтен иҗатын балкытып тора. Әнисез якты дөнья юк. Ләкин әниләрнең тормыш дәвамы — улларында, бездәге барлык күркәм сыйфатлар — әниләребез төсе. Шуңа күрә шагыйрь төп юлыннан-мәсләгеннән тайпылмаслык көч таба, яшәү рухын эзләп туган иленә сыена:

**Тик син генә**
**мине аңларсың да,**
**Юатырсың әнкәм шикелле, —**
**Чәчләремнән сыйпап җилең белән,**
**Яңгырың белән үбеп битемне!..**

— ди ул бер шигырендә.

Беренче карашка бик тыйнак юллар, ә нинди тирән хис: югалтулар аша табылган рухи таяныч!

Хисам Камалов тойгыларны ялангачландырып бирми: нәфрәт булса да, мәхәббәт булса да шулай. Әмма хис-кичереш турында никадәр генә тыйнак, никадәр генә җисемле итеп язмасын, фәлсәфә корудан, гыйбрәт чыгарудан котылу җиңел түгел аңа. Җанлы картиналары, элекке фикер җебе булган «Мәхәббәт хакы» поэмасы да, мәсәлән, нәкъ шуның аркасында ялыктыргычрак килеп чыккан. Шагыйрь моны үзе дә белә. Әсәрләрен кабат бастырганда, иҗатының яңа баскычларында ул сурәтле фикер агышын тирәнрәк һәм саллырак итүгә йөз тота.

**... Теләсә нинди әрне күтәрермен,**
**Тик син генә мине ташлама!**

Тән һәм җан газапларыннан горурлыгын җуймый чыккан кешенең мәхәббәт хакына яңа югалтулардан курыкмавын шул кадәр табигый итеп сурәтләү һәркемгә дә бирелми.

Шагыйрьне адәм баласының дөнья белән алыш-биреш вакытыннан бигрәк, кешеләр арасында үзен ничек тотуы кызыксындыра. Шул рәвешчә, ул тормышның рухи эчтәлеген аңларга һәм безгә аңлатырга омтыла. Әйе, шагыйрь шәхси кичерешләре белән артык мавыккан төсле, кабат-кабат шуларга әйләнеп кайткан сыман... Тыштан караганда! Асылда, аның белән бергә без әхлакый идеалларның беренчел нигезләренә кайтабыз, үзебездәге ниндидер яңа сыйфатларны ачабыз. Шагыйрь безне тагын бер адым алга таба атларга мәҗбүр итә. Кешелеклелеккә таба.

**Башта ватан өчен торырлык**
**Булсын дидем тыйнак көчләрем.**
**Хәзер инмәмә торырлык**
**Булсын иде димен эшләрем.**

*«Тормыш сабаклары»нннан*

Дөньяга үз язмышың аша карарга өйрәтүче биеклекләр бар. Гомер юлыбызның теләсә кайсы төшеннән дә күренерлек биеклекләр... Расул Гамзатов өчен ул ерак Дагстандагы Цада авылы, Сибгат Хәким өчен — «тәрәзәләре кояшка караган» Казан арты.

Хисам Камаловны да туган туфрагы тарта, яшьлек эзләре сагындыра. Ә иң мөһиме: «сүрелгәндә тормыш учагы... ут алырга» кайта ул туган җиренә.

Утлар-сулар кичкән шагыйрьләрнең бүгенге чынбарлыгыбызга үз карашлары бар. Алар әле дә дөньяга авыр елларның канлы-кызыл офыгы, дары исе сеңгән һавасы аша карыйлар сыман. Заман темасына язылган әсәрләренең драматизмы һәм кешелекле пафосы да шуннан килә: «Шәфкатьлелек арта кешеләрдә». Ләкин сугыштан соң халыкның тормышында, эчке дөньясында тагын да кискенрәк үсешләр булуы мәгълүм. Туган ягына кайткан шагыйрь әнә шул үсеш-үзгәрешләр чолганышында кала. Яңа шәһәр манзарасы белән хозурлану гына түгел, шул җирлектә элекке танышларын очрату әсәрләндерә аны. («Әлмәт эскизлары»).

«Күңелем акка көнем ак минем» дип куанучы эшче Харис, яңа шәһәр иҗат итүчеләрнең берсе Сөмбел... Образлар эш-хәрәкәт эчендә генә түгел, тормышка мөнәсәбәтләрендә, дөньяга карашларында да ачылалар. Шагыйрь белән бергә бу күренешләрнең эчтәлегенә төшенәсең, гади кешеләр күңелендәге матурлыкны күрергә, «шатланырга өйрәнәсең».

Х. Камаловның «нефтьне ташлап автогигант төзелешенә чыгып китүе» заманында кайберәүләрне шактый сәерсендергән иде (бу хакта матбугатта да сүз булды). Әмма «Әлмәт эскизлары» белән «Язмыш елмаюы» арасында каршылык күрү, бигрәк тә

мода белән бәйләү гадел булмастыр. Сугышта үзен арсланнан да көчлерәк итеп күрсәткән халыкның тыныч тормышта да батырлыклар елъязмасы дәвам итә. Иген үстергәндә, нефть ятмаларын актарганда, автомобиль гигантларын күтәргәндә... Шушы сәхифәләр буйлап килә шагыйрь. Тыйнак батырлыклар эзеннән. Һәм КамАЗ — аның өчен табигый тукталыш. Хисам Камалов КамАЗ турында язарга тиеш иде.

Сүз дә юк, Әлмәткә яки Чаллыга барып кайтудан гына әдәби әсәрнең умыртка баганасын төзеп булмый. Шагыйрьнең бер үк вакытта үз биографиясенә, үз күңел хәзинәсенә таба сәфәр кылуы да мөһим. Шушы ике яссылыктагы тәэсирләр бергә кушылганда гына, кеше һәм яшәеш, гаделлек һәм батырлык турында әсәр иҗат ителәргә мөмкин. «Әлмәт эскизлары» да, «Язмыш елмаюы» да нәкъ әнә шулай — киңлеккә һәм тирәнлеккә омтылып язылган поэмалар. Чаллы, Әлмәт ягы кебек үк, авторның үсмер чагы белән бәйләнгән. Камы-Исмәгыйльдән (туган авылыннан) туксан чакрымда гына. Сельпо өчен товарга барылган. Сабынга, тозга, дегеткә яки керосинга. Ат белән. Чагыштырып кына карасаң да — күпме тәэсирләр, хатирәләр! Шулай да шагыйрь ул хакта язмый. Чаллының бүгенге масштаблары таң калдыра аны. Әмма тышкы тәэсирләрдән югарырак күтәреләсе, зур төзелешнең проблемаларын, кабатланмас язмышлы кешеләрен күрсәтәсе иде, дип уйлый шагыйрь. Төзелеш мәйданнарында, планеркаларда, тулай торакларда була. Хәтта Казанга кайткач та тәзүчеләр арасында «илһам җыеп» йөри.

Билгеле булганча, КамАЗга багышлап кызыклы гына әсәрләр языла тора. Арадан Сибгат Хәким һәм Рөстәм Мингалимов поэмалары, мәсәлән, әдәби тәнкыйтьнең аерым игътибарына лаек булган иде. Бу ике әсәрдә гигант төзелеш рухын укучыга эре штрихлар, бик үзенчәлекле чаралар ярдәмендә тулы һәм масштаблы итеп җиткерергә омтылу бар.

Хисам Камаловның нияте — КамАЗны эчтән күрү. Ул биредә дә үзенең табигатенә, иҗат рәвешенә каршы килә алмый. Төзелеш эченә кереп югалса югала — гомуми бәя бирергә алынмый. Шуңа күрә «Язмыш елмаюы» тышкы кыяфәте белән, «Мин—КамАЗ турында!» дип кычкырып та тормый. Поэма, тематик вакланудан курыкмыйча, шигъри репортаж рухындарак иҗат ителгән. Кайнар эздән барып язганда, мондый алым бәлки аклана да торгандыр. Әсәрнең бөтен агышы геройлар һәм аларның эш-хәрәкәтләре, кичерешләре стихиясендә. Автор аерым детальләргә озак тукталып-текәлеп тормаска тырыша, һәм бу шулай булырга тиеш тә: алар бит — конкрет мәгънә нигезенә ятачак кирпечләр генә. Тик ара-тирә очраклы күренешләр дә кызыктырып куя, фикернең канатына ябыша, күтәрелергә ирек бирми...

Шагыйрь гадәтләнелгән романтикага бөтәнчәрәк карый. Зур төзелешкә кешеләрнең үз язмышларын да корырга килүләрен күрә.

**Кемнеңдер рухи көймәсе**
**Ватылып яра алса,**
**Бу зур төзелешкә килеп**
**Ярасын дәваласа,**
**Гаҗәп түгел...**

Хисам Камалов — катлаулы характерлар иҗат итү остасы. Нур Хәлкин һәм поэмадагы башка геройлар үз-үзләренә бераз юмор белән карый торган, юлларының хаклыгына нык ышанган, «Мин — базис!» дип горурлана алырлык кешеләр. Шуңа күрә алар язмышларын елмайтырга сәләтлеләр. Шагыйрь дә геройларының уңышларын һәм гөнаһларын холык-фигыльләре, яшәү рәвешләре белән бәйләп аңлата.

Кырыс чынбарлык һәм тормыш иллюзияләре, кешеләр арасындагы яңа мөнәсәбәтләр турында җитди уйланулар поэманың сулышын киңәйтеп җибәрә. Исеменнән үк башлап («язмыш» һәм «елмаю») каршылыкларның үрелеп үсүенә корылган бу әсәр, тулаем алганда, шагыйрь иҗатының яңа мөмкинлекләре турында сөйли.

**«Шигырьдә иң мөһиме чын күңеллелек һәм ялганламау, хисләрне уйлап чыгармау...»**

*Шагыйрьнең Шамил Маннапов җыентыгына язган кереш сүзеннән*

Х. Камаловның күләмле әсәрләре белән кабат очрашканда кечкенә генә деталь күзгә чалына: тәүге басмаларында алар «әнкәй үлеменә язылган шигырьләрдән»,

«Әлмәт эскизлары», «лирик эскизлар» дип кенә тәкъдим ителәләр. Мондый тыйнаклык, мөгаен, авторның үз иҗатына зур таләпчәнлеге белән дә бәйләнгәндер. Шул ук вакытта «эскизлар» дип атау әсәрнең композицион үзенчәлегенә дә ишарә итү түгелме икән? Бигрәк тә «Туган җир» һәм «Язмыш елмаюы» поэмалары белән танышканда күңелгә шундый уй килә. Алардагы аерым бүлекләр, аерым бизәкләр кайвакыт төп җирлеккә «чигелеп» тә бетми кебек. Поэма шигырьләр циклын хәтерләтә башлый. Әлбәттә, шигъри табышлар соңгы исәптә «киеменә карап» кына бәяләнми.

Әмма әлеге композициядә укучыны дулкынландыру куәте артык зур булмаган кисәкләр дә очрап куя. Беренче укып карауга ук йомшак тоелган, хәтта төп сюжет агышына аркылы килеп яткан өлешләр... Бөтен хикмәт шунда, шагыйрь дә, укучы да, мөгаен, аларны сызып ташлый алмас иде. Сызасың икән — чылбыр өзелә, фикер, хис һәм интонация дулкыны килеп җитмичә сүнә. Мондый бөтенлекнең нигезе кайда соң? Икеләнмичә әйтергә мөмкин — шагыйрь табигатенең эзлеклелегендә. Үз дөньясы белән иҗатын аерып карамауда.

Хисам Камалов хис һәм уй-фикерләренең тормышчанлыгын форма гадилеге белән дә беркетә шикелле. Шигырьнең һәр күзәнәген гап-гади кешеләр үзара сөйләшкән төсле итеп оештырырга тырыша.

> **... Кинәт фриц**
> **Дальнебойный белән төкерде.**
> **Котелокка блиндаж түшәменнән**
> **Туфрак тулды, ашны бетерде.**

Әйе, гади язу җиңел түгел. Кайвакыт менә шулай шигырь белән проза арасындагы кыл өстеннән үтәсең. Бер рус шагыйренең (Евг. Винокуров) прозаизмнарны шигъриятнең «бас регистрларына» охшатуы, аларда зур тәэсир көчен күрүе искә төшә. «Киселмәгән ефәк көе», «керендерә мина белән, кая керер тишек юк...» кебек халыкчан гыйбарәләр, җөмләләргә һәм «буй зифасы аның сынында...» дигән тасвирларга тоташып шагыйрьнең үз күңел гөлләре дә үсә: «авыр яраларга күнегеп була, җиңелүгә булмый күнегеп».

Х. Камаловның байтак шигырьләрен җорлык һәм тапкырлык бизәп тора. Бөтенләй көтелмәгән мәлләрдә дә. Әнә сазламыкта ярылмаган снаряд... «чыжлап ята суга тыккан кебек кисәүне!» Яки элемтәчеләрне рус теленә өйрәтү күренеше... Сугыш бара. Ә солдат йомшак кына шаяртып алырга җай таба: «Шулай да без нык өйрәндек — ипи-тозлык», — ди.

Х. Камалов иҗатының башкалардан кискен аерылып торган тышкы стиле бар дип булмый. Күзгә чалынмауның сере — ритмик төзелешне, сурәтләү чараларын бер генә юнәлешкә буйсындыруда. Ул — шигырьнең мәгънәви асылы таләп иткән юнәлеш. Шуңа күрә поэмалардагы ритмик күчешләр, эчке монолог һәм җыр элементлары, көтмәгәндә генә ГЭС белән Уэллсны рифмалаштырып кую гади сөйләмдәге кебек табигый кабул ителә. Образлы чагыштырулар да, нигездә, «мишеньгә тия»:

> **Курляндия сазлыгы,**
> **Аяк баскан саен,**
> **Немец дуңгызыдай мыркылдый.**

«Камы егете» дигән балладаның тулысынча антитезага корылуы да образның эчке дөньясын, характерын ачуга хезмәт итә (үсмер чакта «кызлар кулын түгел, сабан кулын күбрәк тоттык без»). Бизәкләү белән мавыгыбрак киткәндә исә шигырьгә ясалмалык килеп керергә мөмкин. «Туган җирдә» поэмасының «Янган йөрәк» бүлеген генә искә төшерик. Бушка янган факеллар өчен әрнүче йөрәк үзе үк... бушка янып торган факелга тиң күрелгән. Тулаем алганда, метафорик чараларның күбесе эчке уртаклыкка нигезләнә (мәсәлән, «Яну» поэмасындагы зәңгәр чәчәк, пар аккош образлары).

Х. Камалов шигырьләрендә поэтик чараларның кабатланмас эчтәлекле булуына мисалларны күп китерергә мөмкин. Арадан тагын берсенә, характерлысына — башка шагыйрьләрдә дә актив кулланыштагы боҗралы кабатлауга гына тукталыйк.

> **Авыр кайгы, кайнар ярчык булып,**
> **Күкрәгемә килеп утырды.**

Әнисе үлеменә язган шигырендә бу ике юлның бөҗра ясап кабатлануы әрнүле фикерне бер ноктага туплый. Трагизмны сүздә генә түгел, шигъри гәүдәләнештә белдерә.

Шулай итеп, шигырьләрнең тыенкы рухы, солдатларча кырыс формасы кайнар хис һәм эзләнүчән фәлсәфи фикер агымын тагын да куәтлерәк итеп күрсәтә. Бу җәһәттән шагыйрьнең гади генә бер чагыштыруын дәвам итәсе килә... «Ир һәм хатын — гади вакланмадай: ир — санаучы, хатын — ваклаучы», — ди ул. Шигырьнең тышкы формасына да шагыйрь шундый нисбәттә карыйдыр күк: ваклаучыдагы форма берүк артык чекерәеп китә күрмәсен!

Х. Камаловны төрле темалар дулкынландыра. Күңелен төрле интонацияләр били. Иҗаты тоташ уңышлардан гына тормый. (Таулары һәм иңкүлекләре булмаса, шигърият дөньясы да яссы тоелыр иде, диләр бит!) Шулай да аның теләсә кайсы шигыре төп ике сыйфатка ия: сафлыкка һәм тугрылыкка. Шушы хасиятләрне шагыйрь тормыштан, заманнан һәм замандашларыннан эзли.

**Кадерле Ильич, ниндирәк иде**
**Син хыялда йөрткән егетләр!**

. . . . . . . . . . . . .

**Нинди баһадирлар узды икән**
**Ул чагында синең уеңнан!**
**Мин аларны бик күп табам бүген,**
**Табам, Ильич, безнең буыннан.**

«Күңелдәге язулар» поэмасы — Хисам Камалов иҗатының яңа офыкларын күрсәтүче биеклек. Әсәрнең ике канаты — ачык публицистик фикерләү белән кешелек тарихына киң караш. Шагыйрь бүгенге көннәр батырлыгын Париж коммунарлары һәм Ленин яшәгән чорлар белән бәйләнештә күрә. Аның эзләнү объекты олы: революцион рухның яңа буыннарда яшәү диалектикасы. Поэманың нигезендә тирән фәлсәфи конфликт ята: бер яктан, дөреслек һәм турылык тантанасы өчен көрәш, икенче яктан, чынбарлыкның, хакыйкать өчен көрәшнең катлаулыгы, кеше хисләренең кырыс сынауларга дучар ителүе.

Лирик герой юлбашчы тормышының хәлиткеч вакытлары турында уйлана, аның образын үз тормышы, язмышы белән бәйләнештә күрә. Ләкин вакыйгалар, детальләр шагыйрьнең башка әсәрләренә караганда ныграк гомумиләштерелгән, хәтта шартлы символлар дәрәҗәсенә якынайган. Газинурлар, Мусалар — каһарманлык гәүдәләнеше булып, «хаклык дәресе биргән» замполит исә гаделлек өчен көрәшүчеләрнең бер вәкиле сыйфатында күз алдына килә.

Шагыйрьнең фәлсәфи уйланулары элеккегә караганда киңрәк колачлы, тирәнрәк тамырлы. Олы төшенчәләр турында җирдән аерылмыйча сөйләшә ул. Дөреслек — үз-үзең һәм дөнья белән авыр көрәштә генә килә торган җиңү, бу көрәштә никадәр гаделрәк булсаң, шул кадәр ныграк отасың, дигән сөземтә чыгара.

Сибгат Хәким аның шигъри җанын аңлап, якын күреп, болай дип язган иде: «Хисамны мин, ул икенче фронтта сугышып йөрсә дә, үз взводымдагы солдат кебек хис итәм...»

«Яраланган пулеметчы» турындагы шигырендә шагыйрь үзе дә шундыйрак ассоциациягә таяна:

**Калдырыгыз пулемет төбендә,**
**Мин чигенә алмыйм барыбер!**

Әйе, Хисам Камалов шигъриятгә дә үзен гади солдат итеп күз алдына китерә һәм бер адым да чигенергә уйламый. Кордашлары янында ул — окопташ һәм сугышчан дус, яшьрәк буыннар өчен — олы язмышлы абый.

Шагыйрьнең язмышы ил белән бер сафта, урыны — алгы сызыкта.

**Вахит Хаков,**
филология фәннәре докторы

# «МӘХӘББӘТНАМӘ» ӘСӘРЕ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА АНЫҢ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Шагыйрь тәбәнәк кенә, бизәкле һәм затлы өстәл янына утырган да иҗат итә. Аның бөтен игътибары ак кәгазь өстендәге юлларга, анда тезелеп баручы хәрефләргә текәлгән. Уйланып тора да, авыз эченнән көйләп, ул кинәт тиз-тиз язып китә. Шагыйрь мәңгелек мәхәббәт турында яза. Ул ышана: аның җыры күп илләргә җитәр, күп халык арасында таралыр. Әсәре гасырларга калсын иде... Шагыйрь шул турыда уйлана, шул җаваплылыкны сизә.

Чыннан да, гасырлар буе тарих пәрдәсе артында, исәпсез-хисапсыз кульъязмалар арасында ята биргән бу кульъязма, ниһаять, кабат калыкты, халыкка кайтты.

Бу нинди әсәр? Аны иҗат иткән шагыйрь кем соң?

Без, 1353 елда иҗат ителеп, төрки халыклар әдәбияты тарихында зур урын тоткан «Мәхәббәтнамә» әсәре турында сүз алып барабыз.

Шагыйрьнең тулы исеме билгесез. Ул аны әйтми, үзен Харәзми дигән псевдоним белән генә атый. Әмма шунысы ачык: әсәрдә аның Көнчыгыш һәм төрки традицияләренә тугрылыклы, оста шагыйрь, зирәк фикер иясе икәнлеге күренә. Ул үзе турында күп сөйләми, үзен беренче планга куймый, тик бүлек ахырларында гына тегеге яки бу мәсьәләгә бәйләнешле рәвештә, лирик кичерешләрен белдерә. Бу исә әсәрнең лирик-эмоциональ юнәлешен көчәйтүгә һәм үстерүгә ярдәм итә. Шуңа күрә «Харәзми» псевдонимы әсәрдә фикерне гомумиләштерүче бер символик образ булып та яңгырый.

«Мәхәббәтнамә»нең хәзерге көндә ике кульъязмасы бар. Алар икесе дә Лондондагы Британ музеенда саклана. Берсе уйгур, икенчесе гарәп хәрефләре белән язылган.

Уйгур нөсхәсе[1] гарәп әлифбасындагы күчермәгә караганда кыскарак. Безнең илгә ул фотокопия хәлендә 1952 елда кайта. 14 кәгазьдән, 28 биттән тора. Анда «Сүз башы» исеме астында 14 бүлек, 3 газәл бирелгән. Бу нөсхә әсәрнең язылуыннан соң 79 ел үткәч күчерелгән. Күчереп язучысы—Мансур исемле кеше. Әсәрнең кайчан һәм кайда күчерелүе турында ул болай дип яза: «Тәмам булды Мәхәббәтнамә китабы. Кутлуг булсын, тарих сикез йүз отуз биштә, сычкан йыл, рәҗәб айының алтысында. Йәзд шәһрендә Мир Җәлалдин буйурган үчен бу фәкыйр Мансур бакшый бөтеде».

Һиҗри 835 ел хәзерге исәп белән 1432 елга туры килә. Димәк, уйгур тексты Ман-

[1] Бу кульъязма А. Щербакның «Огуз-наме. Мухаббат-наме» (Көнчыгыш әдәбияты нәшрияты, Мәскәү, 1959) дигән китабында басылып чыкты. Автор кульъязманың транскрипциясен, русчага тәрҗемәсен һәм башка аңлатмалар бирә.

сур бакшый (бакшый — күчерүче, язучы мәгънәсендә) тарафыннан Йәзд шәһәрендә (хәзер Иран территориясендә) язылган.

Гарәп әлифбасында язылган «Мәхәббәтнамә»—шактый тулы вариант. Моны Мәскәү галиме Ә. Нәҗип бастырып чыгара[1]. Ул 47 биттән тора, барлыгы 948 шигъри юлны эченә ала. Керештән соң, язма әсәрләрдәге традицион форма буенча бүлекләрнең исеме бирелгән. Мәсәлән: «Әввәлги намәни әйтер» (Беренче хат), «Икенче намәни әйтер» (Икенче хат), «Өчүнчи намәни әйтер» (Өченче хат) һ. б. Шул рәвешчә, һәр хат аерым бүлекне тәшкил итә. Хат текстларында 11 мәснәви (янәшә, ягъни парлы рифмалардан торган ике юллык шигырьләр) аралаштырылып китерелгән. Әсәрдә мөнәҗәт тә, кыйтга да (Көнчыгыш поэзиясендә газәлнең бер төре, янәшә рифмалардан тора) очрый. Унберенче хаттан соң йомгаклау өлеше—«Хәтимәтелкитаб», «Хикайәт», «Илтимасын әйтер» бүлекләре бирелгән. Әсәрнең төзелеше менә шундый.

Гарәп хәрефле нөсхәдә кайбер бүлекләр фарсы телендә язылган. Бу—шагыйрьнең Көнчыгыш Иран культурасы, әдәбияты белән якыннан таныш булуы һәм фарсы телен яхшы белүе турында сөйли. Әсәрнең кайчан язылуы турында «Хәтимәтелкитаб» (китапның ахыры) бүлегендә мондый сүзләр бар:

**Мәхәббәтнамә сүзин мунда беттем,**
**Камугын Сыр йакасында бөтедем...**
**Бу дәфтәр кем булыптыр Мыср кәнде,**
**Йети йүз илли түрт ичрә төкәнди.**

Әсәрнең оригиналы Сыр-Дәрья буенда Арал диңгезе тирәләрендә 754 елда язылган булып чыга. Нөсхәнең 914 елда күчерелүе турында әсәрнең ахырында әйтелгән. Бу—XVI йөз башларына туры килә, димәк, ул уйгур кульъязмасыннан соңрак күчерелгән. Кем тарафыннан күчерелүе билгесез. Төрле урыннарда күчерелүенә карамастан, «Мәхәббәтнамә»нең һәр ике вариантында да тел, эчтәлек ягыннан, аваз системасындагы аерымлыклар гына күзәтелә. Моны күчерүчеләрнең төрле диалект вәкилләре булуы белән аңлатырга мөмкин. Шунысы билгеле: «Мәхәббәтнамә» әсәре ул чорда киң территориядә таралган булган. Табылган кульъязмалар шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирәләр.

«Мәхәббәтнамә» поэмасы тарихта зур социаль үзгәрешләр, олы вакыйгалар чорында языла. XIII—XIV йөзләрдә монголлар тарафыннан буйсындырылган киң территориядә Алтын Урда империясе төзелә. Күп шәһәрләр, мәдәният һәм мәгърифәт учаклары җимерелеп, харабәләргә әйләнүгә карамастан, җирле культура үзенең үсүен дәвам итә, төрки халыклар яшәгән өлкәләрдә—Идел буенда, Урта Азиядә, Якын Көнчыгышта, Кырымда уртак төрки культура үсә, әдәби һәм фәнни әсәрләр языла. Бу төрки әдәбиятны һәм культураны үстерүдә татар халкының элекке бабалары да катнаша. Ул чорларда иҗат ителгән язма әдәбият татар әдәбиятының һәм әдәби теленең үсешенә дә зур йогынты ясый. XIII—XIV йөзләрдәге төрки әдәбият турында Әмир Нәҗип болай ди: «Күп кенә төрки халыкларның (мәсәлән, үзбәк, татар, казакъ, төрекмән һ. б.) әдәбияты һәм әдәби тел тарихы Алтын Урда әдәби теле, шул чорда иҗат ителгән әдәби мирас белән тыгыз бәйләнгән»[2]. Ул чорда, фәнни, дидактик әдәбияттан тыш, зур күләмле матур әдәбият әсәрләре дә иҗат ителгән («Хөсрәү вә Ширин», «Гөлстан», «Җөм-җөмә солтан» һ. б.). Безнең заманга килеп җиткән әсәрләр арасында «Мәхәббәтнамә» дә бар.

Кешелек дөньясы тудырган әдәби җәүһәрләр арасында «Мәхәббәтнамә» поэмасы аеруча зур урын тота. Мәхәббәт турында язылган бу китап гүзәллеккә дан җырлый, кешенең эчке дөньясын, хис-кичерешләрен сурәтли. Әсәрдә мәхәббәт проблемасы иҗтимагый тормыштан аерым торган күренеш итеп түгел, бәлки җәмгыять үсеше, кешеләр арасындагы мөнәсәбәт белән тыгыз үрелеп бара. Әсәрнең беренче юлларында ук без моны ачык күрәбез:

**Олуг таңринең атын йад кылдым,**
**Мәхәббәтнамәне бунйад кылдым.**

---

[1] Хорезми. Мухаббат-наме. Издание текста, транскрипция, перевод и исследование Э. Н. Наджипа. Көнчыгыш әдәбияты нәшрияты, Мәскәү, 1961.
[2] Хорезми. Мухаббат-наме, 20 бит.

**Ике йакты гәүһәр галәмгә биргән,**
**Мәхәббәт ганҗене адәмгә биргән...** [1]

Шул рәвешле, әсәрнең башыннан алып ахырына кадәр мәхәббәтнең кешеләр тормышында тоткан урыны, аның фәлсәфи җирлеге ачыла. Әсәрдә куелган әхлакый-мораль принциплар бүгенге көндә дә үзләренең әһәмиятен югалтмаган. Мәхәббәт кешелек дөньясының иҗтимагый үсеше, аерым мораль кодекслар белән бәйле. Кешелекнең интеллектуаль үсешендә мәхәббәтнең дә роле зур булган—ул кешеләрне үстергән, бөек иткән, аларның рухи дөньясын баеткан. Шагыйрь проблеманың нәкъ шул ягына басым ясый. Ул күктәге, теге дөньядагы илаһи мәхәббәт турында түгел, ә кешеләр арасындагы саф тойгыларны зурлап җырлый.

Җәмгыятьтә мәхәббәт төшенчәсе һәр чорның үз культурасы һәм социаль җирлеге белән бәйләп аңлатыла. Иҗат өчен бу тема гасырлар буе искерми, мәңге саекмый торган бай чыганаклардан санала. Борын-борыннан укымышлылар, язучылар һәм халык чичәннәре мәңгелек мәхәббәт темасына мөрәҗәгать иткәннәр, кешелек җәмгыятендәге бу серле халәтне аңлатып бирергә тырышканнар. Моңа күп әсәрләр багышланган. Еш кына мәхәббәт төшенчәсенә бер яклы гына бәя биреп, аны кешеләр арасындагы бәйләнешләргә һәм интим мөнәсәбәтләргә генә кайтарып калдырырга омтылучылар да булган. Проблеманы иҗтимагый нигездә аңлату җитмәгән. Бу иҗтимагый күренешкә бәя биргәндә, без һәр вакыт марксистик-ленинчыл тәгълимат нигезләренә таянабыз. К. Маркс бу хакта: «Кешедәге гадәти сиземләү генә түгел, хәтта практик рухи хисләр дә (мәхәббәт, ихтыяр һ. б.), бер сүз белән әйткәндә, кеше тойгылары, кешегә хас хисси органнар да бары тик шул предметның яшәешенә, кеше табигатенә бәйле рәвештә генә барлыкка киләләр»,—дип күрсәтеп үтә[2].

Дөнья әдәбиятында мәхәббәт темасына багышланган әсәрләр аз түгел. Көнчыгыш һәм төрки әдәбиятта да аның бөеклеген һәм гүзәллеген гәүдәләндергән классик образлар—Йосыф—Зөләйхалар, Хөсрәү—Шириннәр, Ләйлә—Мәҗнүннәр, Таһир—Зөһрәләр туган.

Харәзми әсәре, мәхәббәт темасына багышланган башка әсәрләрдән аермалы буларак, үзенчәлекле итеп, үзенә бер калыпта язылган. Анда трагик ситуацияләргә нигезләнгән сюжет та, романтик образлар да юк. Шагыйрь андый юлны сайламый. Ул үз фикерен куәтләү өчен Көнчыгыш поэмаларында, дастаннарда киң таралган, халыкка мәгълүм булган образларның кайберләрен искә алып кына үтә яки аларга ишарә итә:

**Оган Йосыф җәмален сезгә бирде,**
**Мәхәббәт кимийәсен безгә бирде.**
**(Унынчы хат)**

Шагыйрь мәхәббәт темасын кешенең күңел кичерешләре, тирән психологик уйланулары аша дөньяви җирлектә ачуга зур игътибар бирә. Әсәр тулысы белән диярлек эпистоляр стильдә язылган. Төрки әдәбиятта бу һичшиксез яңа юнәлеш була. Татар әдәбияты аны киң күләмдә дәвам итә, тулыландыра һәм баетып җибәрә.

Автор, сәнгатьчә сурәтләү алымнарыннан, телнең бай мөмкинлекләреннән оста файдаланып, лирик геройны көчле эмоциональ чаралар, поэтик образлар аша тасвирлый. Ул үзенең фикерләрен еш кына киная һәм ассоциатив чаралар белән бәлдерә, чын гүзәллек һәм күркәмлек хакына күңел түреннән чыккан изге хисләрен багышлый, җирдәге матурлыкны, нәфислекне югары оптимистик рухта сурәтли.

Поэмада кучерелмә мәгънәдәге сүзләр—метафоралар, чагыштырулар, образлы сыйфатламалар һ. б. чаралар аша кеше белән табигать арасындагы бердәмлек тасвирлана. Моны, беренче нәүбәттә, кешенең портретын сурәтләгәндә ачык күрергә була. Традицион сурәтләүләр шул чорлардан ук килә. Мәсәлән, поэмада кешенең йөзен табигатьнең иң матур, яшәргән вакыты яз, чәчкәләр белән чагыштыруга киң урын бирелә. Шулай ук йөзне, кашны, күзне тасвирлау өчен ай образы кулланыла. Гәүдә төз наратлар, кипарислар, җәннәт агачлары, теш энҗеләр белән чагыштырыла.

Табигать күренешләре белән иҗтимагый күренешләр тиңләштерелә:

---

[1] Атын йад кылдым—исемен искә алдым; бунйад кылдым—иҗат иттем; ганҗене — хәзинәсен.
[2] Маркс К. и Энгельс Ф. Из ранних произведений. М., 1956. 593—594 битләр.

**Әйа намәхрибән, әхди бәкасыз,**
**Җиһан йил тик, гомер гөл тик вафасыз.**[1]
**(Унынчы хат)**

Элек-электән кеше портретын сурәтләү юнәлешендә телнең киң мөмкинлекләреннән файдаланылган. Халык иҗаты әсәрләрендә үк портретны тасвирлау чаралары барлыкка килгән. XVI—XVIII гасырларда төрки язма ядкярләрдә портретны сурәтли торган күп сүзләр, төрле алымнар очрый. Төрки халыкларда ислам дине таралу рәсем сәнгатенең үсешен шактый тоткарлауга китергән. Бу хәл язма әдәбиятта кешенең тәсен-битен, буен-сынын, гәүдә төзелешен тел-стиль чаралары аша сурәтләүгә игътибарны аеруча көчәйткән. Шул рәвешчә, төрки культура тарихында компенсация алымы туган. Язма әдәбиятның тел-стиль, тасвирлау алымнарына бай булуы, өлешчә, шулар белән дә аңлатыла. Халыклар тарихында, тыгыз бәйләнештә торган культура компонентларының бер-берсен тулыландыруы иҗтимагый кануннар җирлегендә бара. Культураны бер бөтен иткән, аның үсешенә киң юл ачкан компенсация алымы әле фәнни яктан тиешенчә өйрәнелмәгән. Киләчәктә аны комплекслы рәвештә өйрәнү бурычы тора.

Борынгы әдәби әсәрләрдә портрет алымы аша кешенең тышкы гүзәллеген һәм көчен сурәтләүгә зур игътибар бирелгән. Кол Галинең XIII йөзнең беренче яртысында иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» поэмасында, мәсәлән, портрет, образлы сурәтләү чаралары югары яңгырашка ия булган сәнгатьчә сөйләм үрнәге тәшкил итә.

Менә Зөләйха тасвирлаган Йосыф портреты:

**Һилалә биңзәр сәнең кашларың вар,**
**Энҗүйә биңзәр сәнең дөшләрең вар,**
**Гаҗәп зиба мисек йопар сачларың вар,**
**Кәндү әлен үрмәгә лайык имди...**[2]

Мондый тасвирлаулар «Мәхәббәтнамә»дә дә һәм шул чордагы башка әсәрләрдә дә киң урын алалар. Без ул сурәтләр, сүзбизәкләрнең тагы да яңа эчтәлек алып, тулыланып буыннан-буынга күчеп барганлыгын күрәбез. Мәсәлән, XVI йөз татар шагыйре Мөхәммәдьяр поэмаларында моның уңай тәэсире сизелә:

**Йөзе аның кичә туган ай тик,**
**Сүзе ширин, маһру диләрән тик...**[3]
**(«Төхфәи Мәрдән»)**

Шундый эволюцион үсеш аннан соңгы чорда да ачык күзәтелә.

XIX йөздә матур әдәбиятның киң үсеш алуы, яңа жанрларның барлыкка килүе нәтиҗәсендә портретларны куллануда да үзгәрешләр туа: бу чор өчен халык сөйләү теле үзенчәлекләре нигезендә аларны төрле жанрларда тулы һәм төгәл итеп сурәтләү хас. Бу—язучының индивидуаль стиле белән дә бәйләнгән. Үз нәүбәтендә, шул җирлектә әдәби тел дә байый. Традицияләр һәр чорга, язучының үз стиленә яраклы рәвештә үзгәрә торалар, яңа эчтәлек алып, тагы да байыйлар һәм үсәләр. Мисалга Г. Кандалый, Акмулла, З. Бигиев, Муса Акъегет һ. б. язучыларның әсәрләрен алырга мөмкин.

XX йөз башы татар әдәбиятында исә чагыштыру, охшашландыру алымына корылган портретлар, югары эмоциональ яңгыраш алып бик үзенчәлекле биреләләр. Бирелә без табигать күренешләрен һәм иҗтимагый процессларны параллель кую нигезендә ясалган традицион сурәтләрне дә, әдипләрнең үз тел-стиль алымнарын, сөйләм төзелешен дә күрәбез. Г. Тукайның «Бер рәсемгә» шигыренә мөрәҗәгать итик:

**И кояш! Ямьсезлегеңнән син оялырсың, беләм,**
**Гәр чагыштырсаң йөзеңне син бу бит алмасына.**
**Күрсә яңлыш бу матур кызның фәкать рәсмен генә,**
**Шөбһәсез, селтәр кулын Мәҗнүн дә үз Ләйләсенә.**

---

[1] Намәхрибән — сөйкемсез; әхди бәкасыз—антлар мәңгелек түгел, вафасыз—даими түгел.

[2] Һилалә биңзәр — айга охшаган; зиба—матур, зифа; мисек йопар—хуш исле; кәндү әлен — үз кулы белән.

[3] Ширин — татлы; маһру диләрән тик—айга тиң йөзле күңел юатучы кебек.

Шагыйрь стилистик максатларда аерым сүзләрнең, фразаларның кабатлануына корылган сурәтләргә аеруча игътибар итә. Бу «Татар кызлары»на шигырендә дә ачык күренә.

С. Рәмиев шигъри сөйләмдә кыскалыкка, җыйнаклыкка ирешү юлында кешенең тәсе-битен, буй-кыяфәтен үзенчә, башкалардан аерым итеп сурәтли. Моңа шагыйрь шулай ук элекке төрки поэтик традицияләр җирлегендә ирешә. «Ул» шигырен алыйк:

Кашлары — ай аның яңа туган,
Йөзе—айның тулган көннәре;
Керпекләре—нурлар кич чәчелгән,
Ике күзе—шул кичнең күлләре.

Мондый алым кыскартылган чагыштыруларга корыла, ике күренеш мәгънә ягыннан бер-беренә тәңгәл куелганда гадәттә кулланыла торган чаралардан (шикелле, кебек, төсле, күк бәйлекләреннән, -дай, -тай кушымчаларыннан, гүя теркәгеченнән һ. б. лардан башка) гына бирелә. Моның матур үрнәкләре XIII—XIV йөзләрдән үк килгән «Мәхәббәтнамә» поэмасындагы түбәндәге юллар ачык күрсәтә:

Фәләк гыйшкың юлыңда бәсару пай,
Ысыргаң данәсе—зөһрә, йөзең—ай.
(Беренче хат)

Әйа хөршид тик галәм чырагы,
Мөнәввәр чәһрәңез—фирдәвес багы.[1]
(Өченче хат)

Татар әдәбиятында ике кисәктән торган мондый чагыштырулар киң кулланылыш таба.

Мәсәлән:

Бик күңелсез бер начар ж у р н а л—г о м е р,
Анда, әлбәт, б а ш м ә к а л ә м а л ирер.
(Г. Тукай)

Кояш—безгә иптәш,
Җ и л—д у с к е ш е,
Ә җ и р инде — б е з н е ң а н а б ы з.
(Һ. Такташ)

Нур каләмен кулына тотып,
Чыгып баскан шагыйрь—кояш.
(М. Җәлил)

Портретларны тасвирлауда стилистик алымнар — сөйләмнең аерылгысыз компонентлары. Дәрдмәнднең «Рәсем» шигырен искә төшерик:

Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан,
Биткәенең иң очында миң яраткан,
Саклар өчен зифа буен яман күздән,
Чәчкәйләрен аяк белән тиң яраткан.

Биредә поэтик сөйләмнең эмоциональлеге югары, яңгырашы көчле. Моңа шагыйрь чагыштырулар белән беррәттән, иркәләү кушымчаларын урынлы куллану нәтиҗәсендә ирешә. Дәрдмәнд бу юлларны Навоидан файдаланып язуы турында әйтә. Табигый ки, Навои үзе дә элекке традицияләрдән оста файдаланган. Чагыштыру өчен «Мәхәббәтнамә»дәге түбәндәге юлларга мөрәҗәгать итик:

---

[1] Хәзерге татар телендә бирелеше:

Синең мәхәббәтең алдында күк тә акылдан яза,
К о л а к а л к а ң к а ш ы—Зөһрә йолдыз, й ө з е ң—ай.
Әй ,кояштай булган галәм нуры,
Я к т ы л ы к б и р г ә н й ө з е ң—җәннәт бакчасы.

**Аның кем ал иңендә миң яратты,**
**Буе берлә сачыны тиң яратты.**

Шул рәвешчә, традицияләр яшиләр, үсәләр һәм яңача яңгыраш алалар. Фольклорда гына түгел, язма әдәбиятта да бу юнәлеш халыкның тарихы, аның этнографиясе һәм тормыш-яшәеше белән тыгыз бәйләнгән.

Поэзиядә портретларны бирү күп яктан элекке традицияләрне саклый. Ш. Бабич «Исемнәр бакчасы»нда диган шигырендә строфа саен бер-берсен кабатламый торган портретлар галереясен иҗат итә. Анда фикер тирәнлеге, сүзнең кыскалыгы сокландыра. Гөлгенәгә багышланган строфаны гына алыйк:

**Гөлгенәнең керфекләре гөл киенгән,**
**Ике күзе кечке тонык күл диелгән,**
**Ай-кояшның ак нурларын оялтырлык**
**Күзләренә чем-карачкыл нур җыелган.**

Портретлар бирелешендә лирик һәм эстетик юнәлеш һәр вакыт өстенлек ала. Анда-эндәшү алымы да традицион сурәтләр белән бергә кушыла:

**Айлы кичләрдә әгәр чыксаң, йөзеңне нык яшер,**
**Юкса бу матур йөзеңне ай күрер дә көнләшер,**
**Ул чыдый алмас, сине күргәч, ачудан чайкалыр,**
**Ул китәр башка галәмгә, җир йөзе айсыз калыр.**

**(М. Гафури. «Бер матурга»)**

Мондый үзенчәлекләр проза әсәрләрендә дә күренә. Г. Ибраһимов «Көтүчеләр» хикәясендә сөйләмне бертөрлелектән коткару һәм лирик-эмоциональ кичерешләрне киң диапазонда тасвирлау өчен, шәфкать туташы портретын индивидуаль стиль үзенчәлекләре белән баета. Еш кына ул фикерне әйтеп бетерми, сөйләмне кыскарту— эллипсис алымы куллана. Портретның риторик сорауга төгәлләнүе дә укучыга тәэсир итү көчен арттыра. Г. Ибраһимов «Безнең көннәр» романында Разия Ширинскаяның портретын биргәндә дә сурәтләү алымнары, синтаксик-фигураль чараларның төрле төрләреннән оста файдалана. Бу юнәлеш башка проза әсәрләрендә дә киң күләмдә дәвам итә һәм тагы да үстерелә. А. Шамовның Рәүфә, М. Әмирнең Артыкбикә портретлары шуның ачык мисалы.

Без биредә портретларның барлык төренә дә тукталып үтүне максат итеп куймадык, бары тик «Мәхәббәтнамә» әсәре традицияләре нигезендә килә торган кайбер үзенчәлекләргә генә игътибар иттек.

«Мәхәббәтнамә» әсәрендә XIII—XIV йөзләрдәге төрки язма тел үзенчәлекләре киң чагылыш таба. Ул чорда иҗат ителгән әсәрләрнең бер төркемендә хәзерге татар теле үсешендә зур урын тоткан тел нормалары төп урынны били. Нәкъ шушы үзенчәлекне «Мәхәббәтнамә»дә дә ачык күрергә була. Әсәрнең сүзлек хәзинәсе, беренче нәүбәттә, борынгы төрки язма традицияне саклый (кыпчак, угыз, уйгур үзенчәлекләре һ. б.). Моның белән бер рәттән, гарәп, фарсы телләреннән кергән сүзләр дә очрый. Шул язма формалар XIV йөзләрдә халык теле җирлегендә төрле территориядә формалашып килә торган аерым төрки телләргә хас үзенчәлекләр белән тыгыз үрелеп баралар. Халык җырларындагы кебек җанлы сөйләм теленә нигезләнгән тасвирлау чаралары, янәшә рифмалы шигъри юллар әсәрнең эмоциональлеген һәм лирик агышын тагын да көчәйтәләр.

Татар әдәби теле әлеге традицияләр җирлегендә гасырлар буе үскән һәм камилләшә барган. Шунлыктан татар теле тарихын XIII—XIV йөзләрдәге язма истәлекләрдән аерып карау мөмкин түгел. «Мәхәббәтнамә» поэмасының сүзлек хәзинәсе XV—XVI, XVII—XVIII йөз татар язма әсәрләрендә нигездә саклана, күбесе хәзерге телдә дә дәвам итә. XIX йөздә һәм XX йөз башында халык сөйләү теле җирлегендә яңа әдәби телнең үсеп чыгуы нәтиҗәсендә, халык теленнән ерак торган язма китап теле сүзләренең бер өлеше кулланылыштан төшә. Моңа өлешчә архаик төрки лексика да, гарәп һәм фарсы алынмалары да керә.

Төрки телләрдә гомуми уртак сүзләр элек-электән зур урын алган. Мәсәлән: саз (уен коралы), кояш, камчы, якты, арслан, йир, йил, энҗе, олуг, багыр (бавыр), айак (азак), багу, булу, күрү һ. б. лар. Һәр төрки телдә алар телнең үзенә хас әйтелешенә җайлашканнар. Кайбер сүзләр теге яки бу телдә ешрак кулланыла. Мәгънә төсмерләрендә дә кайбер үзгәрешләр күзәтелә. «Мәхәббәтнамә» дә татар теле өчен хас, татар телендәге мәгънә үзенчәлекләрен эченә алган сүзләрне дә очратырга була. Мәсәлән, **шоңкар, ашау** (йийү сүзе белән параллель йөргән), **кояш** (хәзерге мәгънәдә; элек аның **көн** сүзе мәгънәсе дә булган) һ. б. лар. **Урам** сүзенең кулланылышы бик үзенчәлекле. Поэмада ул хәзерге татар телендәге мәгънәдә килгән. Күпчелек төрки телләрдә (үзбәк, әзербәйҗан һ. б.) бу мәгънәне бирә торган **күчә** сүзе «Мәхәббәтнамә»дә очрамый. **Аш** сүзе үзбәк телендәгечә **пылау** төшенчәсендә генә түгел, хәзерге татар телендәге кебек, киң мәгънәдә, гомумән ашау әйберен, ризыкны белдерә. Мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин булыр иде.

Әсәрдә татар теленең аерым сөйләшләрендә очрый торган үзенчәлекләр дә шактый. **Көтмәгә** (әдәби телдә көтәргә), шәкәр, **катында** (янында), **булысар** һ. б. сүзләр шундыйлар.

Татар теленә хас үзенчәлекләрнең үсеп һәм нормалашып баруы төрле сүз төркемнәрендә һәм грамматик категорияләрдә ачык чагылыш таба. Бу килеш кушымчаларында да (җиһан-**ның**, шоңкар-**га**, су-**ны**, күңелең-**дә**), алмашлыкларда да (кайда, мин, бу, моны, монда, моның), фигыль төркемчәләренең ясалышында да киң күзәтелә. Борынгы төрки язма формалар (татлыг, йүзлүг, катыг) белән беррәттән, сыйфатларда татар теленә хас **татлы, йүзле, каты** формалары да очрый. Шушы уңай белән, **аруг** (арыг) сүзенең соңгы авазы төшеп, нормалашып киткән **ару** сүзен дә (саф, чиста мәгънәсендә) игътибардан читтә калдырырга ярамый. Шул мәгънә хәзер дә үзгәрмичә татар халык телендә киң кулланылышта йөри. Әсәрдә татар теленең бай хәзинәсе булып саналган **күңел каны, йөз нуры, саба җиле, җиде галәм, таң ату, йөз ору** кебек фразеологик әйтелмәләр дә күп очрый.

Шулай итеп, поэмада татар теленең лексик, фонетик, грамматик нормалары үсешен ачыклый торган күп кенә үзенчәлекләр табарга мөмкин. Болар белән бергә элекке формалар да шактый кулланыла (тупрактин, сачыны, чыраг, баглагайын һ. б.).

«Мәхәббәтнамә» әсәрендә гасырлар буе төрки халыклар, шул җөмләдән, татар әдәбиятына хас булып килгән үгет-нәсихәт стиленең тәэсире дә көчле. Мондый стильдә язылган әсәрләрдә беренче планда кешенең иң югары әхлакый сыйфатлары— гаделлек, дуслык, тугрылык, шәфкатьлелек, юмартлык, дөрес сүзле булу, бер-береңә ихтирам, нәзакәтлелек турында сөйләнә, шул сыйфатлар пропагандалана. «Мәхәббәтнамә» әсәрендә бу сыйфатлар мәхәббәт проблемасы белән тыгыз бәйләнештә бирелгәннәр. Бу яктан «Мәхәббәтнамә» поэмасы бүгенге көндә дә үзенең кыйммәтен, тәрбияви әһәмиятен югалтмый. Ул үзенә укучыларның яңа буыннарын җәлеп итә, дөньяны танып-белергә, чынбарлыктагы күренешләрнең асылын аңларга һәм иҗтимагый аңның үсешен ачыкларга ярдәм итә.

Әсәрне тәгәл фәнни аңлатма-комментарийлар белән, халыкка аңлаешлы рәвештә һәм элекке поэтик яңгырашын саклап, аерым китап итеп бастыру да көн тәртибендә тора.

**Турсун Каhhари,**
УЙГУР ШАГЫЙРЕ

# МӘҢГЕЛЕК ФАКЕЛ

*Муса Җәлилгә багышланган поэмадан өзек*

Кырык икенче ел. Авыр сугышлар...
Канлы көн шагыйрьне хәсрәткә салды.
Камауда көрәшә сугышчан дуслар...
Яралы хәлдә ул ялгызы калды.

Буялып канына, югалтып аңын,
Нәкъ кызыл байрактай ул җиргә ауды.
Ач бүре шикелле фашистлар аның
Хәлсез гәүдәсен шундук урап алды...

Гәүдәләр тау кебек үлем даласында.
Кара болытлар каракош кук гизә.
Кызгануны белми җәлладлар монда
Канлы йөрәкләрне кол итеп изә.

Сугыш кырын баскан кызыл томаннар,
Аh-зар белән җир йөрәге тула.
Хәятка кабер казый явыз җаннар,
Канлы кулда әсирләр һәлак була.

Муса, дулкыннар ярган кораб кук,
Куркусыз карый өмет дигән ярга.
Офыкларга җиткән горур канат кук
Тилпенә, күзен текәп еракларга.

Җир шарын күтәргән кебек кулында,
Яралы кукрәген киереп, торды.
Яңгырады җырлар куңел түрендә,
Җәлладка, үлемгә ләгънәт яудырды:

— Теләсәгез, бәйләп утка атыгыз,
Ялкынлы йөрәгем көчлерәк янар.
Кабер казып, әнә, дарга асыгыз,
Без — кызгануны сорамый торганнар!
Һәлак итегез, баз, зинданга салып,
Черетеп тәнем, саргайтып йөземне.

Ватандашлар мине хәтергә алып,
Эзләп табарлар керсез эземне.

...Горур буен-сынын бөкми килде ул,
Җиңелмәс, буйсынмас кодрәтле көч күк.
Мәңге тез чүкмәскә антлар бирде ул,
Дошманнар алдында сынмас корыч күк.

Хөкем итте суды явыз җаннарның
Үлем җәзасына үлмәс Мусаны,
Үтермәкче булып изге эшен аның...
Каплап алды матәм бөтен дөньяны.

Гомере киселде шагыйрьнең зинданда,
Тибүдән туктады ялкынлы йөрәк.
Ул үлде үзе. Тик яши һаман да
Аның җырларында якты киләчәк.
...Муса — бөек һәйкәл барлык күңелдә.
Ул — мәңгелек факел, яна бүген дә.

Уйгурчадан **ӘХМӘТ ИСХАК** тәрҗемәсе

## Укучының күңел дәфтәренә

**Абхаз мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Син белмәгән озын юлдан бормалы таныш юл кыска.*
*Ат тыңламый дип, иярен кыйный.*
*Төлке кая юл тотса да, койрыгын арттан өстери.*
*Яхшы кош арттан оча.*
*Начар тексәң дә, яхшы үтүклә.*
*Начар оста килеп керсә — бөтен урман калтырый.*
*Балта белән өй салдылар, ә балта йортта ята.*
*Су — китерә, җил — очыра.*
*Җир кешесен җирдән башка бер кем дә туендырмый.*

**Авар мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Матур өй — байлык түгел ул, байлык — матур басуда.*
*Күк төсенә карама, җирнең үз төсен күрсәт.*
*Ялкау кеше батыр булалмый.*
*Тәкәббер булган этәчнең йоны бик тиз коела.*
*«Очыйк!» дисәң — ул дөя, иярләсәң — «мин — кош!» ди.*
*Дошманыннан үч алган — дустына яхшы үрнәк.*
*Килмешәк өе — авыл читендә.*
*Яхшыдан алда — яман, яманнан алда — яхшы.*
*Үзен белмәгән — кешене белмәс.*
*Кечкенә авыз зур сүз әйтәлми.*
*Авыздан чыккан уклар күзгә килеп тиялэр.*

**Адыгей мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Хәтта судагы ташлар да очрашып бәрелешә.*
*Алдыйсың килсә, мәеткә сылта.*
*Урлашканы өчен бүре тиресе белән түли.*
*Азык азая төшкәч, бозауга биргән булды.*
*Иярлесе китеп барды, ат иясе җәяү атлый.*
*Шаян сүз — хаклык илчесе.*

**Мөхәммәт Мәһдиев**

# РУС ОРИЕНТАЛИСТЛАРЫНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ ҺӘМ ТАТАР ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТЫ

Унынчы еллар татар вакытлы матбугатында даими чагылып килгән бер тема бар: ул рус ориенталистлары мәктәбенең эшчәнлеге, рус ориенталистлары турында информация, рецензия, тәнкыйть һәм алар белән полемика. Бу теманың даими рәвештә матбугат битләрендә алып барылуы һич тә очраклы хәл түгел.

1910 нчы еллар тирәсендә патша хөкүмәтенең милли политикасы тагын да реакционлаша. Хөкүмәт органнарының актив эшчәнлеге нигездә яңа революцион күтәрелештән куркып калу, милләтләр арасында, бигрәк тә рус һәм рус булмаган милләтләр арасында каршылык тудырырга омтылудан гыйбарәт иде. Реакцион милли политика беренче чиратта татарлар арасында авыр нәтиҗәләр китереп чыгарды, татарның уку йортлары ябылды, доносчылык көчәйде, азмы-күпме демократик фикер уздырган әдипләр яшерен күзәтү астына алынды. Тарих зур хата ясау алдына килеп басты: реакцион милли политика рус халкы белән татар халкы арасында дошманлык тудыруы мөмкин иде. Татар вакытлы матбугаты әнә шул тарихи хәвефтән халыкны саклап калу өчен әһәмиятле кампания башлый — газета-журналлар рус милләтенең татарларга хәерхаһ булган катлавын аерып күрсәтә. Вакытлы матбугат бу максатка рус ориенталистларының эшчәнлеген объект итеп ала һәм һәр адымында әйтеп бара: карагыз, ди, русларның менә шундый катлавы бар, алар безгә бертигез дәрәҗәдә кеше итеп карыйлар, менә болар безнең ватандашларыбыз, диләр.

Дөрес, унынчы еллардагы ориенталистика мәктәбе әле сыйнфый мәсьәләләргә кагылмый, культура-мәгърифәт-фән мәсьәләләрен генә күтәрә. Татар матбугатының аеруча зур әһәмият биргән шәхесләре — В. В. Бартольд, В. В. Радлов, Н. Ф. Катанов һ. б. эшчәнлеге патша режимы шартларында милләтләрнең үзара культура арадашлыгына омтылуы билгесе иде. Әлеге арадашлык фикерләрен либераль матбугат та уздыра иде. Ләкин матбугатта мәктәп, мәдрәсә, театр, концерт, гыйльми җәмгыятьләр, фән, әдәбият мәсьәләләрен күтәреп тә, алар мәсьәләләрне яшәп килүче самодержавие режимының асылына тимичә генә хәл итәргә омтылалар. Татар вакытлы матбугаты — бигрәк тә ул елларда даими чыгып килгән «Йолдыз», «Вакыт», «Шура», «Кояш» кебек газета-журналлар әнә шуңа күрә дә үз карашлары белән ориенталистлар карашы арасында уртаклык күрәләр һәм шул караштан чыгып рус ориенталистика мәктәбен ике милләт арасындагы дуслыкны ныгытучы күпер буларак пропагандалыйлар.

Вакытлы матбугатның ориенталистикага һәм ориенталист галимнәргә мөнәсәбәте бик сак, ориенталист галим аз гына саксыз сүз ычкындырдымы, татарларга карата

аз гына кимсетүле бер сүз әйттеме — бу турыда инде матбугат шаулый, теге галимгә чакыру ташлый, матбугатта кампания башлана. Әйтик, ориенталист С. Рыбаков 1912 елда Петербургта дамский кружокта татар-башкорт җырлары турында лекция укый һәм татар җырларының эчтәлеге турында мыскыллырак караш сизелеп ала. Бу хәл рус һәм татар матбугатында зур бәхәскә кадәр барып җитә һәм Рыбаковның мондый тонына протест белдергән мәкаләләр күренә. Венгр галиме ориенталист Вамбери турында исә 1911 елда бөтен дөнья матбугатын шаулатырлык бәхәс булып ала. Петербург агентлыгы телеграммасына таянып, «Вакыт» газетасы Вамберының «Будапешт һирлап» газетасында төрки халыкларны мәсхәрә итеп язган мәкаләсе турында хәбәр итә. Бу хәбәр Бөтенроссия мөселманнарының колагын торгыза һәм газета-журналларның барысында да диярлек протест, гаҗәпләнү күренә. Газета-журнал идарәләре килешмәү авазлары белән тула. Татар матбугатын даими рәвештә карап барган Вамбери Будапешттан «Вакыт» идарәсенә хат җибәрергә мәҗбүр була. «...Минем төркиләргә... хәерхаһлыгым мәгълүм. Мондый нахак сүз акылга сыймас» дигән сүзләр белән тәмамланган хат Вамбери имзасы белән «Вакыт»та басыла.

Татар матбугаты иң зур игътибарны В. В. Бартольд, В. В. Радлов һәм Н. Ф. Катановлар эшчәнлегенә бирә. Академик Радлов эшчәнлегенә бәя, аңа мөнәсәбәт мәсьәләсе матбугатта зур күләмдә ике тапкыр күтәрелгән. Беренчесе 1909 елда, Радловның гыйльми эшчәнлегенә 50 ел тулу уңае белән, икенчесе 1916 елның ахыры һәм 1917 елның башында — аңа 80 яшь тулу уңае белән.

Татар матбугаты зур галимнең кайсы якларына игътибар итә соң? «Вакыт»ның язуынча, татарның әдәбияты, фикере уянуга К. Насыйри белән Ш. Мәрҗани никадәр зур тәэсир ясаган булсалар, төрки теленә һәм тарихына Радловның иткән хезмәте, тәэсире дә шул дәрәҗәдәдер (1912, 90 сан). Шуның өстенә Радлов татар теленең иҗади мөмкинлекләрен ачып бирүе белән дә татар интеллигенциясенең ихтирамын казанган. Үзенең журналистлар белән булган шәхси әңгәмәләрендә ул татар теленең бик бай, сыгылмалы гыйбарәләре булуын, аның мөмкинлекләре зурлыгын күрсәткән. («Йолдыз», 1911, 651 сан). Радловның эшчәнлеге, бигрәк тә, «Йолдыз һәм «Вакыт» тарафыннан игътибар үзәгенә алына. «Вакыт» газетасы Радловның гыйльми эшчәнлегенә илле ел тулу уңае белән аның төрки шивәләре сүзлегенә зур бәя бирә: «иң олугъ тюркологка безнең телемезгә вә кавемебезгә ихлас куйдыгы өчен вә бөтен гомерен шуңа фида итдеге өчен хәлас тәшәккерәтемезне гарыз кыйлып кабулыны үтенәбез», — дип яза (1909, 469 сан).

В. В. Радловның укучыларына сүз бирелә. «Вакыт» газетасында алар истәлек белән чыгалар. Радлов Уфадагы учительская школаны тәмамлаучылар алдында речь сөйләгән икән. «Сез татарлар, — дигән ул анда, — белемгә шул кадәр сусагансыз, хәтта сусаганлыгыгызны да белмисез. Никадәр сөйләсәм дә, сезнең татар милләтенә иң зарур вә иң лязим нәрсә гыйлем вә мәгърифәт диячәгем» дип тәмамлаган ул аны. Мәгърифәтче ориенталистның бу фикерләре, нигездә, «Вакыт» газетасы тоткан юл белән тәңгәл килә һәм «Вакыт» үзенең фикердәше булган Радловның нәкъ әнә шул ягына һәр вакыт басым ясый. Радловның хезмәт юбилее матбугат битләрендә аның исеменә догалар кылуга кадәр барып җитә.

Радловның юбилее Петербургта уздырыла. Бу юбилей турында Казан һәм Оренбургтагы татар газеталары махсус сәхифәләр бирәләр. Аларда Радловның бөтен гыйлемен татар-башкорт арасында мәгърифәт таратуга гына хезмәт иттергәнлеге, үз белемен явыз ният белән файдаланмавы әйтелә. «Аның, диелә, башка галимнәрдән аермасы шунда: ул һичвакыт үзенең гыйлемен вөҗданына хилаф булган урыннарга сарыф кылмаган». Матбугат аның Казанда торган вакытта Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйри белән дус булганлыгына игътибар итә. Ориенталист Самойлович Петербургтагы татар яшьләрен оештырып кичәгә алып килә. Җыелышта татарлар да бар, дигәч, Радлов бабайның йөзләре яктырып, шатланып китте, дип яза газетаның махсус мөхбире Кәбер Бәкер. Юбилей кичәсендә доклад ясаган Ш. Мөхәммәдьяров Казандагы учительская школаның әһәмияте, татарлар арасында рус һәм Европа мәдәниятен таратуда Радловның роле турында сөйли. Кичәдә катнашучы курсистка татар кызы татарча сөйли. Радловка мөрәҗәгать итеп, ул, татар кызын караңгылыктан чыгару өчен кылган эшегез безгә бик якын, ди. Радлов үзен тәбрикләгән татар курсисткалары белән таныша, алар арасында Чистайның Закир хәзрәт кызын да күргәч, өлкән галим

хәйран кала. Чөнки Закир хәзрәт еллар буе рус теле укытуга каршы килгән кеше. Радлов бу вакыйганы берничә елдан соң да хәтерләп сөйли: «Дөньялар үзгәрде, — ди ул. — Мин Казанда вакытта рус телен укытуга иң каршы килгән кеше Чистайдан Закир хәзрәт иде. Шул гына хәтердә калган. Ә менә шуның кызы юбилейда мине тәбрик итте».

Радловның башка галимнәрдән аермасы тагын нәрсәдә? «Йолдыз» газетасы бу мәсьәлә уңаена болай ди: «Радловка кадәр дә төрки телләрен өйрәнәләр иде. Шәрык телләрен өйрәнүдән максат һәр вакыт я дин миссионерлыгы, я тел миссионерлыгы була иде. Радловның исә шәркый телләрне өйрәнүдән максаты саф гыйлем булган. Ул төрки кавемнәренең тарих вә лисаннарына мәхәббәт иткән. Бонларның тарих вә телләрени яхшылап өйрәнеп тәдкыйк итүче (дикъкать белән нечкәләп тикшерү) аз булганын күргән дә, үзе шул юлга бирелергә ният иткән. Радлов бу телләрне өйрәнүгә саф гыйлем ноктасыннан караган. Өйрәнгән саен ярата барып, ниһаять, бу телләргә вә бу телләрдә сөйләшкән төрки кавемнәргә мәхәббәт иткән. Радлов безем телләргә чын мәхәббәт илә караганыны, боларны сөйгәне, болар хакында китаплар, җилдләр язудан һичбер начар ниятләр булмаенча, анчак гыйлемгә хезмәт итү булганы һәр әсәрдә күренеп торадыр. Радлов саф гыйлемгә хезмәт итәм дип, без төрки кавемнәргә хезмәт иткән. Без телемезнең тарихын белмичә караңгылыкта яши идек. Безгә ярдәмгә Радловлар килделәр».

Шундый зур хезмәт күрсәткән кешене юбилей көннәрендә ничек ихтирамларга соң? Газета Казан җәмәгатьчелеген юбилейда сынатмаска чакыра. Һич югы, диелә газетада («Йолдыз»да), тәбрик телеграммы җибәрергә кирәк. «Радловны тәбрик — үземезнең хазиремезне вә лисанымызны тәбрикләүдер» («Йолдыз», 1909, 397 сан).

Кызганычка каршы, Радловның Мәрҗанига булган мөнәсәбәте, аның белән сөйләшүләре матбугатка язылмаган. Мәрҗани белән Радловның дус булганлыгы, семья дуслары булып йөрешкәнлеге, башка кешене кабул итмәгәндә дә Мәрҗанинең аны кабул итүе мәгълүм. Мәрҗанинең тууына йөз ел тулу уңае белән татар галимнәре һәм журналистлары бер китап хәзерлиләр. Шул уңай белән Петербургта яшәүче Радлов янына Габдулла Гыйсмәти керә. Радлов үзенең Мәрҗани белән якын мөнәсәбәттә булганын әйтә һәм күп истәлекләр сөйли. Аларны Гыйсмәти матбугатта чыгармый, чөнки Радлов чыгачак китапка аерым мәкалә итеп үзе әзерләргә вәгъдә бирә. Бу мәкалә нишләптер 1915 елгы «Мәрҗани» китабына кертелмәгән. «Мин, — ди Гыйсмәти, — монда башка якларны язам. Карт галим татар теле мәсьәләсен кузгатты. Сезнең язган әйберегезне, ди ул, гади халык аңламый. Чөнки гарәпчә бик күп катыштырасыз. Гарәп сүзе катыштырып галим булмакчысыз. Сезгә арабизмны күптән ташларга кирәк иде. Имлягызга килсәң, анысы тагы да начар. Имлягыз элекке хәлендә калса, телегезнең тәрәккый итүен һич тә көтмәгез. Сез үрнәк ала торган төрек теле — иң аламасы. Аларның телен төрек үзе дә аңларлык түгел. Гарәп йогынтысына дучар булмаган татарларның телләре чистара» («Йолдыз», 1913, 1912 сан).

Радловка «Шура» журналы да зур игътибар бирә һәм хөрмәт күрсәтә. Журнал, әйтергә кирәк, Радлов хөрмәтенә шигырь бастыруга кадәр барып җитә. Радловның төрки кавеме хакында әйләмеш хезмәте, ди журнал, һич онытылмаячак хезмәтләрдәндер. Төрки кавемнәре вәхши халыклар дигән бер фикер көчәйгән вакытта Радловның алар турында хезмәт язып чыгуы бик әһәмиятле эш булды. «Шура» аны «Мөхтәрәм пир» дип атый.

Академик Радлов Петербургта яшәгәндә татар дөньясыннан шактый нык аерыла. Сәламәтлеге какшагач ул татар әдәбиятын укымый, газета-журналлар алдырмый. Әйтик, реакция һәм революцион күтәрелеш елларында нык кына үсеп киткән татар әдәбиятын ул белми, хәтта 1913 елда да Тукайны ишетмәгән була. Шулай да татар культурасына элек иткән хезмәтләрен искә алып, киң катлау җәмәгатьчелек, татар укымышлылары 1917 елның башында аның исемен кабат матбугатка күтәреп чыгалар. Татар матбугаты 1917 елның 5 гыйнварында Радловка 80 яшь тулуны билгеләп үтә. «Йолдыз» һәм «Вакыт»ның 6 нчы гыйнвар саннарында Радловка багышланган мәкаләләр, телеграммалар күренә.

«Йолдыз» идарәсе аңа үзеннән шундый телеграмма күндерә: «Мөхтәрәм Василий Васильевич! Сезгә 80 яшь тулу мөнәсәбәте илә затыңызны самими котлыймыз. Безнең арамызда халис мәгариф тарату юлында күп эшләгән гарызсыз педагог булуыңыз

сыйфаты илә дә һәм бахосус тюркологиядәге кыйммәтле гыйльми әсәрләреңез илә дә сезнең кадреңезне бик беләмез. Кыйммәтле, файдалы гыйльми хезмәтләреңезне дәвам иттерү өчен аллаһы тәгалә сезгә дәхи дә күп еллар яшәүне насип итсен».

«Вакыт»та зур мәкалә һәм Радловның рәсеме басыла. «Без үз тарафымыздан бу олугъ вә мөхтәрәм гыйлем хадимен 80 яшькә җитүе белән тәбрик итеп, тагы да күп еллар гыйлем мәйданында якты бер чыраг булып торуыны җәнап хактан сорыйбыз», — дип язылa анда.

Революциягә кадәрге матбугатта академик Василий Владимирович Бартольдка да зур урын бирелә. Мәгълүм булганча, Бартольдның иҗат чоры ике заманга — революциягә кадәрге һәм революциядән соңгы заманга бүленә. Аны совет галиме дип атыйлар. Шулай да Бартольд Октябрь революциясенә кадәрге чорда ук инде үзен танытып өлгергән галим. Дөрес, ул чорда әле ул тарихи процессны аңлауда нигездә идеалистик позициядә торган. Ләкин Бартольдны һәр вакытта да үзе өйрәнә торган халыкның социаль-экономик шартлары кызыксындыра. Бартольд яшәп килгән бик күп тарихи доктриналарны өр-яңадан карап чыга. Хаталарны төзәтә һәм көнчыгыш халыклары тарихы буенча искиткеч зур материал туплый. Бартольд Совет хөкүмәте заданиесе буенча зур җаваплы гыйльми эшләр башкара. (Урта Азия университетын оештыра һ. б.).

Татар вакытлы матбугаты Бартольдны ни өчен игътибар үзәгенә ала соң? Язган хезмәтләренә караганда, Идел буе татарлары беркайчан да Бартольдның махсус өйрәнү объекты булмаган бит! Моның да хикмәте бер генә әйбергә кайтып кала: самодержавиенең реакцион шовинистик политикасы котырынган бер чорда академик Бартольд мөселман халыклары тарихын өйрәнүне киң җәелдереп җибәрә, аларга ихтирам белән карый. Татар матбугатындагы демократик агым зур галимнең беренче чиратта әнә шул симпатиясен сизеп ала һәм аның хезмәтен, эшен пропагандалый башлый. Моны күтәрү дә татар халкын рус милләтенең ике милләт икәнлегенә, пуришкевичлар милләтеннән Чернышевскийлар, Белинскийлар милләтен аерып карарга өйрәтүгә хезмәт итә. Ф. Кәрими язуына караганда, рус галимнәренең безнең хакта хезмәтләре күбрәк булса, «бер тәкам ялганчы, ифтирачы вә доносчылар өчен урынлы-урынсыз борыннарын тыгып мөселманнар илә руслар... арасына суыклык төшерергә юл бикләнер иде» («Вакыт», 1911, 811 сан).

«Вакыт» газетасы Бартольд эшчәнлеген шул рәвешчә ике милләт арасындагы дуслыкны ныгытучы фактор буларак күтәрә. 1913 елның апрель аенда академик Бартольд Уфа—Оренбург ягына сәяхәткә чыга дигән хәбәр татар вакытлы матбугатын шаулата. «Вакыт» идарәсе моңа зур әһәмият бирә. Бартольд безнең тарихыбызга кагылса, һичшиксез тарихыбыз бәхетле булыр иде, дигән өмет белдерелә. Газета Бартольдның бөтен хезмәтләрен санап чыга да бәхәсләшергә бүген дә урын калдырмый торган фикер әйтә: «Аның бу әсәрләре, — ди, — гаять зур гыйлем, чиксез иҗтиһад һәм күп вакыт исбат итә торган исабәт тугры фикер илә язылганнар. Бартольд... тарихымызның иң олугъ һәм бу көнгә кадәрге муәррихлары арасында иң гадел бер галим саналырга тиешдер» («Вакыт»,1913, 1224 сан).

Бартольд Оренбургка килгәч «Вакыт» газетасы аның һәр адымы, очрашулары турында тулы информация биреп бара. Оренбургта ул «Вакыт» редакциясенә килә, Ф. Кәрими белән әңгәмә ясый. Ике көннән соң Бартольд Ф. Кәрими белән берлектә мәдрәсәи «Хөсәения»гә килә, андагы китаплар, программа белән таныша, Оренбург мөселман җәмгыятенең китапханәсен, Кәрвансарайны карый. Хөсәеновлар аңа автомобильләрен бирәләр, Ф. Кәрими һәм доктор Попов зур галимне Каргалыга алып баралар.

Бартольд Стәрлебаш мәдрәсәсендә дә була, аның программасы, дәресләкләрен тикшерә, борынгы кульъязмалар белән таныша, зиратка барып борынгы ташларны өйрәнә. Мәдрәсә хәлфәләренең шәхси китапханәләрен карый. Бартольдка хәтфә белән тышланган иске кульъязма «Стәрлебаш тарихын» бүләк итәләр. Бу кульъязма хәзергә көндә Бартольдның архивында булырга тиеш.

Бартольд гомере буе татар матбугатын, фәнни хезмәтләрне күзәтеп барган кеше. Татар матбугатыннан ул «Вакыт» белән «Шура»ны яратып укыган. «Вакыт» һәм «Шура»да аның мәкаләләре дә басылган. Татарлар арасында үзенең хезмәтләрен белүче кешеләр булганга чын күңелдән шатланган. Татар газеталары аның ачык йөзле, мө-

лаем, хакыйкатьпәрвәр зат икәнлеген язалар. «Шура» еш кына аның хезмәтләренә кагыла, аны телгә ала. Арадан берсендә аның сүзләрен китергәндә хата җибәрә. Бартольд моңа зур игътибар бирә һәм «Вакыт»ка хат яза. Анда, ди, галим, минем тарафтан төрки халыклары адресына каты сүз әйтелгән дигән фикер аңлашыла. «Төрки милләте хакында һичбер вакыт вә һичбер урында миннән садир булмаган (башланмаган) каты сүзләр миңа нисбәт бирелмәсен иде, минем өчен анысы бик әһәмиятле». «Шура» болай җавап бирә: «Остазларымыз булган Григорьев, Бартольд, Радловларның әсәрләре белән танышлыгымыз арткан саен ул хаталар кими барырлар. Ул хаталарны гыйльми максатта төзәтеп барырга кирәк. Россиядәге төркиләр илә руслар арасында инде искедән бирле дәвам итеп килгән аңлашмау, бер-береңнән читләшү бетәргә тиеш. Болар арасында инде хәкыйкый мөнәсәбәт, кулга-кул тотышып бару башлансын иде».

Татар матбугаты битләрендә болардан тыш академик Федор Евгеньевич Корш, профессор Катанов, Йосиф Готвальд турында язылган бик күп җылы материаллар табарга мөмкин. Материал сайлап алуда критерий бер генә: ул галимнең татар халкына мөнәсәбәте. Корш турында зур материаллар бирү дә шуңа кайтып кала. Ул, ди, «Вакыт» газетасы, безне сөйде, безнең хакыбызда йөз яктылыгы булырлык сүзләр әйтте. Россиядә шәрык гыйлемнәре белән шөгыльләнүчеләр байтак булса да, үзләренең белекләрен хәкыйкатькә генә хезмәт иттерүчеләр, безгә дә үз белекләреннән файда тигезүчеләр бик сирәк очрый. Ахыр гомерендә мөстәшрыйкъ булган Корш безне бик якын күрде, шул нисбәттә үзенең вафаты белән безне артыграк кайгыга төшерде» («Вакыт», 1915, 1910 сан).

Ориенталист Н. Ф. Катановның татар культурасы өлкәсендәге роле матбугатта галим Петербургка күчеп китәр алдыннан күтәрелә. Моны иң актив күтәрүче органнардан «Йолдыз»ны күрсәтергә мөмкин. Эш шунда ки, Катанов китәр алдыннан үзенең китапханәсен Казанда сатып калдыру турында хәбәр бирә. Бу мәсьәлә буенча «Йолдыз» бөрөзлексез информация биреп бара.

Либераль газета мәсьәләне либералларча ача: газета битләрендә татар байларын шушы китапханәне сатып алырга үгетләү башлана. 30 мең сумлык китап 10 меңгә сатыла дип хәбәр бирелә. «Йолдыз» китапханәнең нидән торганын белмичә сөйли. Моны «Вакыт» ачып бирә. Китапханә нигездә төрки китаплардан, букинист, антикварлардан җыйган китаплардан тора. Анда кульъязмалар күп. Бөтендөнья ориенталистларының иң сирәк китаплары бар. Атласлар, рәсемнәр. Барлыгы 10 мең том чамасы — 24 шкаф, һәр шкафта 6 шүрлек китап. «Вакыт» газетасы моны сатып алырга Уфа, Оренбург байларын өндәп карый. Казанда өмет юк, булдыра алмаслар, ди. Анда хаҗәтсенү күренми. Моны сатып алсак, «берничә ун мең сумлар сарыф итеп, бәгъзы бер хәзрәтләрнең исемнәре, шөһрәтләре өчен салынган мәдрәсәләрдән, авылларны вак кисәкләргә бүлеп теләгән кешеләрне имам итмәк өчен салына торган мәсҗетләрдән әллә никадәр артык файдалы һәм саваплы эш булыр иде» («Вакыт», 1913, 1213 сан). Шунысы характерлы, һәр ике газета бу очракта динне тәнкыйть итә. Нинди сак «Йолдыз»да болай дип яза: «Шушы китапханәне алырга бер бай табылмады. Үткән елларда Казанда бер атаклы бай 15 меңгә төшереп кирәкмәгән урында мәчет салдырды. Әгәр бер кеше мөфти хәзрәт исеменә мәчет салырга яки көмеш комган бүләк итәргә дисә иде, һичшиксез, күбрәк тә җыелыр иде. Бездә урманга утын ташучы, диңгезгә су ташучы байлар байтак. 50 шәр сум гына җыйыйк. 200 бай юкмыни? Халыкның алга китүендә, аның төрле фәннәрдән җиңеллек илә хәбәрдар булып мәгълүматын арттыруында иң зур урын тотучы, шөбһәсез, китапханәдер».

Казан шулай үгет-нәсихәт сатып ятканда Төркиянең бер вакыфлар назәрәте «Йолдыз» аркылы китапханәнең хакын сорап ала. Озак та үтми, бу китапларның бәясенә килешеп вакыфлар назәрәте гыйльми мөәссисләр назире Рәшид бәкне Россиягә җибәрә. «Йолдыз» һәм башкалар китапханәнең ничек сатылганын күзәтәләр.

1914 елда М. Акъегетзадәнең сеңлесе Хәдичәнең кияве инженер-полковник Гомәрбәй килеп, китапханәне төяп алып китә. Китапханәне Алтын Мөгез ярына бер бина салып урнаштыралар. М. Акъегетзадә моны эшкәртү өчен Стамбулдагы татар студентларыннан бер группа төзи. Китапханә нигезендә Төркиянең тюркология институты төзелә. Китапханәдә барлыгы 22 телдәге китаплар була. М. Акъегетзадә боларны эшкәртә башлагач Төркиядә кульъязмалар җыю кирәклеге турында фикер туа һәм бу

эш башлана. М. Акъегетзадә Катанов китапханәсен каталогка алып бетерә алмыйча үлеп китә, ләкин Төркиядә китапны, кульъязмалар җыю, эшкәртү инде кузгалган була.

Татар матбугаты исә китапханә ычкыну уңае белән аһ оруын дәвам итә. Бу уңай белән рус галимнәренә, аларның хезмәтләренә игътибар итү кирәклеге мәсьәләсе тагын да күтәрелә. «Катановлар да надан татар дөньясы тарафыннан һич тә игътибарга алынмый үтеп баралар. Анларның барганнарына руслардан артык безләр әһәмият бирергә тиешле булсак та, наданлыгымыз шомлыгында мәгаттәэссеф әһәмият бирә алмыйбыз. Мөхтәрәм Катановның язган нәрсәләре татарлар өчен бик мөһим булсалар да, без бу урында аның язганнарыны, күп булдыклары сәбәпле, зекер итә алмыйбыз»,— дип яза «Шура». Катанов, ди журнал, «татар галимнәренең төшенә дә кермәгән китапларны телгә алып сөйли. Ә бездә мәдрәсәләрдә егермешәр ел гомер череткән җаһил руханиларыбызны карагыз инде. Кемдер әйткән иде. Катановны чиртсәң гыйлем чыга, дип. Безнекеләргә чиртсәң, җәһаләт белән хәйваният кенә чыгарырга мөмкин».

Катанов китапханәсе уңае белән татар матбугаты шул рәвешле татарлар арасындагы фикер торгынлыгын, схоластик тәртипләрне тәнкыйть итә, гыйлем юлында руслардан өйрәнергә чакыра. Тик шунысы кызганыч, Катанов үзенең элгәре булган Иосиф Федорович Готвальдтан үрнәк алмаган. Гарәп һәм фарсы телләренең ординар профессоры И. Ф. Готвальд университетта көнчыгыш бүлеге ябылгач Петербургка күчеп китми, Казанда китапханәче булып ала; аның кызы Йозефина Иосифовна Креллен-берг әтисенең васыяте буенча Казан университеты китапханәсенә зур-зур 10 сандык китап тапшыра. Бу китапларны Катанов эшкәртеп чыга, каталогын төзи.

Нәтиҗә ясап шуны әйтә алабыз: татар вакытлы матбугаты 1910—17 елларда патша хөкүмәтенең реакцион милли политикасына җавап йөзеннән рус культурасы, прогрессив карашлы рус галимнәренә ихтирам тәрбияләгән. Максатка ирешүдә ул төп объект итеп ориенталистика мәсьәләләрен алган. Бу иң уңай өлкә булган.

Татар матбугатында ориенталистика мәсьәләләре һәр вакытта да ике халыкның культура арадашлыгын ныгыту максатында каралган, шул уңай белән татарлардагы фикри торгынлык, гыйлем өлкәсендәге феодализм калдыклары тәнкыйть ителгән.

Дөрес, татарларның культура, аң-белемдә артта калуының сәбәпләрен ачу юнәлешендә ориенталистлар мәгърифәтчеләр дәрәҗәсендә калганнар. Халыкның наданлыгын аларның кайберләре милли сыйфат итеп билгеләргә омтылган, аларның күбесе төрки группасындагы халыкларны бер бөтен итеп караган һ. б., һ. б. Болар барысы да ориенталистларның үз эшчәнлекләрен тар күләмдә генә алып барулары, тарихны аңлауда марксистик позициядән ерак торуларының нәтиҗәсе. Әмма рус ориенталистлары самодержавие тарафыннан икеләтә изү астында иза чиккән татар халкына ярдәм кулы сузганнар, халыкны агарту өчен үзләре булдыра алганча хезмәт иткәннәр.

Бүгенге фәндә, тарихта алар әнә шул — булдыра алганча, шартлар мөмкинлек биргәнчә иткән хезмәтләре өчен тәкъдир ителергә лаек кешеләр.

## Гамир Дәүләтшин

# БОЛГАР ЯЗМА КУЛЬТУРАСЫ

Монголлар һөҗүменә кадәрге чорда (X—XIII гасырлар башында) Идел Болгарстаны политик һәм экономик яктан шактый алга киткән дәүләт була. Чагыштырмача зур үсешкә ирешкән материаль культура, илнең мөстәкыйльлеге, территория бөтенлеге, болгар кабиләләренең халык булып формалашуы Идел Болгарстанында рухи, шул исәптән, язма культура үсеше өчен дә нигез булган.

Болгар язма культурасына, аерым алганда әлифба, уку-язу, мәгърифәт, фән башлангычларына багышланган махсус тикшеренүләр әле фәндә күренми. Шулай да Х. М. Френ [1], В. В. Григорьев [2], А. Ф. Лихачев [3], Ш. Б. Мәрҗани [4], Г. В. Юсупов [5], Х. Р. Курбатов [6], Г. А. Таһирҗанов [7], А. Х. Халиков [8] һ. б. үзләренең хезмәтләрендә бу мәсьәләгә өлешчә кагылып үтәләр. Шиһап Мәрҗани моңа кадәр билгеле булмаган чыганаклар нигезендә болгарлардагы фән торышы турында шактый күп мәгълүматлар китерә. Әмма тикшеренүчеләрнең күбесе бу хакта билгеле язма чыганакларны кабатлау белән генә чикләнәләр. Әйтелгән фикерләр, фаразлар фактик материаллар белән ныгытылмый.

Болгар җәмгыяте үсешкә ирешә барган саен, гомум аңлаешлы, бердәм һәм камил язуга ихтыяҗ тагын да көчәя. Кешеләрнең аралашуын, культура тәҗрибәсе туплануын һәм җәмгыять үсешен тәэмин итүдә мәгърифәтлелекнең әһәмияте ачыграк була бара.

Үзәкләшкән дәүләт аппараты да бердәм язусыз яши алмаган. Мәсәлән, ясак-салымнар җыю тәртибе исәп-хисап кәгазьләре кертүне таләп иткән.

970 елларда Дунай буена киткән болгарларның Венгр корольлегендә хисап эшләренә билгеләнүе болгарларның элгәрге дәүләт оешмаларында ук исәп-хисап эшләренең шактый югары куелышы хакында сөйли. Бердәм язуга суд эшләре дә мохтаҗ булган. Шикаятьләр һәм хөкем карарлары язмача алып барылган. Болгар казыйлары Якуб ибн-Ногман һәм Әбел-Гала Хәмид ибн-Идрис әл-Болгарилар үз заманының мәгърифәтле кешеләре булганнар. Болгар илендә феодализм ныгыган саен, эш кәгазьләрендә законлаштырылган шәхси милекнең роле дә арта барган. Шәригать законнарыннан аермалы буларак, мәҗүси болгарларда милек атадан улга түгел, ө туганнан туганга күчкән. Әле шәригать кануннары тулысынча үтәлә башлаганчы, мондый хәл күп кенә аңлашылмаучылыклар китереп чыгарган дип уйларга мөмкин. Ә бу очракта инде язма васыятьнамәләрнең әһәмияте зур була.

---

[1] Ch. M. Fraehn. Drei münzen der Wolga-Bulgarien aus dem X. jahrhundert N. Ch. erlätert. SPB, 1816.

[2] Григорьев В. В. Волжские булгары. — «Россия и Азия». М., 1876.

[3] Лихачев А. Ф. Великая Булгария. Казан дәүләт университеты китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк очрый торган китаплар бүлеге, 167 эш.

[4] Мәрҗани Ш. Мөстафад-эл-әхбәр... Казан, 1897.

[5] Юсупов Г. В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.—Л. 1960.

[6] Курбатов Х. Р. Татар алфавиты һәм орфографиясе тарихы. Казан, 1960.

[7] Таһирҗанов Г. Әдәбият тарихында иҗтимагый—мәдәни мөнәсәбәтләрнең роле. «Казан утлары», 1975, 8 сан.

[8] Халиков А. Х. Культура народов Среднего Поволжья в средние века (X—XIII вв.) «Вопросы истории» журналы. М., 1976, 4 сан.

Болгар шәһәрләрендә исемле печать-мөһерләрнең еш табылуы болгарларда исәп-хисап, эш кәгазьләре системасының югары үсеше хакында сөйли. Яхшы грамоталы булуны дәүләтара бәйләнешләр да һәм, беренче чиратта, дипломатия эшләре дә таләп иткән. Безгә билгеле булган рус-болгар килешүләренең төп нөсхәләре, һичшиксез, ике телдә дә булгандыр. Бу хакта 985 елгы килешүдән аңлатма табарга мөмкин: аңа болгар әйтеме дә кертелгән. Анда ... толи не буди мира межи нами, оли же камень начнет плавать, а хмель грязнути»[1], — дип язылган. Бу әйтем «кайчан кем колмак суга батар, таш суга калкыр, бу вәгъдә шунда бозылыр[2]» рәвешендәге татар халык мәкалендә сакланып калган. 1006 елгы килешү буенча болгар сәүдәгәрләренә Русь җирендә тоткарлыксыз сәүдә өчен ышаныч язулары бирелгән[3]. Шундый ук ышаныч язулары Болгар дәүләте аппараты тарафыннан Болгар илендә сәүдә итүче рус сәүдәгәрләренә дә бирелгән дип уйларга кирәк. Мондый грамоталар мөһер-печать рәвешендә дә булганнар. Шундый бер печать Биләрдә рус һөнәрчесенең гарәбә мастерскоенда табылды. Аның өслегендә җайдак сурәте, Новгород кнәзе Всеволодның исеме һәм 1222—1224 еллар дигән язу бар.

Дәүләтара башка мөнәсәбәтләр дә нигездә язмача хәл ителгән. Алмас патша 922 елда хәлифәгә хат җибәрә, шулай ук төньяк кабиләләре белән дә хат алыша[4]. Әле гарәп графикасы таралганчы болгарларда төрки (орхон) руннарына хас алфавит кулланылышта була. Маяцк, Саркель, Абоба-Плиска (Болгария) шәһәрләрендә, Новочеркасск музеенда, Сент-Миклош хәзинәсендә (Венгрия) болгар-хазарларга караган рун язулы әйберләр очраганлыгы билгеле. Болгарлар килеп утырганчы ук, берничә мәртәбә төркиләшүгә дучар булган Идел, Кама буйларында да рун язулы археологик истәлекләр табыла[5]. 1958 елда Мари АССРның Юрино авылы янында табылган ташта X—XII йөзләрдәге төрки-орхон графикасына якын язу бар[6]. X—XII гасырларга караган мондый язулар Кама буенда табылган көмеш коелмаларда да очрый[7].

Рун язуларының бу районнарда X—XII гасырларга караган материалларда очравы өлеге графиканың гарәп әлифбасы таралганнан соң да кулланылыштан бөтенләй үк төшмәвен күрсәтә. Шулай да борынгы язуның язмышы хәл ителгән була инде: ислам дине ныграк үтеп кергән саен, мәҗүсилекнең бер чагылышы буларак, болгарлар тормышыннан ул кысрыклап чыгарыла. Алар тамга-билге ролен генә үти башлыйлар. Биләр шәһәрләрендә табылган чүлмәк савыт-сабаларда бөтенләе белән диярлек төрки-орхон әлифбасын кабатлаучы 20 дән артык төрдәге тамга очрый. Алар арасында иң нык таралганы — төрки-орхон әлифбасында «Б» авазын белдергән үзенчәлекле тамга. Мөгаен, ул «Болгар», «Биләр» сүзләренең баш хәрефен аңлаткандыр. Аерым тамгалар кабилә, кнәзьлек билгесенә әверелә. Бетүгә йөз тоткан мондый тамгаларны болгарлар төньяк кабиләләре белән алып барылган сәүдәдә үз товарларына да куйганнар.

IX—X гасырга караган нумизматик материаллар (металл акчалар) болгарларга гарәп алфавитының иртә үтеп керүе һәм таралуын күрсәтә. X гасырда ул болгар акча сугучыларының үзенчәлекле матур язу рәвешенә, грамоталылыкка ия булулары билгеле. Болгар иленә гарәп әлифбасының үтеп керүе дә иң беренче чиратта Урта Азия белән тыгыз сәүдә мөнәсәбәтләре нәтиҗәсе булып тора.

Болгарлар баштагы чорда гомуми язышу материалы буларак яхшы эшкәртелгән тузлардан файдаланганнар. «Тузга язмаганны сөйләмә» дигән әйтем, беренчедән, безнең бабаларның язу материалын күрсәтсә, икенчедән, аларның язуга чиксез хөрмәтен дә чагылдыра. Тузларга һәм балавыз такталарга болгарлар рус «писала»ларын хәтерләткән, матурлар эшләнгән очлы сөяк таякчыклар белән тырнап язганнар.

X гасырлардан башлап, болгарларда Хәрәзмнән килгән мамыктан эшләнгән кәгазь

---

[1] Татищев В. Н. История Российская. М.—Л., 1964, 4 том, 133 бит.
[2] Татар халык мәкальләре. Җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. 3 томда, Казан, 1967, 780 бит.
[3] Татищев В. Н. История Российская. 2 том, 69 бит.
[4] Ковалевский А. П. Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921—922 г. Харьков, 1956, 134 бит.
[5] Халиков А. Х. Истоки формирования тюркоязычных народов Среднего Поволжья и Приуралья. Сб. «Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья и Приуралья». Казань, 1971, 28 бит.
[6] Тенишев Э. М. Камень с рунической надписью из Юрино. Сб. «Лингвистический сборник», Ташкент, 1971, 23 бит.
[7] Халиков А. Х. Татар халкының килеп чыгышы. Казан, 1976, 26 бит.

төп язу материалына әверелә. Болгар археологик материаллары арасында балчыктан яки бронзадан эшләнгән кечкенә кара савытлары очравы да кәгазь кулланылуын күрсәтә. Безнең көнгә кадәр бу кәгазь китапларның кыйммәтле ташлар куеп бизәкләнгән бронза тышлыклары гына сакланып калган.

Язмалардан күренгәнчә, болгарлар гарәп каллиграфиясенең төрле мөмкинлекләреннән файдаланып язганнар. Язу нигездә сульс стилендә булган, ә куфи, традиция буларак, эпитафик язмалар һәм архитектура төзелешләрен бизәү өчен генә кулланылган.

Гарәп графикасы Көнчыгыш мөселман дөньясы белән Идел Болгарстаны арасында үзенә күрә бер күперчек ролен үтәгән. Ул болгарларны Көнчыгышның дөньякүләм әһәмияткә ия булган фән һәм культура казанышлары белән таныштырган. Бу хәл болгарларда мәгърифәтнең тиз үсүенә дә этәргеч ясаган. Инде X гасыр башында ук фарсы сәяхәтчесе Ибн-Рустә күпчелек болгарларның ислам дине тотуын, шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да башлангыч мәктәпләр булуын яза[1].

Халык арасында грамоталылык таралу белән югары үскән язма культурага таянучы ислам дине дә кызыксынган. Чөнки гарәпчә укый-яза белү турыдан-туры корьән, дини трактатлар, мәҗүсилеккә каршы юнәлтелгән дидактик әсәрләр белән танышырга мөмкинлек биргән. Корьәннең үзе кебек үк изге хисапланган гарәп хәрефләрен дога итеп ятлаганнар. Мәҗүси бөтиләргә дә корьәннән алынган сүрәләр языла башлаган. Еш кына бу амулет-язу өчен болгарларда яхшылап шомартылып язарлык хәлгә китерелгән хайван калак сөякләре файдаланылган. Элек татарлар юраганда башка күп кенә төрки халыклар кебек үк шундый калак сөякләреннән файдаланганнар[2]. Шомартылган һәм төрле билгеләр сызылган бу калак сөякләре археологик истәлекләр арасында да очрый. Тамгалы яки руник язулы, ә соңрак инде гарәп хәрефле калак сөякләре тагылып йөртелгән.

Халыкның шактый киң катлауларына грамоталылык үтеп керүгә болгар һөнәрчеләре эшләгән әйберләр дә дәлил була ала. Чокып яки батырып язылган язулар әерүча чүлмәкчеләр, асылташчылар, коралчылар һәм металлдан тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары эшләүчеләрнең әйберләре арасында очрый. Чүлмәк ватыкларында «Дауд», «Адәм» кебек кеше һәм «Болгар», «Биләр» кебек шәһәр исемнәре бар. Мондый язулар белән бергәттән кайчак руник хәрефләр дә урын алган. Бизәү әйберләреннән язулы көмеш беләзекләр, йөзекләр, бронза көзгеләр аерылып тора. Бер болгар йөзегендә «Арслан» дигән кеше исеме язылган. Күрәсең, «Кулымдагы йөзегемнең исемнәре...» дип ул чорда ук җырлаганнар. Биләрдә табылган материаллар арасында язулы кылычлар да бар.

Ислам дине таралу дини мәктәпләр зарурлыгын да китереп чыгарган. Болгарларның мәгариф системасы турында чыганаклар аз булганлыктан, бу хакта анык фикер йөртүе авыр. Шулай да кайбер чыганаклар нигезендә һәм аналогияләр юлы белән, схематик характерда булса да, бу мәсьәләгә бераз ачыклык кертергә мөмкин.

Ибн-Рустә хәбәр иткән башлангыч мәктәпләр Болгар илендә шактый киң таралыш алган: сәяхәтче аларның болгар авылларында да булуын яза. Аларда имамнар һәм мәзиннәр укыткан, укыту тулаем диярлек дини характерда булган. Монда укырга, язарга өйрәнгәннәр һәм дини әсәрләрне ятлаганнар. Югарырак баскыч уку йорты ролен үтәгән мәдрәсәләр башкалада һәм эре шәһәрләрдә урнашкан. Болгар һәм чит ил галимнәре шушы мәдрәсәләрдә белем алганнар. Мөселман илләрендәге кебек үк, биредә төп игътибар дини тәгълиматны, догмаларны ятлауга, дин әһелләре әзерләүгә юнәлдерелгән. Укыту корьәнне аңлату (тәдрис) һәм өлешчә әйтеп яздыру (имла) белән барган. Дин әһелләрен әзерләүдән тыш, мәдрәсәләрдә арифметика, астрономия, медицина, география, тарих кебек дөньяви фәннәрдән дә мәгълүматлар бирелгән. Бу дәүләт чиновниклары, сәүдәгәрләр, табиплар әзерләү өчен кирәк булган. Болгар мәдрәсәләрендә белем алган табип, тарихчы, шагыйрьләрнең булуы шул хакта сөйли. Илдән читкә китеп, Көнчыгышның Бохара, Сәмәрканд, Газна, Нишапур, Балх, Багдад, Мерв кебек фән һәм культура үзәкләрендә белем алып кайту болгар мәгариф системасының үзенә күрә өченче баскычын тәшкил иткән. Аларда

[1] Хвольсон Д. А. Известия о хазарах, буртасах, мадъярах, славянах и руссах Абу Али Бен-Омар ибн-Даста... Спб. 1869, 23 бит.
[2] Татар халык мәкальләре, җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт, 3 томда, III том, 970 бит.

бер төркем болгар укымышлылары күренекле көнчыгыш галимнәреннән белем алганнар.

Болгарларда гарәп, фарсы кебек классик көнчыгыш телләрен белүгә дә игътибар бирелгән. Болгар галимнәре һәм дин тәгълиматчылары үзләренең әсәрләрен ул чордагы фән, дин теле һәм гомумән мөселман илләре өчен дәүләтара китап теле булган гарәп телендә язганнар. Ә фарсы теле XI гасырдан башлап көнчыгыш поэзиясенең төп теленә әверелә. Көнчыгыш һәм рус телләрен белү сәүдә, илчелек эшендә дә кирәк була. Моннан тыш Болгар илендә Көнчыгыштан һәм күрше рус дәүләтеннән килгән дин таратучылар, һөнәрчеләр дә аз булмаган. Ибн-Фадлан үз язмаларында Һиндстанлыны, Бохара тегүчесен телгә ала[1]. Багдад илчелегендә гарәп, иран архитекторлары, һөнәрчеләре күп булган, Биләр шәһәренең архитектура төзелешен өйрәнүчеләр шәһәр төзелешенә аларның турыдан-туры катнашуларын әйтәләр. Моннан тыш башкалада христиан колониясе кебек чит ил сәүдәгәрләре колонияләре дә урнашкан. Аларның барысы да болгарларның чит телләрне үзләштерүенә тәэсир иткәндер. Аерым алганда, гарәп телен белү болгар һөнәрчеләре эшләгән әйберләрдәге язулардан да күренә.

Халыкның күп тел белергә омтылышы фольклорда һәм борынгы әдәбият үрнәкләрендә дә чагыла. «Җиде йортның телен бел, җиде төрле белем бел» диелә татар халык мәкалендә. «Кыйссаи Йосыф» поэмасы героеның, мәсәлән, иң яхшы сыйфатларыннан берсе итеп 72 тел белүе әйтелә.

Шулай итеп, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән болгар язулары хәзергә күп санда булмаса да, аларның гади һөнәрчеләр эшләгән әйберләрдә очравы һәм тегеяки бу әйберне эшләү процессында язылуы грамоталылыкның, мәгърифәтнең шактый иртә һәм киң катлау болгарлар арасында таралуы хакында сөйли.

## Укучының күңел дәфтәренә

### Әзербәйҗан мәкальләре һәм әйтемнәре

*Караңгы җиргә таш ташламыйлар.*
*Телдән чыккан һәр нәрсә башка китереп суга.*
*Куакның башын кискәч — барча кош очып китте.*
*Сыңар кул белән генә төен төенләп булмый.*
*Сул кул эшен уң кул башкармый.*
*Зур юлны көчле җиңә, агачны пычкы җиңә.*
*Акча яраткан кеше үзен-үзе ратмый.*
*Җылысы һич җылытмый, төтене — күз ачкысыз.*
*Дары утка дус түгел.*
*Җимешле агач җиргә иелә.*
*Тимерне тутык кимерә, киемне көя кисә.*
*Түбәнгә утыра белми, ә биектә урын юк.*
*Талаш — ялган акча кебек: әйләнеп кире кайта.*
*Бүтәннәргә эт өрә, аңа шакал ырылдый.*
*«Ләкин» чәчсәң, «юк»ны урырсың.*
*Акча — кулга кунган кер ул: юсаң — бернәрсә калмый.*
*Бәйләп салган юлбарыска куяннар да ташлана.*
*Биек таулар түбәсендә карның да тәме була.*
*Агым су үз юлын табар.*
*Агач — яшь белән, кеше — баш белән.*

### Балкар мәкальләре һәм әйтемнәре

*Алдаша торган кешенең муены кылдан нечкә.*
*Яхшы итеп күпер салсаң — үзең кичәрсең,*
*кешегә казыган базга үзең төшәрсең.*

---

[1] Ковалевский А. П. Күрсәтелгән хезмәт ,137 бит.

**Габделхәй Әхәтов,**
филология фәннәре докторы

# СҮЗНЕҢ ХИКМӘТЕН ТАБЫП

Тел — челтерәп аккан серле чишмә төсле. Аның күзгә бәрелеп тормаган сихри көче бар. Бу көч телнең мөмкинлекләреннән урынлы һәм уңышлы файдаланган саен киңрәк һәм тулырак ачыла.

Ана телебезнең матурлыгын һәм байлыгын Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Х. Туфан, С. Хәким шигырьләренең һәм поэмаларының, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, К. Нәҗми, Ф. Хөсни хикәяләренең, Г. Ибраһимов, Г. Бәширов, Ә. Еники, Г. Ахунов, Ә. Баянов повестьларының һәм романнарының, Г. Камал, М. Фәйзи, К. Тинчурин, Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт пьесаларының телендә һәм стилендә ачык күрәбез. Бүгенге әдәбиятыбызда сүзләрнең һәм синтаксик конструкцияләрнең куәте, җегәре, эчке мөмкинлекләре әсәрдән-әсәргә киңрәк ачыла бара.

Телебезнең образлылыгын, аһәңле яңгырашын тәэмин итүдә фразеологик әйтелмәләр бик мөһим роль уйный. Мәсәлән, авыз еру (көлү, елмаю), аяк астына салып таптау (хур итү, мыскыл итү), аяк чалу (каршылык күрсәтү), балавыз сыгу (елау), баш күккә тию (шатлану, куану), борын чөю (һавалану), ике күз дүрт булу (аптырау, гаҗәпләнү), йөз яктыру (шатлану), кот чыгу, кот очу (курку), эч пошу (борчылу) һ. б. Фразеологик әйтелмәләр әдәби әсәрдә персонажларның, күренеш-вакыйгаларның төп сыйфатларын үзенчәлекле итеп тасвирлауда, стиль матурлыгын тудыруда зур мөмкинлеккә ия һәм актив чаралардан исәпләнәләр. Күзаллау өчен язучыларыбызның кайбер әсәрләреннән мисаллар китерик.

1. Хатын-кызлар, ирләре өйдә юклыктан файдаланып, эчке өйләрендә **лэчтит сатып** утырдылар булса кирәк. (М. Әмир.) 2. Мәгыйшә түти, кулына сукыр лампа тотып, аның кергәнен **дүрт күз белән** көтеп торды. (Г. Ахунов.) 3. Чаллы җирендә кабат очрашуга балаларча сөенешкән дусларның, һәм монда да, Фәез производство бүлегендә гади инженер гына чакта, сулыш алулары да бергә булган кешеләрнең, хәзер **араларыннан ник кара мәче узды** дисең? (Ә. Баянов.) 4. Исәбе — төзелеш барган һәм барачак мәйданнарны **күздән кичерү иде.** 5. Шуннан соң боларның эти-энииләре азрак уйланып, гел шулай **трай тибеп йөрергә** ярамаганын аңларлар да, идарәгә килеп, малайларына үзләре эш сорарлар дип көткән идем. (В. Нуруллин.) 6. Ачлы-туклы яшәүдән, арудан **авызын ачса, үпкәсе күренерлек** хәлгә килгән Бибиҗамал апа. (Ш. Хөсәенов.) 7. Утырган җиреннән сикереп торды, **йөзеннән кан качкан** төсле булды. (Б. Камалов.)

Югарыдагы мисалларда **лэчтит сату** дигән фразеологик әйтелмә «юк бар сөйләү», «буш сүз сөйләү» дигән мәгънәдә, **дүрт күз белән** — «тилмереп, зарыгып», **араларыннан кара мәче узу** — «ара бозылу», **күздән кичерү** — «карап чыгу, тикшерү», **трай тибеп йөрү** — «эшсез йөрү», **авызын ачса, үпкәсе күренерлек хәлгә килү** — «ябыгу», **йөздән кан качу** — «агару» дигән мәгънәдә кулланылган. Күренүенчә, бу мисалларда фразеологик әйтелмәләрнең мәгънә җегәре, стилистик функцияләре һәм язучыларның сүз рәссамы буларак осталыклары бик ачык чагыла.

Тел гыйлемендә һәм әдәбият белемендә фразеологиянең асылына карата төрле карашлар яши. Берәүләр аны сүзлек хәзинәсе итеп танымыйлар, стилистик чаралар исәбенә генә кертәләр (мәсәлән, француз галиме Ш. Байи). Икенчеләр фразеологияне халык авыз иҗаты әсәрләре (мәкальләр һәм әйтемнәр) белән буташтыралар (мәсәлән, Л. Җәләй, Л. Мәхмүтова, Н. Борһанова). Өченчеләр фразеологиягә, мәкаль һәм әйтемнәрдән тыш, кушма сүзләрне, фигыльләрнең төрле типтагы аналитик конструкцияләрен, афоризмнарны һәм канатлы шигырь строфаларын да кертеп, аның күләмен бөтенләй чикләмиләр (Ш. Рамазанов, Г. Ахунҗанов).

Бу мәкаләдә фразеологияне өйрәнү өлкәсендәге әнә шул бәхәсле, четерекле мәсьәләләрне яктырту төп максат итеп куела.

Фразеологик әйтелмәләр телебезнең эчке мөмкинлекләрен чагылдыралар, аның матурлыгын, күркәмлеген, үтемлелеген, тәэсирлелеген арттыралар һәм рәвешле әдәби сурәт чараларының кыйммәтле фондына керәләр. Ләкин аларны саф стилистик күренеш дип кенә карау хата булыр иде. Чөнки фразеологик әйтелмәләр үзләренең мәгънәләре белән аерым сүзләргә якын торалар һәм лексик берәмлек дип исәпләнәләр, ә инде формалары ягыннан сүзтезмәләргә охшыйлар һәм синтаксиста тикшереләләр. Мәсәлән, **кан йоту** дигән фразеологик әйтелмә «борчылу» дигән мәгънәне аңлата. **Күз ачып йомганчы** «бик тиз» дигәнне белдерә. **Телне аркылы тешләү** «эндәшмәү» дигән сүзгә тиңдәш була. **Чәч үрә тору** — «гаҗәпләнү», **тел белән тегермән тарту** — «күп сөйләү», **урам авыз** — «гайбәтче» дигән экспрессив төшенчәләрне тәгъбир итәләр. Шулай итеп, фразеологик әйтелмәләрдә эчтәлек, башлыча, эчке формага нигезләнә. Шуңа күрә форма ягы фразеологик әйтелмәләрне сүздән, мәгънә ягы сүзтезмәләрдән аеру өчен критерий булып тора. Димәк, фразеологик әйтелмә сүз белән сүзтезмә арасында тора. Аны тел карамагында булган барлык «тукымалар»дан сугып эшкәртелгән лексик-грамматик берәмлек дип әйтергә мөмкин. Чыннан да, ул телнең барлык компонентларын — сүзлек байлыгын һәм грамматик төзелешен — тоташтырып тора.

Димәк, бер бөтен мәгънә белдерә торган тотрыклы сүзтезмәләрне генә фразеологик әйтелмәләр дип атый алабыз.

Ш. Рамазанов белән Г. Ахунҗанов **урынбасар, култык, көн-төн, юк-бар** тибындагы кушма һәм парлы сүзләрне фразеологик әйтелмәләр исәбенә кертәләр. Күреп үткәнебезчә, мондый сүзләр тышкы яктан ук, ягъни төзелешләре белән үк фразеология була алмыйлар. Алар гадәттә ике генә сүздән ясала һәм кушылып яки сызыкча аша язылып йөртелә. Ә фразеологик әйтелмәләр ике генә түгел, ә бәлки өч, дүрт һәм аннан да артык сүздән ясала һәм беркайчан да кушылып язылмый; **борын күтәрү, күзгә йокы кермәү, кызган табага бастыру, баскан җирдән ут чыгару, үлән астыннан төтен йөгертү, каш төзәтәм дип күз чыгару, җир тишегенә кереп китәрдәй булу.**

Фразеологик әйтелмәләрнең барлыкка килүе кешеләрдә читләтмә (абстракт), метафорик уйлау сәләте үсү белән бәйләнгән. Ягъни фразеологизмнар әйберләрне, күренешләрне бер-берләренә охшату, чагыштыруга нигезләнгәннәр. Мәсәлән, **тозсыз сүз** дигән фразеологик әйтелмә, һичшиксез, **тозсыз аш** (ашамлык) белән чагыштырудан килеп чыккан. Болар арасындагы уртаклык, охшашлык — тәмсезлек, татсызлык.

Бу үзенчәлекне күзаллау өчен, әдәби әсәрләрдән берничә мисал китерик: Шәми, үз сүзләренең көченә үзе хәйран калып, үз гайрәтеннән үзе ләззәт табып, аның саен **авызыннан ут чәчә** (Р. Төхфәтуллин). Монда тиз, күп сөйләү «утның чәчрәп торуына» чагыштырылган. Бүтән объектларга да шулай әкренләп **җан керәчәк** инде (Ә. Баянов). Бу мисалда эшнең башланып китүе «җан керүгә», терелүгә тиңләштерелгән. Партоешма секретаребыз ул яктан **ут уйната торган** кеше дә, тик ул өйдә юк, аның бер айга укырга киткән чагы иде (В. Нуруллин). Китерелгән җөмләдә уңганлык, булганлык «ут уйнатып торуга» охшатылган.

Ләкин бу төр төшенчәләрне күпмәгънәлелек күренеше белән бутарга ярамый. Сүзләрнең күп мәгънәләрдә йөртелүе элек заманнарда чагыштырмача киңрәк таралган булган. Мәсәлән, **кирәк** сүзе «бетем, үлем, кирәклек, язмыш» дигән мәгънәләрне аңлаткан. Хәзерге телебездә ул, билгеле булганча, шуларның берсен генә (кирәклек мәгънәсен генә) саклаган. **Әл** сүзе дә борынгы язмаларда берничә мәгънәдә йөртелгән. Мәсәлән, **әл** — ил, халык; **әл** — кабилә; **әл** — кул; **әлиг** — илле; **әлик** — идарәче;

**элгәре** — көнчыгыш як (хәзерге татар телендә элгәре, **элек** — үткән заман). Әл сүзе хәзерге телебездә **алкышлау** (әл кушлау; ягъни кул кушлау, кул чабу) сүзендә генә кулланыла.

Кайбер фразеологик әйтелмәләр бер үк конструкцияләрне сөйләмдә еш куллану нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Еш файдалану, башлыча, аралашу, аңлашу, фикерләү ихтыяҗыннан килеп чыга. Мондый кулланышка кергән конструкцияләр телдә йөри-йөри катып калалар һәм оешма хәлгә киләләр. Татар әдәби телендәге **төкле аягың белән, кул артың җиңел булсын, авызыңнан җил алсын, авызыңа бал да май, җылы авызыңнан җылы куеныңа, иш өстенә куш, чүп өстенә чүмәлә** һ. б. фразалар сөйләмдә күп куллану нәтиҗәсендә берегеп киткәннәр. Әдәби әсәрләрдә алар да актив файдаланыла: Синең анаң, Гөлбикә ахирәт, берүк **авыр туфрагы җиңел булсын**, бик күркәм холыклы кеше иде (Г. Бәширов). Һай йөзе кара икән. Ярабби ходаем, **башы гына бетсен!** (Г. Камал).

Фразеологик әйтелмәләр башка сүз тезмәләреннән нинди сыйфатлары белән аерылып торалар соң?

Барыннан да элек, фразеологик әйтелмә, телдә әзер килеш сакланган хәлдә, сөйләмгә сүзләр кебек үк «урнаштырыла» ала. Ә гадәти сүзтезмә сөйләм барышында гына туа. Мәсәлән, **агач йорт** дигән сүзтезмә билгеле бер конкрет сөйләм барышында туа һәм яши. **Куздән кичерү, авызны чөйгә элү, ис китү, тел шартлату** кебек фразеологик әйтелмәләрне кучерелмә эчтәлек бер бөтен «кушылма» иткән. Бу «кушылмалар» сөйләмгә аерым сүзләр кебек «урнаштырылалар» гына: Фәез малайлар белән бергә ятып икесен дә баштанаяк **күздән кичерде**. (Ә. Баянов). Аның хакында авыл картлары әле булса **исләре китеп, тел шартлатып** сөйли. (В. Нуруллин.) Кемнең тагын бер-ике сәгать **авызын чөйгә элеп** утырасы килер икән? (Н. Фәттах.)

Фразеологизмнар, гадәттә, семантик яктан бөтен була, ягъни, нинди дә булса бер читләтелгән төшенчәгә кайтып кала: Сугыш башланганнан соң бөтен илдә барган шушы бөек түзелешнең тамырына **балта чабарга**, совет халыкларын **коллыкка төшерергә** омтылган кыргый фашистларга каршы Мансуров күңелендә бигрәк тә басылмаслык нәфрәт, чиксез ачу туды. (Г. Бәширов.) Ә инде сезне үги итәргә теләүчеләр бар икән, — министр директор өстәле ягына ым какты — үзләрен **утлы табага бастырып** биетербез. (Э. Касыймов.)

Бу мисалларда **тамырына балта чабу, коллыкка төшерү, утлы табага бастырып** биетү дигән фразеологик әйтелмәләр бар. Аларның һәммәсе бер төшенчә, мәгънә белдереп килә һәм бу мәгънәләр аерым компонентларның гади кушылуыннан килеп чыкмый. Алар — икенче, сыйфат ягыннан яңа, күчерелмә мәгънәләр. Чыннан да, мәсәлән, **тамырына балта чабу** әйтелмәсенең күчерелмә мәгънәсе **тамыр, балта** һәм **чабу** сүзләренең арифметик суммасыннан аңлашылмый. Бер төшенчә бирүче әйтелмәләрнең компонентлары, мөстәкыйль лексик берәмлекләр булуга карамастан, фразеологик бәйләнешкә кергәч, үзләренең мөстәкыйльлекләрен югалталар һәм сүзнең «кисәкләре» ролен генә үтәп килгән төсле булалар.

Фразеологик әйтелмәләргә грамматик таркалмаучанлык та хас, ягъни фразеологик әйтелмәләрнең компонентлары үзара шундый берекккән була, араларына «чит» сүзләр кыстырып та булмый. Әгәр бер компонентны икенче сүз белән алмаштырсаң, мәгънәгә үзгәреш керә, яңа мәгънә туа. Мәсәлән, язучы Әхсән Баяновның «Ут һәм Су» романыннан бер җөмлә: Ә Рая, кайчан чакырыр дигәндәй, Фәезгә астыртын гына **күз ташлый. Күз ташлый** «карый» мәгънәсендә кулланылган. Әгәр бу әйтелмәнең, **күз** сүзен саклаган хәлдә, **ташлый** сүзен башка сүзләр белән алмаштырсак, **карый** мәгънәсеннән ерак торучы икенче яңа мәгънәләр барлыкка килә: **күз кысты, күз йомды, күз буды, күз ялтыратты, күз камаштырды.**

Әгәр компонентның берсе аңа синонимик булган икенче бер сүз белән алмаштырылса, мәгънәгә тамырдан түгел, өлешчә генә үзгәреш керә. Мәсәлән, **ташлый** сүзен аңа синонимик булган **ата, төшерә, төби, теги, йөгертә, сала** дигән сүзләр белән алмаштырыйк. Барлыкка килгән **күз ата, күз төшерә, күз төби, күз теги, күз йөгертә, күз сала** әйтелмәләре **күз ташлыйга** карата синонимик булып торалар һәм, шунлыктан китерелгән җөмләдә артык мәгънә үзгәреше тудырмыйлар. Алар сөйләмдә стиль төрлелеген тәэмин итәләр.

Шулай итеп, компонентларның даими һәм үзара тыгыз береккән булуы фразеологик әйтелмәләрнең мәгънә бөтенлекләре белән дә аңлатыла.

Кайбер әйтелмәләрнең компонентлары телдә йөри-йөри кушылып китәргә һәм бер сүзгә әйләнергә мөмкин. Мәсәлән, **буйсыну** дигән сүзне генә алыйк. Хәзер ул татар теленең төп сүзлек хәзинәсенә кергән. Әгәр дә морфема төзелешен тикшереп карасак, аның кайчандыр сүзтезмә хәлендә булганлыгын ачабыз. Беренче элементы — **буй**, икенчесе — **сыну.**

Фразеологик әйтелмәләргә сурәтлелек, образлылык хас. Билгеле булуынча, аерым сүз һәм сүзтезмәләр ике төрле функцияне үтиләр: а) кешенең логик уйларын тәгъбирлиләр, әйтеп бирәләр. Мәсәлән, ут, су, ташу, яну, йоту һ. б. әйберләр һәм күренешләрнең исемнәрен атау чарасы хезмәтен үтиләр. **Ут яна** дигән фраза белән без утның яну хәлендә — процессында булуын әйтеп бирәбез; су ташу, су йоттым, су эчтем кебек фразаларда да реаль күренешләр турында хәбәр бирелә; б) шундый ук сүз һәм сүз тезмәләре, мәгълүм шартларда, кешенең кичерешләрен сурәтләүгә хезмәт итә. Мәсәлән, **ут йота** (кайгыра дигән төшенчәне бирә), **йөрәгем яна** (борчылам, пошынам, кайгырам) кебек фразалардан без процессның турыдан-туры үзен түгел, бәлки аңа охшатып читләтелгән, абстракцияләнгән икенче бер хәлнең сурәтен күз алдына китерәбез. Икенче төрле әйткәндә, кайгының иң зурысы, иң катысы «ут йоту» кебек чамадан тыш кыен бер эшкә охшатылып сурәтләндерелгән була: Хәйран башыңны вәйран итеп дигәндәй, **ут йотып** йөрмәсәң, Нәфисә шикелле матурлар тагын да табылмас дисеңмени? (Г. Бәширов.) Фразеологик әйтелмәләр әнә шундый сурәтләндерү чараларыннан берсе булып торалар.

Билгеле, һәрбер фразеологик берәмлектә дә тулысынча тирән тойгы, кичереш һәм сурәтлелек чагылырга тиеш дигән таләп куела алмый. Мәсәлән, **ачык авыз** (аңгыра, тинтәк), **җилкуар** (эшсез), **урам авыз** (гайбәтче) һ. б. әйтелмәләрдә андый тойгылар, кичерешләр юк, бары охшатуга нигезләнгән сурәтлелек кенә бар.

Кайбер сүз тезмәләренең бер очракта үзләренең туры мәгънәләрендә, икенче бер контекстта күчерелмә төшенчәдә йөрүләре мөмкин. Мәсәлән, ул идәнгә утырды да **аякларын сузды.** Монда **аякларын сузды** үзенең туры мәгънәсендә килә. Әмма ул инде әллә кайчан **аягын сузды,** аның үлгәненә биш былтыр, дигән контекстта аяк сузу — фразеологик әйтелмә.

Бер телдән икенче телгә сүзгә-сүз күчерелмәү — шулай ук фразеологизмнарга хас үзенчәлек.

Фразеологик әйтелмәнең бер телдән икенче телгә сүзгә-сүз тәрҗемә ителә алмавы, башлыча, аның күпмәгънәлелеге һәм нигезендә ятучы чагыштыруларның үзенчәлеге бәйле булуы белән аңлатыла. Шулай ук фразеологик әйтелмә составында теге яки бу халыкның тормыш-көнкүрешен һ. б. чагылдыра торган специфик сүзләрнең саклануы, борынгы грамматик формаларның яшәп килүе шактый роль уйный. Татар телендәге **«кылны кырыкка ярырлык», «теңкәгә тию», «күз буу»** кебек әйтелмәләрне рус теленә һәм, киресенчә, рус телендәге кайбер әйтелмәләрне татар теленә сүзгә-сүз күчереп булмый. Мондый очракта тәрҗемә ителүче телнең фразеологик әйләнмәсенә тәрҗемә итүче телдән параллельләр эзләнелә һәм контекстка туры килгәне файдаланыла. Әгәр дә мәгънә ягыннан бәрабәр фразеологик әйтелмә табылмаса, шуны аңлатучы сүз яки сүзләр куела. Мәсәлән, рус телендәге **«бить баклуши»** татар телендәге **«трай тибү»** әйтелмәсенә параллель була. Ә менә **«попасть впросак»** әйтелмәсенә параллель табуы авыр. Ул **«кәкре каенга терәтү», «көймә комга терәлү», «агач атка атландыру»** кебек фразеологизмнарга да туры килеп бетми. Шунлыктан аны **«кыен хәлдә калу»** дип тәрҗемә итү уңышлырак була.

Дөрес, кайбер әйтелмәләр калька юлы белән тәрҗемә ителергә мөмкин: **баш вату** (ломать голову), **борын күтәрү** (нос задирать), **кул селтәү** (махнуть рукой), **түшәмнән алу** (брать с потолка), **бармакка бармак сукмау** (не ударять палец о палец). Ләкин мондый тар фразеологизмнар телдә бик аз була.

Китерелгән үзенчәлекләр фразеологик әйтелмәләрнең күләмен дөрес билгеләү өчен дә нигез булып тора. Шушы күзлектән караганда, лексик-семантик һәм грамматик яктан таркалучы афоризмнарны да, канатлы шигырь строфаларын да, мәкаль

һәм әйтемнәрне дә фразеологиягә кертеп булмый. Шулар арасыннан мәкаль һәм әйтемнәргә аерым тукталыйк.

Бер төркем галимнәр мәкаль һәм әйтемнәрне ни өчен фразеологик әйтелмәләр белән катыштырып йөртәләр соң? Моңа, күрәсең, образлылык сәбәпче була. Мәкаль һәм әйтемнәр фразеологик әйтелмәләр кебек үк образлы булалар, кыскалыклары һәм үткенлекләре белән җәлеп итәләр. Ләкин уртаклык шуның белән бетә дә.

Мәкаль һәм әйтемнәр — халык авыз иҗатының мөстәкыйль әсәрләре. Алар, М. Горький сүзләре белән әйткәндә, хезмәт ияләренең бөтен тормыш, социаль-тарихи тәҗрибәләрен үрнәк булырлык рәвештә калыпка салалар. Ә фразеологик әйтелмәләр объектив чынбарлыктагы фактларны, күренешләрне бары констатациялиләр генә. Мәсәлән, чагыштырыгыз: **сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың** (мәкаль), **без капчыкта ятмый** (әйтем) һәм **чәч үрә тору, көймә комга терәлү, аяк чалу** (фразеологик әйтелмәләр).

Мәкаль һәм әйтем дидактик характерда була, ул вәгазь уку, акыл бирү, өйрәтү, әхлак тәрбияләү кебек максатларга корыла. Шуңа күрә сөйләүче кеше теге яки бу мәкальне яки әйтемне файдалангач, тыңлаучы алдында үз максатына ярашлы нәтиҗәләрне чыгарып бирергә тиеш була. Мәсәлән, **калган эшкә кар ява** дигән мәкаль кулланылган булса, димәк, эшне вакытында эшләргә кирәк, дигән йомгак ясала. Фразеологик әйтелмәләр андый максатларга хезмәт итмиләр: Чын коммунист булыйм дисәң, халык күңеленә **колак сал** (М. Әмир). Шәфкатьле ата белән газиз ана кебек, **кочакларын җәеп** каршы алалар иде алар безне (Р. Төхфәтуллин). Үз нужасы да **башыннан ташып** киткән иде әле (Ф. Хөсни). Бу чыннан да **утырып җиткән** чын егет иде (Ә. Еники).

Мәкаль һәм әйтемнәр универсаль мәгънәле булалар. Аудитория, обстановка аларның мәгънәләрен конкретлаштыра. Мәсәлән, **калган эшкә кар ява** мәкаленең мәгънәсе колхозчылар, эшчеләр, студентлар һ. б. алдында әйтелүгә карап конкретләшә. Ә фразеологик әйтелмәнең мәгънәсе һәрвакыт ачык, билгеле, конкрет була.

Сөйләүче мәкаль һәм әйтемнәрне гадәттә башка кеше сүзләре рәвешендә куллана. Мәкаль һәм әйтемле сөйләм, башлыча, **«ди», «диләр», «дип әйтәләр», «дип сөйлиләр»** кебек сүзләрдән тора. Мәкалә һәм әйтем сөйләүче контекстына «картлар әйтмешли» рәвешендәге сүзләр белән дә, аерым очракларда үзе генә дә килеп керә. Фразеологизмнар белән мондый хәл булмый. Алар сөйләмдә сөйләүченең үз сүзе булып киләләр.

Язучы-художник әдәби әсәр иҗат иткәндә, конкрет геройларны, тормыш-көнкүреш картиналарын тасвирлаганда тел хәзинәсеннән мөмкин кадәр нәтиҗәле файдаланырга тырыша. Ә фразеология шул хәзинәнең мөһим һәм кыйммәтле өлеше.

# АВЫЛ УРАМНАРЫ БУЙЛАП

Башта ук әйтеп куйыйк: без бүген искитәрлек һәм башны әйләндерерлек зур вакыйгалар белән очрашмабыз. Сәяхәтебез кешеләрнең күз алдында ап-ачык булып җәелеп ятмаган, без күрергә иләнгәннән икенчерәк рәвештәге, тирәнгәрәк, эчкәрәк яшеренгән дөнья буйлап барыр. Ул — кеше күңеле. Ул — тышкы дөньядагы бик олы үзгәрешләрне, хәтта соңыннан күпләр таң калып сөйләрдәй күренешләрне күз алдына китергән серле мохит. Әнә шундый көчкә ия булганы өчен — кешеләр язмышын хәл иткән күп кенә мөһим процессларны аңлата алганга бу мәсьәлә хәзер киң колач белән өйрәнелә башлады. Ул хәзер кайсы гына фәннәрне, нинди генә кешеләрне кызыксындырмый?!

Әмма бер өлкә кешеләренең — язучыларның һәм сәнгать эшлеклеләренең күңел дөньясын өйрәнүдәге мөмкинлекләре чагыштыргысыз дәрәҗәдә зуррак. Чөнки алар кулында (юк, «кулында» дөрес сүз түгел, «күңелендә»!) иң көчле һәм иң универсаль корал, әлеге дөньяны аңлау чарасы — образлылык бар. Образлылык үзенең чиксез мәгънәләргә, ассоциацияләргә сәләтлелеге аркасында, әдәбият-сәнгатьне кеше күңелен, җанын, рухын өйрәнүдә алыштыргысыз көч итә.

Без мәнә хәзер сәяхәт итәчәк дөнья — язучы Мәгъсүм Хуҗинның «Авылым урамнары» дип исемләнгән китабы да, һичшиксез, шул фикерне раслый [1].

Аның иҗаты тудырган мохит белән танышуыбызны китапта иң беренче итеп урнаштырылган әсәрдән — «Соң» хикәясеннән башлыйк. Хикәя җирлегенә аяк атлау белән безгә Гәрәйша очрый. Язучы бернинчә җирдә аны үз исеме белән әйтмичә — Сөйләшми торган кеше дип атый. Моның сере нәрсәдә соң? Укый-укый без Гәрәйшаның малае белән икесе генә калган ир икәнен беләбез, күп сөйләшмәскә күнеккән, басынкы холкын күрәбез һәм яшь удмурт кызы Любаша белән сүзсез генә аңлашылган мәхәббәтен табабыз.

Гәрәйша күңелендәге мәхәббәт... Бу очракта Гәрәйша, әгәр бик оста сөйләшә алу сәләте булса да, нәрсә генә сөйли алыр иде икән соң? Гәрәйша бары тик чын мөнәсәбәтләрнең яшәешенә генә күнеккән. Мөнәсәбәтләрне, караш-аңлауларны, берәр вакытлы максат өчен генә үзгәртү, алыштыру Гәрәйшага ят нәрсә. Ул аның табигатенә, асылына чит, каршы. Ул атна саен күрше авылдагы Петрух дәдәйләргә — Любашаларга барып әкрен генә, сүзгә әз-әз генә катнашкалап, гәпләшеп утыра. Тик, үз язмышы өчен үтә кискен көннәр икәнен тоеп торуына карамастан, ул Петрух дәдәй белән дә, Любашаның үзе белән дә ныклап сөйләшә алмый.

Автор беренче хикәясендә безне менә шундый кеше белән очраштыра. Бүгенге тормыш, хәзерге әдәбият өчен мондый күренеш ни дәрәҗәдә мөһим? Тирә-ягыбызга күтәрелеп карасак — әнә бит, безнең тирәдә бөтенләй бүтән кешеләр: көчлеләр, гайрәтлеләр, акыллылар,— нәрсә эшләргә кирәген, ничек итәргә кирәген яхшы белеп яшәүчеләр. Язучы Мәгъсүм Хуҗин үзенең Гәрәйшасын юри әнә шундый типларга каршы китереп куя кебек.

Хикәядәге Гәрәйшаны тормыштагы башка типлар, характерлар белән шулай чагыштырып карау бүгенге әхлак мәсьәләсендә әһәмиятле ачышларга алып килә. Нинди ачышлар турында сүз бара соң? Тормышта Гәрәйшага охшамаган кешеләр дә җитәрлек. Аларның берсе һәм Гәрәйшаның диаметраль ноктадагы антиподы булган тип болайрак гәүдәләнә. Ул күпмедер уңышлар, үрләр яулап алган, башкалар күз алдында дан һәм дәрәҗә казанган. Хәзер үзен акыллылыкның иң югары ноктасында дип саный. һәм шул чиксез ышанычы аркасында мескен калган ул шәхес, башкалардан өскә күтәреләм дип мавыгудан, үзе дә сизмичә, түбән төшкән. Әгәр дә җирдә, тормышта нечкә тоемга ия булып, матур һәм ихлас күңел белән яшәүне барлык дан һәм мал шаукымыннан өстен күргән кешелек рухы яшәмәсә, әгәр дә җирдә бары тик акыл көченә генә ия роботлар торып калган булса — бәлки мондый типлар кешелек өчен кадерле дә саналыр иде. Әмма миллионлаган еллык кешелек җәмгыяте өчен акыл белән бергә шәхеснең кешелеклелеге бик нык кирәк. Чөнки кеше акылын хәзер уйлаучы машина да алыштыра ала. Димәк, теге кешене— үтә акыллы булган типны да бер машина алыштыра ала диген сүз. Ә чын кешелеклелек комплексын — беркайчан, беркайда һәм берниндн ясалмалылык та алыштыра алмаячак!

[1] Мәгъсүм Хуҗин, Авылым урамнары. Казан, 1978 ел.

Гәрәйша — Сөйләшми торган кеше образы — әнә шундый зур нәтиҗәләр ясата. Хикәянең исеме дә мәгънәле: үзенә тартып, серен белергә ымсындырып тора. Икенче әйбәт сыйфат — иң баштагы җөмләдән үк без әсәрнең игътибарлы, салмак һәм җитди атмосферасына элэгәбез. Язучының җөмлә төзү интонациясе үк безнең дикъкатебезне үзенә җәлеп итә: «Көрт койманы ашып килә». Аннан соң инде истә калырлык итеп кышкы авыл табигате тасвирлана. Ул да шулай ук кыска, җитди, ярым кырыс, әмма тәэсиргә бай, күп төсмерле сүзләрдән тора. Хикәянең мондый иплә һәм үзенең эчке мәгънәсе талап иткән акрын җай белән агышы ахырга кадәр дәвам итә. Соңыннан, Любаша башкага тормышка чыкса да, Гәрәйшаның һаман аны оныта алмавын, моның мәхәббәт дигән зур хис булганын язучы гади генә сүзләр белән бирә: «Карый бит менә, карый, тик үзе күренми генә». Любаша һаман шулай карап торгандай тоела Гәрәйшага. Аның күңеле шулай тоя еракгагы Любашаның карашын... Өченче сыйфат —хикәянең эчке рухы геройның характерына бик тәңгәл, аваздаш булу. Автор Гәрәйшаның бөтен күңел тибрәлешләренә кадәр тоеп, аңлап бара, ул аның үзенә дә бик якын һәм кадерле зат. Әнә шундый якынлык, герой белән иҗатчының әсәрдәге бердәмлеге, һаман көчәеп, укучыга да күчә. Хикәягә уңыш китергән сыйфатларның соңгысы итеп, аның герое Гәрәйшаның оригиналь, кабатланмаган шәхес булуын әйтергә кирәк. Рухи яшәеш өчен үзе бер биеклек булып торган фигура икәнлеген. Бусы әсәрнең төп уңышыдыр, күрәсең...

Язучының «Соң» хикәясенә озаграк тукталуның сәбәбе шунда, чөнки ул, китаптагы беренче әсәр булу өстенә, тулаем Мәгъсүм Хуҗин иҗаты өчен характерлы күп кенә типик сыйфатларны да чагылдыра. Менә «Мәк чәчәге» хикәясенең төп герое — Шимай. Гәрәйша кебек «сөйләшми торган кеше» дигән исеме булмаса да, ул да сүзгә үтә саран. Хатыны Фәрхия белән менә ничек сөйләшә ул: «Туйралыкка бардыңмы?» «Әһе». «Мине дә чакырган булсаң соң». «Мин сине бүген эшеңә барып каршы алмакчы идем». «Киләләр аны». «Мин түгел, син мине каршы алдың». «Анысы гомер буе инде». «Әһе». «Шәмсетдин». «Син генә миңа исемем белән эндәшәсең. Башкаларга мин Шимай да Шимай».

Мәгъсүм Хуҗинның башка әсәрләрендә дә күпчелек геройлар аз сүзле, ашыкмый, кабаланмый торган, көнкүреш ыгы-зыгысына бөтенләй диярлек баш бирмәгән кешеләр. Авторның менә шундый характерлы шәхесләргә игътибар юнәлтүендә үк, безнең уебызча, бер эчке мәгънә бар. Тормышта матур сөйләшүчеләр, бөтен кешене авызына гына каратып тотардайлар күп, шуннан оста файдаланучылар да бар. Икенче яктан караганда, культура дәрәҗәсенең күтәрелүе, яшәүнең интенсивлашуы, заман кешеләренең бер-берсе белән актив аралашуы сүзнең, сөйләшүнең ролен нык үстерде. Әмма иң башта синең үзеңдә кеше белән бүлешә алырлык эчке байлык, олы җан булырга тиештер. Иң мөһиме әнә шунда. Бу китабындагы аз сүзле геройлары белән, язучы әйтерсең безгә болай диярге тели: «Әнә, игътибар иттегезме икән: алар өчен сүз — бик кадерле нәрсә. Сүз — аларның җаннарының бер өлеше».

Шимай элек шахталарда эшләгән, тир түгеп тырышкан. Хәзер ул тимер юл буендагы бер кечкенә поселокның урман янәшәсендәге иң арткы урамында яшәп ята. Аларның бирегә торырга калулары да кызык кына була. Туган авылга дип шахтадан кайтып барганда, поезд бер станциядә озак кына тукталып тора. Шимай тәмәке тарта-тарта йөреп керергә чыга һәм бераздан, инде поезд кузгалып китә дигәндә генә, вагонга килеп керә дә: «Әйдә, җыен! Җәһәт!» ди. Алар шул станциядә калалар. Хикәянең менә шушы детале — кеше характерының бер чагылышы — үзе үк бик мәгънәле. Шимай тормышта үзен иркен, күңеле кушканча тота. Бу — аның көчлелеге, кыюлыгы билгесе. Ул кайберәүләр кебек һәммәсен алдан уйлап, хәзерләп тормый. Болай эшләү, шартларны алдан хәзерләп кую, күрәсең, йомшаграк, көчсезрәк натуралар өчен кирәк. Ә Шимай кебекләр — тормышка олы ышанычы булган, үзләрен вак-төяк очраклылык кына юк итә, җиңә алмый дип санаучы кешеләр. Бер характерның шушы чагылышы һәрбер вак-төяккә ябышып ятуның нинди мескенлек булуын ачып сала...

Менә Шимай, урманны әйбәтрәк хәлдә сакларга иде, дигән ихлас ният белән поселок Советына килә. «Анда, дөньяга бүген килгән кебек, белмәгән идек, дип гаҗәпләнделәр, тыярбыз, дип өметләндерделәр, син шунда торасың, үзең дә күз-колак бул, дип бурыч йөкләп җибәрделәр. Абруең чамалы икән, ни кыласың — Шимайның кисәтүен колакларына да элмәделәр, хәтта бер апай аның үзенә кәттә генә киңәш биреп ташлады: «Син булып син тыкшынасың бит, әй! Әнә үз йорт-җиреңә хуҗа була бел! Бакчагыздан сыңар җимеш тә каба алмыйсыз бит! Сукбай! Эчмәгән көнең юк!»

Мыскыл иттеләр үзен. һәм ул көне буе шул апайга эченнән генә җавап эзләп йөрде: «Миңа җимеш кирәкми дә... Эчәм икән — синекен эчмим! Шушы яшеңә җитеп, сукбайның кем икәнлеген белмисең... Минем сукбай булганым юк!»

Менә бу өзектә никадәрле чынлык! Олы гына ир кешенең күңеле төшү, үпкәләү сәбәбе (һәм киңрәк алып караганда — кайбер әйбәт күңелле кешеләрнең читтә, сүлпән йөрүләренең сәбәбе дә шулдыр) ничек дөрес ачылган хикәядә. Бу инде — кеше күңеленең бюрократия салкынлыгы белән очрашуы күренеше. Ул бик типик итеп, мәгънәсе белән киң масштабны иңләп бирелгән.

Пошынмый гына эшләп һәм яшәп яткан Шимай көннәрдән бер көнне, үзе белән әңгәмә корып утырганда, бер агач төбе янында мәк чәчәге күрә. Буш шешәләр янәшәсендә үскән чәчәкне. Хикәянең ахырында килеп кергән менә шушы мәк чәчәге образы, әсәрне укып чыгып шактый йөргәч кенә, «кылт» итеп ачылып китә.

Кара әле! Шимай бит бәләкәй вакытта да Мәк чәчәгенә кызыккан иде. Тик аны ул чагында күршесе балта белән атып куды Мәк түтәле яныннан. Балтасы ботка тиде— тирән яра ясады. Менә хәзер, хикәяне тулысынча укып чыккач, без уйлап алабыз: Шимайның хәзерге гомере — шул вакытта матурлыктан куылган, читләтелгән кеше яшәве микән әллә ул?! Шуннан читтә йөргәнгә әллә ул бик битараф, басынкы һәм күңелсез микән?! Әмма хикәя ахырында аның яңадан Мәк чәчәге янына килеп чыгуы безне куандыра. Чөнки биредә Мәк чәчәге — балкып торган тормыш, матур яшәү, чын гомер итү дигән сүз икән бит ул!

Мәгъсүм Хуҗинның күп хикәяләрендәге геройлар үз башларыннан әнә шундый бик гыйбрәтле хәлләр кичерәләр. Иҗатчының сәнгатьчә осталыгы, геройлар кичергәнне укучылары күңеленә тулы килеш күчерә алуы аркасында хәлләр безнең дә баштан кичкән сыман була. Аларны укыгач без дә рухи яктан баеп, күңел тәҗрибәбез тагын да тулылана төшә. Психологик яктан оста эшләнгән, ышандыру көче зур булган, геройларның үз тормышларында хәл иткән мәсьәләләре бүтәннәр яшәеше өчен дә мөһим проблема булып кала. Бу сыйфат авторның күңел байлыгы, заманның яңа процессларына, үзгәрешләренә сизгер булуы хакында сөйли.

Инде бу китап белән танышкач нинди теләкләр туа соң? Әйткәнебезчә, язучының персонажлары безгә ошады. Әмма, шулай да, киләчәктә ул тормыштагы характерлар даирәсен киңрәк иңләсен иде, диясе килә. Хикәяләргә бүтән типлар да кыю килеп керсеннәр һәм, югарыда әйтелгән әсәрләрдәге сыман, мәгънәле итеп яшәсеннәр иде. Геройларны тормышның зуррак вакыйгалары диңгезенә чыгару өчен дә тырышырга кирәк. Аларны безнең рухи чынбарлыгыбызның тагын да олырак проблемаларына китереп ялгыйсы, яшәү рухларын биеккәрәк күтәрәсе иде!

**МАНСУР ВӘЛИЕВ.**

---

# ТЕЛ ДИГӘН ДӘРЬЯ БАР

Халкыбызның культура дәрәҗәсе тулаем күтәрелү туган телебезгә булган игътибарны да арттырды. Дистәләгән осталарыбыз тарафыннан эшкәртелгән, камилләштерелгән әдәби телебездә дөрес, матур итеп сөйләшү һәм язу галим, артист, язучы, журналистлар өчен генә түгел, хәзер инде һәркемгә хас теләк, омтылышка әйләнде. Соңгы елларда бер-бер артлы басылып торган төрле сүзлекләр, Гомәр Бәширов, Нәкый Исәнбәт, Фатих Хөсни, Йосыф Гәрәй кебек аксакалларыбызның ана теле җәүһәрләренә дикъкать юнәлтеп язган мәкаләләре, китаплары һәм, хәтта галимнәребезнең фәнни тикшеренүләре дә меңнәр көтеп ала торган кадерле хәзинәгә әверелде. Вакытлы матбугат битләрендә сүзләребез тарихын ачып Нурихан Фәттах, исемнәребез бакчасы белән таныштырып Гомәр Саттаров чыгышларын да җәмәгатьчелек кызыксынып кабул итте. Шуларга Казан радиосының «Тел күрке — сүз» тапшырулары килеп ялганды. Әмма сусын һаман канмый. Мирфатих Зәкиевнең «Татар халкы теленең барлыкка килүе», Хәсән Сарьянның «Уеңны уйдырып сал» китапларын, әле күптән түгел генә дөнья күрүләренә карамастан, көндез шәм яндырып эзләп тә табып булмый. Укучылар газета-журнал редакцияләренә, тыңлаучылар — радиостудиягә туган телебезнең төрле мәсьәләләрен күтәреп мөрәҗәгать итә. Аларга инде бер тапшыруда, бер мәкаләдә генә җавап биреп бетерү дә мөмкин түгел, кулларына тулы бер китап тоттыру хаерле.

Флера Сафиуллинаның «Тел дигән дәрья бар»[1] исемле хезмәте киң катлам укучыларның нәкъ менә шундый ихтыяҗларын күздә тотып язылган.

«Безне чолгап алган чынбарлык белән сүз арасында нинди дә булса бәйләнеш бармы соң? Яңа сүзләр ничек барлыкка килә? Алар кайчан, ничек картая һәм ни өчен төшеп кала? Сүз нинди мәгънәләр белдерә? Яңа мәгънәләр ничек туа? Ни өчен тел алынмалар кабул итә һәм аларны ничек үзгәртә? Сүзне кайчан «әйтергә ярамый»? Аваздаш, мәгънәдәш сүзләр ничек барлыкка килә? Аерым сүзләр ничек килеп чыккан? Ни өчен төрле авылда төрлечә сөйләшәләр? Тәрҗемә иткәндә сүзнең язмышы нинди? Төрле сүзлекләр нәрсәгә кирәк?» — ди автор.

Югарыдагы сорауларга, гомумән алганда, фән инде күптән җавап биргән, автор бу өлкәдә гыйльми яңалык ачмый һәм ачарга да җыенмый. Аның максаты — бүгенге фән казанышларына таянып, шушы мәсьәләләрне татар теленә бәйле рәвештә яктырту, бу өлкәдә белгеч булмаган укучы массаның мәгълүматын киңәйтү. Хезмәтнең кыйммәте дә, димәк, укучыларны кызыксындырганрак мәсьәләләрне яктыртуы, мисалларның отышлы, стиленең гади һәм җыйнак булуы, фикерләрнең ачык аңлаешлы, образлы әйтелүе белән билгеләнергә тиеш.

Китапта күзгатылган сораулар күпләрне кызыксындырадыр дип уйлыйм. Дөньяга килеп беренче әйткән, гомер буе сөйләшеп туймаган сүзләребез татарча булса да, туган телебезнең һәркемгә ачылмаган серләре хәйран калырлык ишле. Мәсәлән, азаккы сүзе белән аяк сүзе арасында бәйләнеш барлыгын чамалау бик кыен. Азакның тамыры азак соңгы мәгънәсендә, әмма ул шул хәлдә татар әдәби телендә

[1] Ф. Сафиуллина. Тел дигән дәрья бар. Казан, 1979.

сакланмаган. Төрки язма истәлекләрдә һәм «Хәзерге хакас телендә азах — аяк мәгънәсен белдерә. Димәк, кешенең башыннан аягы соңгы өлеш була» (7 бит). Авторга кушылып, казакъ телендә «бетте, азагы җитте, соңы җитте» мәгънәсенең «аякталды» (аяклан ды!) сүзе белән белдерелүен дә искәртәсе килә.

Ипигә май ягу тезмәсен барыбыз да куллана. Төрекмән телендә йааг — үзе май төшенчәсен белдерә икән (8 бит). Димәк, май ягу—май майлау мәгънәсен аңлата. Без әле майны гына түгел, варенье, балны да «майлыйбыз». Вакытлар узу белән майлау, ягу сүзләре сылау төшенчәсен белдерә башлаган.

«Татар хатын-кызлары кәшмир шәл, батис яулык ябынганнар, — ди автор. — Кәшмир, батис сүзләре каян килеп чыккан соң? Кашмир — Һималай тауларының көнбатышындагы таулы өлкә. Анда дөньяда иң шәп нечкә йон тукымалар эшләнгән. Башта шунда, аннары инде үзебездә эшләнгән йон тукыманы да шулай атаганнар» (30 бит).

Китапта батис, одеколон һ. б. күп кенә сүзләрнең дә килеп чыгышы ачыклана. Алтай телләре ярдәмендә дөм-караңгы сүзендәге дөм кисәгенең дә мәгънәсен белергә мөмкин икән. Дөм караңгы, дөм сукыр тезмәләрендәге «дөм» монгол телендә караңгылыкны белдерә. (57 бит).

«Ә ни өчен гөберле бака дигәннәр? Гөбер — бөкре дигән сүз. Димәк, бөкре бака була. Төклетура бар. Турасы нәрсә икән? Төрки телләрдә, татар теленең үзендә тура — аяк мәгънәсендә сакланган, мәсәлән, тәпи — турак, озын торыклы дигән тезмә дә бар. Бу аяк, тәпи мәгънәсен белдерә. Димәк, төклетура төкле тәпи була» (58 бит).

Ф. Сафиуллина менә шулай укучыларын тел белеменең этимология дигән тармагы белән таныштыра. Аннары измәсен изү, җепнең очын табу, кыл кыймылдатмау, алтын куллы һ. б. сүз тезмәләренең күчерелмә мәгънәдә кулланылуын мисал итеп, фразеологик берәмлекләрдә халыкның тапкырлыгы, сүзгә, чагыштыруларга осталыгы, җорлыгы чагылуын күрсәтә. Фразеологиядә мәгънәсе аңлашылып җитмәгән сүзләр дә саклануын мисалга китереп, аларның байтагын төшендереп тә бирә. Популяр китап булса да, галим монда элегрәк ясалган аңлатмаларга үз мөнәсәбәтен белдерүдән дә тайчанмый. Бу исә укучының кызыксынуын, авторга хөрмәтен арттыра. Мәсәлән, кына ташка бетәр, белем башка бетәр гыйбарәсендәге «бетәр» фигылен Н. Исәнбәт «үсү» дип аңлата. Автор исә «бу сүздә «язылу» мәгънәсе бар, төрки телдә бетиг — язма» (67 бит), дип, минемчә, уңышлырак аңлатма тәкъдим итә.

Фразеологизм ничек туа соң? Төрле телләрдә ул туры киләме? Бер телдән икенчесенә тәрҗемә иткәндә андый тотрыклы тезмәләрне нишләтергә? Туган әдәбиятыбызда аның нинди үрнәкләре бар? Ф. Сафиуллина китабында бу сорауларның һәммәсенә җавап табарга була.

Мич, уҗым, гөмбә, әвен сүзләре рустан; миләш, бүкән, поши — фин-угыр телләреннән; мәктәп, фикер, дошман, дус сүзләре гарәп-фарсыдан кереп, безнең көндәлек аралашуыбызга хезмәт итә икән. Баксаң, тагын байтак телләрдән сүзләр алганбыз икән әле. Шуның белән бергә, үзебез дә бурычлы булып калмаган — әйрән, алаша, алмаз, башмак, таңкә, камыш кебек меңләгән сүзне төрле халыклар белән уртаклашканбыз. Автор сүзләр алмашуга, алынмаларны үзләштерү кагыйдәләренә дә киң туктала һәм күпләр кызыксына торган мәсьәлә буенча бай мәгълүмат бирә. Алынмалар белән мавыгуның да, җанлы аралашудан качып, тел үсешен ясалма тоткарлауның да игелекле җимеш бирмәвен матур тарихи экскурслар, дәлилле мисаллар ярдәмендә ача. «Хәзерге рус-татар ике теллелеге шартларында татар теленә рус сүзләренең күпләп керүе күзәтелә. Кирәкме алар? Татар теленең үз сүзе була торып, кирәксезгә кертмибезме без аларны? Әйтик, гариза сүзе телдә күптәннән йөри, шулай да заявление сүзе аны кысрыклап чыгару дәрәҗәсендә активлашып бара, — ди автор һәм, — рус сүзләрен урынсыз куллануга, телгә игътибарсыз, саксыз карауга юл куелмаска тиеш, әлбәттә» (82 бит), — дип нәтиҗә ясый.

Ф. Сафиуллина бүгенге әдәби телебезнең сүзлек составы, аның төрле катламнары, сүз ясагыч чараларына да киң туктала, төрле стильләр куллануга мисаллар китерә, аерым төбәкләрдәге үзенчәлекләр хакында мәгълүмат бирә. Телләр кардәшлеге, исемнәребез, сүзнең халкыбыз тарихын ачудагы хасияте, сүзлекләр, татар һәм бүтән төрки телләрне өйрәнүдәге казанышларыбыз — автор артык күләмле булмаган хезмәтендә әнә шундый күп кенә мәсьәләләрне яктыртуга алынган. «Сүзләрне төркемлиләр», «Әйтмәгәнем булсын», «Аттым карга, төште карга», «Тузга язмаганны сөйләмә», «Сүзнең дә бизәге бар» кебек бүлек исемнәре үзләре генә дә китапның колачын, хезмәтнең образлы тел белән язылуын дәлилле күрсәтә ала.

Кыскасы, автор тел дигән дәрьяны колачларга алынып кына калмаган, куйган бурычын уңышлы үтәп тә чыккан. Балалар, эшчеләр, хезмәткәрләр, авыл хезмәт ияләре — туган теле белән кызыксынучы меңнәргә матур китап бүләк иткән. Ф. Сафиуллина анда илебезнең төрле тарафларында үзе җыйган тел үрнәкләрен дә, төрле чыганакларны, шул исәптән, башка телләрдәге хезмәтләрне дә мул файдаланган. Китап ахырында бирелгән библиография тел дәрьясына тирәнрәк чумарга теләүчеләргә әйбәт юл күрсәткеч була ала.

Автор әдәби телебезне кулланудагы җитешсезлекләргә дә туктала. «Телнең үз сүзе булганда да, аны эзләп мәшәкатьләнмичә, тиз генә тамырга — тамыр, кушымчага — кушымча туры китереп яңа сүз ясый бирәләр, — ди ул. — Менә кайбер мисаллар: «Җимерекләр булганда яртыкөн, ә кайвакытта тулы эш көне югала». Поломки сүзе шулай тәрҗемә ителгән, югыйсә сүз комбайн ватылу турында бара.

«Яңа чикләр чакыра». Бу мәгънәви калька. Әмма үрләр дигән матур сүзебез дә бар бит безнең» (130 бит).

Автор, тагын байтак мисаллар китереп, матбугатыбызда очраштыргалый торган кимчелекләрне бетерергә өнди. Бик урынлы һәм хаклы искәртү бу!

Шушы уңайдан, «Тел дигән дәрья бар» китабындагы кайбер җитешсезлекләргә тукталу да зарур. Әйтик, әдәби тел нигезләрен ныгыту максатында язылган хезмәттә алынма сүз, гыйбарәләргә мисал итеп «стройга басу», «мушкага алу» (69 бит), виноград, бидрә (70 бит) кебек берәмлекләр китерелмәсә дә ярар иде. Чөнки халкыбыз бер дә авырсынмыйча «сафка баса», «мөшкәгә ала», йөзем белән сыйлана, чиләк белән су ташый.

«Киләп сарып йөрисең» (69 бит) дип, минемчә, эшсез йөргән кешедән бигрәк, күп йөрүчегә әйтәләр. Чөнки киләп сару үзе дә эш ич инде. Аннары, «Китапханәләрдә дә, бик күп аерым йортларда да... энциклопедияләр бар» (117 бит) диюне ничек аңларга? Вокзалларда, кинотеатрларда һәм тагын шундый «йортларда да» була микәнни соң ул? Әллә соң «аерым кешеләрдә дә» дип язу кирәк идеме?

Эзләсәң, мондый кимчелекләр китапта тагын табылачак әле. Бәлки Фаил Шәфигуллин хикәясен ике бит (10—11 битләр), Нәкый Исәнбәт аңлатмасын тулы бер бит (54—55 битләр) итеп күчерү дә кирәкмәгәндер? Хәер, болар — принципиаль җитешсезлек түгел әле. Мине «Тел, теш сүзләре төрки телләрдә түбәндәгечә әйтелә» (15 бит) дип бирелгән ике «багана» аптырашта калдырды. Транскрипциясе булмагач, әзерлексез укучы төрле алфавитта язылган сүзләрнең ничек укылырга тиешлеген кайдан белсен соң? Бәлки мисалларны «түбәндәгечә языла» дип тәкъдим итәргә кирәк булгандыр? Дөрес, язылыш кардәшлекне, якынлыкны ачмаячак. Мисалга, укучы татарча «күр — күрдем — күргәнсеңнең кыргызча «көр — көрдүм — көргөнсүң» (15 бит) дип язылуына карап, бу телләр бер-берсеннән хәйран аерыла икән ләбаса, диячәк. Әгәр автор кыргыз, казакъ, каракалпак алфавитларындагы «ө» хәрефенең татарча «ү»гә, «ү»нең исә «ө»гә туры килүен искәртсә, якынлык аермачык күренер иде. Казакъча «о»ның «у», «ш»ның «ч» итеп укылырга тиешлеген белгерткәндә «ошак»ның (7 бит) шул ук учак икәнлеге ачыкланачак. Кыскасы, транскрипция бик кирәк мондый китапка. Аны кайбер бүлекләрдәге кабатлануларны бетерү хисабына да бик иркен сыйдырырга мөмкин иде.

Әдәби телебезне җаны-тәне белән тоеп, аның саф, җегәрле булуын кайгыртып чыгыш ясаучы хөрмәтле каләмдәшебез Хәсән Сарьян вакытсыз арабыздан киткәч, барыбыз да уфтанган идек. Күптән түгел кулыбызга кергән «Тел дигән дәрья бар» китабы боеккан күңелләргә шифа булды. Анда сүзлек составы турында кайбер белешмәләр генә бирелми, халык иҗаты, әдәбиятыбызның нинди тылсымлы көчкә ия булуы да сурәтләнә, дөньяны танып-белүдә, рухи матурлыкка ирешүдә туган тел хәзинәсенең роле, әһәмияте дә ачыла.

Флера Сафиуллина соңгы елларда төрле жанрларда нәтиҗәле эшләп килүче җитди галимнәребезнең берсе. Аның грамматика түтәлләреннән чыгып, әдәбият бакчасына да аяк басуы, хәзер университет кафедрасыннан төшеп, телнең хуҗасы — масса белән йөзгә-йөз, турыдан-туры сөйләшүе һәм, әйтергә кирәк, мавыктыргыч итеп, әңгәмәдәшләренең зиһеннәрен баетырлык, күңел офыкларын киңәйтерлек итеп сөйләшүе мактауга лаек эш. Берүк дәвамы гына була күрсен!

**ТӘУФИКЪ ӘЙДИ.**

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Язучылар союзы партия оешмасының ачык җыелышы булып узды. Көн тәртибенә коммунист Марс Шабаевның иҗатын тикшерү куелган иде. Чыгышларда шагыйрьнең бөтен иҗаты уңай бәя алды. Бигрәк тә аның поэмаларына һәм балалар өчен язган шигырьләренә югары бәя бирелде. Шагыйрьләр Р. Фәйзуллин һәм Р. Гатауллин үзләренең чыгышларында, әдәбиятка килгәндә, М. Шабаевның аларга ярдәм кулы сузуын, яшьләргә хәер-хак булуын әйтеп үттеләр. Әдәбият белгече Х. Хәйри шагыйрь иҗатының кимчелекле якларына да тукталды. Чыгыш ясаучы иптәшләре шагыйрьне әдәбиятта активлаша төшәргә чакырдылар.

## ЧАЛЛЫДА ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫ АЧЫЛДЫ

Чаллы шәһәренең «Энергетик» культура сараенда Татарстан Язучылар союзының Чаллы язучылар оешмасын ачуга багышланган җыелышы булды. Анда СССР Язучылар союзы членнары, Чаллыдагы «Лэйсән», «Орфей», Түбән Камадагы «Кама таңнары» әдәбият-иҗат берләшмәләре вәкилләре катнашты. Җыелышны кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты. Аннары «Лэйсән», «Орфей» һәм «Кама таңнары» әдәбият-иҗат берләшмәләре җитәкчеләре Г. Кашапов, Н. Алешкин, Р. Хисмәтуллин, Татарстан Язучылар союзы идарәсе члены, Алабуга дәүләт педагогия институты ректоры Т. Галиуллин үз төбәкләрендәге әдәбият-иҗат берләшмәләренең эшчәнлеге турында сөйләделәр. Филология фәннәре кандидаты, «Лэйсән» берләшмәсенең шеф-консультанты язучы Э. Касыймов Чаллыдагы яшь һәм башлап язучыларның иҗатларына анализ ясады.

Аннары Татарстан Язучылар союзының Чаллы язучылар оешмасы бюросына сайлаулар үткәрелде. Бюро членнары итеп прозаик Э. Касыймов, тәнкыйтьче Т. Галиуллин, шагыйрь К. Сибгатуллин сайландылар. Бюроның беренче утырышында Чаллы язучылар оешмасының җаваплы секретаре итеп Э. Касыймов сайланды.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм Чаллыдагы яңа ачылган язучылар оешмасы җитәкчеләре белән КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Р. К. Беляев әңгәмә үткәрде.

## РЕСПУБЛИКА КОМПОЗИТОРЛАРЫ ҖЫЕЛЫШЫ

Казанның Актерлар йортында Татарстан композиторларының җыелышы булды. Анда, музыка сәнгате эшлеклеләре белән бергәттән, Казанның күп кенә культура учреждениеләре вәкилләре дә катнашты.

Җыелышта ТАССР Композиторлар союзы каршында эшләүче секцияләр җитәкчеләре Ф. Әхмәтов, Б. Мулюков, Р. Еникеев, М. Нигъмәтҗанов чыгыш ясады. Алар СССР композиторларының VI съездында алган тәэсирләре белән уртаклаштылар һәм съезд карарлары яктылыгында Татарстан композиторлары алдында торган бурычларны билгеләделәр.

Республика композиторлары җыелышында КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин чыгыш ясады.

## ОТЧЕТ-САЙЛАУ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Казанның Актерлар йортында Бөтенроссия театр җәмгыяте Татарстан бүлегенең XV отчет-сайлау конференциясе булды. Анда бүлек идарәсе председателе, РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисткасы Р. А. Җиһаншина һәм ревизия комиссиясе председателе, ТАССРның халык артисты Е. А. Кузин докладлары тыңланды. Аннары докладлар буенча фикер алышулар булды.

Конференция Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составларын сайлады. Идарә председателе итеп яңадан Р. А. Җиһаншина сайланды.

## ТАНТАНАЛЫ ҖЫЕЛЫШ

Казанның Актерлар йортында Татарстан китап нәшриятының 60 еллыгына багышланган тантаналы җыелыш булды. Анда нәшриятлар, республика газеталары һәм журналлары, радио һәм телевидение работниклары, полиграфистлар, язучылар, партия, совет һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре катнашты.

Татарстан китап нәшриятының 60 еллыгы турындагы докладны нәшрият директоры Г. Н. Шәрәфетдинов ясады.

Тантаналы җыелышта ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев чыгыш ясады.

* * *

Язучылар союзында яшь авторлар белән эшләү комиссиясенең чираттагы утырышы булды. Көн тәртибендә район газеталары каршындагы әдәби берләшмәләрнең яшь язучылар белән эше турындагы мәсьәлә каралды.

Шагыйрьләр һәм тәнкыйтьчеләрдән М. Вәлиев, Р. Миңнуллин, Р. Вәлиев, Р. Мөхәммәдиев, Р. Низамиев һәм башкалар үзләренә беркетелгән район газеталарына күзәтү ясадылар. Анда басылган әдәби әсәр-

ләрне һәръяклап анализлап, өметле яшь язучылар иҗатының район газетасы битләрендә ничегрәк яктыртылуын ачыкладылар.

Утырышта Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, партоешма секретаре Т. Миңнуллин һәм идарә председателенең яшь авторлар белән эшләү буенча урынбасары И. Юзеев эшлекле тәкъдимнәр керттеләр.

Утырыш киләчәктә район әдәби берләшмәләре белән элемтәне һәрьяклап ныгыту буенча конкрет чаралар билгеләде.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Язучылар союзы каршындагы проза һәм тәнкыйть секцияләренең берләштерелгән утырышы булып узды. Көн тәртибенә А. Расихның «Сынау», В. Нуруллинның «Аккан су юлын табар» әсәрләре куелды. Шул әсәрләр нигезендә бүгенге прозада тәрбия һәм әхлак мәсьәләләренең чагылышы турында зур сөйләшү булды.

Сөйләшүне тәнкыйтьче Ф. Мусин ачып җибәрде. Аннан соң прозаик В. Нуруллин әсәренең язылу тарихын, геройларының еллар буе күңелендә йөрүен һәм менә әсәр басылып чыгып, укучылардан күп хатлар килүен сөйләде.

Утырышта Г. Ахунов, Ф. Миңнуллин, Х. Госман, И. Нуруллин, Х. Хәйри, Р. Мөхәммәдиев, М. Галиев, М. Вәлиев, С. Маннапов, Р. Ишморатова, А. Вергазов, Ә. Сәйфетдинов, Ф. Галимуллин, М. Насыйбуллин һ. б. иптәшләр бу ике әсәрнең уңай һәм кимчелекле якларын билгеләп үттеләр.

Утырышка йомгак ясап, Г. Ахунов яшьләр арасыннан әдәбиятыбызга уңышлы әсәрләргә сөенә белүче тәнкыйтьчеләр килүен әйтеп узды. Ул А. Расих романының кыю язылуын, авторның элегрәк иҗат иткән «Язгы авазлар», «Ике буйдак» романнарын да искә алсаң, заман тормышына багышланган трилогия хасил булуын һәм аны русчага тәрҗемә итеп чыгару күздә тотылырга тиешлеген әйтте.

* * *

Поэзия секциясенең чираттагы утырышында яшь шагыйрьләр Флера Гыйззәтуллина белән Зиннур Мансуров иҗатлары тикшерелде. Утырышта аларның иҗатлары турында шагыйрь һәм прозаик Әхсән Баянов һәм тәнкыйтьче Мансур Вәлиев докладлары тыңланды. Докладчылар яшь авторларның басылып чыккан китапларына һәм кульязмаларына анализ ясадылар, үзләренең теләк һәм фикерләре белән уртаклаштылар.

Утырышта шагыйрьләр Шәйхи Маннур, Марс Шабаев, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләмов, Рашат Низамиев, тәнкыйтьчеләр Ринат Мөхәммәдиев, Равил Кукушкин һ. б. чыгыш ясады.

Поэзия секциясе утырышы Флера Гыйззәтуллина белән Зиннур Мансуровны СССР Язучылар союзы членылыгына тәкъдим итте.

* * *

Тәрҗемәчеләр секциясенең чираттагы утырышы булды. Утырышта сүз тәрҗемә осталары Кыям Миңлебаев һәм Рәис Даутовларның иҗатында тәрҗемә практикасында очрый торган кыен мәсьәләләрнең хәл ителүе турында барды.

Фикер алышуларда Л. Хәмидуллин, Т. Нурмөхәммәтов, Ш. Максудова, Ф. Гайнанова, филология фәннәре кандидаты Р. Юсупов, Р. Даутов, В. Зыятдинов, К. Миңлебаев, Я. Халитов иптәшләр катнашты.

Йомгак сүзе белән Язучылар союзы идарәсе председателе язучы Гариф Ахунов чыкты. Ул тәрҗемә әсәрләренә игътибарны көчәйтергә кирәклеген әйтте. «Хәзерге көндә әдәбиятыбызда татар теленә тәрҗемә итүдә үзенә бер мәктәп барлыкка килде дип горурланып әйтә алабыз. Тәрҗемәләрнең әле мондый камиллеккә ирешкәннәре юк иде. Укучылар тәрҗемә әсәрләрен бик көтеп ала һәм яратып кабул итә», — диде ул. Сүз ахырында Г. Ахунов соңгы елларда тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган мәкаләләрнең бик сирәк күренүен, бу өлкәдә тәрҗемәчеләргә активрак эшләргә кирәклеген әйтеп узды.

* * *

Очерк язучылар секциясенең чираттагы утырышында Түбән Камада яшәүче Рахмай Хисмәтуллин иҗаты тикшерелде.

Язучылардан секция җитәкчесе Марсель Зарипов, Самат Шакир, шагыйрьләрдән Равил Фәйзуллин һәм башкалар Р. Хисмәтуллинның, үз геройлары арасында яшәп, эшчеләр һәм төзүчеләр, игенчеләр тормышын ныклап өйрәнеп язуын билгеләп үттеләр, аңа иҗатын тагын да камиллаштерү юнәлешендә киңәшләрен бирделәр.

Секциядә Рахмай Хисмәтуллин СССР Язучылар союзы членлыгына тәкъдим ителде.

## СҮЗ — ТАМАШАЧЫЛАРГА

Әлмәт татар дәүләт драма театры коллективы Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе драматург Туфан Миңнуллинның «Яшьлегем-җүләрлегем, яшьлегем-гүзәллегем» исемле пьесасын куйды. Спектакльдән соң Әлмәт нефтьчеләренең Техника йорты бинасында тамашачылар конференциясе үткәрелде. Чыгып сөйләүчеләр әсәргә һәм артистларның уенына карата төпле фикерләрен әйттеләр, спектакльне уңай яктан бәяләделәр. Конференциядә Әлмәт язучылары да катнашты.

## «ЛӘЙСӘН» ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕНДӘ

«Ләйсән» әдәби берләшмәсе В. И. Ленинның тууына 110 ел, Татарстан АССРның 60 еллыгына багышлап «Энергетик» Культура сараенда әдәби кичәләр уздыруны планлаштырды. КамАЗ һәм Түбән Кама ГЭСы эшчеләре, төзүчеләр «Таныш булыгыз» дигән беренче кичәне бик яратып кабул иттеләр.

«Туган як шигърияте» дигән икенче кичәдә күренекле прозаик Әмирхан Еники, шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеев, җырчылар Вафирә Гыйззәтуллина һәм Рафаэль Ильясов та катнаштылар.

Кичәдә катнашучылар «Ләйсән» әдәбият-сәнгать берләшмәсе члennары белән дә очраштылар. Язучының иҗат лабораториясе турында сөйләшү озак дәвам итте һәм яшьләр бик канәгать булып калдылар.

Берләшмәнең отчет җыелышы булды. Анда язучы Равил Вәлиев узган бер елда башкарылган эшләре турында сөйләде. Аннан соң фикер алышу булды. Шагыйрь К. Сибгатуллин, язучы Э. Касыймов, берләшмә членнары Х. Хөснуллин, В. Хәбибрахманова, Р. Якупов һәм башкалар яшь иҗат көчләренең эшчәнлеген көчәйтү турында тәкъдимнәрен әйттеләр.

Соңыннан берләшмәнең яңа бюросы сайланды. Җитәкче вазифалары яшь язучы Газиз Кашаповка йөкләнде.

## ЯҢА ЛАУРЕАТЛАР

РСФСР Министрлар Советы, РСФСР Министрлар Советы Президиумының РСФСР Дәүләт премияләре комиссиясе тәкъдимен караганнан соң, әдәбият, сәнгать һәм архитектура өлкәсендә РСФСР-ның 1979 ел Дәүләт премияләрен бирү турында карар кабул итте. Яңа лауреатлар арасында Татарстан республикасының әдәбият һәм сәнгать вәкилләре дә бар. Алар — драматург **Миңнуллин Туфан Абдуллович**, режиссер **Сәлимҗанов Марсель Хәкимович** һәм актер **Биктимеров Шәүкәт Хәсәнович**. Бу иптәшләр театр сәнгате өлкәсендә РСФСРның К. Станиславский исемендәге Дәүләт премиясенә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелган «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле өчен лаек булдылар.

## АРТИСТНЫ ХӨРМӘТЛӘҮ

Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрында РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Габдулла Шамуковка 70 яшь тулуга һәм сәхнә эшчәнлегенең 50 еллыгына багышланган юбилей кичәсе булды. Г. Шамуковның иҗат юлы турында сәнгать белгече Д. Гыймранова сөйләде. Юбилярны аның коллегалары — республикабыз театрлары артистлары, башкалабыз предприятиеләре вәкилләре котлады. Юбилярны котлар өчен Уфадан — артист үзенең иҗат юлын башлаган шәһәрдән дә вәкилләр килгән иде.

Кичәнең ахырында Г. Шамуковның шәкертләре — Казан театр училищесы укучылары чыгыш ясады.

## ЯҢА ХАЛЫК ТЕАТРЫ

Шушы көннәрдә Әлмәт нефтьчеләренең Горький исемендәге клубы каршындагы татар драма коллективына «Халык театры» дигән мактаулы исем бирелде һәм диплом тапшырылды.

* * *

«Советская культура» газетасы хәбәр итүенчә, тиздән Казан шәһәрендә татар халкының данлы улы Мулланур Вахитовның бронзадан эшләнгән һәйкәле куелачак. Бу сын скульптор Юрий Орехов тарафыннан иҗат ителә. Ю. Орехов — Азов шәһәрендәге В. И. Ленин һәйкәлен, Юрий Гагаринның туган җирендә куелган һәм ГДР-ның Хойерсверде шәһәрендәге Бах һәйкәлләрен эшләгән скульптор.

## ЯҢА КИТАПЛАР

Мәскәүнең «Педагогика» нәшриятында «Педагогическое образование в России» дигән монография чыкты. Авторы — Паначин Ф. Г. Китапта Россиядә педагогика белеменең тууы һәм үсеше күзәтелә, педагогия фәненә һәм педагогик белемнәрне таратуда зур өлеш керткән галимнәр, педагоглар турында, большевиклар партиясенең укытучылар арасында алып барылган эше — революцион демократик фикерләрне пропагандалавы күрсәтелгән. Автор күренекле татар галиме, язучы һәм педагог К. Насыйри турында да яза.

* * *

«Искусство» нәшриятының Ленинград бүлегендә «Театральный календарь — 80» дигән китап чыкты. Календарь бөтен дөнья драма һәм балет театры, цирк һәм эстрада тарихында булган әһәмиятле вакыйгаларны чагылдыра. Календарь битләрендә нигездә юбилейлар билгеләнеп үтелә. Анда татар һәм башкорт әдәбияты классигы, драматург Мәҗит Гафуриның 100 еллык юбилее дә билгеләнгән (1880—1934).

* * *

Мәскәүнең «Фән» нәшриятында Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Илдус Гыйззәтуллинның «Октябрь казанышларын саклаганда. Үзәк Мөселман хәрби коллегиясе. 1918—1920 еллар» дигән китабы басылып чыкты.

Үзәк Мөселман хәрби коллегиясенең эшчәнлеге моңа кадәр әдәбиятта ачылмаган иде әле. Китапта коллегиянең рус булмаган халыкларны Совет властен якларга туплавы, халкыбыз хезмәт ияләреннән Кызыл Армиянең милли полкларын, ике татар укчы бригадасын оештыруы, кызыл командирлар һәм политработниклар хәзерләүче курслар ачудагы роле турында сөйләнә. Бу хезмәттә Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов, Камил Якубов, Шамил Усманов, Якуп Чанышев, Кәрим Тинчурин һәм башка күренекле шәхесләрнең эшчәнлеге дә чагылыш тапкан.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм 80 яшь тулу уңаеннан язучы Нәкый Сиражиевич Исәнбәт СССР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 29 декабрь Указы нигезендә Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнде.

# ТӘҮФИКЪ КАМАЛИЕВ

Шушы елның 13 февралендә СССР Язучылар союзы члены, шагыйрь Тәүфикъ Камалиев вафат булды.

Тәүфикъ Камалиев 1940 елда Татарстан АССРның Буа районында туа. Алтынчы класска кадәр шул районның Ташкичү һәм Апас районының Кызыл Тау мәктәпләрендә укый. Җиденче классны Казанда тәмамлый. Аннары һөнәр училищесына укырга керә. 1958—1961 елларда Горбунов исемендәге заводта слесарь-җыючы булып эшли. Бер үк вакытта кичке мәктәптә укуын дәвам иттерә. Өлгергәнлек аттестаты алгач, Казан дәүләт университетына керү өчен имтихан тота. Аны тәмам иткәч, башта район газетасында тәрҗемәче, аннан соң җиде ел буена «Ялкын» журналында бүлек мөдире вазифаларын үти. 1966 елда Коммунистлар партиясе сафына кабул ителә. Соңгы елларда ул Татарстан телевидениесендә өлкән редактор, күп тиражлы газета редакторы һәм «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшләде.

Тәүфикъ Камалиев әдәбиятка алтмышынчы еллар башында килде. Аның беренче җыентыгы 1967 елда басылып чыкты. «Ромашкалар әллим» дип аталган бу җыентыгына кергән шигырьләрендә ул туган җире, якташлары, яшьлек дуслары белән аерылгысыз бәйләнештә булуын күңелгә кереп калырлык поэтик чаралар аша тасвирлады. Аның 1968 һәм 1969 елларда дөнья күргән «Сабыр канатлары сынмый», «Озата бармагыз» исемле җыентыкларына тупланган шигырьләре тулысынча диярлек завод һәм эшчеләр тормышына багышланган. «Сезгә генә сөйлим», «Хәләл көчем белән» җыентыкларында да шагыйрь үзенең яраткан темасына тугрылыклы булып калды. Әлеге җыентыкларындагы шигырьләрендә ул шәһәр һәм авыл кешеләре арасындагы дуслыкны шактый тулы чагылдырды. 1978 елда басылган «Яшьлеккә кайту» җыентыгында Тәүфикъ Камалиев бүгенге авылдагы үзгәрешләрне, туган як моңнарын һәм табигать күренешләрен үзенең каләменә хас матур һәм якты буяулар белән сурәтләде.

Ул әле яңадан-яңа иҗат хыяллары белән янып яши иде. Ләкин мәрхәмәтсез үлем көтмәгәндә аны безнең арабыздан алып китте. Замандашлары һәм каләмдәшләре белән бер сафта атлап барырга аның мул һәм көр хисләр белән сугарылган әчкерсез шигырьләре һәм җырлары калды.

**«Казан утлары» журналы редакциясе.**

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!

Журналның киләсе айда чыгачак 4 нче санында пролетариат юлбашчысы В. И. Ленинның тууына 110 ел тулуга багышлап бирелгән язмалар зур урын алып тора. Алар «Даһи юлбашчы — илһам чишмәсе» дигән гомуми рубрикага берләштерелгәннәр. Монда Ш. Хамматовның публицистик мәкаләсе һәм республикабызның төрле буын шагыйрьләренең Ленинга багышланган шигырьләре тупланган.

«Төрле илләрдән, төрле телләрдән» рубрикасында исә башка милләт әдипләренең Ленин турындагы әсәрләре татарчага тәрҗемә итеп бирелгән.

Даһи юлбашчының туган көне уңаеннан басылган әсәрләрдән шулай ук И. Низамов һәм И. Зәбиров очеркларын, И. Надиров мәкаләсен күрсәтергә мөмкин.

Журналның 4 нче санында Җиңүнең 35 еллыгына багышлап язылган яңа әсәрләр бирү дәвам иттерелә. Язучы М. Мәһдиевнең «Ут чәчәге» повесте укучыны шул еллардагы вакыйгалар белән таныштыра.

М. Скороходов белән Н. Ихсановның бергәләп язган «Йөзгә-йөз» повесте — Себер якларында яшәүче халыкларның революцион көрәш юлына аяк басуын тасвирлаучы тарихи әсәр.

Журналда шагыйрьләребезнең яңа әсәрләреннән дә үрнәкләр күп. Р. Әхмәтҗанов, Г. Афзал, Г. Рәхим шигырьләрен укучы яратыр дип ышанабыз.

«Дуслар җыры», «Яшь язучылар конференциясеннән», «Әдәби тәнкыйть», «Культурабыз тарихына материаллар», «Китап күзәтү», «Безнең календарь», «Мәсәлчеләр мәҗлесе», «Төрлесеннән» кебек гадәттә чыгып килә торган рубрикаларга да ифрат бай эчтәлекле яңа әсәрләр кертелгән.

Соңгы битләрдәге мәгълүматлар укучыны Татарстандагы әдәбият һәм сәнгать яңалыклары белән таныштыра.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210